


# КАЗАН УТЛАРЫ

3
МАРТ
1981

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

3

МАРТ
1981

## *Бу санда*

М. ЮНЫС. Биектә калу. Повесть . . . . . . . . 3

8 МАРТ — ХАЛЫКАРА ХАТЫН-КЫЗЛАР КӨНЕ

Т. СӘГЫЙТОВА. Күк гөмбәзе йолдыз атып уйный. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . 71
В. ХӘБИБРАХМАНОВА. Күңелдәге якты нурлар. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . 73
Ф. БӘШИРОВА. Эш. Шигырь . . . . . . . . 74
Ф. ХӘЛИУЛЛИНА. Керәш уты ага канымда. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . 75
Ф. ГАЛИЕВА. Мактама син мине. Шигырьләр . . 76
Э. ШӘРИФУЛЛИНА. Табигать җимеше. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . 78
Б. РӘХИМОВА. Кыяк үләненең чыклары. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . 80
Н. ГЫЙМАТДИНОВА. Бердәнберем хакына. Повесть . . . . . . . . . . . . . . . 82

Р. ГАТАУЛЛИН. Йөзүчеләр. Шигырь . . . . . . 105
А. ШАМОВ. Соры мәче. Хикәя . . . . . . . . 108
Ш. АНАК. Шат шигырьләр чоры. Шигырьләр . . 124

ОЧЕРК ҺӘМ ПУБЛИЦИСТИКА

М. ӘМИРХАНОВ. Татарстан могҗизасы . . . . 128
Р. КУТУЙ. Яшәү орлыгы . . . . . . . . . 132
Р. ВӘЛИЕВ. Якты төн . . . . . . . . . . 143
А. КОТОВ. Хәерле юл! . . . . . . . . . . 149
М. НИЗАМИЕВ. Татарстан — Лейпциг ярминкәсендә! . . . . . . . . . . . . . . . 153

АФЗАЛ ШАМОВКА 80 ЯШЬ

Ф. МУСИН. Керәшчеләр токымыннан . . . . 158

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

КИТАП КҮЗӘТҮ

**М. ВӘЛИЕВ.** Сандугачлар, кыр казлары һәм кеше 164
**Ш. МАННАПОВ.** Себер киңлегеннән . . . . . 167

ЯШЬ ТӘНКЫЙТЬЧЕ СҮЗ АЛА

**Х. ЯНОВ.** Чишмәләр кайдан башлана! . . . . . 169
**И. ШАҺИЕВ.** Агым уртасындагы язмышлар . . . 171
**З. ХӨСНЕТДИНОВ.** Хыялларга хыянәт итмәгез . 173

СӘНГАТЬ

**Ф. ӘҺЛИУЛЛИНА.** Алтынчәч . . . . . . . . 174
**Р. БЕЛЯЛОВ.** Тамырлары — халыкта . . . . . 180
**Х. КУМЫСНИКОВ.** Гөлсем Камскаяның тууына 80 ел . . . . . . . . . . . . . . . . 182

ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

Үзләре турында үзләре . . . . . . . . . . 184

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 190

**Баш редактор: ЗӘКИ НУРИ**

**Редколлегия: ӘХСӘН БАЯНОВ** (баш редактор урынбасары), **ШАМИЛ БИКЧУРИН, АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ, МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ, ЗӨЛФӘТ, ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН, ТУФАН МИҢНУЛЛИН, РӘФЫЙК НӘФИКОВ, АТИЛЛА РАСИХ, КОЯШ ТИМБИКОВА** (җаваплы секретарь), **СИБГАТ ХӘКИМ, НИЛ ЮЗИЕВ**

---

Техник редакторы *Р. Сөләйманова*
Корректорлары *Ф. Кадыйрова, Т. Шакирҗанова*

---

**Редакциянең адресы:** Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

**Телефоннар:** баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-61, поэзия бүлеге — 3-07-61, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-63, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

---

Производствога бирелде 26/XI-1980 ел. Басарга кул куелды 20/II-1981 ел. ПФ 09004. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 103644 экз. Заказ У-493. Бәясе 50 тиен.

---

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1981 ел.

## Миргазиян Юныс

# БИЕКТӘ КАЛУ

**ПОВЕСТЬ**

*Бөек Ватан сугышының соңгы көннәрендә һәлак булган полкташым өлкән лейтенант Сәләховка багышлыйм.*



Бу көнне Сәйрин Сәләховны иртәнге сәгать дүрттә уяттылар. Орел-Курск юнәлешендәге һөҗүмнең башланган чагы иде. Узган очуда икенче эскадрилья берьюлы дүрт экипажын югалтып кайткач, Сәләховны шунда күчерделәр. Очучы лейтенант Сәләхов моңа кадәр дүртенче эскадрилья сафында иде.

Икенче эскадрилья фронтны өзәргә килүче дошман танкларын бомбага тотарга приказ алды. Самолетларын кичтән әзерләп куйдылар. Торып тамак ялгау белән аэродромга юнәлделәр. Иртәнге сәгать биштә очкычларның моторы үкерүдән җирләр селкенә башлады. Самолетлар бер-бер артлы һавага күтәрелеп, «клин» сафына тезелделәр дә көнбатышка таба юл тоттылар.

Сәләховның штурманы — Астрахань егете Анатолий Эмитов, укчы-радист Мелитопольдән — Николай Стадниченко, һава укчысының фамилиясе Кашаев иде. Рузаевка станциясендә туып үскән егет. Татарча яхшы белсә дә, нигәдер, Кашаев бу телдә сөйләшергә кыенсына.

Экипажның шушы составта дүртенче генә мәртәбә һавага күтәрелүе, алар әле бер-берсенә тулысынча күнегеп тә бетмәгәннәр иде.

Яктыра башлаганда тугыз самолеттан торган эскадрилья фронт сызыгы өстеннән үтте. Кызарып кояш чыкты. Шул чакта очучылар бер могҗиза күрделәр: күк йөзен бомба ташларга баручы һәм бомбаларын дошман гаскәрләре өстенә бушатып аэродромга кайтучы самолетлар чуарлаган. Әйтерсең күк йөзен тимер болыт каплаган. Төрле якка агылып торган кара болыт. Кыямәт көне диярсең. Очарга хәзерләнгән чакта бу турыда кисәтеп куйганнар иде. Бәрелешү хәтәре шул кадәр зур булуын Сәйрин һавадагы очкычларны күргәч кенә аңлады.

«Клин» сафына эскадрильяның һәр звеносы өчпочмак ясап тезелгән була. Иң алда — комэск[1] самолеты. Сәләхов самолеты иң артта, сафның сул як читендә бара иде. Ияреп очканда сул яктан бару читенрәк. Шуңа күрә дә дошман истребительләре очкычларның сул якта-

---

[1] Эскадрилья командиры.

гысына һөҗүм итәргә тырышалар. Гомумән, арттагы самолетны бәреп төшерүе уңайлырак. Сәйрин бу турыда яхшы белә. Экипаж әгъзаларын ул алдан кисәтеп куйды.

Фронт сызыгы өстеннән дә хәвеф-хәтәрсез узып киттеләр. Бомба ташлыйсы җиргә җиткәнче һөҗүм итүче булмады. Эскадрилья тыныч кына оча бирде. Һавада ике якның да самолетлары күп иде. Үз очкычларына тидерүдән куркып, зениткалар атмый иде.

Алда немец танклары күренде. Комуфляж төсенә буялган танкларны җирдән аерып булмый иде. Артларыннан күтәрелгән тузан биниһая зур койрыкка охшап сөйрәлеп бара. Танкларны табарга шул ярдәм итте.

Бомба ташлар өчен эскадрилья сугышчан курска чыга башлады. Бу иң мөһим, иң җаваплы чак. Тизлекне һәм биеклекне үзгәртергә ярамый.

Сәләхов комэскның һәр хәрәкәтен, самолетның кыймылдап куюын да бөтен күзәнәге белән сизеп бара. Менә аның бомболюклары ачылып китте. Озакламый бомболюктан бомбаларның кара борыннары күренәчәк. Хәлиткеч мизгел. Әгъзаларда көчле киеренкелек. Нәкъ шул чакта укчы-радист кычкырып җибәрде:

— «Фоккер»лар!

Дошман истребительләре атакага Сәләхов самолетының траверсыннан киләләр. Бу юнәлешкә очкычтагы бер генә пулемет та төзәп ата алмый иде.

— Командир, сулгарак бор! Зинһар! Биш кенә градуска...— дип кычкырды укчы-радист. Һава укчысы да үтенеп сорый. Икенче звено командирының самолетыннан да ата башладылар. Аңа эскадрильяның калган экипажлары да кушылды.

Бомба ташлаганчы очкычны курстан читкә алырга ярамый.

— Әз генә түзегез. Хәзер бомбаларны ташлыйбыз, — диде Сәләхов укчы-радистка. Ләкин соң иде инде. Снаряд Сәйриннән метр ярымга урнашкан прибор тактасын умырып алып китте. Фюзеляжга урнашкан бактан бензин чәчрәп чыкты. Секунд үтүгә, очкычны ялкын чорнап алды.

Очкычны пикегә кертеп, Сәләхов самолетны чорнаган ялкынны өзәргә тырышып карады. Снарядның берсе идарә итү төеренә тигән иде. Очкыч рульне тыңламады. Сәйрин тагын һәм тагын штурвалны каергалап карады. Машина җансыз иде. Ул һаман янтая бара һәм дөрләп яна. «Хәзер бензобаклар шартларга тиеш», дигән фикер чагылып китү белән Сәләхов:

— Сикерегез! — дип кычкырды. — Тизрәк сикерегез, бензобаклар шартлый!

«Фронт сызыгын ничек үтәрбез икән?» дигән сорау капылт кабынып сүнде. «Җирдә снарядлар ярыла, шулар арасына ничек төшәрбез икән?» — дип уйларга өлгерде һәм ялкын арасыннан үрмәләп чыгып, Сәләхов бушлыкка чумды. Бушлык дигәне буш түгел иде шул. Анда снарядлар кәтүе ыжгырып оча. Шартлау дулкыннары һаваны туктаусыз актарып, айкап торалар. Җирдә сугыш бара. Андагы сугышчылар җиргә башларын төртеп пулядан саклана, җирне казып яшеренә ала. Һавада син ун чакрымнан күренеп торасың.

Шартлау дулкыны чөеп ыргытканда Сәйрин парашютын ачарга өлгермәгән иде әле. Алданрак сикергән штурман Әмитов парашютын ачып өлгергән өлгерүен, тик егетнең башы җансыз булып күкрәгенә салынган, аяк-куллары җепкә таккан шикелле асылынып калган, гәүдәсе һавада пычкы кибәге тутырган капчыктай чайкала. «Я снаряд, я булмаса шартлаганда самолет кыйпылчыгы тигән», — дип өзгәләнеп куйды Сәләхов. — Парашютымны ачсам, мине дә үтерәчәкләр...»

Курку парашютны ачтырмыйча бер-ике секунд түзәргә мәҗбүр итте. Сәләховны шушы соңару коткарды бугай.

Сәйрин парашютын ачып җибәргәндә штурманның җансыз гәүдәсе һаман әле һавада чайкала иде. Укчы-радист Стадниченко җиргә төшеп җиткән. Аны фашистлар камап азаплаланалар. «Мине дә алырга тырышачаклар», — Сәйрин кобурасын ычкындырып куйды. «Укчы күренми, чыга алмыйча, самолет белән бергә шартладымы икән, мескен?»

Бер генә минут элек алар дүртәү иделәр. Көрәшергә, соңгы тамчы канга кадәр фашистларга каршы торырга әзер иделәр. «Менә нишләдек».

Сәләхов җиргә якынайганда укчы-радистның кулларын артка каерып бәйләп өлгергәннәр иде инде. Ике фашист штурманның кесәләрен актарып азаплана. Җир һаман якыная. Әнә бер төркем солдат өерелеп болай таба йөгерә башлады.

Аяклар дөпелдәп җиргә бәрелде. Сәләхов шундук парашютын ычкындырып ыргытты. Пистолетын суырып алды, йөгерергә тотынды. Туктап тормыйча, як-ягына каранып алды. Уң якта сирәк агачлык, сулда — немецларның позицияләре иде. Сәләхов урман ягын сайлады. Артыннан үлем куганда гына шулай йөгерә аласыңдыр. Һәр адым — бишәр метр. Артыннан җил дә куып җитәрлек түгел. Күзне утлы пәрдә каплаган. Күкрәк эче уттай кызган иде. Үпкә тулы күмер, күмер һаман кыза. Бугазга һава кайнарланып керә. Тамак төбенә борычтай әче корылык тыгылган. Арттан үлем куа. Сәйрин, гүя үзе генә түгел, ә аның яшисе килүе үлемнән кача.

Йөгерә торгач, Сәйрин инеш ярына килеп чыкты. Инешнең теге ягында сирәк түмгәкләр каплаган сазлык иде. Тәмам хәлсезләнгән Сәләхов инешкә ташланды. Инеш суы тездән генә икән. Төбе батккак. Сәйрин ләмгә бата-бата бер тын барды да атлар хәле калмагач, сазлыкка кереп, тал куагы астына посты.

Як-яктан шыбырдап күбек күтәрелә. Күбек ярыла, борынга сасыган йомырка исе килеп бәрелә. Сазлык Сәйринне әкрен генә суыра, җәһәннәмгә сөйри иде. Юешлек тире аша тәнгә, канга үтеп керде. Салкын. Сазлык үзенең кара эшен кара йөрәкләрчә астыртын гына эшли бирә. Якында гына бака кычкырып алды. Күбек һаман күтәрелә, шартлап ярыла. Тирә-якта үлем. Эскадрилья инде кайту юлындадыр. Туплар ата. Моторлар гөжли. Якыннан танклар үтә. Сәйрин йомшак түмгәкне кысып кочаклаган, авызын киереп ачып, һава йота. Тын һаман кысыла бара. Йөрәк тибә иде әле.

Туплар авазы аша эт өргән тавыш ишетелеп китте. Тавыш һаман якыная, якыная. Эт өрүенә гырылдап сөйләшкән тавышлар да кушылды.

«Эзәрлекләп киләләр, — дип уйлады Сәйрин. — Япа-ялгыз калдым... Дүртебез дә исән булсак, болай куркыныч булмас иде. Атышыр, каршы торыр идек. Укчы-радистны нишләттеләр икән? Бәлки штурман аңын гына югалткан булгандыр? Самолет янды. Мин генә җиргә исән-сау төшеп җиттем. Фашистлар мине эзәрлекләп киләләр. Ә сазлык һаман суыра. Өстә дә үлем, аста да».

Этләр якында гына өрә башладылар. Елганың теге ягында кычкырып чит телдә сөйләшкән тавышлар ишетелде. «Тапмасалар гына ярар иде... Йа раббым!» — Сәләхов тәңрегә ялвара башлавын сизми дә калды.

Аяк тавышлары тукталды. Эзәрлекләүчеләр сөйләшмичә тыңланып тора башладылар. Сәйрин аларны күреп алды. Өч солдат. Шуларның икесе эт җитәкләгән. Өсләрендә күкшел кием. Өченчесе автоматын күкрәгенә терәп, сагаеп, тирә-юньне күзәтә. Ниһаять, эзәрлекләүчеләр кузгалып, елга яры буйлап киттеләр. Сәйрин иркенләп сулыш алды. Башын күтәрә төште. «Киттеләр. Ярый әле күрмәделәр. Тизрәк моннан чыгарга кирәк... — дип уйлады ул. Һәм нәкъ шушы мизгелдә яңадан аяк тавышлары ишетелде. Эзәрлекләүчеләр кире әйләнеп кайталар

иде. — Эземә төштеләр. Бетте баш», — дип уйлады Сәйрин һәм шушы фикерне раслагандай автомат такылдап алды. Баш өстеннән бер-бер артлы пулялар сызгырып узды. Су чәчрәде. Сәйрин янындагы куак киселеп сазлыкка ятты.

Сәләховның нигәдер этләргә хәтере калды. «Сез бит адәм баласының иң якын дуслары, — дип уйлады ул, — сез дә фашистлар ягына аугач, бу дөньяда кешелек вазифасына тугрылыклы кемнәр генә калыр? Власть фашистлар кулында, — дип уен дәвам итте ул, — власть аяусызлыгыннан сине беркем коткара алмый.— Икенче мизгелдә этләрне акларлык дәлил табылды. — Этләр дә фашистлар кулында. Тәкъдирне алар хәл итә. Шуңа күрә, бары тик алар ягына ауган җаннар гына яши ала. Ә яшисе килү шундый аяусыз...»

Сәйриннең үләсе килми. Аны исә төрле яктан һәлакәт чорнаган. Адәмнең дусты саналган этләр дә Сәләховка каршы иде.

Эзәрлекләүчеләрнең аяк тавышлары тынганчы Сәләхов шушы турыда уйлап ятты. Сазлыктан чыгарга кирәк иде. Автомат пулялары куакны чабып ташлагач, тотыныр нәрсә дә калмады. Куллар сазлык ләмен айкап, тотыныр урын эзлиләр. Һич тә сазлыкка батып тончыгасы килми иде. Ә мәкерле сазлык Сәйриннең теләге белән исәпләшми, һаман суыра.

Кармалана торгач, Сәйриннең кулы тал тамырына төртелде. Ул аны көче, теләге һәм яшисе килү өмете белән эләктереп алды. «Өзелмә, тамыр! Зинһар өзелмә. Миңа бит әле егерме дә тулмаган. Өзелмә! Син минем бердәнбер ышанычым, киләчәгемнең, миннән туачак балаларымның ышанычы...»

Һәм тал тамыры аның теләген аңлады, үлемнән коткарды.

Сазлыктан чыкканда, көн кичкә авышып беткән иде инде. Иң элек Сәйрин кояш баткан юнәлешне чамалап алды. Каршы якка, көнчыгышка барырга кирәк. Ул, кача-поса, шул якка юнәлде.

Көндезләрен куак астында яшеренеп ятарга туры килде. Төннәрен туктаусыз көнчыгышка үрмәләде. Авыллар — немец кулында. Ул аларны урап узды. Фронт сызыгына якынлашкан саен дошман позицияләре ешая барды. Ничә тапкыр инде Сәйрин фашистлар кулына эләгә язып калды. Нәрсә саклагандыр аны: уяулыкмы, бәхетме? Аны, мөгаен яшисе килү, сугышны бетереп, өйгә, туганнары, сөйгән яры янына кайтасы килү теләге саклап калгандыр. Атна буе авызына бер валчык ипи эләкмәде. Бу юлы аны үлән коткарды.

Сигезенче тәүлектә, дошман оборонасын өзеп, һөҗүмгә баручы үзебезнекеләр часте Сәләховны табып алды. Тагын бер атнадан ул үзенең полкына әйләнеп кайткан иде инде.

*
* *

Соңгы дислокация вакытында авиаполкның икенче эскадрильясын барон утарына урнаштырганнар иде. Кызгылт базальт таштан салынган биек сарай. Һәр кирпече, һәр бизәге биеклеккә, алла яшәгән күкнең җиденче катына омтылып торгандай күренгән готика ысулы. Бинаның дүрт почмагыннан дүрт зифа манара калкып чыккан. Шунлыктан, сарай өмәядләр чорында салынган мөселман мәчетен хәтерләтә иде. Төрле төстәге борынгы пыяладан җыелган тар һәм биек витраж тәрәзәләр балкып ерактан ук күзгә ташлана. Калын, нык диварлар. Аларның өске өлешендә дошман утыннан яшеренеп ук атар өчен җайланган махсус уелмалар. Гаҗәеп бина иде икенче эскадрилья урнашкан барон сарае: сәнгать һәйкәле, хисар, урта гасырның зәвыгы

һәм максаты турында сөйләүче белешмә, елдан-ел бәясе күтәреләчәк кыйммәтле мөлкәт бу.

Сарай янышнан тыныч кына үтеп китеп булмый. Туктыйсың, хәйран калып бер тын карап торасың. Бераздан, күңелдә ялгызлык тойгысы уяна. Гомернең шундый кыска булуы, вакытның аяусыз тиз агуы — тагын әллә нинди кимсенүле уйлар тиз-тиз кабынып сүнә. Сокланасың, шушы матурлыкка карап туйганчы хозурланасың, шушы гүзәллекне тудыручыларга баш иясең килә, ләкин ниндидер көч бу теләкләрне үтәргә ирек бирми, шомландыра, күңелне тынычсызлый. «Бинага шушындый сыйфатлар кертергә нинди көч ярдәм иткән? Кемнәр салган бу сарайны? Җиңүчеләр? Җиңелеп тапталган мескен коллар? Кемнәр салган моны? Җиңелүчеләр түгелдер. Гадәттә, алардан зиндан салдырталар. Җиңелгән халык буйсынырга тиеш. Буйсынучы булган җирдә төрмәгә мохтаҗлык була... Сарайны җиңүчеләр салгандыр. Йөз меңләгән, миллионлаган кешеләрнең башларына җиткән кансыз рыцарьлар әсир төшкән кешеләрдән салдырткандыр бу сарайны».

Эскадрильяның кызыл почмагы баронның кунак бүлмәсенә туры килгән иде. Озынча иркен зал. Түшәмнәр биек. Почмакларга урта гасыр рыцарьларының корыч киемнәрен бастырып куйганнар. Аларның билләрендә озын туры кылыч, кулларында — сөңгеле айбалта. Шуларны күрү белән тәннәрең чымырдап китә. Бер генә мизгелгә сугыш әсбаплары җанланып, хәрәкәткә килгәндәй булалар. Сиздермичә генә артыңнан килеп айбалта белән түбәңә кундырырлар шикелле.

Ишекләр, тәрәзә яңаклары, стена буена тезелгән мәһабәт шкафлар затлы агачтан ясалганнар. Туктаусыз уза торган хисапсыз еллар аларны әкренләп шомартып үткәннәр. Кызгылт гәрәбә төсендәге агач әйберләргә борынгылык сеңгән.

Идән паркетын һәр буынның олтаны ышкып ялтырата торган. Башыңны иеп карасаң, идәндә үзеңнең шәүләңне күрәсең. Шәүлә күңелеңә шом сала. «Әллә сарай хуҗаларының тынычлана алмаган җаннары артыңнан сагалап йөриләрме икән?» — дип шикләнеп куясың. Ак буяу белән кызыл комачка язылып, түр як диварга эленгән «Дошман тар-мар ителде, без җиңдек» дигән лозунгны күргәч кенә җан бераз тынычланып китә. Озынча түгәрәк өстәлгә газеталар бәйләме таратып ташланган. Иң өстә «Сталин лачыны» газетасы ята. Шушы газета тылсымы күңелдә бернинди шик калдырмый.

Сугыш инде тәмамланды диярлек. Әле тукталып бетмәгән атышулар, үлемгә каршы барулар бары тик сүнеп өлгермәгән инерция генә. Шуңа карамастан, бу сарайда үз җиреңә хас йортлардагы тынычлык юк иде шикелле. Сарайның бүлмәләре аша вакыйгалар, еллар, озын гасырлар, очрашулар, аерылышулар, шатлык-куанычлар, күз яшьләре, тар-мар ителгән язмышлар, чәлпәрәмә килеп ватылган кайнар мәхәббәтләр уза торган. Алар каядыр китеп югалганнар, ә шаукымнары шушы стеналарга сеңеп кала килгән. Шул стена ташына сеңеп калган вакыйгалар көче шомландыра бугай кунак бүлмәсенә ялгыз кергән кешене.

Звеню командиры өлкән лейтенант Сәйрин Сәләхов кызыл почмакка кергәндә шушы турыда уйлый иде.

Бүлмәдә беркем дә юк әле. Почмаклардан кукраеп сиңа карап торган корыч киемнәр генә, күнегеп җиткәнче, сакчылар шикелле тоелалар. Шкафлар тулы күн тышлы фолиантлар. Аларның алтын язулы төпләре затлы пыяла аша күренеп тора. Китап битләрендә гасырлар буе тупланып килгән үлмәс фикерләр. Күп гасырлар, күп илләрдән җыелган даһиларның уй-фаразлары. Витраж тәрәзәләр аша салават күперенә охшашлы яктылык иңә. Яктылык айбалталар йөзендә чагылып,

коралга буялып калган кан булып күренә иде. «Менә нәрсә шомландыра икән», — дип уйлады Сәләхов түргә узганда.

Ул тәрәзә каршындагы биек күн кәнәфигә чумып утырды. Кесәсеннән хат чыгарып, укырга кереште.

Бу хат бер мәртәбә укылган инде. Аны сугышчан заданиегә очар алдыннан гына тапшырдылар. Вакыт тар иде. Сәйрин хатка күз йөртеп кенә чыгарга өлгерде. Шул чакта аның, аулак урын табып, хат сүзләрен әнисенең тансык тавышына әйләндереп, туйганчы хозурланасы килгән иде. Менә хәзер шундый шарт туды. Сәйрин рәхәтләнеп әнисенең сүзләрен тыңлаячак.

«...Улым, монда сугыш бетә дип сүләп йөри башладылар. Бетсен, иншалла, шулай булсын. Бетсен дә дөмексен, бүтән кабатланмасын. Куаныч белән, тынычлыкта, бергә-бергә, тигезлек белән дөнья көтәргә язсын... Бу сугыш бик авыр булды. Йорт саен диярлек кара кайгы. Син киткәч, Әбделкәрәмнең, Мотыйкның, Шырый Шәрифулласының үлү хәбәрләре килде. Нинди кешеләрнең башына җитте бу сугыш. Шул башланганнан бирле ут йотып торсак та, тыштан белгертмәдек. Көн саен сезне уйладык. Иншалла, бетә диләр. Синең исән калуыңа шул хәтле сөенәбез. Сиңа озын гомер теләп кылган догаларымны аллаһы тәгалә кабул итте, күрәсең. Инде кайтуыңны көтә башладык. Турай базарына барып, ике каз апкайттым. Икесен дә каклап асып куйдым. Синең кайтуыңны көтәләр. Ризык итәргә язсын инде. Сугыш бетү белән туры өйгә кайт. Тукталып торма, яме. Узган атнаны кич утырырга Мәрфуга ахирәт кергәние. «Сәйриненңе маржалар акайтмаса инде» дип күңелемә шом салып китте. «Минем улым андыйлардан түгел» дигән булдым. Ә үзем шикләнәм. Кичә төнлә төшемдә күгәрчен куып йөргәнеңне күрдем. Шикләндерә башлады. Сугыш бетү белән туры өйгә кайт, яме. Көтәбез...»

«Әниләр онытмыйлар безне, — дип уйлап куйды Сәләхов. — Нинди генә шартларда да онытмыйлар. Үзләре ач яшәп, соңгы сыныкларын безгә саклыйлар. Каклаган казлар әзерләп көтәләр. Ә без кайвакыт хат язарга да онытып йөрибез».

Сәйриннең күңеле йомшаргандай булып китте. Ул бер тын тәрәзәдән иңгән нурларга карап уйланып утырды. Аның әнисе атна саен диярлек язып тора, ә аны армиягә озаткан кыздан инде ярты ай хәбәр юк. Авылда гына торган булса, Разиясы турында Сәйрин бәлки болай борчылмас та иде. Ул бит калада укый. Шәһәр Сәләховны шомландыра иде. Кала шартлары катлаулы. Анда кешеләр күп. Кемнәр генә очрамас...

Сәләховның күз алдына какларга элгән казлар килеп басты:

...Салкынча көн. Язгы якты кояш. Карлар басылган. Көрт өстендәге бозланган кар кәрәзләнеп беткән. Ачыла башлаган юллар еракτан күренә. Юлда җим чүпләп йөргән кара каргалар. Түбә читләреннән чут-чут тамчы тама. Кәрниз астына, тамчы тимәс җиргә, Сәйриннең әнисе Минзифа апа кояшка каршы ике каз түшкәсе асып куйган. Яз җиле казларны назлап кына сыйпап уза. Каз итенә җылы нурлар, язның сафлыгы, әнисенең кунакчыллыгы сеңә.

«Каз каклау борынгыдан калган йола түгелме икән? — дип уйлады Сәләхов. — Моңа күчмә чорда ук өйрәнгәннәр булса кирәк. Каклаган казны юлда йөртергә уңайлы бит. Җәй көннәрендә дә аны бик озак саклап була».

Сәйриннең туган авылында яз житү белән хатыннар ит какларга, киндер агартырга керешәләр иде. Кичләрен моңаеп гармун елый. Моң уяна, теләкләр җанланып китә, яшәү яңара. Гармун тавышы Ык аръягындагы тауларга барып бәреләдә, кайтаваз булып, авылга әйләнеп кайта.

Көзләрен гармун тавышы икенче төрле була. Көзге моңнарда яшерен канәгатьлек, аулак өйләргә җыелып күңел ачарга чакыру, армиягә киткәнче күңел ачып калырга өндәү авазлары ишетелә. Яз моңнарына түзә алмыйча гармун елавы үзәкләргә үтеп керә. Сәйриннең авылында гармун тавышына кушылып мәхәббәтнең кайнар сулышы, яшьлек чорының үкенечле кыскалыгы һәм яшәүнең катлаулы булуы яңгырый иде. Язгы кичтә яңгыраган көмеш телле тальян тавышы гамьсез уйнап көлеп үскән яшь кызларның йөрәкләренә беренче җәрәхәт сала. Мәхәббәт шушы тавышка уянып беренче сулышын ала.

Сәйрин уйга чумды. Казлар какланып җиткән, имеш. Ул сәкегә кырын ятып ит пешкәнен көтә. Күкрәгендә йомшак, җылы песи. Ул йоклый. Шундый рәхәт тынычлык тора аларның өендә. Татулыктан һәм яратудан яралган гаилә җылылыгы. Әнисе казан тирәсендә йөри. Аратирә анын талир тәнкәләре чыңлап куя. Бу бик борынгы тавыш. Талир тәңкә тавышы рәхәт иминлек хисе уята. Җылы мөнәсәбәт, тигезлек, татулык һәм бергәлек көе бу. Талир тәңкәләр тавышы жан тыныч, күңел рәхәт чакта гына яңгырый. Ирләр ызгышкан, хатын-кызлар яшь түккән чакта бу тавыш сүнә, каядыр китеп югала.

— Иптәш өлкән лейтенант, сезне штабка чакыралар, — диде кинәт ирләр тавышы.

Әнисенең сурәте сүнде, юкка чыкты. Шул сурәтне ычкындырмаска теләп, Сәйрин күзен чытырдатып йомып карады — файдасы тимәде. Ул үзенең көндәлек вазифасына, хәрбилегенә кайтты.

*

* *

Ишек яңагына сөялеп полк писаре старшина Васюканцев басып тора иде. Старшина, погонга йолдыз өстәлүне акыл артуга санап, чын күңелдән ышана торган бәхетле бәндә иде. Егетнең кысыграк күзләрендә буйсыну катнаш курку сурәтләнеп калган. Хәрби писарьләрдә генә очрый торган ялагайлык Васюканцевның кыяфәтенә чыгып өлгергән иде инде. Ул күзен челт-челт йомып, кызганыч итеп елмайды да сүзен тагын бер мәртәбә кабатлады:

— Сезне штабка чакыралар, иптәш өлкән лейтенант.

— Ишеттем, Васюканцев, барам, — диде Сәләхов. — Кем чакыра? Майор Побежимовмы?

Старшинаның йөзенә курку йөгерде:

— Ю-ук. Майор Побежимов түгел. Сезне, иптәш өлкән лейтенант, дивизия штабына ук чакыралар. Штаб начальнигы полковник Филимонов үзе шалтыратты. Сәгать төгәл тугызда минем кабинетымда булсын диде. Полковник Филимонов үзе...

— Үземне генә чакыраларммы, әллә экипаж белән бергәме?

— Бу турыда аерып әйтмәделәр, — диде штаб писаре һәм тагын күзләрен челт-челт йомып алды.

— Ачыклап сорамадыңмыни?

— Гафу итегез, сорарга кыймадым шул, — Васюканцев җиңаять өстендә тотылган сабый шикелле кызарынды һәм тәмам югалып калды. Тагын елмайды. Акланыр өченме, Сәләховка штабның бер серен ачып салды:

— Узган атнада, иптәш өлкән лейтенант, лично сезгә Советлар Союзы Герое исеме бирү турында документлар әзерләп җибәрдек. Характеристиканы полк командиры подполковник Красноглазов үзе язды. Шундый шәп, шундый әйбәт характеристика. Җибәргән документлар хәзер Мәскәүдәдер инде. Бирми калмаска тиешләр. Полк

командиры подполковник Красноглазов үзе әйтеп яздырды. Озаклап мый килергә тиеш.

— Сөенчесе сиңа, Васюканцев. Аракы эчәсеңме син? — диде Сәләхов.

Старшина тагын югалып калды.

— Юк, эчмим, — диде ул. — Ярамый эчәргә. Устав рөхсәт итми.

Герой исеме турында сүз тимер юл күперен бомбага тотып кайтканнан соң кузгалган иде. Сан буенча да, жимерелгән объектларның житдилеге буенча да «ирекле ау»га йөрүчеләр арасында Сәләховның экипажы полк күләмендә беренче урынга чыккан иде. Ике елда жиде ай эчендә сугышчан заданиегә очу саны һәм бирелгән заданиене үтәү сыйфаты ягыннан Сәләхов сугыш башланганнан бирле очучы зур, тәжрибәле летчикларны куып житкән иде.

— Штурман белән укчы-радистны тапкач, шулар белән барам, — диде өлкән лейтенант. — Китәргә мөмкин.

— Слушаюсь китәргә, — Васюканцев борылып чыгып китте.

Старшина чыгып киткәч, Сәләхов бер сәбәпсез елмаеп куйды. Аның укчы-радисты сержант Марсель Ялчинский полк штабы начальнигы Побежимовны «майор не догонишь» дип атап йөртә иде. Чыннан да штаб начальнигы йөгерә-йөгерә йөрергә ярата. Ялчинский таккан кушамат һәр очракта ябышып кала торган иде.

*

* *

Урыныннан кузгалыр алдыннан Сәләхов нигәдер тагын каклаган каз турында уйлап алды. «Инде дуңгыз итеннән дә баш тарту юк бит. Ә каклаган каз ите һаман онытылмый. Без аны нигә шулай яратабыз икән? Дөресен әйткәндә, каз ите яратуны яшерергә дә туры килә иде. Каклаган каз итен генә түгел, күңелгә ошаган күп нәрсәне шулай яшерәбез».

Сәйриннең исенә госпитальдә яткан чагы килеп төште. Лодзь шәһәре өчен сугышканда ул авыр яраланды. Сугышчан заданиедән кайтышлый аның звеносы искиткеч каты зенит артиллериясе утына юлыкты. Снаряд кыйпылчыгы аның аягын ике жирдән тишеп узган иде. Икенче бер ярчык Сәләховның ике кабыргасын умырып китте. Яраланган килеш ярты сәгать очарга туры килде. Ярый әле Пе-2 самолетында пилот белән штурман бер үк кабинада очалар. Үзенең соңгы штурманы Максим Майнагашев ярдәме белән Сәләхов самолетын көчкә аэродромга китереп житкерде.

Шул чакта прицелга бәрелеп, аның маңгае тишелгән иде. Яраларын бәйләгәннән соң аны Пенза өлкәсендәге Кузнецк дигән шәһәргә госпитальгә озаттылар. Юлда барганда ярасына микроб эләккән. Сәйриннең каны бозыла башлады.

Тәннең эсселеге утыз тугыз градус. Авыз чатнап кибә. Хәл юк. Тәннән туктаусыз тир ага. Берничә сәгать эчендә жәймәләр суга манып алган шикелле юешләнәләр иде. Күзне йому белән ниндидер кызгылт бушлыкка очып төшеп китәсең. Йөрәкне курку кыса. Әллә нинди дини курку. Туктаусыз саташтыра. Шул чакта һәр көнне диярлек Сәйриннең төшенә каклаган каз ите керә иде.

...Кулына пычак тотып, Сәләхов чормага менә башлый. Йорт почмагындагы бүрәнәләргә тотынып үрмәләргә кирәк. Алар шундый шома. Кул тая. Менүе шулкадәр кыен. Хәл юк. Кул ычкынып китәр дә егылып төшәрсең кебек тоела. Аста бушлык. Куркыныч караңгылык. Йөрәк дөп-дөп тибә. Сәйрин, теш-тырнагы белән ябышып, һаман өскә үрмәли. Ниһаять, соңгы ниргә. Пычкы чүбе салып, туфрак белән бастырып куйган түшәм, өстә — салам түбә. Түбә астына тезгән каз

түшкәләреннән искиткеч тәмле ис килеп тора. Шуларның берсен Сәйрин үрелеп тота. Казның итләч түшенә үткен пычак батыра. Башта майлы йомшак тире киселә, аннан соң карасу кызгылт төстә каты какланган ит. Тоз тәме килеп торган каты иткә Сәйрин җәнлек комсызлыгы белән яшь, үткен тешләрен батыра...

Сәләховның авызында утлы күмер. Аңкауларга ут каба. Тел пешә...

— Су-у-у, — дип кычкыра иде Сәләхов. — Су-у-у...

Шәфкать туташы коридорда йоклый. Няня өенә кайтып киткән була. Ишетмиләр. Шәфкать туташлары шундый яшьләр иде. Яшь кеше каты йоклый бит ул. Янәшә караватларда авыр яралылар ыңгыраша. Алар да су сорыйлар. — Су-у-у... Бер генә тамчы.

Ниһаять, шәфкать туташы уяна һәм яралыларга су өләшә. Сусаган кешегә су бирүдән дә зур шәфкать юктыр бу дөньяда.

Шул чакта Сәйрин үзенең бер җинаятен хәтерләде. Армиягә алынгач, поездда барганда, иптәш малайларыннан оялып, Сәйрин әнисе җибәргән тозлы каз итен вагон тәрәзәсеннән ыргытып калдырган иде. Йокысыз озын төннәрдә аның күңелен шомлы сораулар тырнады: «Әллә шул гөнаһым өчен төшемә каз ите килеп саташтырамы икән?..»

Сугыш чорында яра тиз төзәлүчән була. Ике айдан ул йөри башлады, кабыргалар ялганды. Сәләхов госпитальдән ял итеп, тазарып чыкты. Аны кире үз полкына озаттылар. Күңелдә төнге саташуларның эзе генә калды.

* * *

Сәләхов, кызыл почмактан чыгып, офицерлар яши торган казармага юнәлде. Берничә коридор аша үткәч, өске катка бормалы баскычтан күтәрелә башлады.

Бу сарайда өч төрле баскыч бар: бәйрәмнәрдә, кунак чакырган чакларда йөри торганы, көндәлек өчен билгеләнгәне һәм хезмәтчеләрнеке. Шушы баскычларга, сарайның җиһазларына карап, Сәләхов монда өч төрле, өч сыйфатлы яшәеш акканын ачыклады. «Яшәүнең дүртенчесе, яшерене дә булгандыр әле монда: яшерен мәхәббәт, яшерен дуслык һәм яшерен явызлык. Яшәеш катламнарга бүленгән җирдә бу хәл булмыйча калмый».

Сәләхов казарма ишеген ачты. Дневальный торучы сержант плексигластан ясалган портсигарын шомартып азаплана иде. Соңгы вакытта егетләр ватык самолеттан алган органик пыяладан төрле нәрсә ясау белән мавыгалар иде. Бу хәл сугышның тиздән бетәчәге ачыкланганнан соң башланды. Матур саплы пәкеләр, портсигарлар, зажигалкалар, бизәнү әсбаплары — әллә нинди катлаулы нәрсәләр ясый белә иде алар. Тизрәк чын эшкә, чын яшәүгә керешәсе килеп, аларның куллары кычыта иде.

— Иптәш өлкән лейтенант, сезне дивизия штабына чакырдылар,— диде дневальный.

— Укчы-радист белән штурманга әйтелдеме соң?

— Юк.

— Мин әзерләнгән арада Ялчинскийга хәбәр ит. Штурманны мин үзем табам, — диде Сәләхов.

Сәйрин карават янына килде. Бу бинага урнашкач, офицерларга йомшак түшәк, мамык юрган өләшкәннәр иде. Шундый әйбәт иде офицерларның урыннары. Сугыш башланганнан бирле аларның мондый шартларны беренче күрүләре иде. Элегрәк алар кыр аэродромнарында салкын юеш землянкаларда яшәделәр.

Өстәл янына туктап, Сәләхов бер тын аңа кызыксынып карап торды. «Шундый матур итеп ясый белгәннәр бит. Почмакларында җиздән ясалган бизәкләр беркетелгән. Коеп куйган кебек. Нинди генә

осталар юк немецлар арасында, — дип уйлап куйды өлкән лейтенант, — аларның күбесе кырылып бетте, калганнарының осталыгы бары тик мылтык атарга һәм окоп казырга гына җитә. Бу сугыш күзгатучыларның тагын бер җинаяте». Өстәлнең капкачын ачып, планшетын тапкач, Сәйрин кирәкле карталар сайлап алды. Дәфтәр һәм карандаш кирәк иде. Алар да табылды.

Хәзер өс-башны карарга кирәк. Дивизия штабына хәзерләнмичә барырга ярамый. Сәләхов итеген ялтыратты. Каешын кысыбрак буды. Көзге каршына килеп, фуражкасын төзәтергә кереште. Фуражкага беркетелгән җиз краб нәкъ маңгай уртасында, каешның аелы нәкъ кендек турында һәм сәдәпләрнең барысы да эләктерелгән булырга тиеш. Армия тәгәллекне ярата. Синең киемең, аяк атлавың, кыланышың, хәтта фикерләреңә кадәр устав куйган таләпләргә тәңгәл булырга тиеш. Шул таләпләрне үтәп бармасаң, сиңа авырлык килә. Устав куйган таләпләр үтәлмәгән очракта, сине үзеңнән югарырак чинлы һәр офицер, синнән өстен һәр начальник шелтәли ала. Таләпләр тәгәл үтәлеп барганда — син иреклe кеше диярлек.

Шушы хакыйкатьне Сәйрин Сәләхов хезмәтенең беренче елында ук үзләштергән иде инде. Шуңа күрә, аңа хезмәт итү җиңел булды.

Хәзер краб һәм аел тиешле урында, итек ялтырап тора. Бары тик штурман Майнагашевны эзләп табасы гына калды.

Сәләховның штурманы утар хуҗасының эт асрар өчен махсус салынган сарайчыгында көчек белән уйнап йөри иде. Ул көчекне Максим моннан бер атна элек аэродром янындагы ташландык авылдан табып алып кайтты. Ач, ялгыз, адашкан эт баласы иде ул. Туйганчы ашаттылар. «Дуглас» дигән исем куштылар. Максим аңа эт сараеннан иркен бер бүлмә тапты. Эскадрильяның һәр очучысы көчек турында кайгыртырга тырыша иде. Аны туктаусыз ашаталар, сөяләр, назлыйлар. «Этнең бер генә хуҗасы булырга тиеш, — диде Майнагашев. — Төрле кулда тәрбияләнгән эттән ялагай хәерче генә чыга». Штурман көчекне бикләп үк куйды. Башка кешене аның янына җибәрми башлады.

Сәйрин килгәндә Майнагашев, бик тырышып, Дугласны боерык үтәргә өйрәтеп йөри иде. Үзе шундый шат, шундый канәгать, әйтерсең аңа дөнья малын һәм идарә итү властен тоттырганнар.

Сәләхов штурман белән эт арасындагы керсез саф дуслыкка сокланып куйды. Хәтта ике адәм арасында да мондый дуслык сирәк очрый бит. Бер-береңнән файда көтү сүндерә дуслыкны. Ә тормыш шартлары дуслар ярдәменә мохтаҗлык тудырып тора. Керсез, саф дуслыкны саклау авыр.

Этнең буйсынудан туган психологиясен җиңел аңлатып була. Хуҗасына тугрылыклы, файда китереп торучыны салкында, тузанлы баскыч астында асрыйлар. Ул хуҗаларыннан калган сөякне кимереп, ярым ач яши. Ә каймак урлаучы файдасыз мәче хуҗаларының куенында, юрган астында тора. Сәйрин чынбарлыкта да шундый парадокслар очрата иде. Нилектән бу? Эт — эт тормышына, мәче — мәче тормышына риза булып, безне шуңа күнектергәннәнме икән бу?

Майнагашевның көчек белән уйнавын карап торганда Сәйрин шушы турыда уйлый иде. Алар икесе дә — эт тә, кеше дә — бәхетле иделәр. Шул кадәр бирелеп шаяралар, Максимны бу шөгыленнән аерырга базмыйча, Сәләхов бик озак сокланып карап торды. «Әйдә, рәхәтләнсеннәр, сугыш вакытында мондый куанычлар сирәк очрый»,— дип уйлады ул.

Казармада яшь, таза, көчле ирләр яши. Анда устав һәм тәртип хөкем итә. Көн тәртибе минутлап алдан көйләп куелган. Казарма шартларында тәртипсезлек, шапшаклык, җәбер ише нәрсәләрнең булмаслыгын алдан белеп торасың. Казармада яшәүчеләрнең үзара мө-

нәсәбәтләрен устав хәл итә. Шундый уңайлы булырга тиеш казарма көнкүреше. Ләкин анда бераз яшәгәннән соң нәрсәдер җитмәгәнен сизә башлыйсың. Нәрсә җитми?

Соңгы вакытта Сәйрин бала-чага белән сөйләшергә тели иде. Ул әнисенең җылы, кайгыртучан мөнәсәбәтенә мохтаҗ иде. Еш кына аның утын кисеп, су кертеп әнисен куандырып аласы килә. Җан рәхәтлеге өчен аңа шушы нәрсәләр җитми иде. Бахмач аэродромында торганда Сәләхов, шәһәргә барган чакта, бер сукыр карчыкны урам аша чыгарды. Шуннан соң ул атна буе диярлек күңелендә ниндидер рәхәт канәгатьлек сизеп йөрде.

Казарма шартларында хатын-кызларда гына була торган йомшаклык һәм гаиләдәге җылылык җитми. Казармада таза, көчле кешеләр яши. Синең ярдәмеңә мохтаҗ кешеләр җитми анда, шундыйлар булмавы интектерә. Шәфкать күрсәтү теләге безнең канда бар күрәсең. Шул эчке рухи теләкне эшкә ашыра алмаган чакларда күңел коргаксый башлый. Миһербанлы буласы, яхшылык күрсәтәсе килү теләге, чыгар юл тапмыйча эчкә җыелып, артык тупланган чакларда ни эшләргә белмичә дошманланып ташлыйсың.

Адәм баласы һәрвакыт корычтай каты була алмый, күрәсең. Ул йомшаклыкка, назга, назлауга да мохтаҗ. Яшәү кануннары шундый катлаулы.

Майнагашевның көчек белән уйнап йөрүен карап торганда Сәйрин шушы турыда уйлады.

— Җитте, Максим. Калдыр этеңне. Эш бар, — диде ул, нечкәлеккә бирелүнең чигенә чыгуын сизеп.

*

* *

Майнагашев сискәнеп китте. Этен, күтәреп алып, кочаклады, күкрәгенә кысты. Әйтерсең, бу эт баласы түгел, ә Максимның имчәк улы иде. Әйтерсең, Майнагашев үзе дә кырыс табигатьле сугышчан офицер түгел, ә бала яратучы яшь ана. Әйтерсең, Сәйрин аның имчәк баласын күкрәгеннән аерырга килгән.

Штурман кашын җимереп экипаж командирына карады:

— Нинди эш?

Әйе, табигать даһи. Табигый шартларда таза ирләр аерым яшәмәскә тиеш. Тирә-юньдә сабый балалар, сине ярдәмеңә мохтаҗ карт-коры, хатын-кыз булмаганда син бәхетле була алмыйсың. Бу — табигатьнең катгый кануны. Шушы канунны син берничек тә үзгәртә алмыйсың. Ул синнән көчлерәк.

Максим айнылы. Ул көчеген бүлмәсенә илтеп ябып, ишеген бикләде.

— Мин әзер, командир. Нинди эш бар?

— Безне дивизия штабына чакыралар, — диде Сәләхов.

— У-һу, дивизия штабына? Нигә чакыралар икән?

— Кунакка түгел, билгеле. Бар, планшетыңны алып чык, — Штурман урыныннан кузгалгач, өстәде. — Гимнастеркаңны да чистарт. Безобразие. Эт йонына батып беткәнсең.

Майнагашев командирына карап, матур итеп елмайды. Аның бите яктырып, нурланып китте. Яратудан, якынлыктан туган шелтәне ул аңлый.

Баскычтан укчы-радист Марсель Ялчинский төшеп килә иде. Ул Майнагашевка нәрсәдер әйтте. Үтешли алар шаярып-төрткәләшеп алдылар. Максим казармага кереп китте. Ялчинский бер-ике басманы тыныч кына төшкәч, сул аягын күтәрде дә титаклап сикерергә кереште.

— Командир, әллә безне җиңү парадына чакыралармы? — диде ул Сәләхов янына килеп җиткәч.

— Баргач белерсең.

— Юк, командир, күңел сизә. Безне берәр төрле почетлы эшкә билгеләгәннәр. Берәр бөек шәхесне чит илгә конференциягә илтергә түгелдер бит? Әллә безнең экипажны Сталин үзен йөртергә чакырамы икән?

— Симерә башладык. Озакламый бозыла башлавыбыз бар. Эшсезлек черетә бит. Фронт өстеннән очып, бераз җилләнеп кайтырга кушалар, — диде Сәләхов шаярта төшеп. —Әнә Майнагашев та чыкты. Кузгалдык. Соңга калуыбыз бар.

*

* *

Сугыш дошман җирендә иде инде. Икенче Белорус фронты Штральзунд — Росток — Шверин юнәлешендә уңышлы һөҗүмнәр алып бара. Беренче Белорус фронты 16 апрельдә башлаган атакасын көннән-көн көчәйтеп, стратегик заданиене үтәп килә иде. Фронт озакламый Берлинга килеп җитәргә тиеш. Каршылык күрсәтү бетмәгән әле. Кайвакыт фашист гаскәрләре өметсез чаялык белән каршы торып карыйлар. Андый урыннарда аяусыз каты кан коюлар булып ала. Дошманнарның чигенергә теләмәгән частьлары юкка чыгып калалар.

Безнең гаскәрләр Германиянең башкаласын камап алырга әзерләнәләр иде.

Сәләхов хезмәт иткән авиаполкта да сугышның тәмамланып килүе ачык сизелә. Соңгы очуда, безнең гаскәрләр чиктән тыш тиз алга китү сәбәпле, эскадрилья үзебезнең частьларга зыян китерүдән куркып, бомба ташлый алмыйча әйләнеп кайтты. Шуннан соң атнадан артык инде беркемнең дә һавага күтәрелгәне булмады.

Экипажның өч очучысы, кояш нурларына коенып, дивизия штабына таба атлыйлар иде.

Итек үкчәләре асфальтка тигән чакта җир астыннан дөпелдәгән тавышлар ишетелеп китә. Нindидер шомлы, матәмле тавышлар. Монда ике яклап агач утыртканнар иде. Тар сукмактан өчәүләп барып булмады. Командир алгарак чыкты. Штурман белән укчы-радист аңа ияреп киттеләр.

Очкан чакта экипажны уртак эш берләштерә. Һавага күтәрелү белән бер теләккә берегеп, уртак ихтыярга кысып төйнәлгәндәй буласың. Кабиналар аерым, шуңа карамастан, ялгызлык юкка чыга, мөстәкыйль булуыңны да тоймый башлыйсың. Очу эше кешегә бик күп яңа сыйфатлар өсти. Бердәмлек хисең көчәя. Үзара элемтәгә җаваплырак карый башлыйсың. Дуслык тойгысы гайрәтләнә. Иптәшлек мөнәсәбәте җитдиләнеп китә. Бергә очкан кешеләр арасында шундый җылы, шундый тирән туганлык тойгысы уяна.

Башлап Сәләхов үзенең штурманы белән дуслашты. Айхал якуты Майнагашев кәкре аяклы бер кеше иде. Ат менеп йөрергә уңайлы сыйраклар. Аның атлап йөрүе дә аюныкына охшашлырак иде. Үкчәләре бер-берсеннән ерак торалар. Йөргәндә аягының баш бармаклары бер-берсенә тия язып китәләр. Максимга битнең дә тактадай яссысы эләккән. Әллә табигать аның битен җентекләп эшкәртергә иренгән, әллә чыдам, нык булсын дип шулай эшләгән. Максимның борыны бөтенләй юк диярлек. Бит уртасында күңелсез булып күренеп торган ике тишек. Битне ясап бетерер алдыннан табигать үзенең гаделсезлек эшләвен аңлап алган күрәсең. Ул Максимга гаҗәп матур, шундый килешле иреннәр уйган. Иман нуры чәчеп торган коң-

гырт күзләр. Таң калырлык ягымлы елмаю. Шуларны күрү белән егетнең бите җәлпәк, аяклары кәкре икәнлеген онытып ташлыйсың.

Табигать барыбер гадел ул. Табигать беркемне дә рәнҗетмичә матурлыкны тигез өләшә. Әгәр гавам шаукымыннан туган сукыр инанудан арына алсак, без аяк атлаган саен табигатьнең бөек рәссам икәнлеген тоеп куанып торыр идек.

Майнагашевны табигыйлегенә, аның рухи матурлыгына эскадрилья очучылары сокланып туя алмыйлар шул. Аны күрү белән эчтә бер җылылык уяна. Бераздан син аның өчен эһ тә итмичә, җаныңны бирергә әзер буласың. Сәләховның штурманы әнә шундый кеше иде.

Элекке гасырларда Максим Майнагашевтан кабилә юлбашчысы, я булмаса мәшһүр шаман-кам чыгар иде. Кайвакыт аның офицер булуы да сәер тоела. Офицер икәнсең син, җилкәңә ука погон тагып йөрүдән тыш, кеше арасында офицерлык ролен оста уйный белергә тиеш. Тормыш сәхнәсендә һәркем артист, һәр кеше үзе уйлап чыгарган рольне уйный. Берәүләр оста уйныйлар, икенчеләр ышандырырлык итеп башкара алмыйлар. Максим шундыйлардан иде.

Солдат-сержантлар каршында үзен тәкәббер тотмаса да офицер үзенең начальник икәнлеген һәр мизгелдә сиздереп торырга тиеш. Офицерның үзен тотуы, фикер йөртүе, мөнәсәбәтләре — һәр адымы «мин офицер» дип кычкырып торырга тиеш. Табигать баласы Максим Майнагашев өчен хәрби әхлакның кануннары таррак иде. Ул аңа сыеп бетми. Офицер үзеннән түбән чин алдында — начальник, югары начальник алдында буйсынучы итеп тота белергә тиеш. Менә шушы кагыйдә интектерә иде Майнагашевны.

Авиаполкка килгән атнаны ук Майнагашев бер дуамаллык эшләп ташлады. Пистолеттан атарга өйрәнү вакыты иде. Максим лейтенант Кононенко белән бәхәсләшеп китте. Ул болай диде: «Әгәр илле метрдан атып фуражкаңа таккан җиз крабның нәкъ уртасын тишеп чыгармасам, бөтен офицерлар алдында битемә төкерерсең». «Нәрсә ул төкерек,— диде Кононенко.— Сөрттең — бетте, эзе калмый». «Кала,— диде эскадрилья штурманы капитан Гусев. — Биткә тигән төкерекне мәңге юып булмый. Ул кешенең намусын, «кеше» дигән бөек исемен пычрата».

Бәхәсне тыңлап торучы лейтенант Бадальян Кононенкодан сорады:

— Әгәр крабыңа тигерә алса ,син Майнагашевның нинди таләбен үтисең?

— Юк минем таләбем,— диде лейтенант Майнагашев.— Аның йөзенә пистолет төзәү үзе ни тора.

Егетләр эскадрилья командиры күрмәслек аулаграк җиргә киттеләр. Һәм шул көнне Кононенкога яңа краб эзләргә туры килде. Аның фуражкасында бармак сыярлык тишек барлыкка килгән иде.

Шушы вакыйгадан соң Майнагашевка кызыксынып карый башладылар. Төз ата белүе аның абруен күтәреп җибәрде.

Сугышчан заданиегә ешрак оча башлагач, егетнең тагын бер сәләте ачылды: Максим дүрт мең метр биеклектән бомбаны кое эченә салып китә ала иде.

Мондый осталыкның каян килүен берничек тә аңлатып булмый. Тәҗрибәгә таянып та, математик хисап белән дә андый төгәллеккә ирешү мөмкин түгел. Табигать Максимга сирәк очрый торган бер зирәклек биргән иде. Бу сыйфат талант дип атала.

* * *

Сәләховның талант турындагы кагыйдәне очратканы юк иде әле. Уртача сәләтле кешене теләсә нинди эшкә өйрәтеп була. Һәм ул һәр

эшне дә уртачарак башкаруга ирешә. Аның мөмкинлеге шул чама була. Талант исә һөнәрен иң югары, иң бөек ноктага житкәнче камилләштерә ала. Талант — эшендә илаһи нечкәлеккә ирешүче.

Америка һиндлеләре үләндәге эзгә карап, сукмактан узган кешенең картмы-яшьме, ирме-хатынмы, кораллымы-коралсызмы икәнлеген әйтә алалар, ди. Һиндлеләрдәге сәләт Максимда да бар иде. Һава торышын ул берничә көн алдан әйтә ала. Көннең болытлымы, аязмы булачагын гына түгел, җилнең кай яктан исәчәген, басым алышынуын, һава дымлылыгын, тагын әллә нинди билгеләрне алдан сизә иде. Бомба ташлыйсы мизгел җиткәнен дә Майнагашев ниндидер эчке бер тоем белән чамалый ала. Шунлыктан ул ташлаган бомба читкә тайпылмый иде.

Штурманнар бомба ташлыйсы вакытны катлаулы формула аша хисаплап чыгаралар. Математик хисап белән генә чикләнмичә, бомба ташлаганда Майнагашев аучылыкта үзләштергән тәҗрибәләрен дә куллана башлады.

Талантлы штурман белән очуы рәхәт. Штурман самолетны алдан сызган маршрут белән адаштырмыйча алып барырга, бомба ташларга, истребительләр һөҗүм иткәндә пулеметтан атып, очкычны һәм экипажны сакларга тиеш. Талантлы штурман бу вазифалар белән генә чикләнеп калмый. Ул летчик һәм укчы-радист белән бергә сугышчан заданиенең үтәлүен хәл итә. Экипажның иминлеге, исән калуы күп яктан аның кулында, шуңа күрә дә Сәйрин үзенең штурманы белән горурлана. Ул укчы-радисттан да уңды.

*

*   *

Марсель Ялчинский гаҗәп чибәр кеше иде. Дулкынланып торган күе кара чәче, кызларныкы шикелле нечкә кара кашлар, ә күзләре авыр керфекләр астына яшеренгән. Табигать Марсельнең һәр әгъзасын артык матур итеп җибәрүен бары тик эшкәртеп бетерер алдыннан гына сизепме, егеткә вак һәм сирәк тешләр куйган.

Ялчинскийның зыялы егет икәнлеген Сәләхов беренче күрүдә үк сизеп алды. Тәрбияле кеше белән мөнәсәбәткә кергән чакта үзеңдә ниндидер эчке рәхәтлек барлыкка килә. Андый кеше янында син үзеңне тыныч һәм ышанычлы тотасың. Зыялы кеше сиңа уңайсызлык тудырмый.

Ялчинский Кара диңгез буендагы таулар янында туып үскән егет иде. Кырык дүртенче елның азагында, бер атна ял биреп, аны туган җиренә җибәрделәр. Ялыннан ул танымаслык булып үзгәреп килде. Әйтерсең аны алыштырганнар иде. Шат күңелле, көләч егет өенә кайтып килгәннән соң әллә нишләде. Юк кына сүзгә дә кабынып китә, күңеле сына һәм муенын элмәккә тыгар хәлгә җитә иде.

Сәләхов укчы-радист белән сөйләшеп тә карады. Сүз кузгату белән аның кәефе кырылды. Егетнең бу турыда сөйләшәсе килми иде. «Сукыр чебен шикелле нигә кешенең күзенә керергә? — дип уйлады Сәләхов. — Һәркемнең күңел түренә бикләп куелган изге сере була. Аңа кагылырга ярамый...»

Эскадрильяның партоешма секретаре капитан Агеев Сәләховка:

— Ялчинскийның хәле бик авыр, син аңа каты бәрелмәскә тырыш. Сөйләшкәндә сак бул, — диде.

Укчы-радистның әнисе — музыкант, үз республикасының халык артисты, әтисе — сәнгать белгече, профессор. Тәрбиянең иң тирән эзе ата-ана канаты астында яшәгәннән кала. Балачакта сәнгать мохитында тәрбияләнеп үскән кешегә казарма шартларында яшәү шактый авыр иде. Марсель бик түзем һәм нык ихтыярлы егет булып чык-

ты. Ирләр колагына гына ярарлык анекдот сөйләү, кызлар турында шапырынулар аны шул кадәр рәнҗетә иде. Ул түзде. Эчендәге тойгылар давылын яшерә белде.

Ялчинский сугышка кадәрге тормышы турында сөйләргә яратмый. Тәрбияле кеше, гомумән, семья тормышы турында туарылырга ашыкмый. Аңларлык кеше табып, Марсельның туйганчы эчен бушатасы килгән чаклары була иде. Бигрәк тә соңгы вакытта. Ул торган төбәккә килгән афәтне ишеткәннән соң, үкереп елыйсы, аңларлык кешегә зарланып юанасы килә иде. Ул әллә ничә мәртәбә бу турыда үзенең командиры белән сөйләшергә чамалап карады. Ничектер җа чыкмады. Ничектер тартындыра иде. Аңларлык кеше булса да — командир бит.

Сәләхов авылда туып үсте. Аң-белемгә омтылган татар гаиләләрендәге зыялылык аның табигатендә иде. Бу сыйфат бүгенге көн интеллигентлыгына охшамаганга күрә кайвакыт аралашырга комачаулык китерә иде.

Лодзь шәһәрендә торганда иптәшләренә ияреп Сәләхов күрше частьта хезмәт итүче кызлар янына барды. Танышу башланды. Башка егетләр җиңел генә исемнәрен әйтәләр дә, куптәнге танышлар шикелле, мыскал да тартынып тормыйча черкелдәшә башлыйлар. Сәйрин исемен әйтә алмыйча газап чикте. Тотлыкты, кызларды һәм ни эшләргә белмичә ярты сәгать чамасы аптырап утыргач, чыгып тайды. Аның өчен исем шундый мөһим, ихтирамга һәм сергә чорналган бер тылсым кебек тоела иде. Танышканда тагын бер авырлык туа иде. Исемен татарча әйтергә Сәләхов тартына, ә русчага әйләндерергә вөҗданы кушмый иде. Борынгылардан калган исем гыйбадәте, антропоморфизм бу егетнең күңелендә һаман яшәп килә иде. Сәйриннең туган авылында борынгыдан калып яши килгән йолалар очрый иде. Сәйриннең әнисе иренең, балаларының исемнәрен дә ят кешеләр алдында әйтми иде. Иренә «син» дип, башка кешеләргә ире турында «үзе» дип сөйли, балаларын «бәбкәм», «карлыгачым» һәм шуның шикелле матур исемнәр белән атый иде.

Сәйрин Сәләхов бала чактан ук кеше исеменә җитди карарга өйрәнде. Аңа һәр начарлык, намусыңа тап төшерерлек һәр начар эш исемгә сеңеп кала шикелле тоела иде. Бала чакта ана: «Исем сиңа гомергә бирелгән, ул бер генә, аның чисталыгын, аның ихтирамын сакларга тиешсең», — дип аңлаттылар. Сәйрин ышанды, исеменә йогарлык начарлык эшләүдән моңа кадәр сакланып килде. Исем ул синең үзең генә дә түгел бит: ул синең йөзең, ата-анаңның, ыругыңның, нәселеңнең йөзе һәм аларның байрагы. Исем ул синең гомереңбуенча күтәреп барган байрагың.

Шулай уйлый иде икенче эскадрильяның икенче звено командиры, очучы, өлкән лейтенант Сәйрин Сәләхов.

*
* *

Алар җимерек йортлар арасына килеп керделәр. Өелеп калган кирпеч ватыклары, газапланып бөгәрләнгән тимер рельслар, дивар калдыклары кабер ташына охшап тырпаеп торалар. Мич торбалары сузаеп калганнар. Моңсу язгы җил җимереклек тузанын кырларга теләр-теләмәс кенә тарата иде. Хәрабәләргә озак карап торсаң, тын кысыла башлый. Елыйсы килә. Хәрабәләр немецларныкы иде. Шушы йортларны төзегән кешеләр, аларның теләкләре кызганыч тоела иде. Бу дөньяда беркем дә җимерер өчен дип сарай салмый. Һәр төзелештә тынычлыкка омтылу өмете, бәхет теләге була.

— «Оча торган крепостьлар» эшкәрткән җир, — диде Сәләхов тын-

лыкны бозып. — Алар хәрби объектларны аерып азапланмаганнар. Бомбаларын «келәм» ысулында коеп киткәннәр.

Агачлык арасыннан чүлмәк түбәле биек йорт калкып чыкты. Бина давылдан котылып калган ялгыз корабны хәтерләтә иде. Ул тирәяктагы җимерекләккә аптырап карап тора. Биек таш диварларга береккән озынча тәрәзәләр. Түбә өстендәге энәдәй нечкә шпильгә этәч утыртып куйганнар.

— Саф готик ысул, — диде Ялчинский сокланып. — Бинаның һәр өлеше җиде кат күккә, аллага таба омтылгандай.

— Омтылган булсалар, аңларлар иде. Тәңре аларга шәһәрләр җимереп, кеше каны коеп йөрергә рөхсәт итмәс иде, — диде Майнагашев.

— Безне комэск көтә, — диде Сәләхов баскыч янында йөреп торган кешегә күрсәтеп. Очучылар адымнарын тизәйттеләр. Баскыч янына җиткәндә, майор Растопчин ашыгырга кушып ишарә ясады.

— Көтәләр сезне, — диде ул, һәр сүздән мөстәкыйль җөмлә тезеп. Ул контузиядән соң шулай сөйләшә башлаган иде. — Задание. Җаваплы. Армия. Штабыннан. Офицер. Килгән.

Госпитальдән чыккан мәлне ул бөтенләй сөйләшә алмый иде әле. Әкренләп теле яңадан ачыла башлады.

Коридорга үткәндә дежур торучы капитан туктарга кушты.

— Полковник. Филимонов. Чакырды, — диде комэск.

Капитан очучыларны штаб начальнигының кабинетына кадәр озатып куйды.

— Рәхим итегез,— диде ул Филимоновның ишегенә күрсәтеп.— Сезне көтеп утыралар.

Рококо ысулында бизәлгән затлы интерьер. Почмакларга кабырчыкка охшашлы ак мәрмәр бизәкләр беркеткәннәр. Мәрмәр фәрештәләр, канатларын салындырып, ишектән керүчене күзәтеп торалар. Түшәм уртасында француз рәссаме Пуссенның «Чәчәкләр патшалыгында» дигән аллегориясе төшерелгән. Дүрт гүзәл кыз елның дүрт фасылын тәшкил итеп, җитәкләшеп торалар.

Штаб начальнигы бер яшь подполковник белән мәрмәр фәрештә янына куелган өстәл кырында сөйләшеп утыра иде. Сержант Ялчинский елмаеп куйды:

— Урнаша белгәннәр болар. Идиллия! — диде ул Майнагашевның колагына.

Сугышчан заданиене нәзберек фәрештәләр янында алу нindидер сәер тойгы уята иде.

— Иптәш. Полковник... Сезнең... чакыруыгыз... буенча... икенче... эскадрилья... очучылары, — дип рапорт бирде майор Растопчин.

— Вольно. Утырыгыз, — штаб начальнигы, каршысында утырган подполковникка карап, өстәде. — Без менә шушы экипажны билгеләдек инде. Соңыннан фикерегезне әйтерсез.

Подполковник очучыларга текәлде. Канәгатьлек күренде аның күз карашында. Ул хәтта Майнагашевның җәлпәк йөзенә кызыксынып каравын да яшерә алды.

— Ну лачыннар, — диде яшь подполковник, — сез заданиене үтәргә әзерме?

— Без әзер, — диде Сәләхов.

Армия штабыннан килгән кеше гаҗәп чибәр иде. Испан кызларыныкыдай авыр кара керфекләр, сөрмәле күз, юка борын, хәйран калырлык җыйнак, килешле гәүдә. Штаб офицерының һәр хәрәкәтендә аның тәрбияле үсүе, сыйфатлы токымнан яралуы сизелеп тора иде.

Артык чибәр булу, кай очракта ир-егеткә килешеп тә бетми. Матурлык тарткан көчкә карата безнең эчтә нindидер капма-каршылык

яши. Чамасыз матурлык безне хәйран калдыра, баш идертә, шомландыра, читкә этәрә. Тулаем уңай сыйфатка ышаныч юк бездә. Әзмекүпме кимчелекле сыйфатка гына без тулысынча ышанабыз. Ир-егетнең, бигрәк тә хәрбиләрнең, кыланышында бер чама табигый тупаслык булырга тиеш. Шул тупаслык безгә табигыйлек булып күренә. Подполковникның кыланышында бер тамчы тупаслык юк иде. Шунлыктанмы, очучылар аңа шикләнебрәк карап утырдылар. Югары инстанциядән килгән кешегә армия шартларында гадәти ихтирам белән карыйсың. Аның һәр кыланышы — сиңа үрнәк булып күренә.

«Әнисенең яраткан улыдыр бу — дип уйлады Сәләхов подполковник турында.— Аны әһәмият биреп, җентекләп тәрбияләгәннәр, зур эшкә, зур кеше булырга көйләгәннәр».

Ялчинский да штаб офицерына карап утыра иде. Ул елмаеп куйды:

— Патша итсәләр, мин бу кешене үземә адьютант итеп алыр идем, — диде ул Майнагашевның колагына. — Бигрәк тә матур инде. Шундый нәфис матурлыкны күтәреп йөрүе мәшәкатьле түгелме икән? Кызлар аның теңкәсен корытып бетерә торганнардыр.

Чибәр кешедә әхлак аеруча көчле булырга тиеш. Шул як такыр булган очракта тышкы матурлыкка ябышып бозыклык кылә. Максим шушы турыда уйлый иде. Гадәттә ул тышкы чибәрлекне күрми, тоймый. Мондый саф, табигый зәвык табигать кочагында яшәүчеләрдә сакланган була. Майнагашев шундыйлардан.

— Заданиене сезгә подполковник Павлов бирә. Ул шуның өчен армия штабыннан килгән. Аның сөйләгәнен дикъкать биреп тыңлагыз. Без әзер, башларга мөмкин, иптәш подполковник, — диде штаб начальнигы, Павловка таба борылып.

Филимонов штаб офицерына ошарга тырыша иде. Бу хәлне Павлов үзе дә сизде булса кирәк. Ул, штаб начальнигына карап, баш какты да Растопчинга әйтте:

— Укчы-радистны җибәрергә ярый. Ул безгә кирәк булмаячак. Әзерләнә торсын.

— Сержант, сиңа китәргә мөмкин. Пулеметыңны әзерли тор,— диде полковник Филимонов.

Ялчинский урыныннан торды:

— Слушаюсь, — диде ул үрә басып. Кулларын кабыргасына кысты, итек үкчәләрен шакылдатып бер-берсенә бәрде, сул җилкәсе аша бөтерелеп борылды. — Слушаюсь катнашмаска! Разрешите идти?

Укчы-радистның дөп-дөп басып чыгып китүендә кимсенү һәм яшерен эчке гарьләнү сизелә иде. Моны Растопчин шундук аңлап алды.

«Үзе шундый культуралы күренә, — дип уйлады ул штаб офицеры турында. — Ә сержантка теләгән әдәп белән җиткерә алмады. Берәр йомыш кушкан булырга кирәк иде. Тыңлап утырса да зыян итмәс иде. Заданиегә очасы кеше бит».

«Кимсенде. Хәтерен калдырдылар, — дип уйлады Сәләхов. — Тик тыңлап утырсын иде. Янәсе, сержант башы белән офицерлар арасында утырмаска тиеш. Җаен табып, кәефен күтәрергә кирәк булыр».

Филимонов урыныннан торды, стена буена килеп, ак пәрдәне шудырып ачты. Пәрдә астыннан эре масштаблы оператив карта килеп чыкты. Штаб начальнигы Павловка күрсәткеч таягын сузып:

— Рәхим итегез, — диде. — Без әзер.

— Ярый, башлыйбыз, — диде штаб офицеры һәм һәр сүзне дөрес, ачык әйтеп, сөйләргә кереште.

* * *

Ул башта фронт күләмендәге яңалыкларга тукталды. Һава армиясенең соңгы вакыттагы эшләрен санап чыкты. Сугышчан задание-

не аңлатуга килеп җиткәч, ашыкмыйча гына трубка төяргә кереште. Филимонов шырпы сызып, трубкага ут кабызырга ярдәм итте. Ләззәтләнеп бер суыртканнан соң, штаб офицеры түшәмдәге сылу кызларга таба хуш исле төтен өрде. Тыңлап утыручыларга таба уйчан караш ташлап, трубкасын учына йомарлаган чакта, ул шундый җитди, шундый мәгърур күренә иде.

«Сталинга охшарга тырыша. Рәвешен дә китерә ала. Озак өйрәнгән булса кирәк», — дип уйлады Сәләхов һәм шушы фикереннән соң дикъкать белән тыңларга кереште.

— Разведка нәтиҗәсендә дошманның мөһим бер объекты ачыкланды, — диде подполковник Павлов. — Разведка менә нәрсәләр күрсәтә: «Эн» ноктасында фашистлар җир асты заводын сүтеп каядыр озатырга әзерләнәләр, — подполковник күрсәткеч таягын җилкәсенә салып, карта тирәсендә килешле итеп йөреп алды.— Хәтерләп калыгыз, Котбус шәһәреннән йөз җитмеш километр көньяк-көнчыгышта Цвайкау исемле тимер юл пункты бар. Таптыгызмы? Шул пункттан утыз биш километр төньяктан елга ага. Елганың дугаланып борылган җиренә ярым айга охшашлы бер калкулык урнашкан. Таптыгызмы?

— Таптык,— диде Сәләхов.— Ул, подполковник күрсәткән ноктаны картадан табып, билге куеп бара иде.

— Шул калкулыкның көнбатыш өлешен куе урман каплаган. Завод шул урман эчендә булырга тиеш, — штаб офицеры өстәл янына килеп портфелен ачты да, берничә негатив фотопленка чыгарды. Бу— фоторазведка материаллары. Эшкәрткәндә бераз бозылган. Шулай да, җентекләп караганда, озатырга әзерләнгән агач тартмаларны күреп була.

— Калкулык нык саклана, — диде ул паузадан соң. —Фотопленкадан урман әйләнәсенә тотылган чәнечкеле тимер чыбыкны да күреп була. Объект тирәсенә күзәтү вышкалары куелган. Кабат әйтәм, объектны каты саклыйлар.— Штаб офицеры трубкасын суырырга кереште. Үзе, күз кыры белән генә, тыңлап утыручыларны күзәтә иде.

— Зенит батареялары объектны урап алган булырга тиеш. Аларга маскировка ясаганнар. Шунлыктан зениткаларның радиусларын билгели алмадык. Җир асты заводын сакларга билгеләнгән аэродром көньяк-көнчыгышта булырга тиеш. Анда ике эскадрилья «мессершмит» тәүлек буе очарга әзер тора дигән өстәмә мәгълүмат бар. Һаваны күзәтүче махсус постлар булырга тиеш. Бу версия ачыкланып җитмәгән әле. Кабат әйтәм, объектка бер генә юнәлештән дә сиздермичә үтеп керерлек түгел. Ә без үтәргә тиешбез. Боерык шундый. Үтеп керүне бездән Ватан көтә,— подполковник Павлов, ак батист яулык чыгарып маңгаен сөрткәч, тагын дәвам итте. — Ышанычлы чыганакларның белгертүенә караганда, фашистлар шушы заводта чиктән тыш дәһшәтле яңа корал әзерләгәннәр. Корал безгә эләкмәсен өчен аны көнбатышка озатырга җыеналар. Без шул коралны юкка чыгарырга тиешбез. Объектны тар-мар итү өчен безгә бер тәүлек вакыт бирелде. Шушы вакыт эчендә заданиене үтәргә кирәк.

Штаб офицеры, сүзе беткәнлеген белгертеп, сөрмәле күзләрен түшәмгә төбәде.

*
* *

Хәзер штаб начальнигы полковник Филимонов сөйли иде:

— Мин шуны өсти алам. Моңа кадәр ясалган ике һөҗүм бернинди нәтиҗә бирмәде. Объект чиктән тыш нык саклана. Зенит батареялар һәр квадратны алдан хисаплап, прицелга алып куйганнар.

Самолет зонага керә башлау белән бердәм залп бирәләр. Ә сез үтеп керергә тиешсез. Задание шулай куелган. Сез чиктән тыш җаваплы һәм почетлы заданиегә очасыз. Шуны бер минутка да онытмаска тиешсез. Сорауларыгыз бармы?

Сүз бетте. Тынычлык урнашты. Газаплы тынычлык. Шуннан котылыр өчен бу очракта сүз кузгатып нәрсәдер әйтергә кирәк иде, ләкин сүз табылмады. Хәтта тәҗрибәле карт очучы майор Растопчин да бер ноктага карап тик тора иде.

Куелган заданиене үтәү турында уйлыйсы урынга Сәләхов штаб офицерының киемен күзәтергә тотынды: «Шушындый китель киеп авылга кайтасы иде, — дип уйлап куйды ул. — Кайда тегәләр икән мондый затлы киемне? Тукымасы һәм тектерүе күпме тора икән?» Сәйрин сугышчан задание турында уйларга, аны баштанаяк күз алдына китерергә тырыша, ә игътибары һаман подполковникның тәненә сыланып торган матур кителе тирәсендә әйләнә иде. «Бу кешенең кыланышлары да шундый затлы, — дип уйлавын дәвам итте Сәйрин. — Хәрәкәтләре күркәм, гәүдәсен тотуы мәгърур. Ул үзен менә шушылай тотарга көзгегә карап өйрәнгән булса кирәк? Без дә үзебезне Павлов шикелле тотарга тиеш тә бит — өйрәнергә вакыт юк».

Сәләховның нигәдер авылына кайтасы килеп китте. Павловныкы шикелле кыйммәтле китель киеп урамнан үтәсе, аулак өйләргә йөрисе иде... Өстә Павловныкы шикелле затлы кием, җилкәләрдә ука погоннар. Сәйрин сөйгән ярын биергә чакыра. Авыл яшьләре Сәйриннең киеменә карап сокланып утыралар...

Сәйриннең исенә аэродромда һава үзгәрүен көтеп ятканда кабынган бер бәхәс килеп төште. Эскадрилья штурманы капитан Гусев — авиаполкның иң культуралы офицеры. Антон Павлович Чеховның бер фикерен искә төшерде: «Тәрбияле кешенең бар ягы да гүзәл булырга тиеш: йөзе, киеме, җаны һәм фикерләре». Марсель Ялчинский бу фикер белән килешмәде. «Без башка чорда яшибез, — диде ул. — Безгә вакыт җитми. Шуңа күрә безнең чор кешесенең көче, мөмкинлеге «пинжәк культурасы» үзләштерүгә генә җитә. Ул шуның белән генә чикләнеп кала. Ә без беренче нәүбәттә иман һәм вөҗдан ягын кайгыртырга тиешбез. Безнең чор өчен иң мөһиме шушы сыйфатлар.

Сәләховның штурманында башка уй иде.

«Моңа кадәр дә сугышчан заданиеләрне үтәп килдек, — дип уйлый иде лейтенант Майнагашев. — Заданиенең катлаулы булуы турында кат-кат кисәтәләр. Бомбаны, гадәттә, дошман позициясенә үтеп кереп ташлыйлар. Моңа кадәр без һәр очуда үтеп керә тордык. Бу юлы да үтмичә калмабыз...» Штурман Сәйрингә таба борылды:

— Подполковник Павлов чит ил кешесенә охшаган, — диде ул капыл гына. — Сугыш булмаган тыныч җирдә яшәгән шикелле.

Полковник Филимоновның кабинетында сугыш турында уйлыйсы килми иде. Таш стеналар аша бернинди тавыш та үтеп керә алмый. Түшәмдә гүзәл кызлар рәсеме. Тәрәзә пыялалары аша язгы кояшның җылы нурлары коела. Тыныч, якты һәм рәхәт. Шундый рәхәт тынычлыкта изрәп утыруы.

Майор Растопчин үзенең звено командиры, аның штурманы турында уйлый иде. «Бигрәк тә яшь күренәләр, — дип, егетләргә кабат карап куйды ул. — Армиягә кадәр кызлар кочып караганнары да булмагандыр бәлки?» — Майорның беренче тапкыр үбешүе исенә төште. Беренче үбешүнең бәгырьләрне эретерлек утлы ләззәте комэскның тамырлары аша кабат үткәндәй булды. — Бу егетләр минем улларым кебек, — дип уйлавын дәвам итте Растопчин. — Шуңа күрә яратам ахры мин аларны. Ә задание катлаулы. Заданиенең катлаулы булуын алар тулысынча аңлап та бетерә алмыйлар әле. Яшь чакта һәр эш җиңел күренә, яшь чакта катлаулыкларга әһәмият биреп тор-

мыйсың. Хәер, бу турыда подполковник Павлов та кисәтеп куйды. Штаб офицеры задание бирергә парадный киемнән килгән. Тәти киенеп йөрергә ярата, күрәсең. Ул, киенеп-ясанып, банкетларга йөри торгандыр. Анда чибәр артисткалар, генерал кызлары белән вальс-бастон биергә яратадыр. Павлов киләчәктә дә биер, театрларга йөрер. Сугыш бетү белән аны Мәскәүгә чакырып алырлар. Гәүдә матур, җилкәләр киң. Ул анда генерал дәрәҗәсенә ирешәчәк. Генерал погоны аңа шулкадәр килешер иде».

Вакытында Растопчинның да банкетларга йөрер, чибәр артисткалар белән танышырга мөмкинлеге бар иде. Испан сугышындагы батырлыклары өчен аңа Ленин ордены бирелде. Ул чакта орденлы кешеләр аз иде әле. Сугышка кадәр Растопчинны күтәреп кенә йөртмәделәр. Испаниядә бергә сугышкан очучыларның күбесе күрсәткән ихтирамнан вакытында файдалана белделәр. Кирәкле кеше белән аралашканга күрә аларның чиннары бик тиз үсте, үзләре югары күтәрелделәр. Аның дусларының күбесе хәзер генерал. Ә Николай Якубович Растопчинның гомере һавада һәм шәһәрләрдән ерак урнашкан кыр аэродромнарында узды. Ул очу эшен яратты. Сөйгән кызын яраткандай бирелеп, онытылып яратты ул очу эшен. Шуның аркасында танцыга да өйрәнә алмый калды. Хатын-кызлар белән дә сөйләшә белми иде ул. Ә хәзер, контузиядән соң, сүз саен тотлыга. Ул алардан ояла иде.

Подполковник Павлов комэскка ошамады.

— Эшалонированный һөҗүм ясап карасак ничек булыр икән? — диде Растопчин.

— Кирәкми, — диде штаб офицеры кырт кисеп. — Бу эшкә бер экипаж җитә. Оста, кыю, Ватанга тугрылыклы бер экипаж.

— Минем тагын соравым бар, — диде комэск кыза төшеп.

— Рәхим итегез, — диде полковник, үзе эченнән уйлады: «Гаҗәп үҗәт һәм примитив күренә миңа бу майор. Белеме дә чамалы булса кирәк».

— Нинди курс үтеп керергә уңайлырак булыр?

— Обстановкага карап, — диде штаб офицеры. — Сез үзегез белергә тиешсез. Полковник заданиегә иң сәләтле экипажны билгеләдек диде. Аларга ышанырга була.

Полковник Филимонов исә очуны югарыдан фәрман биреп туктатырлар дип ышана иде. Бәлки армия штабы белән сөйләшеп, яңа разведкага кадәр заданиене бер-ике тәүлеккә соңартып та булыр. Бу очракта, сугыш бетү сәбәпле, задание үзеннән-үзе юкка чыгачак иде.

— Аңлашылдымы? — дип сорады полковник Филимонов, — нинди сорауларыгыз бар? Кабат кисәтәм, ашыгырга ярамый. Бик җитди, бик җентекләп әзерләнергә кирәк. Ну, лачыннар, уңышлар телим.

Растопчин урыныннан торды, ярдәм көткәндәй, як-ягына карап алды. Күзе штаб офицерына тукталгач, аның кинәт кашы җимерелде.

— Киттек, — диде ул. — Аңлашылды, әзерләнә башларга кирәк.

*
* *

Майор Растопчин зур тәҗрибәле, сәләтле командир иде. Гомерен очу эшенә багышлаган, түзем, күндәм, курку белми торган хәрби летчик иде ул. Авиациядә хезмәт итә башлаганчы шахтада эшләде. Аннан соң ОСАВИАХИМ. Очарга өйрәнү. Котып, Ерак Көнчыгыш күкләрен яулау. Испания сугышы. Халхин-Гол. Көнбатыш Украина белән көнбатыш Белоруссияне СССРга кушылдыру. Фин сугышы. Ватан сугышының беренче көненнән башлап заданиеләргә очу. Иң

авыр, иң җаваплы эшкә аның үзен яисә аның эскадрильясын җибәрәләр иде. Очу эшен үлеп яратса да, ул, командир вафизасын үтәп, фәрман биреп кенә йөрүне өнәп бетерми иде. Шуңа күрә Растопчин эскадрильяда калдыра килүләренә чын күңелдән куана иде. Күп гадәтләреннән көлсәләр дә, очучылар Растопчинны яраталар, ихтирам итәләр иде. «Зениткалар урнашкан җирләрне дә билгели алмагач, разведка буламыни ул»? — Ачуын басу өчен комэск рәхәтләнеп сүгенде, сүгенгәч, эче бушагандай булып китте.

Хәзер комэск заданиегә очасы экипажга ярдәм итү турында уйлый иде: «Бәлки күрше полкта, армия штабының үзендә, дошманның зенит артиллериясе урнашуы турында мәгълүматлар бардыр, — дип бераз тынычланып куйды эскадрилья командиры. — Эзләргә, табарга, егетләргә ярдәм итәргә кирәк».

Штабтан кайткач, Растопчин үзенең штурманын, элемтә начальнигын һәм адъютантны[1] чакырды. Алар озак киңәштеләр. Алган заданиене җентеклә тикшереп чыктылар. Беренчедән, дошман зениткалары урнашкан нокталар билгеле түгел. Икенчедән, Сәләхов экипажы бомбага тотасы объектның җир асты заводы булуы, аның җиһазларын җир өстенә чыгарып, озатырга әзерләп куюлары бәхәсле иде. Разведка җыйган мәгълүматлар беркайчан да йөз процент дөрес булмый. Разведка әйләнеп кайткан арада гына да хәл шактый үзгәрергә мөмкин. Бу авыр һәм катлаулы эш. Разведчик күреп белүдән тыш, алдан сизеп, чамалап та белергә тиеш.

Киңәшмәдә шушы турыда сөйләшеп баш ваттылар. Киңәшмә азагында эскадрилья штурманы яңадан разведка ясарга кирәк дигән фикерен әйтте. Адъютант исә «разведка алып кайткан мәгълүматларга тулысынча ышанырга һәм аны үзгәртмичә хәзерләнергә кирәк», — диде.

Киңәшмә азагында Сәләхов экипажын чакырдылар.

— Ничә бомба аласыз? — дип сорады комэск Майнагашевтан, таралыр вакыт җиткәч. — Вакнымы? Эренеме?

— Командир, — диде штурман, — объектның кайсы өлешен җимерергә кирәк. Җир астындагысынмы, әллә өскә чыгарганын гына айкап ыргытыргамы?

— Һе, айкап ыргытырга? Кара... Нишләмәкче була. Кызу канлы монгол, — диде комэск сокланып. — Самолет күпме бомба күтәрә ала? Юрганыңа карап аяк сузарга кирәк.

— Иптәш майор, сез Майнагашевны аңлап бетермәдегез, — диде Сәләхов. — Җир астын шартлатырга булганда браб алыр идек, ә болай фугас бомбалар белән дә чикләнергә була.

— Алтышар йөз килограммлы дүрт фугаска алсагыз, шул җиткән, — диде эскадрилья штурманы.

— Объектка кайсы яктан үтеп кермәкче буласыз? — диде комэск. Аны бу хәл бик борчый иде.

— Обстановкага карап эш итәрсез дип киңәш бирделәр штабта.— Сәләхов комэскка карады.

Растопчинның заданиегә җыенган экипажга бик тә ярдәм итәсе килә иде.

— Минем машинаны ал, Сәләхов, ал, рәхмәт әйтерсең. Моторлары яңа, җен кебек эшли. Ал, үкенмәссең, — диде Растопчин.

Комэск чыгып киткәч, Гусев көлеп җибәрде:

— Ни булган безнең картлачка? Самолетын башка кешегә бирми иде ул. Картая башлады командир.

---

[1] Эскадрилья штабының начальнигы авиациядә эскадрилья адъютанты дип атала.

Комэскның мондый юмартлыгы Сәләховка да сәер тоелды. «Заданиенең катлаулы булуын бераз арттыралар,— дип уйлады ул.— Авыр заданиеләргә очмадыкмыни без? Очуның әллә ниндиләре булды. Сугыш бит. Сугыш шартларында җиңеллек кенә көтеп булмый».

Задание турында капитан Гусев та борчыла иде. «Кабат разведка ясап карыйсы иде», — дип уйлап куйды ул. — Мондый экипаж үти алмаслык задание булмаска тиеш. Үтәрләр, һәрвакыт шулай, хәзерләнгән чакта артык борчыласың. Әллә нинди кимчелекләр табылып куя. Һавага күтәрелгәч эш җайлана. Бу юлы да шулай булачак. Очуның иң авыр чаклары артта инде. Беренче елларда кыен иде ул. Хәзер җиңеләйде. Җиңү ышанычы шулай җиңеләйтте. Инде ял һәм киләчәк турында кайгыртырга кирәк, — шушы куанычлы уйлар эскадрилья штурманын тынычландырып җибәрде. Ул комэск артыннан полк штабына юнәлде.

*
* *

Икенче эскадрильяның иң яхшы самолеты майор Растопчинда иде. Ул үзе, мин менә шушы машинаны алам, дип әйтеп тормады. Тоттылар да иң яңа, иң әйбәт очкычны аңа билгеләделәр. Шундый гадәт инде. Иң яхшы корал һәрвакыт командирның үзендә була. Полк командирында частьның иң яхшы самолеты, комдивта — дивизиянеке. «Бәлки бу борынгыдан калган йоладыр,— дип уйлады Сәләхов.— Ул башка эшләрен бетереп, аэродромга барырга чыккан иде инде. — Бу гадәт сугышка ат менеп йөргән чаклардан калуы ихтимал. Ул чорда да бит яхшы ат, әйбәт корал чиру башлыгында булган. Чөнки командир — сиңа үрнәк. Күп эшне син аңа карап эшлисең. Авырлыкларны да ул күбрәк кичерә. Рядовой очучы үзе турында гына уйлый, үзен кайгырта. Ә командирга безнең барыбыз турында да кайгыртырга туры килә. «Комэск миңа үз машинасын бирде. Ул, җае чыккан саен, ярдәм күрсәтергә, игелек эшләргә тырыша. Миңа гына түгел, эскадрильяның һәр очучысына, юлында очраган һәр кешегә. Бер Растопчин гына андый мыни? Авиаторларның һәркайсы диярлек шундый. Бер-береңә ярдәм итү, яхшылык күрсәтү булмаса, сугыш шартларына чыдап булмас иде. Без эшләгән эшебездән куаныч табарга тырышабыз. Адәм баласы һәрвакыт куанычка мохтаҗ. Ә куанычның иң зурысы — дуслар ярдәме. Бу дөньяда син аларның ярдәменә ышанып, якынлыгына сөенеп яшисең. Яныңда әйбәт кешеләр булуы, аларның фидакарьлеген, аларның ихтирамын йөрәк белән тоеп тору — җир йөзендә иң зур бәхет, — дип уйлады Сәләхов. — Мин үзем дә башкаларга бурычлы булып калмаска тырышам. Җае чыкканда дусларыма яхшылык күрсәтәм. Ләкин мин үземнән өстенрәк торган кешенең күңелен күрә белмим. Ялагайлыктан куркам. Эскадрилья командирына да игелек эшләгәнем булмады. Ә менә Кононенко яхшылыкны гел үзеннән өстәрәк торган начальникларга күрсәтә. Файдалы кешеләр өчен ул берни кызганмый. Бәлки ул дөрес эшли торгандыр? Начальниклар да яхшылыкка мохтаҗ бит...»

«Бер-береңә начарлык эшләп йөрүгә калса, яшәүнең мәгънәсе бетәр иде, — дип фикерен дәвам итте Сәйрин. — Адәм баласына җылы мөнәсәбәт җитми. Ә без, бу турыда онытып, фани дөнья ызы-зыгысына бирелеп китәбез. Рухи яшәүгә кул җитми. Ул читтә кала. Эчне туктаусыз матди кирәклекләр тырнап тора. Безне бәхетле була белергә өйрәтмиләр. Ә бәхетле булуның сере шундый гади. Бүген нинди аяз матур көн. Саф һава. Кояшлы күк. Язның иң ямьле чагы. Янымда дустым Максим Майнагашев. Ул миңа соңгы сулышын бирергә әзер. Мин дә аңа бер икеләнеп тормыйча, калган гомеремне бирер идем.

Шушы көн, шушы һава, шушы зәңгәр күк һәм Максимның янәшәдә булуы байлык түгелмени? Байлык һәм куаныч. Куаныч һәм бәхет. Зәңгәр күкне миннән беркем дә тартып ала алмый. Миңа тиешле кояшның нурларын беркем киметеп бирә алмый. Минем Майнагашевка булган ләззәтле тойгыларымны да басып кала алмыйлар. Аларның барысы да миндә һәм мин шушы байлыкның янымда булуына туйганчы сөенә алам. Алар иртәгә дә, берсекөнгә дә минем белән булачаклар. Шушы хакыйкатьне без заданиегә очар алдыннан гына аңлый башлыйбыз. Башка вакытта ул нигәдер онытыла...»

Сәйриннең шушы хакыйкатьне аңлау бәхетен кем белән булса да бүлешәсе килеп китте.

*
* *

Көннең болай матур булуына Максим да шатлана иде. Ул үзенең туган җире турында уйлап бара иде. «Боланнарны диңгез ягына таба куар вакыт җитте, — дип исәпләп куйды Майнагашев. — Кар да эри башлагандыр инде? Безнең якта озакламый яшь үлән шытып чыгачак. Тундра чәчәкләргә күмелер. Боланнар өчен дә, аларның хуҗалары өчен дә мул, рәхәт тормыш башланып китәчәк. Җир йөзендә болан сыерыннан да акыллы ни бар икән? Боланнар арасында татулык, алардагы бердәмлек, алардагы гадилек бәлки башка бер җан иясендә дә юктыр? Дөрес, болан үгезләре яз житкәч бераз сугышып алалар. Хәлдән таеп егылганчы, имгәнгәнче сөзешәләр. Болан табигатен белгән һәм сугышуның максатын аңлаган кешегә бу көрәш гадел тоела. Алар бер-берсен үтерер өчен түгел, ә көчләрен, батырлыкларын сынау өчен сугышалар. Ана боланнарның мәхәббәтләрен яулар өчен көрәшәләр алар. Иң тик җинеп чыккан, иң көчле, иң батыр, иң зирәк үгез генә нәсел калдыра ала. Шунлыктан, боланнарның нәселе беркайчан да начарланмый, киресенчә, туктаусыз яхшырып тора. Мәхәббәт ләззәтенә ирешү өчен болан үгезләре, икеләнеп тормыйча, үлем белән чикләнгән көрәшкә чыгалар. Шундый көрәштә яуланган мәхәббәт нинди тансык, нинди ләззәтле була торгандыр. Кешеләр дә мәхәббәт өчен шулай көрәшсеннәр иде».

«...Җиңеп чыккан үгез нәсел калдыру белән генә чикләнми бит. Көтүне әйдәп барырга лаеклы юлбашчыга әйләнә. Андый үгезне көтү ихтирам итә. Чөнки ул иң көчле, иң зирәк, иң түзем, иң чыдам болан. Ул башкаларга үрнәк булырлык, көтү куркынычка юлыкканда коткарып калырлык була. Әгәр киләсе язга бу юлбашчыдан көчлерәк, зирәгрәк үгез табылса, көтүне әйдәп йөрү аңа күчә...»

Шушы фикереннән соң Максим болан бозаулары турында уйларга керешә: «Дөньяда алардан да матур, алардан да нарасый җан иясе бармы икән? Болан бозавының муеныннан кочаклыйсың да, бармак очы белән аның тамак астын кашый башлыйсың. Бозау әлсерәп төшә: муенын суза, рәхәтләнеп күзләрен йома. Ул муен кашучыны шулкадәр ярата, ул синнән шундый канәгать, теләсәң, җанын бирергә риза. Бу — җир йөзендәге иң гади, иң аңлаешлы ярату».

Ниһаять, болан йөрәгенең сәякле булуы Максимның исенә төште. «Башка бер җан иясенең дә йөрәгендә сөяк юк бит. Ә болан йөрәге сөякле. Нилектән алай икән ул? Сөяк ныгытмаса, тубыктан карга батып, тәүлекләр буе җил тизлеге белән тундрада чабып йөрүгә болан йөрәге чыдамас иде. Табигать ничек кайгырта...» — шушы фикеренә куанып Максим елмаеп җибәрде.

Сәлахов белән Майнагашев ачык кырга чыгып киләләр иде. Көн һаман матурлана. Агачлык эчендә кошлар сайрый! Якында гына ша-

шынып чикерткә черелди. Кояшлы матур көндә ашыкмыйча гына аэродромга бару нинди рәхәт.

Һавадагы кояш нурлары, җирдәге агачлар, үләннәр, чәчәктән-чәчәккә кунып йөргән күбәләкләр, тамырлар арасында адашып йөргән кырмыскалар, хәтта барон басуындагы соргылт балчыкларга кадәр тынычлык килүен сизеп куаналар шикелле. Шундый рәхәт иде бу дөньяда яшәү. Шушы һаваны бер генә кат сулар өчен һич икеләнмичә дөнья малын бирерсең.

Майнагашев кинәт туктап калды:

— Карлыгач оясы, — диде ул. — Күрәсеңме?

*

* *

Калайдан гына әмәлләнгән бинаның почмагына бер учлам соргылт балчык ябышып каткан. Балчык арасыннан ат кылы, үлән кисәкләре күренеп тора. Ике җәпле карлыгач койрыгы ояга сыймыйча читкә чыгып калган.

— Гаҗәп кеше син, Максим,— диде Сәләхов сокланып.— Очуга әзерләнәбез. Җитди, җаваплы очуга. Ә син карлыгач оясы күреп куанып барасың.

— Бездә карлыгачлар шомырт чәчәк атканда кайталар. Алар кайткач көн җылына.

— Синең монда шомырт агачы очратканың булдымы? Монда нишләптер шомырт юк, — диде Сәләхов.

— Утыртмый торганнардыр. Алар юл буена да җимеш агачлары утырталар бит. Мондагы халык гел файда өчен генә яшәгән булса кирәк. Бер карыш эшкәртелмәгән җир табып булмый.

— Гел файдага гына яшәгәч, сугыш башламаска кирәк иде. Иң зыянлы нәрсә — сугыш. Алар шуны аңларга теләмәгәннәр.

— Аңлыйбыз дип нишләсеннәр? Сугышны Гитлер башлаган. Каршы килеп, сугышка барырга карышып кара әле? Сугыш игълан иткәч, берни эшләп булмый. Сине ике яклап камчылыйлар. Бер яктан — милли патриотлык, икенче яктан — аяусыз закон, — диде Майнагашев. — Сугыштан баш тарткан кеше төрмәгә эләгә.

— Сугыш фәлсәфәсе искиткеч катлаулы. Баш ватып интекмик әле, — диде Сәйрин. — Минем армиягә киткәннән бирле урманга чыкканым юк. Заданиедән әйләнеп кайткач, әнә теге имәнлеккә барып, агач төбендә туйганчы ял итәргә иде бер.

«Әйләнеп кайткач» сүзе ничектер сәер яңгырады. Майнагашев сизде: «Шушы ике сүзгә ни кадәр өмет сеңгән», — дип уйлады ул.

Алар үзләре оча торган самолет янына килеп җиттеләр. Капонирның ачык ягыннан Пе-2нең борыны гына күренеп тора иде. Сәйриннең күкрәгенә җылы дулкын килеп бәрелде. «Хәлең ничек, акыллым?» — дип очкычның муеныннан кочаклап сорыйсы килеп китте. Майнагашев та самолетка карата эчендә бер җылылык уянганын тоеп елмайды.

Авыл балалары йорт хайваннары арасында үсә. Аларның ничек яшәүләрен, холыкларын күзәтә. Алар белән уйнап үсү тойгыларны баета, шәфкатькә өйрәтә булса кирәк.

Сәйрин белән Майнагашевка очкыч та җанлы булып тоела иде. Шәһәр малае Ялчинский очкычны бары тик дюральдән ясалган машина итеп кенә кабул итә иде. Марсель машиналарга йөрәк җылысы катнашмаган аек акыл белән генә карый иде.

Самолет янында Сәйриннең дә, Максимның да тойгылары нечкәреп киткәндәй булды. Ерак бабалар йөгерек тулпарларга атланып офыктан офыкка җилдәй очып йөрергә яратканнар. Шушы ярату кан

белән буыннан-буынга тапшырылып, Сәйрин белән Максимга да килеп җиткән. Дошман истребительләре һөҗүмен көткәндә уяна торган ләззәтле ярсу, әсәрләнеп сугышу да — ерак бабалар мирасы. «Без аны аңлап кына җиткермибез,— дип уйлады Сәләхов күңелендә шушы фикер уянгач. — Ихтыяр ягыннан ерак бабаларыбыз бездән көчлерәк тә булгандыр? Алардан соңгы буыннар көчле кимсенү аша үткәннәр. Шул кимсетүләр шактый зыян китергән безгә. Шул чакта сәләтле булуыбызга, мөмкинлекләребезгә ышанмый башлаганбыз. Шушы хәл зыян китерә безгә».

Самолет яратуның файдасы бар иде. Ярату ышануга тоташкан була. Шушы ике хис арасында даими уртаклык бар. Яраткан дусларга, сөйгән ярга без риясыз ышанабыз. Машина да шулай. Син аңа ышанасың. Һава сугышында ышану кирәк. Ышану сиңа көч кертә, кыюлык өсти, канат булып сине афәттән саклап йөри.

*

* *

Үз самолетлары янына тукталып торганнан соң Сәләхов белән Майнагашев комэск машинасы янына киттеләр. Бу күптән түгел заводтан чыккан яңа очкыч иде. Машинаның аскы ягын зәңгәргә, өстен яшелгә буяганнар. Астан караганда самолет зәңгәр күккә, өстән — яшел үлән төсенә кушыла. Матур һәм сылу очкыч иде Пе-2. Кызлар гәүдәседәй җыйнак фюзеляж. Һава кисәргә әзер торган юка канатлар. Центропланда су белән суытыла торган Климов моторлары, икәү. Мотор редукторына пропеллер беркетелгән. Шулар әйләнә башлау белән самолетка җан керә.

Укчы-радист аэродромга алданрак килгән иде. Ул эшләрен бетергән, канат өстенә кырын ятып, авыз гармонында уйный. Тирә-якка, кояш нурларына кушылып, язгы моң ага. «Санта Лючия» көен уйный иде укчы-радист. Италиянең нурга күмелгән зәңгәр Неополитан култыгында туган көй. Һәм ни гаҗәп, кояшның нурлары шушы моңга сеңеп калган шикелле.

Укчы-радист, уйнаудан туктап, дусларына карады. Күкрәк эченә кереп калган моң яшь, тамырлар буйлап һаман агыла иде. Ялчинский гармунын куен кесәсенә тыгып, җиргә төште:

— Иптәш өлкән лейтенант, пулеметларны кордым. Радиостанцияне эшләтеп, тикшереп карадым. Боезапас — тулы комплект. Пристрелка ясалган. Мин заданиене үтәргә әзер.

— Бомбаларны асмадылармы әле? — дип сорады Майнагашев рапорт тәмамлангач.

— Күптән инде,— диде Ялчинский елмаеп. — Синең пулеметны да тикшердем. Аны да корып куйдык. Бомба ташлау механизмнарын коралчылар тикшереп карадылар. Монда сезгә эш калмады инде.

— Задание җаваплы. Тагын бер кат тикшереп чыксак та зыян итмәс, — диде Сәләхов. Гармун тавышы Сәләховның йөрәгендә канатлы дәрт уяткан иде.

— Мин өйрәткән көйне онытмадыңмы әле? — дип сорады ул укчы-радисттан.

— «Карурман» көенме?

— Юк. «Карурман»ны түгел, икенчесен, — диде Сәләхов.

— Аңладым. Брамсның «Мадьяр танцылары»на охшашлы «Гөлҗамал»нымы? Хәзер.

Ялчинский куен кесәсеннән гармунын алды. Өрде. Ирененә терәгәч, аны як-яктан учлары белән каплады. Башта татар кызларына хас оялчан, әдәпле генә, торган саен һаман кыюлана, көчәя барган «Гөлҗамал» көе аэродромга, янәшәдәге кырларга, җимерелеп яткан шәһәр хәрабәләренә таралды.

*
* *

Шәмдәлләрдә генә утлар яна, Гөлҗамал,
Җиткән кызлар киндер җеп эрлиләр...

Сәйриннең туган авылы кызлары, кич утырып, киндер җеп эрлиләр. Җиз шәмдәлләрдә балкып ут яна. Ут ялкыны кызларның яшь, ярсу йөрәкләрендә дә дөрли. Һәр кызның алдында бизәкләп эшләнгән тәрәшле каба. Кабага кызлар чәче кебек матур житен сүсе эленгән. Орчыклар зырлап бөтерелә. Орчык тавышына кушылып, кызлар «Гөлҗамал» көен сузалар.

Нәзберек шәм уты кызлар тыныннан сизелер-сизелмәс кенә тибрәнә. Йөрәктәге мәхәббәт уты да нәкъ шулай салмак һәм әкрен генә хәрәкәтләнеп тора. Кызлар җыр җырлыйлар.

Егетләр еракта. Алар сугыш кырында. Тормышны буарга, тар-мар итәргә килгән дошман белән сугышалар алар. Сугыш — хәтәр. Сугыштагы егетләрнең гомерләре шәм утыннан да нәзберек. Йомшак җил, гади сулыш шәм утын сүндергән кебек, очып килгән ук, күтәрелгән кылыч егет гомерен сүндереп ташлый ала. Сугышта йөргән кешенең гомере һәр мизгелдә куркыныч астында.

Егетләр сугышта. Кыз бала гомерендә иң зур куаныч — җиңүчене каршылау. Сугыштан җиңеп кайткан ярларны каршы алу — иң зур бәхет, иң көчле тантана. Алар тизрәк кайтсыннар иде. Кайтсыннар иде. Кайта гына күрсеннәр! Үзләре кайтса, аларның энҗе-мәрҗәннәре, затлы бүләкләре дә кирәкми. Кайтмый калсалар, без кемнәргә генә чыгарбыз икән дип ут йотып елыйлар кызлар. Әгәр сөйгән ярлар сугыш кырында калсалар, кызларын аяусыз ялгызлык көтә. Утырып калу, баласыз картаю, нәсел калдырмыйча үлү — иң каһәрле тәкъдир. «Кавышу, ир кочу, бала сөю бәхетен бир, раббым» — дип ялварган авазлар ишетелә «Гөлҗамал» көендә. «Өмет тә, бәхет тә сугыш кырында йөрүчеләрнең исән калуларында», — дип кисәтә борынгы көй. Җырны, билгеле, күп сугыш, күп сагыш, күп михнәт күргән татар кызлары чыгарган.

«Гөлҗамал» җырын Сәйрин менә шулай аңлый иде. Җыр аның йөрәген җәрәхәтләп, бәгыренә үтеп керә иде. Шушы ачы, афәтле хакыйкатьне аяныч лы йөрәк белән, кан белән аңлау егеткә җан егәрлеге, вөждан гайрәте бирә иде.

...Шәм уты Сәйриннең сөйгән кызы Разия сурәтен яктыртты. Башына ак яулык чөйгән, билендә кукрәкчәле ак алъяпкыч. Шәм яктысы аның колак яфрагындагы көмеш алкаларда уйнап ала.

Сәйриннең сөйгән яры «Гөлҗамал» көен җырлый. Көйне сузар өчен сулыш алганда аның тыгыз күкрәкләре сизелер-сизелмәс күтәрелеп куя. Авыр керфекләр астына яшеренгән уйчан коңгырт күзләр тез өстендә бөтерелеп торган орчыкка төбәлгәннәр. Ул үзе Сәйрин турында уйлый. «Гөлҗамал» җырындагы кызлар шикелле Разия да аның кайтуын сагынып көтә, аның исән калуын теләп, төн урталарына кадәр ялварып ята.

Алар җиде ел бер мәктәпкә йөрделәр, бер класста укыдылар. Ул чакта Разияның башка кызлардан бер аермасы да юк иде. Озын торыклы, ябык, ике толымын җилкә аша түшенә асылындырып йөрүче гади генә бер кызый иде. Тәнәфес вакытында аларның ничә тапкыр сугышканнары булды. Аларның авылында кыз-хатыннар юаш затлардан түгелләр.

Тәнәфес вакытында кызлар малайлар белән тигез сугышалар иде. Алар Разия белән отряд җыелышына, отличниклар слетына да бергә йөрделәр. Колхоз эшенә, дәрт керә башлагач, кичке уеннарга да бергә чыктылар. Армиягә китәсе елның язында Сәләхов Разияны аулак

өйдә очратты. Кызны алыштырып куйганнар диярсең. Карап торырга шул ук: озын аяклы, тулы иренле отличница, ә кызның елмаюында, кулын күтәреп, чәчләрен төзәтүендә, һәр сулышында сине акылдан яздырырлык көчле тылсым бар. Аулак өй таралганчы Сәйрин классташының битеннән күзен ала алмыйча татлы газап чигеп, саташып утырды. Кызның елмаюы, һәр хәрәкәте Сәйриннең эчендәге иң сизгер, иң авыртулы бер ноктага килеп бәрелеп тора һәм шул авырту нигәдер газиз һәм ләззәтле иде. Шул авыртуны, шул татлы интегүне тоеп тору өчен Сәйрин җир йөзендәге нинди генә газапка да риза. Шул көннән Разияның тавышы, дөньяларны яктыртып елмаюы, бүселеп чыккан кара чәчен сыпырып яулык астына кертүе — һәр кыланышы Сәйриннең бәгыренә сеңеп сурәтләнеп калды. Ул кыз әле дә аның күз алдында. Ул кызны һәр теләгән мизгелдә күреп һәм тоеп була. Күзгә күренү белән үрелеп тотасы, назлыйсы, үбәсе килә. Шул чакта күз алдында бары тик сурәт кенә икәнлеген сизеп аласың. Юксыну газабы ачыттырып ала йөрәкне, күкрәкне сагыну кыса башлый.

Алар аерыласы кичне генә беренче тапкыр үбештеләр. Үбешүнең тәме, аның бәгырьләрне айкый торган рәхәт газабы әле дә Сәйриннең иренендә иде. Шул чакта Сәләхов Разиядан «нигә моңа кадәр үптермәдең?» дип сорады. «Сиңа ошарлык матур күлмәгем юк иде, шуңа үптерәсем килмәде», — дип аңлатты аның сөйгән яры. Ай-һай катлаулы кызларны аңлавы...

...Шәмдәлләрдә генә утлар яна. Гасырлар аша үтеп безнең чорга килеп җитә алган чын милли көй халык зарын, аның сугыш-ызгыштан туеп, тынычлыкка омтылуын безгә сөйли. Җырлый-җырлый, елыйелый җеп эрләүче кызлар гасырлар буе күз яше, кан койган халык тәкъдирен тасвирлыйлар. Халык язмышы яшь кызлар тәкъдире аша үтә. Нәселне дәвам иттерү, ата-бабадан калган йолаларны, гадәтләрне саклап тоту да бар аларда. Токым пакьлеген саклап килү дә алар кулында. Нәселләрнең дәвамы кызларның егетләр белән кавыша алуында. Ир-егетләр сугыш кырында ятып кала килсә, нәсел корыячак. Шәмдәлләрдәге утлар сүнәчәк, ил өстенә караңгылык иңәчәк.

Кызлар эрләгән җептәй нәзберек, нечкә язмышларны канлы сугышлар туктаусыз өзә торган.

«Шәмдәлләрдә утлар сүнеп бетмәгән әле, — дип уйлады Сәләхов.— Утлар яна. Шәм уты безнең киләчәк бәхетне яктырта. Шәм яктысы алда өмет барлыгын күрсәтә, көтәргә, түзәргә куша. Сугыш тиздән бетәчәк. Җиткән кызлар Сәйриннәрне җыр җырлап каршы алырлар. Исән кайта алган егетләргә алар алма кебек матур балалар үстереп бирәчәкләр. Иң мөһиме — сугыштан исән кайту. Йөз дә утыз алты мәртәбә очты Сәләховның экипажы сугышчан заданиегә. Бусы йөз дә утыз җиденчесе иде.

«Шәмдәлләрдә генә утлар яна. Җиткән кызлар киндер җеп эрлиләр...»

— Безнең нәкъ шушыңа охшашлы көйләребез бар, — диде Майнагашев укчы-радист уйнаудан туктагач.

— Грек мифологиясендәге арахналар бит бу җеп эрләүче кызлар. Татар мифологиясе грекларныкына тоташмагандыр бит? — дип сорады Ялчинский уйнаудан туктагач. — Нинди генә могҗиза юк бу дөньяда!

— Ярый, — диде өлкән лейтенант Сәләхов. — Эшне бетерик тә ял итик. Иртәгә — җаваплы задание.

Шәмдәлләрдә янган утлар, җеп эрләүче яшь, чибәр кызлар сурәте тоныгая төште. Тира-юньдә Герман җире, шундагы кыр аэродромы, капонирлар эчендә утырган очкычлар күренә иде.

Егетләр урыннарыннан кузгалдылар, самолетны җентекләп тикшерергә, иртәгәге очуга әзерләнергә керештеләр.

* *

Сәләхов экипажы сугышчан заданиегә әзерләнә башлаган көнн Разия больницада ята иде. Моңа кадәр аның авырганы булмады. Бал чакта канга сеңеп калган шифалы авыл һавасы картайганчы чирг каршы көрәшеп тора ала диләр. Разияда картайганчы чирләмичә яшә мөмкинлеге бар иде. Бер көтелмәгән хәл аны аяктан егып ташлады.

Каза ялгыз килми, диләр.

Иң башта комсомол комитетына чакырып, кыздан чын-чынлап сора алдылар. Бу эштән Разия тәмам югалып калды. Ул нигә бәйләнүләре белми иде әле. Исламнурова моңа кадәр яхшы укып, җәмәгать эшен актив катнашып килде. Кыз бернинди ярамас эш эшләмәвен, ярамага сүз әйтүен хәтерләми иде. Комитетка чакырылуның сәбәбе бернич көннән ачыкланды.

Алар тулай торак бүлмәсендә дүртәү яшиләр иде. Тәтеш кызы Настя Дурова, Башкортстанның Чакмагыш районында туып үскән Ярмә кәева Эльвира, Канаш кызы Маша Козлова һәм Разия. Моңа кадәр тату яшәп килделәр. Соңгы сыныкларын бүлешеп ашадылар. Бер ахмак вакыйга Настяны Разиягә дошман итеп ташламаган булса, туганлык хисләре бәлки үлгәнче сүнмәс иде.

Бер көнне Настя Дурова Разиянең чемодан төбендә яткан зәңгәр күлмәген танцыга киеп барырга сорады. Сәйринне озатканда беренче тапкыр киелгән, беренче кочаклашуга, үбешүгә шаһит күлмәк иде бу. Разия Сәйрин белән кавышканчы ул күлмәкне бүтән кимәскә нәзер әйтте. Настяга бирмәүнең сәбәбе шушы иде. Нәзер турында Дуровага чишмәскә кирәк булган икән. Разия әйтте, ә иптәше аңламады. Аларда нәзер әйтү гадәте юк иде. Башта рәхәтләнеп көлде.

— Юләр син, Раечка, — диде ул көмеш кыңгырау тавышлары чыгарып. — Үбешкән саен күлмәгемне бикләп куя калсам, җитмеш чемодан җыелыр иде. Юләрләнмә, бир, укасы коелмас күлмәгеңнең. Зәңгәр күзле лейтенант белән очрашам, башка төсле күлмәк килешми. Шул күлмәк белән охмурять итмәкче булам.

Разия үз сүзендә торды:

— Теләсәң җанымны ярып ал, кызганмыйм, ләкин күлмәгемне бирә алмыйм, — диде.

Настя тузына башлады:

— Мин сине күптән сынап йөрим, — диде ул, — дин тотучы, хорафатка баткан кыз син. Комсомол комитетында җәмәгать эше оештырып йөргән буласың. Сине комсомолдан бүген үк куып чыгарырга кирәк. Үкенерсең — соң булыр.

— Настя, җан кисәгем, син аңларга тиеш, — дип үгетләп карады Разия.— Сөйгән ярымны армиягә озатканда кигән күлмәгемне ничек бирим. Танцы вакытында әллә нинди егетләр сине кочаклап йөриләр. Күлмәктә бит Сәйриннең кулыннан калган эзләр бар. Аның төсе итеп саклыйм мин аны.

— Синең дини фанатик булуыңа тамчы шигем калмады, — дип караватына кырын ятып кычкырды Дурова. — Бездә дә бар, әйберләрен башка кеше кулына тоттырмый торган сектант-фанатиклар. Староверм молоканнар дип атап йөртәләр аларны. Ә мин, дура, өч ел буе синдәй фанатик белән дуслашып йөргәнмен.

Ара өзелде. Шушы көннән башлап Настя Дурова Разия белән сөйләшми башлады. Һәм берничә көннән студентлар арасында гайбәт таралды. Имеш, комсомол комитеты әгъзасы, Сталин стипендианты Исламнурова Разия мәчеткә намаз укырга йөри икән...

Настя тараткан гайбәт чара күрергә ярарлык булып рәсмиләшмәде. Разияны белгәннәр бу гайбәттән көлделәр генә. Кызны яратмаучылар

гайбәт сүзләрен туйганчы чәйнәделәр. Гайбәт гайбәт килеш калды. Разия да комитет әгъзасы, уңган чибәр кыз килеш яши бирде. Әмма гайбәт кызның абруенда капкага буялган деггет шикелле тап булып тора иде.

Сишәмбе көн аны комсомол комитетына чакырттылар. Комсомол секретаре Вадим Ильминский акыллы егет иде. Гайбәтнең каян чыкканын сөйләп аңлаткач, рәхәтләнеп көлде дә:

— Бу нәкъ Дурова ысулында. Ул шундый фантазерка инде. Аның үзен чакырып сөйләшергә кирәк. Соңгы вакытта ул еш кына рестораннан исереп кайта дип сөйлиләр, — диде. Бу сүз дөрес иде. Үч ала дип уйлауларыннан куркып, Разия расламады, иптәшенең гөнаһысын яшерде.

Икенче каза да озак көттермәде.

Шимбә көн Разияның өйдән алып килгән ярты капчык бәрәңгесе югалды. Институтка киткәндә бәрәңге караватт астында калган иде, кайтуга — җилләр исә. Разия бу турыда беркемгә әйтмәде. Караватына капланып ятып эче бушаганчы елады. Күз яше аны җиңеләйтеп җибәрде. Ничек тә түзәргә кирәк иде.

Студентларны көненә бер тапкыр талон белән ашаталар иде. Ышаныч шул талонга терәлеп калды. Өйдән алып килгән ашамлык беткән чакларда шул аш, хөкүмәт ашы, киләчәккә өмет биреп, куандырып тора иде.

Март азагында витамин җитмәгәнлектән Разия «тавык күзе» дигән сәер авыруга юлыкты. Бер җире авыртмый югыйсә. Бары тик, кояш бату белән, якын-тирәдәге әйберләр генә тоныкланып китәләр. Күз аларны начар күрә, аера алмый. Бер тапкыр шаяра-көлә институттан кайтып килгәндә, Разия, тротуарда утырган фонарь баганасына бәрелеп, маңгаен тишә язды. Шуннан соң, кичке эңгер житкәч, вакытын гел торакта утырып уздыра башлады. Китап хәрефләрен күз аера иде. «Тавык күзе»нең укуга зыяны тимәде.

Талонга бирелгән кәбестә шулпасы төшенкелеккә бирелүдән саклап тора иде. Шул ашка тиздән сугыш бетә дигән хәбәр җиткергән шатлыклы өмет килеп өстәлде. Яшәү матур һәм рәхәт иде. Алда — институтны тәмамлау. Сәйрин белән кавышу. Шундый бәхетле киләчәк синнән бер генә адымда торганда нинди төшенкелек булсын ди?

Өченче каза көтмәгәндә аяктан егып ташламаган булса, Разия талонга бирелгән аш белән дүртенче курсны тәмамлый иде. Җәйге каникулга кайткач, өйдә бәрәңге, балтырган, суган бар. Теңкәгә тия торган хәлсезлек һәм ахмак авыру — «тавык күзе» атна эчендә юкка чыгачак. Разия пешкән алма шикелле булып кызарып, матурланып китәчәк. Һәм май урталарында Сәйрин дә кайтып төшәр. Соңгы хатында ул: «Тиздән сугыш бетә. Мин ял сорап, синең яныңа кайтам», — дип язган иде. Хатның азагында: «Кавышу белән туй ясыйбыз, әзерләнә башла», — дип өстәгән иде.

Апрельнең егерме икесе көнне Разия керләрен юды. Кер юу җанны тынычландыра. Разия кер уганда җырларга ярата иде. «Сагыну» көен җырлап, акка кызыл борчак төшкән күлмәген уганда, аның кинәт тәне чымырдап китте. Күлмәкне селтәле судан сөйрәп чыгарды. Кулын күлмәк кесәсенә тыкты. Күлмәк кесәсендә калган сигез көнлек аш талоны саклана иде.

Разияның учында укмашып, камырга әйләнеп беткән чикләвек зурлыгы кәгазь ята. Ул аны сүтәргә тырышып карады. Әмма талоннар тәмам җебеп беткәннәр иде.

Исламнурова бу турыда да беркемгә белгертмәде. Соңгы көннәрдә, тараткан гайбәт бернинди нәтиҗә чыгара алмагач, Настя Дурованың каныгуы бермә-бер арткан иде. Аны сөендерәсе килмәде.

Сигез көннән яңа талон бирергә тиешләр. Бер атна һәм тагын бер көн. Адәм баласы айдан артык ач тора ала дип сөйлиләр. Хәтта ач яшәп дәваланучылар да бар. Бу очракта тәннең таза күзәнәкләре авыру тигән күзәнәкләр белән тукланып яши, шунлыктан чир юкка чыга дип сөйлиләр. Разия ябык иде. Бәрәңгесе югалганнан соң ул бик йончып төште. Йокыга китәр алдыннан ул тәнен капшап карый иде. Өстән тире белән тартылган коры кабыргалар. Сөяк һәм сеңер. Яшереп кенә елап ала иде Разия. Сәйриннең бизүеннән курка иде ул. Шушындый билләрне кочаклаудан егет кеше нинди тәм тапсын...

Кер юганнан соң төгәл дүрт көн үткәч, мең тугыз йөз кырык бишенче елның егерме алтынчы апрелендә аш талоны алырга төгәл дүрт көн кала, рус әдәбияты буенча «Бөек пролетар язучысы Максим Горькийның «Клим Самгин тормышы» романында революцион хәрәкәт чагылышы» дигән махсус семинар вакытында Исламнурова Разия аңын югалтып, идәнгә ауды.

Семинар бүленде. Кызны күтәреп алып коридорга чыгардылар да, ясалма сулыш алдырырга тотындылар.

Сәгать ярымнан кызыл хач төшкән машина ашыгып килеп җитте. Машинага утырып килгән яшь врач Разияның пульсын капшап карады, йөрәк тибешен тыңлар өчен изүен чиште. Пульс җитмеш ике. Йөрәк тибә иде. «Господи, — дип уйлады яшь «Әбугалисина», — җир йөзендә җитмеш мең төрле авыру бар. Шуларның кайсысы кереп оялаган бу чибәр кызга?» Студентның күзе Разияның шәрә беләкләренә, аның кибеп беткән күкрәгенә төште. Кызның тәнендә бер чеметем ит юк иде. Мизгел эчендә алты ел ятлаган кагыйдәләр ми сырыннан очып чыгып беттеләр. Адәмдәге иң бөек, шәфкатьлелек атлы даһи тойгы егетнең колагына пышылдады: «Ач йөри бу. Бер минут соңга калмыйча ярдәм итәргә кирәк...»

— Больницага салырга кирәк бу кызны, — диде яшь табип өерелеп карап торган филологларга.

Яшь врач кызгана белүчеләрдән иде, — аның киләчәк пациентлары бәхетле булачаклар.

Разияны «ашыгыч ярдәм» машинасына чыгарып салдылар.

*
* *

Тамак ягын кайгыртуга бәйләнешле вак, әрсез мәшәкатьләрдән берничек тә котылып булмый. Чынбарлыкта хезмәт белән, көн саен эшкә йөреп кенә яшәп була бит. Көндәлек тормышта җан, иман турында кайгыртырга вакыт калмый. Вакыт табылган чакта кәеф башка юнәлешкә борылган була. Мең төрле сәбәпләр урап алган безнең көндәлек тормышны. Җан, иман турында онытуыбыздан акланыр өчен әллә нинди зур планнар корган булабыз, әллә нинди эшкә ашмаслык бөек гамәлләргә кинәнеп карыйбыз. Көндәлек ыгы-зыгы, ташка тамган тамчы шикелле, корган планнарны, өмет багланышларын туктаусыз ашап тора.

Госпитальдә ятканда Максим Майнагашев шушы турыда уйлады. Йокысыз госпиталь төннәре шундый озын иде. Йокысызлыкка ияреп ниндидер авыр тынгысызлык килә. Бу — җанга кирәкле, шифалы тынгысызлык. Ул сине уй-фараз дөньясына алып китә. Шундый мавыктыргыч иде уй дөньясын гизү. Шул чакта үткән гомерне җентекләп күз алдыннан үткәреп җибәрәсең. Аның артта калган өлеше тоташ беркатлылык иде. Шул ук донкихотлык, җил тегермәннәре белән сугышып үткән иде Майнагашевның гомере. Дон-Кихотка очраган тегермәннәр эре булганнар. Максимныкы шундый вак, тотрыксыз иде. Ләкин сугышка кадәр алар зур һәм мәгърур күренгәннәр икән.

Теләкләр үтәлмәгән чакларда, без тизрәк киләчәккә яисә үткән гомер хәрабәләренә качабыз. Ә яшәү киләчәктә дә, үткәндә дә түгел. Үткән гомер үлгән, ул җансыз. Киләчәккә әле җан кереп җитмәгән. Чын яшәү — шушы мизгелдә, безнең шушы сулышыбызда. Ул туктаусыз кими тора. Ә кимүне туктатырга бернинди чара юк. Шушы чарасызлык тизрәк киләчәккә элдертергә, яисә үткән көннәр артына посып юанырга мәҗбүр итә. Госпитальдә чакта менә шушы турыда уйлап ятты Майнагашев.

Госпитальдә ятучыларга посылкалар килеп тора иде. Яшь кызлар, уллары сугышта йөргән чал чәчле аналар, ирләрен фронтка озаткан солдаткалар соңгы сыныкларын, соңгы бөртек малларын яралыларга җибәреп, изгелек эшләргә тырышалар иде. Изгелек эшләү — безнең халыкның канында булса кирәк. Аны без авыр елларда тоябыз.

Чираты җиткәч, Максимга да бер посылка тапшырдылар. Аны Татарстанның Кәрәкәшле дигән авылыннан Рәзинә исемле бер кыз җибәргән иде. Тартма эченә фоторәсем дә салынган. Түгәрәк битле мөлаем бер татар кызы көлемсерәп якут малаена карап тора. Сулъяк бит алмасында ясмык чаклы гына бер миң дә бар. Миң кызның гаилә эшенә чиктән тыш гадел, иренә мәрхәмәтле, балаларына ягымлы булачагы турында әйтергә җыенган шикелле чекрәеп тора. Фоторәсем янына кош теле чаклы гына хат та язып салганнар. «Абый, фашистларны тар-мар итегез. Җиңүне якынайту өчен көн-төн, армый-талмый эшлибез»,— дип язган иде миңле Рәзинә.

Кәрәкәшле кызы фанер такта эченә күпме шатлык, күпме куаныч салып җибәрүен аңлый идеме икән?

Майнагашев бүләкләрне бушатырга кереште. Дулкынландыра. Куллар дерелди. Менә җылы оекбаш. Йомшак, җыйнак итеп бәйләнгән, ап-ак итеп юылган. Нафталин исе аңкып тора. Бәлки, булачак кияү егетенә дип, җылы өмет белән бәйләнгән оекбаштыр бу? Сырлап бәйләнгән ак перчатка. Тап-таман, кигәч куллар рәхәтләнеп китте. Балга катырган бавырсак, без аны, гадәттә, туй ашы дип йөртәбез. Ә борынгылар бавырсакны ияр капчыгына салып сугыш кырына алып китә торган булганнар. Җиңел, татлы, бәрәкәтле һәм озак искерми торган затлы ашамлык. Бавырсак исенә ияреп Татарстан туфрагының тыны, аның татлы сулышы килеп бәрелде. Максимның күзеннән яшь тәгәрәп төште. «Кызый, син мине бурычлы иттең. Бу игелегеңне нинди юл белән кайтара алырмын икән?»

Тартма төбенә Кәрәкәшле кызы Лев Толстойның «Хаҗи Морат» исемле китабын да салган иде.

Максим ихтыярсыз сагышка тыгылып бавырсак ашады. Оекбаш белән перчатканы мендәре астына салып куйгач, «Хаҗи Морат»ны укырга кереште.

Шул китапны Майнагашев рәттән дүрт кат укып чыкты.

«Тукта әле, — дип уйлады ул беренче тапкыр укыганнан соң. — Китап язган кеше — граф, бай алпавыт, Кавказ сугышында катнашкан рус офицеры. Нилектән ул менә шушылай итеп яза алган?..»

Бу китаптан ул яңа бер фикерне аңлау дәрәҗәсенә иреште. Җир йөзендә хакыйкать дигән кодрәтле көч бар. Һәм шул көчкә һәр чорда яла ягалар, таптыйлар, сөрәләр. Хакыйкать өчен көрәшүчеләрнең битләренә төкерәләр. Күпчелек шуңа күнә, ышана. Фаш итүчеләр җиңдек дип куаналар. Ә хакыйкать яши. Аңа миллионнан бер кешенең вөҗданына кереп калу, урнашу җитә. Һәм шул, хакыйкать тәмен татып караган шәхес, ялган ягулар, михнәтләр, ачлыклар аша үтеп хакыйкатьне киләчәк буынга тапшыра килә. Бер мәртәбә хакыйкать тәмен татыган кешегә дөреслектән тыш шатлык та, куаныч та юк. Ул ансыз яши алмый. Көн күрүгә санамый ул хакыйкатьсез яшәүне.

«Ә нигә кирәк соң ул хакыйкать?» — дип уйлавын дәвам итте Майнагашев, йокысыз төннәрдә. Һәм бу сорауга да ул янача җавап тапты.

Галәмнең иминлеге, аның дәвам итүе хакыйкатькә нигезләнгән. Хакыйкать яшәү — исән калу кануны. Һәр молекула, һәр үлән бөртеге, хәтта бушлык шушы кагыйдә нигезендә генә саклана ала. Әйтик, хакыйкать нигезендә кыштан соң яз һәм җәй килергә тиеш. Табигать, ялганлап, җәй урынына көз китерде, ди. Шытып чыккан үләннәр, бөреләрдә ярылган агачлар һәм кышкы йокыдан уянган бөҗәкләр бер көн эчендә кырылып бетәчәкләр. Бозаулар, сарык бәтиләре, колыннар туңып үләчәк. Табигатьнең бердәнбер ялганы җир йөзен шыксыз туфракка әйләндерәчәк.

Без, адәми затлар, вакытлы файда өчен, иркен торак, күбрәк акча, дан өчен күпме күз буяу, күпме ялган тудырабыз. Лев Толстой әнә кешелек дөньясына искиткеч зур зыян китерә торган ялганга каршы көрәшкә чыккан. Ул шул ягы белән бөек. Ә рус халкы — Толстой кебек әдип тудыруы белән бөек.

Максим Майнагашев госпитальдән шушы фикерләргә баеп чыкты. Аның өчен госпиталь Әбугалисинага акыл һәм белем биргән мәгарә шикелле булды.

*

* *

Рәхәт яши башладылар эскадрилья офицерлары. Казарманы чиста итеп җыештырып торалар. Торак иркен. Җиһазлар затлы. Тыныч. Шушындый шартлар кешене җыйнаклыкка, тормыш культурасына өйрәтә. Йокыдан торгач, кагыйдәгә буйсынудан гына түгел, үзең теләп урын җыя башлыйсың.

Ләкин, нинди генә шартларда да, казарманың бер үзенчәлекле ягы бар. Аны берничек тә бетереп һәм үзгәртеп булмый. Бу — казарманың үзе белән генә бетә торган даими үзгәлек.

Казарманың ишеген ачу белән борынга ирләр исе килеп бәрелә. Мылтык мае, каеш һәм тәмәке исләре бергә кушылганда барлыкка килә торган катлаулы ис. Аны хлорлы известь белән ышкып юып та, чиләкләп хушбуй коеп та бетереп булмый. Бу — хатын-кызсыз яшәгәндә барлыкка килә торган торак исе. Күмәк ялгызлык, сагыну исе бу.

Сәйрин йокыдан уянганда аның борынына шушы ис килеп бәрелде. Караңгы иде әле. Сәләхов, кулын сузып, кичтән тумбочка өстенә куеп калдырган сәгатен алды. Төнге бер иде. «Нишләп болай иртә уяндым икән?» — дип уйлады ул һәм тәрәзәдән карап торган тулган айны күреп алды. — Ай тулган чак икән».

Кичә, йокларга яту белән, аның янына лейтенант Кононенко килеп утырды. Характеристика сорарга килгән иде. «Заданиедән әйләнеп кайткач язып бирермен, нигә ашыгасың?» — диде Сәләхов. Летчик Кононенко ашыгуның сәбәбен ачып салды. «Калган эшкә кар ява, — диде ул. — Сугыш бит. Иртәгә нәрсә булуын алдан кем әйтә ала? Бүген мин командирларның квалификациясен күтәрү курсына ике разнарядка килүен белдем. Рапортны бүген тапшырырга кирәк. Миннән алда башка офицерларның тапшырып өлгерүләре бар». «Нигә кирәк ул сиңа квалификация күтәрү?» — дип сорады Сәләхов кызыксынып. «Икенче эскадрильяда каласым килми минем. Монда перспектива юк. Растопчинны югары күтәрмәячәкләр. Ул отставкага чыкканчы комэск булып калачак. Әгәр ул күтәрелсә, комэск ярдәмчесе Бондаренконы аның урынына, сезне Бондаренко урынына, мине сезнең урынга куярлар иде. Ә болай бернинди үсү булмаячак. Квалификация күтәрү курсыннан кайту белән звено командиры итеп билгеләячәкләр. Приказда шулай әйтелгән».

Сәйрин Кононенкога характеристика язып бирде. Мактап язды, чөнки аның эшендә кимчелекләр юк иде. «Генерал булырга теләмәгән солдат начар солдат» дигән әйтем дә бар хәрбиләр арасында.

Янәшә караватта изрәп Майнагашев йоклый. Чәче бөселеп мангаена төшкән. Иреннәре йомык. Йөзендә сабыйлар йөзендә генә була торган керсез елмаю. Сулыш алганда егетнең борын тишекләре киңәеп китә. Максим төш күреп ята иде шикелле.

«Моңа бер тамчы да тормыш кере йокмаган»,— дип уйлады Сәләхов. Сабыйлыгы бер мыскалга кимемичә сакланган. Очарга әзерләнеп йөргәндә, һавада бомба ташлаганда, Максим шундый өлкән, житди булып күренә иде. Алар, чыннан да, искиткеч җаваплы эш башкаралар. Дөресен әйткәндә, сугышта җавапсыз эш юк. Очучы булып, һавада сугышып йөрү аеруча житди һәм чиктән тыш катлаулы хезмәт. Шушындый житди, өлкән егетләр, хәрби киемнәрен салып ташлау белән, бала гына булып калалар.

Сугыш Сәйриннәр буынын колакларыннан тартып үстерде, ашыктырып өлкәннәр сафына кертте. Алар үсмерлек чоры тәмен татый да алмый калдылар. Яшәү чорының иң тылсымлы, татлы чагы аларны читтән урап узды. Германиягә фашизм килгән елны мәктәпкә йөри башлаган малайлар үсмерлек аша атлап өлкәннәр рәтенә үттеләр. Хәзер алар кулында ил язмышы.

Житдилек өчен киелгән битлек белән йөрү шактый авыр иде аларга. Яшәүнең тулы бер чоры бөтенләй төшеп калды. Үсмер чакка хас дуамаллыклар эшләү, ялгышулар кирәк икән ул. Шул ялгышлыкларны төзәтү дәверендә чын, табигый житдилеккә өйрәнсәң икән. Адәм баласы яшәү дәвереннең һәр чорын үз вакытында үтәргә тиеш. Балачакның татлы назлары, үсмер вакытның ваемсызлыгы, аның мөлаем гыйсьяннары — барысы да кешe булырга өйрәнү өчен кирәк икән. Адәми зат дигән бөек исемне күтәреп йөрү өчен шундый житди өйрәнүләр, сугышта күргән катгый сынаулар аша үтәргә кирәк икән. Һөнәр үзләштергәнче, җәмгыятьтәге урыныңны яулап алганчы иң башта чын кеше, чын шәхес булырга өйрәнергә кирәк икән.

Сугышчан заданиегә оча башлагач, тагын бер хакыйкатьне аңлады Сәләхов. Парашютны киеп, кабинага кереп утыру белән дөнья ваклыклары әллә кая китеп онытыла. Егетләрнең бер генә сыйфатлары кала — алар очучылар, синең коралдашларың. Алар да үлем белән нәкъ синең шикелле качышлы уйнаучылар. Ир-егет өчен коралдашлыктан да бөек тойгы юктыр да, бәлки.

Фронттагы еллар дәверендә Сәйриннең күп кенә дуслары заданиегә очкан җирдән әйләнеп кайтмадылар. Очучының кире кайтмавына тиз генә күнегә алмыйсың. Аның егылып төшкәне, җан биргәне сиңа күренми, шуңа күрә әзме-күпме өмет кала. Өмет кала, ә заданиегә киткән дустың һаман юк. Сугыш чынбарлыгы исраф иткән дусларны башка берни алмаштыра алмый. Кайтмый калган дусларның көннән-көн күбәя баруы, шушы югалтулар, иптәшләреңне яратырга, дуслыкның кадерен белергә өйрәтә дә инде. Йөрәгеңдә дуслык тойгысы булмаганда яшәү заяга уза. Сәйрин коралдашларының кимчелекләрен күрмәскә, аңа әһәмият бирмәскә өйрәнде. Аларның һәрберсендә уңай сыйфатлар да житәрлек иде.

Сәләхов йоклап яткан дусларына тагын бер мәртәбә күз салып алды. Алар шундый кадерле, шундый газиз иделәр.

Тиздән сугыш бетәчәк. Авылга кайтыргамы, армиядә калыргамы дигән сорауга хәзер үк җавап әзерләп куярга кирәк. Сәйрин үзенә дә, халкына да йөз кызыллыгы китермәслек итеп сугышты. Аның абруе житәрлек, ләкин ул, мөмкинлек чыгу белән, авылына кайтып китәчәк. Сәләховның нигәдер авылына кайтасы килә. Армиядә калып, тыныч вакытта хезмәт итү отышлырак та булыр иде югыйсә.

Соңгы көннәрдә Сәләхов бәхет турында ешрак уйлый. Сугышның тиздән бетәчәге беленгәч, сугышчылар киләчәк турында кайгырта башладылар. Без туктаусыз бәхет күтәргә өйрәнгәнбез. Туклык белән генә канәгать түгел без. Нигәдер бәхетле дә буласыбыз килә.

«Юкка баш ватмаска кирәк әле, — диде ул уйларыннан арынырга теләп.— Җитте. Исәпләп ятудан ни файда?» — Ләкин уй-исәпләр һаман аның күңеленә килеп тора иде. — «Минем звенода егерме тугыз сугышчы, — дип дәвам итте Сәйрин, — сугыш беткәч алар өйләренә таралырлар. Ун елдан кемнәр кайда булыр икән? Кызганычка каршы, сугыш бетеп җитмәгән әле. «Егерме тугыз» дип санау дөрес булып бетмәс. Тукта. Җитте. Йокларга кирәк».

*

* *

Разияның хәлен белергә больницага институтның комсомол секретаре Вадим Ильминский килгән иде. Аңа Разияның бүлмәдәш кызлары ияргәннәр.

— Раечка, күз нурым, талон югалтуыңны нигә миңа әйтмәдең? — дип, ишектән керү белән, Маша Козлова аны кочаклап алды. Ярмәкәева татар кызларына хас кыюсызлык белән яңа мохитка ияләшергә тырышып, як-ягына каранып тора иде.

— Чын дуслар алай кыланмыйлар, — диде күнегә төшкәч. — Белгерткән булсаң, ярдәм итмәс идекмени?

Акыллы кызларның төшенә керердәй чамасыз чибәр егет Вадим Ильминский, башын селкеп, елмая-елмая:

— Ну и ну-у,— диде, караватъ янындагы урындыкка җайлап урнашып. — Мондый фортельны көтмәгән идек без синнән, Исламнурова.

Дусларының килүенә Разия чын күңелдән шатлана иде. Алар кергәч, палата яктырып киткәндәй булды. Авыру булуын, гемоглобин җитмәвен, тәнендә витамин юклыгын мизгел эчендә онытып ташлады. Уен-көлке, шаярулар башланды. Авыруларның күңелен күтәрү өчен оештырылган ясалма шатлык түгел, чын, табигый шатлык, яшьлек шаукымы килеп керде студентларга ияреп. Хәтта авыру хатыннар торып утырдылар. Аларның да йөзләренә болыт артыннан караган кояшка охшашлы елмаю чыкты.

Вадим Ильминский соңгы көннәрдә булган хәлләр турында сөйләргә кереште:

— Май бәйрәменә әзерләнү башланды бит. Бүген институт ишегалдын җыештырып чыктык. Без ишегалды себерәбез. Сезнең курстагы атка охшашлы бер таза егет баганага сөялгән дә, борынын чокып, тик карап тора. Янына килдем. «Син нәрсә эшли беләсең?» — дип сорадым. «Урам себерә беләм», — ди. «Тагын нәрсә эшли беләсең?» — дим. «Себермәскә дә булдыра алам»,— ди зур горурлык белән.

Институт яңалыкларына керештеләр. Шеф саналган хәрби училище курсантлары узган кичне институтка килеп, кичә оештырып киткәннәр. Настя Дурова үзеннән егерме яшь өлкән бер майорга кияүгә чыгарга әзерләнеп йөри ди. «Аның әзерләнүләре шактый еш була», — дип эчтән генә көлемсерәп куйды Разия. Киләсе елга чыгарылыш имтиханына электәгечә дәүләт имтиханы һәм диплом эше кермәячәк икән. Хәзер студент, үз теләге белән, шуларның кайсын булса да берсен генә сайлап ала икән.

Өч тәүлек эчендә бер өем үзгәреш туып өлгергән иде. Шушы берберартлы ябырылып килеп торган үзгәрешләргә карап, Разия студент тормышының гаҗәп бай һәм эчтәлекле икәнлеген аңлады.

Нәрсә турында сөйләшә башласаң да, әңгәмә сугыш бетү турын-

дагы куанычка әйләнеп кайта иде. Тиздән — тынычлык. Кулыңны гына суз, аны инде үрелеп тотарлык. Алда зур үзгәрешләр булачак.

Сөйләшеп утырган арада ике сәгатьләп вакыт узганын сизми дә калдылар. Больницага керү вакыты тәмамланган иде. Разияның иптәшләре җыена башладылар. Ярмәкаева белән Козлова коридорга чыккач, Ильминский, ымлап, Разияны палатаның аулаграк җиренә, тәрәзә янына чакырды:

— Исламнурова, синең чемоданыңда ике кило он булуы дөресме?— дип сорады ул капыл гына.

Разия каушап калды. Нигә бу турыда сорыйлар икән? Аның чемоданындагы әйберләргә кемнең катнашы бар? Ул кызарынды һәм, җавапны озакка сузарга ярамаганын сизеп, әйтте:

— Дөрес. Бар. Нигә ул сезгә?

Алар комсомол секретаре белән бер-берсенә мәгънәле итеп карашып алдылар. Секретарьның кашы җимерелгән иде.

— Оның булгач, аяктан егылганчы нигә ач йөрдең соң, Исламнурова? Моның бер төрле сере булырга тиеш. — Ильминский текәлеп Разияның күзенә карады. Күзен дә йоммады Разия.

«Настя бу турыда да гайбәт таратып өлгергән икән, — дип уйлады ул. — Сөйгән егетең кайтуга коймак пешерәсе онны саклап тотуның ни гаебе бар икән?» Ләкин бу турыда сөйлисе, белгертәсе килми иде. Бу — аның тирән яшереп, саклап йөрткән интим сере иде. Үзенә генә мәгълүм куанычлы сюрприз иде. Сөйгән ярына коймак пешереп ашату, үбешү кебек үк, кеше күзеннән, аларның кызыксынуыннан яшерен булырга тиеш иде. Кеше сере белән кызыксынуны Разия зур тупаслыкка, әдәпсезлеккә саный иде. Ул ялганларга ниятләде. Ялганлау да авыр иде. Тел буйсынмый. Җан карыша. Аның тәненә салкын тир бәреп чыкты. «Мин аны оныткан идем» дигән әзер аклануны ул комсомол секретарена әйтергә теләде — теле әйләнмәде. Ялган сөйләргә күнекмәгән иде ул, тәҗрибәсе юк иде.

Шәфкать туташы ишекне ачып карады. Кыз белән егетнең бер-берсенә текәлеп тәрәзә янында басып торуларын күргәч, йомшарды:

— Аерылышыр вакыт, — диде ул. — Калган сүзләрегезне киләсе очрашуда әйтеп бетерерсез.

— Он саклап ач йөрүнең сере булырга тиеш. Больницага кермәгән булсагыз, сүз булыр идемени? Сез бит, Исламнурова, комитет әгъзасы, стипендиат, башкаларга үрнәк студентка. Яшьләр арасында сезнең ураза тотуыгыз турында сүз йөри. Дөресме ул?

— Ялган! — дип кычкырды Разия үзе дә сизмәстән. Авырулар, башларын күтәреп, кызга таба борылдылар. — Миңа Дурованың гайбәтен алып килгәнсез. Хәзер үк чыгып китегез!

Ильминский бер сүзсез ишеккә таба юнәлде. Бераздан ишектә Ярмәкаеваның башы күренде:

— Кертмиләр,— диде ул елар хәлгә житеп. — Чык әле бер генә минутка.

Разия коридорга чыкты. Эльвира аны җиңеннән эләктереп алды:

— Ильминский барында сөйләргә базмадым. Сине ураза тота икән дип институтта сөйләп йөриләр. Дурова тараткан. Мин аңлатып карадым. Ураза тотканда иртә-кич, караңгы чакта, ашарга ярый, дидем. Рамазан ае быел кыш урталарында гына килә дип карадым. Аңларга теләмиләр. Мин ашыгам. Алар мине көтеп торалар. Туалетка керәм, дип кенә киттем. Бу серне әйтүемне белмәскә тиешләр. Больницадан чыккач, сине бюрога чакырып, персональ эшеңне карарга тиешләр.

— Кирәкми, Эльвира, яклама мине, — диде Разия күз яшенә тыгылып. — Үзеңә авырлык килер. Барыбер аңлата алмассың.

Ярмәкаева күзен сөртте:

— Сау бул, Разия. Тизрәк терел. Мин киттем.

Ялгыз калгач, Разия коридор очындагы ташландык өстәлләр өеме артына барып утырды. Яшәү шундый катлаулы. Тормыш агымына акыл, логика бөтенләй катнашмый диярлек. Яшәү кануннары ниндидер шаблон җайланышка көйләнгәннәр. Моңа кадәр ул отличник саналып йөри иде. Аны шушы көнгә кадәр үрнәк итеп куялар иде. Укуын, үз-үзен тотышын һәм җәмәгать эшенә катнашуын башкаларга өлге итеп күрсәтәләр иде. Хәзер, гайбәттән соң, аның һәр адымыннан гаеп таба башлаячаклар. Абруе төшкән кешенең уңай якларын күрми башлыйлар. Күрсәләр дә әһәмият бирмиләр. Ә моңа кадәр аның кимчелекләрен искәрмиләр иде. Кайчакта, сынау вакытында сорауларга ул башка студентларга караганда шактый сүлпән җавап бирә иде. Андый вакытта барыбер «бишле» билгесе куялар. Чөнки укытучылар аның отличница булуына тәмам инанганнар. Отличницаның җавабы начар булыр дип уйлап та карамыйлар иде. Менә шушындый җайланыш хөкем итә тормышта. Шул җайланыш хәзер Разияның һәр эшен, һәр гамәлен начар якка әйләндереп торачак. Дингә ышанып, ураза тотып йөргән кыздан нинди үрнәк эш көтеп булсын ди.

«Шуларга үч итеп бүгеннән ураза тота башларга кирәк!» — дип ачу белән уйлады Разия һәм шундук үзенең ялгышуын аңлап алды. «Кемнәргә?» Настя Дуровадан тыш үзенә дошман кешене белми иде ул. Киресенчә, һәр очракта, кирәкме-юкмы, хәтта, җае юк чакларда да аңа һәрвакыт яхшылык эшләргә, игелек күрсәтергә тырышалар. Менә әле дә, әгәр Разия чемоданда сакланган онның серен комсомол секретарена ачкан булса, Вадим Ильминский елмаеп бармак янар иде дә, шуның белән бетәр иде. Юк, ул дөрес эшләде. Нигә акланырга.

— Инде ярты сәгать эзлим, — диде Евдокия Семеновна өстәлләр арасыннан үтеп,— кичке ашка соңга каласың, Раечка. Ашханәне җыештыра башладылар. Тизрәк йөгер. Палатага да кереп торма. Бүген кичкелеккә солы боткасы бирделәр.

— Рәхмәт, Евдокия Семеновна,— диде Разия.— Зур рәхмәт сезгә, мине эзләп мәшәкатьләнүегез өчен. Минем ашыйсым килми.

Карчык, тораташ булып, катып калды. Аның бу сүзне сугыш башланганнан бирле ишеткәне юк иде әле.

*
* *

Ай һаман тәрәзәдән карап тора иде. Аның дымлы һәм сүрән нурлары тигән урын юешләнгән шикелле булып салкынаеп китә.

Ай Сәләховның җене, газабы иде. Ай тулган көннәрне аны йокысызлык интектерә иде. Бер сәбәпсез күңел сына, кәеф кырыла. Дөнья шыксызлана, тәндә ниндидер авыр тынгысызлык уяна. Яшәү тиктомалдан газаплы тоела башлый. Мондый чакларда беркемне күрәсең килми, хәтта яраткан дусларыңнан гарык буласың. Аның өчен шундый газаплы иде ай тулган чакны үткәрү.

Сәйрин урыныннан торды. Тәрәзә янына барып, пәрдәне төзәтте. Ай яктысы тукыма аша үтеп керә иде. Тынычланыр өчен Сәләхов коридорга чыгып, бер тын йөреп керде. Йокы качкан иде инде.

Армиягә киткәнче дә ай тулуга бәйләнешле тынгысызлыклар булгалады. Ул чакта Сәләхов әчке сыкрануның ай тулуга бәйле икәнен белми иде әле. Бу турыда аңа Ялчинский аңлатты.

«Ай өянәге белән авыручы төннәрен урыныннан торып, йорт түбәләренә, агач башларына менеп йөри икән, — диде ул. Алар арасында, хәтта, телеграф чыбыгына басып йөри алучылар була, дип сөйлиләр. Әгәр андый кешене биеклектә йөргәндә йокыдан уятсаң, куркудан егылып төшеп, үлә икән, дип сөйлиләр. Фән аны борынгы инстинктларга бәйләп аңлата».

Шушы сүзләрдән соң Сәйрин үзенең башыннан узган берничә сәер вакыйганы искә төшерде. Бер мәртәбә алар этисе белән төн куна утынга барганнар иде. Урманның бер аулак аланына туктап, атны туардылар да, тышаулап, үлән утларга җибәрделәр. Үзләре, урын җәеп, арба астына кереп яттылар.

Төнге урман гаҗәп шомлы була. Якында гына нәрсәдер кыштырдый. Арба тирәсендә ниндидер утлы бөҗәкләр кыймылдап йөри. Кайдадыр, буылып, төлке өрә. Шулкадәр сәер икән ул төлке өрүе. Әйтерсең аны бугазыннан кысып тотканнар, үтерергә азапланалар. Сак-сокка охшатып, ниндидер кош кычкыра. Еракта шомлы итеп мәче башлы ябалак елый. Шул тавышларны тыңлап, Сәйрин йокыга китә алмый ятты.

Таң алдыннан ул урыныннан торган, арба астыннан чыгып, агачлык эченә кереп киткән. Шундый караңгылыкта, куе урман эченнән, чакрымнан артык җир барган. Юлында очраган агачларга бәрелмичә ул нечкәтер урап үткән. Упкын өстенә сузылып үскән кәкре каенга үрмәләп менеп азапланганда, этисе аны күлмәк итәгеннән эләктереп алган иде.

Икенче тапкыр шундый хәл сугыш чыккан елны кабатланды. Ул чакта Сәйрин иптәшендә куна калган иде. Төз лапас түбәсенә менеп яткач, иртә уятмасыннар өчен, баскычны тибеп аударсылар. Монда шундый аулак иде. Алар төн урталарына кадәр йолдызларга карап хыялланып яттылар.

Малайлар йокыга киткәч ай калыккан. Сәйрин, урыныннан торып, лапас түбәсеннән төшкән, авыл буйлап сәяхәткә чыгып киткән. Кайларда йөрүен һәм нәрсә эшләвен ул хәтерли алмады. Авылның икенче очында яшәүче бер тиле карчыкның ишегең шакып азапланганда, Сәйрин йокыдан уянып китте. Бу куркыныч йорт иде. Аны балалар гына түгел, хәтта көндез өлкән кешеләр дә ерактан урап узалар иде.

Соңыннан, никадәр тырышып караса да, Сәләхов дүрт метрлы лапас түбәсеннән ничек төшүен, ике чакрым араны ничек үтүен, авылның икенче урамына нинди максат белән килеп чыгуын хәтерли алмады. Тиле карчыкның баскычына менеп, ишек шакый башлаганчы ул тирән йокыда булган. Бусы шиксез иде.

Аның газаплары, куркыныч маҗаралары ай тулган чакта була иде. «Нинди генә могҗизалар юк бу дөньяда, — дип уйлады ул. — Аңларга, ачыкларга көч җитмәгән хәлне без тизрәк инкяр итәргә ашыгабыз. Бәлки айның кешегә берәр төрле тәэсире бардыр? Ай тулган чакта диңгезләрнең суы күтәрелә. Кайвакыт этләр айга карап бер сәбәпсез өрергә тотыналар. Айдагы үзгәрешләрне бәлки безнең кан сизеп торадыр, яисә тулган ай нервларга тәэсир итәдер?»

Сәйрин тиз генә йокыга китә алмаячагын аңлады.

*

* *

Сәләхов урыныннан торды. Шинелен җилкәсенә салып коридорга чыкты.

Ишек кырындагы өстәлгә маңгаен терәп дневальный утыра. Хат укыган җиреннән йокымсырап киткән. Төн уртасыннан соң электр утын сүндерәләр иде. Өстәлдәге коптилканың мае беткән күрәсең, филтәсеннән сасы кара төтен күтәрелә.

Аяк тавышына дневальный сискәнеп уянды.

— Йоклап булмыймыни, иптәш өлкән лейтенант? — дип сорады дневальный. Ул Сәләхов звеносына беркетелгән кече сержант Ильин иде. Коралчы булып хезмәт итә иде ул. Сугышка кадәр Гжельдәге фарфор заводында рәссам булып эшләгән егет. Сәйрин ярата иде Ильинны. Помшаклыгы, җыйнак һәм гадел яшәве өчен ярата иде ул аны. Кече сержант Ильин командирына ихтирам белән карый иде.

— Һава сулыйсы килә. Тынчу, — диде ул дневальныйга.

— Сезнең экипажны дүртенче яртыда уятырга куштылар. Өч сәгать вакыт калды. Йокларга була әле. Йокыдан үлүче юк диләр. Рәхәтләнеп калыгыз, иптәш өлкән лейтенант.

Сәйриннең дикъкате «калыгыз» сүзенә тукталды. «Нишләп бүген генә йоклап «калырга» булсын? Сугыш тукталырга тора. Яшәү дәвам итәчәк. Тыныч, татлы йокы бирәчәк көннәр алда шул кадәр күп. Сугышчан заданиене үтәп кайткач, башта «боевой ике йөз грамм»ны куячаклар. Гадәттәгечә, Сәйрин аннан баш тартачак. Тагын өчесенә дә бер тәүлек ял бирерләр. Менә шул ялда, Майнагашев белән Ялчинскийны ияртеп, Сәләхов урманга барачак. Урманда йөреп, арып кайткач, майга салган шикелле эреп йокларга була. Туйганчы йоклыйсы көннәре күп әле аның. Киләчәктә Сәйринне тәмле йокы һәм рәхәт тормыш көтә. Тынгысыз төннәрнең соңгысыдыр бу, бәлки?

Ильинның сөйләшәсе килә иде. Сәләховны яныннан җибәрәсе килмичә, ул берничә тапкыр сүз кузгатып карады. Файдасы тимәде. Сәйрин коридор аша ишегалдына саф һава суларга дип чыгып китте.

*

* *

Җиргә караңгылык иңгәндә ялгызлык аеруча ачы тоела. Төн — кешеләрнең берләшү, бер-берсенә якынаю вакыты. Әллә караңгылыктан куркып, әллә көн эшләп арыганга күрә, төн килгәч, адәм балаларының бер-берсенә сыенасылары килә. Караңгы төшү — сөйгән ярларның кавышу вакыты ул. Караңгылык җир йөзенә мәрхәмәтлек алып килә. Төн сугыш калдырып киткән җәрәхәтләрне каплый. Җимерелгән йортлар, киселеп ауган агачлар, тар-мар ителгән язмышлар вакытлыча күздән югалалар. Җир йөзен йомшак, тигез караңгылык каплап китә. Күз күрмәгәндә җан алай ук сыкранмый. Караңгы төн яралы сугышчыларга, сугышта ата-аналарын югалткан балаларга ял һәм өмет алып килә. Төн — тәүлекнең мәрхәмәтле чагы.

Сәйрин җир йөзенә караңгылык иңгәндә ялгыз калган иде. Ул өч ел инде кавышу көтә. Сөйгән яры еракта калды. Һәр төнне аның янына ялгызлык килеп ята да таң атканчы китми. Көн тугач, ялгызлыктан дуслар коткара.

Сәләхов, тезен кочаклап, салкынча таш баскычта утыра иде. Адәм балалары йокы куенында. Җир йоклый, үсемлекләр, җәнлек балалары, таулар, елгалар, һавадагы йомшак болытлар йоклый. Йөнтәс болан бозаулары йокыга талганнар. Шулар белән бергә — якут малае Максим Майнагашев. Ул төш күреп ята иде.

...Имеш, җир шары зур болан икән. Таулар аның сырты, урманнар аның йоны, күлләр — күзе. Ташлар очыртып дулаган давыл аның тын алуы икән. Болан нигәдер ыңгыраша. Мескеннең тәне авырта торгандыр? Аның тәнен тоташ җәрәхәт каплаган. Аны самолетлардан бомба ташлап, туп атып җәрәхәтлиләр...

Бу төнне күк йөзендә кара болытлар йөзә иде. Алар әкрен генә көнчыгышка, Максимның һәм Сәйриннең туган җиренә таба агылалар. Болыт арасыннан тулган ай килеп чыкты. Салкынча авыр нурлар Максимның битенә килеп бәрелделәр. Майнагашевның йөзе борынгы төрки кабиләләрдән калган таш сыннарныкына охшаш иде. Нәкъ шушындый битле сыннар Гоби чүленнән алып Карпат тауларына кадәр таралган ялгыз курганнар өстендә киләчәк гасырларга карап моңаеп утыралар. Аларның күзләре чиксезлеккә төбәлгән. Йөзләрендә илаһи тынычлык. Өмет тә, өметсезлек тә юк аларның күз карашында. Мал, дан, өстенлек күптән татып каралган. Мал да, дан да, өстенлек тә бәхет

китерми. Аларның берсе дә мәңгелек түгел. Бер генә нәрсә дә адәм баласына мәңгелеккә бирелмәгән.

Шул сыннарның берсе — Майнагашевның гасырлар артында югалган бабасы булырга тиеш. Нишләп якутлар чәчәкләргә күмелеп яткан жылы далаларны ташлап, жир шарының иң кырыс, иң салкын төбәгенә күчеп киткәннәр икән? Әгәр шул таш сыннарны тергезеп булса, алар барсын да сөйләрләр иде. Хәзер инде таш сыннар бетеп бара.

Тышта моңлы яз сулышы. Чык төшкән. Юрган астында жылы, рәхәт иде. Өч сәгатьтән Максимны уятачаклар. Лейтенант Майнагашев сугышчан задание үтәргә китәчәк. Күктә очып бару һәм бомбага тотасы объектны эзләп табу өчен көч, үткен акыл һәм зур түземлек кирәк. Максим йоклый, көч, акыл, түземлек туплый.

...Майнагашевның төше әкренләп болан көтүенә әверелде. Тундраны бер офыктан икенче офыкка кадәр зур көтү каплаган имеш. Боланнар ботаклы мөгезләрен сыртларына салып, тауга төшеп килгән кайнар кояшка таба чабып баралар. Аларны куып житеп, туктатырга кирәк. Имеш, армия штабыннан килгән фәрман шундый. Туктатырга һәм штаб каршысына китереп сафка тезәргә.

...Максим болан көтүе артыннан йөгерә. Боланнар һаман чабалар. Өлгереп булмый. Куып житеп туктатмасаң, хайваннар офык читенә таянган кояшка утырып башка планетага китәчәкләр, имеш. Ничек кенә булса да туктатырга кирәк... Офык читеннән кара самолет күтәрелеп китте. Канатларында фашист тәресе. Эре калибрлы пулемет атарга тотынды. Максимның йөрәген курку авырттырып кысты. Ул йокыдан уянды.

Лейтенант Майнагашев офицерлар казармасында йоклап ята иде. Кемдер тәмле итеп гырлый. Мышнаган тавышлар ишетелә. Йокларга, ял итәргә кирәк. Алда — жаваплы задание.

*
* *

— Безнең гаскәрләр Берлинны чолгап алганнар!

Евдокия Семеновна палата уртасында басып тора иде. Күзләре киң итеп ачылган. Еш-еш сулыш ала. Чал кергән соргылт чәче маңгаена бөселеп төшкән.

— Раечка, нишләп ятасың? Безнең гаскәрләр Германиянең башкаласы Берлинны чорнап алганнар. Моннан ярты гына минут элек радиодан әйттеләр. Господи! — карчык мыш-мыш еларга тотынды.

Разия Сәйрин турында уйлый иде.

Сәйриннең хаты аның кулында. Евдокия Семеновна күрми. Хат юрган астында, кызның күкрәгендә иде.

Евдокия Семеновнаның шатлыгы бер урында торырга ирек бирмичә, аны каядыр әйди, куа иде. Карчык йөгерә-атлый ишектән чыгып китте. Ялгыз калгач, «Сәйриннең хатындагы сүзләр дөрес икән, — дип уйлады Разия. — Берлинны да чорнаганнар. Ә мин әле больницада ятам. Бүген үк чыгарга кирәк».

Алар Казан аэропортында кавышачаклар. Очучы, өлкән лейтенант Сәләхов гади солдат шикелле поездга утырып йөрмәячәк. Туган жиренә аны самолет белән кайтарачаклар. Герой офицерның өстендә елкылдап торган күн куртка, галифе чалбар, ялтыравыклы хром итек һәм башында алтын путалы очучылар фуражкасы. Алар күзләрен ала алмыйча бер-берсенә карап торалар.

— Әйдә, кайтабыз, — ди аңа Разия һәм интеллигент хатыннарыча Сәйринне үзе култыклап ала һәм алар такси янына киләләр. Моңа кадәр аның таксига утырганы юк иде әле. Ул гомер буе гел таксига утырып йөргән кеше шикелле кыланачак.

Фронттан самолет алырга килүче офицерлар Настяны тулай торакка таксига утыртып китерәләр иде. Җиңел машинага утырып кайтуына Дурова чиксез горурлана иде. Кыз, очып тулай торакка килеп керә, тәрәзәне ачып ташлый, китерүче егеткә кул болгый. Настя нәрсә тапкыр, үзенә иярергә теләп, Разияны кыстап карады, ялынды, ялварды, үгеләп, мәсхәрә итеп, көлеп карады. Күнмәде Разия. Ул сөйгән яры кайтканчы беркая йөрмәскә сүз биргән иде. Кыз бәйрәмнәрне, күңел ачуларны Сәйрин кайтуына саклый иде. Гомерендә беренче мәртәбә аңа ияреп танцыга барачак. Аның терсәгенә тотынып, бер аяктан атлап, оялмыйча, гәүдәсенә сырышып барачак. Беренче мәртәбә аның белән таксига утырачак. Беренче мәртәбә ресторанга... Бу сүз аны нигәдер куркыта иде. Шул бинага керү Разияга ничектер җинаять тоела. Ул йортка бары тик азгын кешеләр, мәхәббәт һәм намус белән алыш-биреш итүчеләр генә йөри кебек тоела иде. Бу фикернең тулысынча дөрес түгел икәнлеген аңлый иде Разия. Ләкин, никадәр тырышса да, шушы ышануыннан арына алмады. Сәйрин теләсә, ул ресторанга да барачак. Аның белән бергә булганда Разия беркемнән, бернәрсәдән курыкмый иде. Аның үзе белән бергә. «Үзе» сүзен ул татар хатыннары шикелле тантаналы тирән мәгънәле, тоташ ихтирам белән әйтергә өйрәнеп килә иде.

Такси Казан аэропортыннан кузгалып китәчәк. Очраган кешеләр хәйран калып карап калачаклар. «Нинди бәхетле кыз бу? Янындагы летчигын күр: түше тулы орден, ә үзе? Бар бит бу дөньяда бәхетле кызлар...» — дип сокланып карап торачаклар.

Разия Сәйринне тулай торакка алып кайтмаска булды. Тулай торак бүлмәсе андый кеше белән очраша торган урын түгел иде. Инде күптән сөйләшеп куелган: Казанда аларның авылдашлары Мәгъмүрә исемле хатын яши. Мәгъмүрә апаның ире үлгән, малайлары фронтта, ул өч бүлмәле гүрнәчә кебек фатирда ялгызы тора. Фатирны мичкә ягып җылыталар — шушы ягы бик мөһим иде Разияга.

Кайтып керү белән, сөйгән егетен түргә уздырып, өстен алыштырып тормыйча, Разия алъяпкыч бәйләп алачак. Он, май, йомырка, утын — барысы да әзер. Ул коймак пешерергә тотыначак. Тантаналы бәйрәмнәрдә генә була торган коймак пешерү хозурлыгы — шул куаныч өчен ул әздән генә ачка үлми калды. Он исән. Ул ачка үлсә дә коймак онына ягылмас иде.

Мичтә дәртләнеп кызыл ялкыннар бии. Каен утыны шартлап яна. Табалар кызган. Өйдә чиксез татлы камыр исе. Ул бит теге гомуми ашханәләрдә кемгә икәнлеген белмичә тугылаган кәҗүннәй камыр түгел. Коймак камырына Разия өч йомырка сытачак, тугылар алдыннан сөт һәм май эретеп салачак. Май камырның үзендә булганда коймак аеруча тәмле пешә. Табага да майны кызганмыйча салырга кирәк. Майда кайнап пешсен — Сәйрингә диген коймак бит.

Пешереп бетергәч, Разия коймакларны табага өячәк. Табаның өстен ябып һәм тагын май салып, аларны кайнар мичкә куячак.

Авылда яшәгәндә, Разия коймакны бал, каймак һәм кура җиләге белән генә ашап була дип йөри иде. Чеховның бер хикәясеннән ул коймакны балык уылдыгы, сөләйман балыгы һәм тагын әллә нинди татлы нәрсәләр белән ашап булуы турында укыды. Балык уылдыгы табыла ул, акчаң гына булсын. Кичләрен хат таратырга ялланып, уылдыкка җитәрлек акча эшләргә сөйләшеп куйган иде инде. Больницага керү комачаулады.

Сәйрин белән Разия икәүләп коймак белән чәй эчәрләр.

Сәйрингә пешерәсе коймак турында уйлаганда кайчакта ашыйсы килүдән Разияның күз аллары караңгыланып китә иде. «Бер генә уч он алып, үземә пешерсәм, аңа да калыр, җитәр иде әле», дип тәмам тәвәккәлләп бетергән чаклары да була иде. Кыз түзде. Тимәде ул

Сәирингә дип саклаган онга. Ураза тота дип мәсхәрә кылсыннар, институттан куып чыгарсыннар, хәтта төрмәгә япсыннар — коймак оның ул Сәйрин кайтканчы саклаячак.

Коймаклап чәй эчкәч, Разия сөйгән ярын шәһәргә алып чыгачак. Сәйриннең шушы көнгә кадәр Татарстанның башкаласын күргәне юк. Сәйрин, чит илләрдә әллә нинди матур шәһәрләрне карап йөргәндер, бәлки, Казан — бөтенләй икенче шәһәр.

Разия сөйгән ярын Тукай йөргән урамнарга алып барачак, Кремльгә, Сөембикә манарасын карарга. Сәйрин сөйгән ярының шундый һәйкәлләрне белеп, аларны ихтирам итүенә чын күңелдән куаначак. Кич белән алар театрга барырлар. Татар театры мондагы һәйкәлләр шикелле егеткә тансык булырга тиеш.

Фараз итүнең иң катлаулы урыны — театрдан кайтып, кичке чәйне эчкәч, ятар вакыт җиткәндә башлана иде. Саубуллашкан чакта кочаклашып үбешерләр. Үбешүнең бармак очларына кадәр тарала торган татлы газабын, аның буыннарны йомшарта торган тетрәндергеч көчен кыз Сәйринне армиягә озатканда татып карады. Шул чакта тәнгә ашкындыргыч дулкыннар таралган, тын кысылган иде. Шундый котылгысыз, илаһи рәхәтлектә Разия үзенең затын, җенесен югалтып, соңгы күзәнәгенә кадәр Сәйрингә кушыла башлавын тойган иде. Шул хәлнең кабатлануыннан курка иде Разия. Курка һәм каршы тора алмыйча, шул мизгелгә ашкына иде.

Театрдан соң, Сәйринне Мәгъмүрә апаларда калдырып, Разия тулай торакка кайтып китәчәк. Ул шулай тырышачак, шулай эшләячәк. Кайтып киту — иң дөресе.

Кайвакытта Разия бу турыда баш ватмаска, бар катлаулыкларын Сәйриннең үз карамагына тапшырырга тырыша иде. Ул бит гаилә иминлеге өчен җавап бирәчәк хуҗа кеше. Юк, язылышканчы, төн кунарга Разия аның янында калмаска тиеш. Иң дөресе — шул.

*

* *

Командиры йокыга китә алмыйча уйланып ятканда укчы-радистның да күзе ачык иде. Аның уйлары әнисе тирәсендә әйләнеп йөриләр.

Әллә эше тыгыз булды, әллә әтиләр гомумән шундый булалар. Марсель һәм аның ике сеңелесе аталарын сирәк күрә иделәр. Йокыдан торганчы ул эшкә киткән була. Аннан кайту белән ашык-пошык кына капкалап ала да, язарга утыра. Ялчинскийның әтисе тарих буенча зур китап яза иде. Сирәк, бик сирәк килә торган бәйрәм көннәрендә генә улы белән шахмат уйный һәм җәй көннәрендә бер-ике мәртәбә балаларын диңгезгә алып төшеп су коендыра иде ул.

Әнисенең дә күп вакыты музыка мәктәбендә дәрес биреп, гастрольгә йөрүдә һәм кичке концертларда үтә иде. Шуңа карамастан, өйгә кайткан арада әнисе балаларын назлап сөяргә өлгерә иде. Шушы мизгелне алар түземсезлек белән көтеп алалар иде. Бала назлау, бала сөеп үстерү өчен яралган кеше иде Марсельның әнисе. Менә хәзер, егет булып җиткәч тә, «үз гомереңдәге иң кадерле, мәңге онытылмаслык хатирәне әйт әле», дип сорасалар, Марсель һич икеләнеп тормыйча, «әниемнең иркәләп сөюе», — дип җавап бирер иде.

Концерт залы. Зал шыгрым тулы. Тыңлаучыларның авызлары ярым ачык, күзләре бер ноктага текәлгән. Сәхнә уртасында ялгыз кара рояль. «Блютнер» фирмасы ясаган зур концерт коралы. Әйтерсең рояльне сизер белгән өчен ялгызлыкка дучар иткәннәр. Марсельнең әнисе дә ялгыз. Ул, арыган бармакларын ак клавишлар өстенә салып, ял итеп утыра. Сәхнәне караңгылык чорнаган. Прожекторларның аяусыз чаткылары, караңгылыкны тишеп, ялтыравыклы чатыр ясаганнар. Чат-

кылар әнисенең кара гипюрга төрелгән гәүдәсенә терәлеп туктаганнар да аны җибәрмичә сәхнә уртасында тотып торалар. Көчле яктылыктан әнисенең күзе чагыла. Шундый кызганыч, шундый газиз иде ул шушы минутта.

Залга кергәндә тамашачылар бөтенләй икенче төрле иделәр. Тәкәбберлек, минминлек тойгысы баскан иде тамашачыларны. Өсләренә моң тылсымы ява башлагач, кинәт үзгәреп киттеләр. Рояльдән чыккан авазлар сүз белән аңлатып булмаслык бөек дөреслекне турыдан-туры тамашачыларның йөрәкләренә илтеп тапшырып торалар иде. Моңа кадәр мөһим тоелган вакчыллыкларның бәясе төште. Тойгы һәм вөждан дөреслеген тыңлыйлар иде залда утыручылар.

Кинәт зал тетрәнеп китте. Күктән таш яуган, тау елгасы аккан тавышлар ишетелеп китте. Тамашачылар кул чабалар иде. Алкышлаучылар Марсельнең әнисенә мәңге сокланырга, мәңге баш иярга кул чабып вәгъдә бирәләр сыман иде. Менә шушы мизгел куркыта иде малайны. Алкышлау авазларын ишетү белән ул һушыннан язар чиккә җитеп тетрәнә иде. Көчле алкышлар башланганда, тамашачылар акылдан шашып, әнисен таптый башларлар дип курка иде Марсель.

Ниһаять, әнисе аягүрә басты. Сөйрәлеп торган күлмәк итәген кулы белән тотып, сәхнә читенә килде, тамашачыларга баш ия башлады. Иң куркыныч мизгел шушы иде. Ышанмый иде Марсель баш июләренә. Ышанмый иде. Баш ию алкышлаудан да куркынычлырак иде. Хәтәр иде кешеләрнең бер-берсенә баш игән булып күз буяулары. Әгәр аның ихтыярында булса, адәми затларга үзара баш июне катгый рәвештә тыяр иде.

Матур иде аның әнисе, шундый якын иде. Читтән тыш яратудан Марсельнең елыйсы килгән чаклар да була иде. Шушы читтән тыш ярату алдагы зур афәт билгесе иде.

*
* *

Концерт беткәч, Ялчинский сәхнә артына күтәрелә иде. Әнисе аны көтеп торган була. Күрү белән кочаклап алып, күкрәгенә кыса башлый. Алар, бер-берсенә сырышып, баскычтан әкрен генә төшәләр. Концерт бетүгә, һәр кичне такси чакырылган була. Чакырылган һәм түләнгән. Марсельнең әнисе машинага утырырга теләмичә бер тын бәхәсләшә. Аның таксины кем чакырганын беләсе килә иде. Шофер бер сүз дәшмичә, аның әнисенә сокланып карап тора. Чит кешеләрнең әнисенә соклануы чиксез рәнҗетә иде Марсельны.

— Җәяү генә кайтыйк, улым, — ди әнисе. — Мин арыдым. Ял итәсем, тынычланасым килә.

Алар җәяүләп китәләр. Ә такси артларыннан ияреп бара. Арттан машина ияреп килгәндә сөйләшеп булмый. Берни эшләп булмый, сине машина ээрлекләгәндә. Алар таксига кереп утыралар.

Шәһәр утлары, урам уртасыннан сөйрәлеп баручы көрән трамвайлар, каядыр ашыгучы җәяүлеләр, җиңел машина тәрәзәсе яныннан артка таба агылалар. Төнге шәһәр малайга шундый сәер тоела иде. Әйтерсең, төнгә каршы шәһәргә башка бер планета иңләре җыелалар.

Кайтып җиткәч, алар икәүләп киң мәрмәр баскычтан икенче катка күтәреләләр. Марсель тынычлана. Ул үзен әкияттәге батыр итеп сизә иде. Ул бит әнисен тамашачылар золымыннан коткарды, урамда сагалап йөргән «пиратларга» бирмичә, әнисен өйгә алып кайтты.

Әнисе, урын җәеп, Марсельны йокларга яткыра. Чыгып китәр алдыннан, башыннан сыйпап, озак итеп үбә. Шуннан соң гына алар әтисе белән икәүләп чәй эчәргә утыралар. Аларның кухняда басынкы гына сөйләшүләре ишетелә. Чәйдән соң әнисе малае янына тагын

керә. Әнисенең тылсым белгән матур бармаклары аның чәч арасына кереп, назлап сыпырырга керешәләр. Малайның тәненә иң матур музыка яңгыравына охшашлы рәхәтлек йөгерә.

Кайда икән хәзер аның әнисе, исәнме икән? Сәләте, таланты исәнме икән? Ә бармаклары?.. Шушы урында Ялчинскийның күз аллары томалана, бугазына ачы төер тыгыла иде.

Сугыш бетүгә якынлашып килә. Тиздән сугышчылар өйләренә туганнары янына тарала башларлар. Шул чакта Марсель ялгыз башын кая куяр, нәрсә эшләр? Бу турыда уйлаганда Ялчинскийның йөрәген курку кыса башлый иде. Бизгәк хастасына охшашлы салкын, шыксыз курку. Шул нәрсә бәгырьне өшетә, яшәүне агулый иде.

Марсель беренче мәртәбә сугышчан заданиегә очканда да каты курку сизде. Ул чакта, аэродромнан күтәрелеп китү белән касыкка ниндидер тынгысызлык кереп утырды, курыккан чакларда син нәрсәдер көтәсең. Һавадагы һәр болыт кисәге, иллюминатордагы һәр тап сиңа үлем алып килүче дошман истребителе булып күренә. Ләкин очу вакытындагы курку бөтенләй икенче төрле курку иде.

Нәрсә соң ул курку? Бу турыда Марсель күп уйланды. Һәм батырлык нәрсә ул? Бу турыда да уйланды ул. Кем батыр: сызгырып килгән пуляларга баш имичә атакага баручымы, әллә инде теләсә нинди шартларда, кем каршында булуына карамастан, хакыйкатьне ярып салучымы? Хакыйкатьне яклау дөньядагы иң зур батырлык булып тоела иде аңа.

Соңгы вакытта Ялчинский шуңа төшенә башлады: эчендә җаны булган кеше куркудан котыла алмый. Куркуның файдалы, кирәк ягы бар. Ул булмаса, сугыш кырында үзеңне ничек саклап калыр идең? «Фоккер»ның пулемет көпшәләре тезелгән тупас борыны сиңа туп-туры үлем төзәгәндә ничек курыкмыйсың ди? Без бит бу дөньяга яшәр өчен килгәнбез. Тыныч яшәр өчен. Рәхәт, куанычлы яшәр өчен. Шатлык һәм мәхәббәт өчен. Ә без айлар, еллар буе үлем аша — сугыш аша үтәргә тиешбез. Туктаусыз сагалап йөргән үлем белән ничек килешеп булсын?

Курыккан чакларда буыннары йомшарып китә иде Ялчинскийның. Тәнен көчсезлек чорнап ала. Ихтыяры югала. Шушындый чакларда ул көчсезлеккә каршы көрәшүен дәвам итә иде. Һәм шулай итеп ул паникага бирелмәскә өйрәнде. Аның эчендә ниндидер бер егәрлек туа башлады. Шул егәрлек, заданиегә очкан саен, һаман үсә, ныгый бара иде. Хәзер ул, зиһене таралып, буыннары йомшарган чакта да эшен дәвам иттерә ала. Батырлык шушыдыр бәлки?

Туганнан бирле аңа лаеклы яшәү турында сөйләүләрен ишетергә туры килде. Ә нәрсә ул лаеклы яшәү? Яшәргә өйрәтүчеләрнең сүзен тыңлаумы, әллә башыңны югары күтәреп, үз кыйблаңа таба барумы? Сугыш бетеп килә. Бу турыда уйларга кирәк булачак. Сугыш безнең җиңү белән тәмамлана. Шундый зур куаныч, шундый зур шатлык.

Йокыга китәр алдыннан гына ул: «Җиңү безнең башны әйләндермәсме икән? Тарихта моңа хәтсез мисаллар бар», — дип уйлап куйды...

*
* *

Палата тәрәзәсеннән тулган ай карап тора иде. «Сагынганда айга карыйм, ай да ялгыз...» — дигән җыр сүзләре килеп төште Разияның хәтеренә. Сәйрин аңа айны яратмавы турында әйткән иде. Ул айга карамый торгандыр инде. Әгәр шушы мизгелдә ул да айга карап торган булса, аларның күз карашлары очрашыр иде.

Ай нурлары Разияда ниндидер татлы хисләр уятып, уй-фаразларын көчәйтеп җибәрәләр. Ай яктысы рәхәт тынычлык китерә. Теләкләрең

көчәя, өметләрең ныгып киткәнен сизәсең. «Сәйрин нигә айны яратмый икән, әллә аңа бәйләнешле берәр үкенечле истәлеге бармы икән?» — дип уйлады Разия.

Башка авырулар йоклыйлар иде. Тәрәзә янындагы караватта йөрәк авыруы белән кергән Евдокия Семеновна ята. Кайсы хатын-кызга матурлык картлыкка ияреп килә. Яшь чагында чибәрлеге уртача гына булган кыз гомеренең соңгы елларында кинәт, танымаслык булып, матураеп куя. Бу хәл бай эчтәлекле рухи тормыш белән яшәгән хатыннарда очрый. Карчык шундыйлардан иде. Пенсиягә чыкканчы Казан университетында рус әдәбияты укыткан. Дүрт тәүлек эчендә алар дуслашып өлгерделәр. Аңлашу дөнья хәлләре турында сөйләшүдән башланып китте. Евдокия Семеновна революциягә кадәр Казан университетының Шәрык бүлегендә эшләгән күренекле галим кызы иде. Карчыкның татар тарихын, җирле гореф-гадәтләр, көнкүреш ысулларын белүе Разияны таң калдырды.

Сөйләшә торгач, алар рус әдәбиятына күчтеләр. Шушы әңгәмәләрдән соң Разия әдәбиятның нәрсә икәнлеген аңлый башлады. Әдәбиятның язмышлар фәне, хакыйкать һәм вөҗдан дәреслеге булуын аның моңа кадәр ишеткәне юк иде әле. Институтта аларны әсәрдән уңай һәм кире образлар йолкып алып шуларны яттан белергә өйрәттеләр. Евдокия Семеновна уенча, бу ысул әдәбиятны тирән аңларга комачаулый.

Карчык ялгыз яши иде. Больницадан чыккач, Разия карчыкның хәлен белеп, аңа ярдәм итеп йөрерғә булды.

Евдокия Семеновнага янәшә караватта заводта эшләүче токарь кыз Шакирова Сәлимә ята иде. Авылча оялчан, авылча тыйнак һәм эшчән иде бу кыз. Алар дуслаштылар. Сәлимәнең сул күзен суппорттан ычкынып киткән металл кыйпылчыгы тишкән иде. Токарь кыз, сыңар күзле булып калудан куркып, көн саен елый иде.

Больницада ятуның бер үзенчәлекле ягы бар. Мондагылар тирәюньдә гел үзләре шикелле сырхауларны гына күреп торалар. Аларга уртак тел табу җиңел. Башка авырулар Сәлимәне юаталар, сыңар күз белән дә бәхетле яшәп була дип аңлаталар иде.

Дүрт тәүлек эчендә палатада ятучылар бер-берсе белән якынаеп киттеләр. Авырлык килгәндә шушы хатыннарның һәркайсы сиңа рухи терәк булырга әзер иде. «Безнең язмышлар белән шәфкатьлелек идарә итә, — дигән фикергә килде Разия. — Настя Дурова шикелле үч һәм гайбәт белән куанып яшәүчеләр шактый сирәк очрый. Кешеләрне берләштерүче төп канун — шәфкать».

Көненә ике тапкыр кадаган глюкоза уколы, балык мае, ял кызның хәлен үзгәртеп җибәрде. Баш әйләнү һәм хәлсезлек бетте. Ике ай аны интектереп торган «тавык күзе» юкка чыкты. Күзләре хәзер кичке караңгылыкта да күрәләр. Яшәү рәхәт һәм куанычлы иде.

Разияга больницадан чыгуны ашыктырырга кирәк иде. Беренчедән, тиздән сынаулар башлана. Икенчедән, сынаулардан да мөһимрәк бер эш бар: Сәйринне каршылар вакыт җитеп килә. Аны зурлап, лаеклы итеп каршыларга кирәк иде. Разияга сәламәт булу кирәк. Тиздән аның кулына үсмер балаларның язмышлары тапшырылачак. Андый катлаулы авыр эшне уңышлы алып бару өчен сәламәтлек кирәк. Укыту эшенә тагын бер зур вазифа өстәлә. Сәйрингә тыныч, рәхәт һәм ышанычлы тормыш шартлары оештыру вазифасы. Бу эш укыту, тәрбия бирү кебек үк җаваплы. Бәлки җаваплырактыр әле? Разияның сөйгән яры рәхәт торырга тиеш. Ул фронтта яраланды, өч ел буена үлем аша үтеп йөрде. Мул, тыныч тормышка лаеклы ул хәзер. Разия үз ягыннан аңа җил-яңгыр тидермәскә тырышачак. Әгәр мәхәббәт туу белән өйләнешеп яши башласалар, Разия күп нәрсәне аңлап өлгерә алмый калган булыр иде. Өч ел туктаусыз сөйгән ярын уйлап йөргәндә ул күп нәрсәгә төшенде. Гаиләдәге иминлек, татулык, тынычлык өчен ул җавап бирә-

чәк. Шушы зур җаваплылыкны өстенә алырга ул әзер иде. Синең намуслы булуың үзең өчен генә түгел, ирең, балаларың өчен дә кирәк. Җәмгыять өчен дә кирәк бу сыйфат. Разия соңгы сулышына кадәр Сәйриннең исеменә тап төшермәскә тырышачак. Ул моңа әзер иде.

*

* *

Йокыдан торыр вакыт җитеп килә. Сәләхов балачагы турында уйланып ята иде. Шундый рәхәт ул балачакны искә төшерү.

Сәйрин укыган чакта мәктәп балалары «кем булу» мәсьәләсе белән чиктән тыш мавыгалар иде. Чоры шундый булды. Мәктәпкә йөрүче балалар әле дә «кем булу»ны онытмыйлар. Сәйрин укыган чорда «кеше булырга» тырышу аеруча көчле һәм хәлиткеч мәсьәлә иде. Алар бары тик уку, белем алу гына тормышның олы юлына чыгарып, «кеше итәчәк» дип ихлас ышаналар иде.

Утызынчы елларда кытлыклар да булгалады, кием һәм акча җитмәү Сәйриннәр гаиләсендә табигый хәл иде. Бар дикъкатең, багланышларың киләчәккә, «кеше булуга» төбәлгән очракта авырлыклар сизелми икән ул. Үзенә ашкындырып торган киләчәк сиңа алтын таулардан да кыйммәтлерәк куаныч вәгъдә итә. Тырышып укысаң, укытучыларның сүзен тыңласаң, туган илең Россияне ихлас күңелдән яратсаң, киләчәктә син «кеше булачаксың». Шушындый куанычлы, матур өметләр чорнап алган иде Сәйриннең уку елларын. Киләчәккә омтылу, аңа ышану чиксез көчле иде.

Күп вакыйгаларның тарих битендә беренче күренүе. Сокланырлык зур эшләр, җиңүләр, бөек яуланышлар. Беренче тапкыр полюс аша Америкага очу. Беренче мәртәбә хатын-кызның тракторга утыруы. Мәчет манаралары гөрселдәп җиргә авалар иде. Манаралар белән мең еллаган иске гореф-гадәтләр, йолалар, ышанулар авып челпәрәмә килде. Сугышчан алласызлар халыкны клубка җыеп, искелекнең тамырына балта чабу турында ялкынлы нотыклар сөйлиләр. Яшәүнең иң зур дошманы — искелек. Аны, төрле яктан урап алып, тар-мар итәләр. Һәр сүздә тылсым. Һәр эштә — дәрт. Колачлы кизәнүләр. Һәм искиткеч яңгыравыклы матур исемнәр: Чкалов — Байдуков — Беляков, Папанин — Ширшов — Кренкель — Федоров, Мәмләкәт — Стаханов—Карацупа һәм старшина Карацупаның герой эте Илдус. Герой Батыршин һәм Һади Такташның «Киләчәккә хатлары». БГТО, БГСО, МОПР значоклары.

Ул чакта халык сабыйларча эчкерсез шатлана белә иде. Әзгә генә дә, ачыктан-ачык ихлас күңелдән, күмәк шатлану хөкем итә иде ул чакта. Экранга чыккан һәр кинофильмның эчтәлеген дога шикелле яттан беләләр. Һәр яңа җырны бөтен ил күмәк, бер авыздан җырлый. Яше, карты, сабанчысы, министры барысы бергә. Һәр көн бәйрәм шатлыгына төренеп туа. Яшәү — Сәйрингә тоташ бәйрәм, бизәкле карнавал иде. Киләчәк — җәннәттән дә матур тоела иде ул чорда. Әллә шунлыктан, Сәйриннең классында бер генә малай да сабан сөрү турында уйлап хыялланмый иде. Малайлар «лүтчик» булалар, кызлар — «брач», «Лүтчик булып», башларына шлемофон киеп, җилкәләренә планшет асалар да, кешеләрне сокландырып, урамда йөриләр, «кәртечкәгә» төшәләр, имеш.

«Кем булу»ны сугыш бик тиз хәл итеп ташлады. Илдә ике генә вазифа, ике генә һөнәр калды: кулга мылтык тотып ватанны саклау һәм фронт өчен армый-талмый тылда эшләү. Хыял ассортименты бермә-бер кимеде. Ике теләк калды: фронттагыларны котеп алу һәм сугыштан исән кайтып кавышу.

Тарих битен канлы сугышлар каплаган. Россия халыклары күп нәрсәгә мохтаҗ яшәсәләр дә сугышка беркайчан мохтаҗ булмаганнар.

Сәләховның вакыйгаларны гына теркәп барган елъязмалар укыйсы килә иде. Сугыш беткәч, Сәйрин шушы хыялын тормышка ашырачак.

Икенче эскадрильяда уникe миллэт вәкиле хезмәт итә. Алар үзара шундый тату яшиләр. Аларның төрле милләттән булулары турында исләренә дә төшергәннәре юк иде. Тарих турында сүз чыгу белән бер ана балалары булып яшәүче очучылар арасында ниндидер дулкын кузгала. Шундый катлаулы иде тарих мәсьәләсе...

Кырык беренче ел күп нәрсәләрне үзгәртте.

Сәйрин үзенең экипажын сугыш азагына кадәр саклап килә алды. Алар бер-берсенә шул кадәр күнектеләр. Сугыш беткәч, Ялчинский институтта укуын дәвам иттерәчәк. Майнагашев бомба ташлау бәләме турында дәреслек язарга хыялланып йөри. Сәирингә дә киләчәк турында уйланырга, алдан план корып куярга туры киләчәк.

«Ярый, йокларга, ял итәргә кирәк,— дип үз-үзен кисәтте ул.— Задание катлаулы. Ял итеп, көч җыймыйча, аны үтәве кыен булыр».

*

* *

Ул машина тавышына уянды. Тәрәзә каршыннан гөжләп машиналар уза иде. Кузовта утыручыларның сөйләшкән тавышлары ишетелеп калды. «Техниклар аэродромга киттеләр,— дип уйлады Сәйрин.— Аларны бездән иртәрәк уяталар. Тагын бераз йоклап алырга вакыт бар икән әле».

Тырышып караса да Сәләхов йокыга китә алмады. Күңелен катлаулы исәпләр чорнаган иде. Ул армиягә алынган чагы турында уйлый иде.

Каралырга барганда Сәйрин авиациягә эләгерен белми иде әле.

Гадәт буенча, аларга колхозның иң яхшы атларын бирделәр. Дугага кыңгырау тагып җибәрделәр. Кыңгырау тавышы атларны ярсыта. Егетләр үзләре дә каядыр алгысыналар иде. Унҗиде яшьтә армиягә алыну тантаналы тоела бит ул.

Көз, әбиләр чуагы иде. Күңел көр, тәндә — яшьлек дәрте. Атлар, йөрәк кагып, урыннарыннан дәррәү кузгалдылар. Ат — адәм баласының иң борынгы, иң тугрылыклы дусты. Алар егетләрнең кая баруларын аңлыйлар иде шикелле.

Юлга чыгар алдыннан кайбер егетләр «төшереп» тә алганнар иде. Ул чакта татар авылларында ныклап эчү юк иде әле. Хәтта бәйрәм көннәрендә дә эчеп былагайланып йөрү зур җинаять санала иде. Яратмыйлар иде «салмыш» кешене. Эчүнең әшәкелек икәнлегенә ихлас күңелдән ышаналар һәм ана юл куймыйлар иде.

Каралырга баручы егетләр гармунга кушылып, җырлап авылдан чыгып киттеләр. Авыл халкы — ирләре сугышта йөргән солдаткалар, яшь кызлар, карт-коры, бала-чага урамга чыгып, аларны озатып калды.

Баулы күренгәч, егетләр арбадан төшеп, озаклап тәмәке көйрәттеләр. Хәрби комиссариат бинасының кызыл калай түбәсе күренеп тора иде. Шул калай түбә егетләрне айнытып җибәрде.

Сәләховның әле дә хәтерендә. Ул чакта Сәйрин Рифкать исемле бер малай белән дуслашып йөри иде. Арбадан төшеп, куак янына килгәч, Рифкать аның янына чүгәләде: «Сәйрин, әйдә, «лүтчик»леккә языла-быз, ә» — диде ул. Бу сүз аның бала чактагы зәңгәр хыялын яңартып җибәрде.

Таза егет иде Рифкать. Таза һәм житлеккән егет иде. Ә ул чакта Сәйриннең култык астына төк тә чыкмаган иде әле. Әллә шунлыктан, ул чишенеп шәрә калудан ояла иде. Сәләховның чалбарын көчләп салдырттылар. Шул кадәр оят иде шәрә калу... Шул газаптан егетнен тәне калтырый иде.

Авиациягә язылучыларны түгәрәк урындыкка утыртып, зур тизлектә әйләндереп карадылар. Тикшерүне Сәләхов җиңел үтте. Рифкать кенә,

урындыктан тору белән, каралу комиссиясе председателенең өстәленә барып ауды.

Аны авиациягә алмадылар. Егетнең өмете киселде.

Баулыга барганда ул Сәйрингә үзенең йөрәк серен сөйләгән иде: «Минем генерал да буласым килмәй, маршал да. Мин, малай, «лүтчик» булам. Очарга үрәнү белән, ярапланга утырып, авылга кайтам. Йорт-лар өстеннән, канат кагып, бер кат очып үтәм. Аннан соң, кырда эшләп йөрүче Миннисаны эзләп табам. Шуның өстеннән выжлап үтеп китәм дә сәләмүт җиле белән аның итәген күтәртәм. Ул бит, малай, миннән бо-рын чөйде. Минем ярапланга утырып йөргәнемне күрсә терсәген тешләр, әмма соң булыр...»

Каралудан кайтканда Рифкать туктаусыз зарланды: «Башкаемны шул чуаш көмешкәсе ашады. Шуны эчеп кенә харап булдым мин. Без-нең нәселгә эчке ярамый. Шуны эчмәгән булсам, Миннисаның терсәген тешләтә идем...»

Сәйрин дә «лүтчик»ләр исемлегеннән төшеп кала язды. Училищега алыну өчен кимендә тугыз класс белем кирәк иде. Сәләхов анкетага ту-гызны бетердем дип язды. Анкетага язганны рәсми кәгазь белән раслар-га кирәк икән. Хәрби комиссар таныклык китерергә кушты. Әгәр Сәй-риннең әнисе бертуган укытучы апасы аша таныклык табып бирмәгән булса, «лүтчик» булу хыялы белән саубуллашырга туры киләчәк иде.

*
* *

Армиягә эләккәнче Максим Майнагашев сугышның нәрсә икәнлеген аңлый алмый иде әле. Ул борынгы сугышларны бүгенге көн сугышлары белән чагыштырып карый иде. Хәйран калырлык аерма: «Олонхо» да-станындагы сугыш — батырлар ярышы, көч сынашу, егетлек күрсәтү генә булган икән. Хәзерге сугышта дәһшәтле машиналар адәм балала-рының гомерләрен иттурагыч шикелле туктаусыз «эшкәртеп» торалар.

Максимны армиягә интернаттан алып киттеләр.

Армиягә китәсе көнне Максим интернат директоры янына керде. Николай Юльевич Бадер сөргенгә килгән җиреннән Айхалда төпләнеп калган кеше иде. Ул ялгыз яшәде. Максим кергәндә директор, мичкә аркасын терәп, китап укып утыра иде. Укучысын күргәч, урыныннан торды:

— Түрдән уз, Майнагашев. Рәхмәт, карт кешене онытмавың өчен, рәхмәт. Хәзер икәүләп чәй эчәбез,— диде ул, Максимның кулын кысып...

— Армиягә китәм, Николай Юльевич.

— Сугышка мыни?

— Әйе, сугышка.

Карт остаз бер тын мичтә янган утыннарга карап утырды:

— Тыныч тормыш өчен тәрбияләп үстергән идек без сезне. Без башлап җибәргән эшне дәвам иттерерсез дип өметләнеп үстергән идек.

— Берничә айдан җиңеп кайтырбыз. Нәрсә ул безгә фашистлар?

Карт педагог бу сүзләрне игътибарсыз калдырды.

— Белмим, күрә алырмынмы икән мин сине, Майнагашев? Монда яши башлавыма тагын ике айдан алты ел тула. Мин бит Ленинградта туып үстем. Ә төп урыным шушында, якутлар арасында булган икән.— Картның күзеннән яшь бөртеге тәгәрәп чыкты.— Якутлар турында зур китап язарга әзерләнеп йөрдем — вакыт җитмәде. Интернатның эше бик четерекле.

— Язарсыз әле,— диде Максим остазын юатып.— Артта калган, ярым кыргый халык турында нәрсә яза алырсыз икән?

— Дөрес түгел,— диде Николай Юльевич, йодрыкларын йомарлап.— Җир йөзендә якутларга тиң халык барлыгын белмим мин. Кызганычка

каршы, сезнең турыда язарга Фенимор Купер шикелле әдип табылмаган. Якутлар җир шарының иң суык төбәгендә яшиләр. Кышларын салкыннан агачлар чатнап ярыла, ташлар уалып төшә. Ә сез түзәсез. Якутлар арасында төшенкелеккә бирелүчене очратканым юк минем. Шушындый кырыс шартларда яшәү искиткеч күркәм гореф-гадәтләр тудырган: сез балачак сафлыгын картайганчы саклый беләсез.— Карт педагог кесәсеннән яулык чыгарып күзен сөртте.— Без сезне уку-язуга өйрәттек. Хәзер сез русча сөйләшә беләсез. Наданлыктан котылу, белем алу бик күп мөмкинлекләр ача. Шатланырга кирәк иде шушы уңышларга. Ә мин, тиле карт, уйлап утырам: без биргән белем, безнең тәрбия бу тормышка яраклымы икән дип. Шушы сорау борчый мине. Көнетөне борчый. Сез, яшьләр, ата-бабадан калган гореф-гадәтләрне үзләштерә алмадыгыз. Алар, әкренләп, онытылачак, югалып исраф булып бетәчәк. Меңәр еллар буе һәр буын мыскаллап кына өстәп килгән искиткеч зур байлык юкка чыга дигән сүз. Гадәтләрнең яңасы барлыкка килсен өчен бик күп гасырлар кирәк. Сезнең буын һәм сездән соң киләчәк буыннар тормышларын әле чын гореф-гадәткә әйләнеп өлгермәгән вакытлы кагыйдәләр нигезендә корачаклар. Ул кагыйдәләрне кабул итүчеләр рухи бушлыкта калачаклар. Куркыныч хәл ул бушлыкта яшәү. Бушлыкка нәрсә булса да тула. Вакуум буш булмый.

Якутларда начарлык белән көрәшү тәҗрибәсе юк. Бозыклыкка каршы тору иммунитеты юк сездә.

Ул чакта Майнагашев остазының сүзләрен тулысынча аңлап та бетермәгән иде. Хәзер төшенә башлады. Элек якут халкының тормыш кагыйдәләре бик гади булган. Кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләрен, гомумән, күп эшне йолалар хәл иткән. Яшәү кануннарын бозудан гореф-гадәт һәм йола саклап торган. Аракы эчү, кеше өлешенә керү, ришвәт шикелле нәрсәләр гореф-гадәт буенча зур гөнаһ саналган. Ә хәзер шундый яхшы, шундый акыллы рәсми кануннар бар. Шуларны тормышка ашыру өчен куйган рәсми оешмалар байтак. Әшәкелек исә күзгә күренмичә генә, астыртын хәрәкәтләнеп ята.

Максим Майнагашев шушы турыда уйлап ята иде.

*

* *

Чиксез кайгы-хәсрәт, югалтулар, йөрәк яралары алып килде бу сугыш. Һәм күп нәрсәгә өйрәтте дә. Ирләр сугышка киткәч, алар урынына хатыннар калды. Тормышның бар авырлыгын хатыннар үз өсләренә алдылар. Сугыш беткәч, ирләр фронттан кайтыр. Аларны каршы алып кунак итәрләр. Ирләр кунак булып яшәгәндә дә авырлыкның юан башы хатыннар җилкәсендә булачак. Менә шушы вакытта кайбер ирләр, җаваплылыкның хатыннар өстендә булуын табигый санап, үз урыннарына басудан баш тартачаклар. Евдокия Семеновна шушы хәлдән курка иде.

«Сугыш беткәч, хатын-кыз өстендәге җаваплылыкны ирләр өстенә кире кайтарасы иде. Ирләр үз рольләренә кайтсыннар иде. Бу бик мөһим мәсьәлә»,— дип хафаланып Разияга сөйләде ул.

Егерменче елларда безнең хатын-кызлар арасында тигез хокуклы булу өчен көрәш кызып китте. Башкача яңалыкка, культурага ирешү, тормыш кору сүздә генә калачак иде. Ләкин шушы көрәшне ялгыш аңлаучылар да күп булды. Тигез хокуклы булуны, наданрак кешеләр, ирләрчә яшәү, аларга бәрабәр булу дип аңладылар. Табигать миллион елларга сузылган эволюция дәверендә җенес аермасына хас җайланышлар тудырган. Ирләр ауга йөргән, хатын-кыз йорт эше караган. Ир-ат мал тапкан, хатын-кыз гаилә иминлеге, андагы җылылыкны саклап килгән. Евдокия Семеновна шулай аңлатты.

Карчыкның сүзләре дөрес тоелды аңа. Разия һаман да хәтерли әле. Тигезлек өчен көрәш елларында Разияларның күршесе Әһлиулла ха-

тыны Гайнекамал, ирләргә тин булам дип, башын пәке белән кырдыртты, чалбар киде һәм түбәсенә картуз чәпәде. Ул хәзер бары тик ирләр эшенә генә йөри иде. Язын — сабанга, кышын — олауга, урман кисү, бүрәнә ташу эшенә дә башлап ул бара иде. Ирләр дәрәҗәсенә күтәрелүен күрсәтер өчен Гайнекамал бик шәпләп сүгенергә дә өйрәнде. Разиялар авылында татарча сүгенә белмиләр иде. Эштән кайткач иренә: «Марш, сабака, чишмәдән су алып кайт»,— дип кычкыра иде. Авыл халкы Гайнекамалдан һәм аның хатыншага әйләнгән иреннән көлә иде.

Институтны бетереп, эшкә урнашкач, «башлы-күзле» булып алгач, нинди тормыш кору турында Разиялар тулай торагында да бәхәсләр еш була иде. Настя Дурова: «ирләр синнән үз «кирәкләрен» алганчы гына юмарт, киң күңелле булалар. «Кирәкләрен» алгач — алар эгоистка әйләнәләр. Хайвани хис көчле аларда. Ашау-эчү, кәеф-сафа кылу, хатын-кыздан «кирәк» нәрсәне алу ирләр максатында иң беренче урында. Алар арасында аерма юк»,— дип аңлата иде.

Настяның бу карашын Разия аңлый иде. Ул гел Казанга эш белән килгән ирләр арасында чуала. Командировкага килгән вакытлы кешеләр чынлап та, Настя әйткән сыйфатларын алга куя торганнардыр? Моңа Настя үзе дә, әкренләп күнегеп киткәндер?

Разиянең Сәйриннән башка беркем белән дә очрашканы юк иде. Шунлыктан сөйгән яры аңа иң матур, иң акыллы кеше булып тоела иде. Евдокия Семеновна аңа: «Ирләр чыдам, көчле, һәм батыр булсалар да, алар һәрвакыт назга, хатын-кызда гына була торган мөгамәләгә мохтаҗлар. Без алардан ныклык, акыл һәм киң күңеллелек көтәбез. Ирләрнең абруен төшерүче иң начар сыйфат — вакчыллык. Аларның киң күңелле, ышанычлы булуларын бездәге нечкә күңеллелек уята»,— дип аңлатты ул.

Разия Сәйриннең керләрен юып, аңа аш әзерләп торырга, бала-чагалар үстерергә әзер иде. Хокук тигез дип, ул аны хатын-кыз эшенә җикмәячәк. Ул аннан бер генә нәрсә таләп итәчәк — тугрылык. Гаилә каршында аның иманы саф булсын. Кыен чакларда аның намусына таянырлык булсын.

Институт кызлары арасында: «Тиздән диплом алам, мин югары белемле булачакмын. Урта белемле ирем миңа буйсынырга тиеш» — дип шапырынып йөрүчеләр бар. Гаиләнең үз кануннары җитәрлек. Дипломның катнашы юк аңа. Бәхетле яшисең килсә, син ул кануннарны үтәргә тиешсең.

Разия больницада Евдокия Семеновна белән ятканда менә шушы фикерләрне үзләштерде. Карчыкның үгете дөрес булуына ул чын күңелдән ышана иде.

Ниһаять, больницадан чыгасы көн дә килеп җитте. Төшке аштан соң ул, дуслары белән саубуллашып, тулай торакка кайтып китәргә тиеш иде. Өйдә дәваланыр өчен аңа бюллетень бирделәр. Иртәгә Май бәйрәме. Ул аны институтта, иптәшләре арасында каршыларга тиеш. Сугыш бетеп килә. Сәйрин исән калды. Бәйрәмнән соң ул кайтыр. Яшәүнең иң зур шатлыгы, иң зур бәхете шушы иде.

* * *

Армиягә киткәнче Сәйриннең гаиләсеннән бер генә көн дә читтә яшәп караганы булмады.

Алынучыларны Бөгелмәнең бер мәктәбенә алып килделәр дә парталары чыгарылган бер буш класска кертеп яптылар. Иң көчле билгесезлек шушы бүлмәдә яшәгәндә башланды. Шушында тоткарлармы? Тотмасалар, кая алып китәрләр? Алып киткәч, нәрсә эшләтерләр? Кайчан? Барыбыз дамы? Куркып, шомланып, авыл малайлары язмышларын

котәләр. Билгесезлек аларны бүредән өреккән сарык көтүенә әйләндерде.

Кинәт, «сохариларны җыеп алалар икән»,— дигән шом таралды. Авыл малайлары шатыр-шотыр сохари кимерергә тотындылар. «Өйдән киеп килгән киемнәрне кайтарып бирмиләр икән».Өстәге киемнәрне әллә кайдан килеп чыккан чегән кыяфәтле бер кызмача хатынга сату башланды.

Шушы шартларда, көтмәгәндә, җылы бер якты тойгы — якташлык тойгысы уянып китте. Авылдашлар, районадашлар бер-берсенә елыша башладылар. Кичкә таба аерым төркемнәр барлыкка килгән иде инде.

Азнакай егетләре, тәрәзә янына җыелып, татарларның туган җирдән аерылу гимны — «Шахтер» көен шыңшыйлар. Бер почмакта Әлмәтлеләр, көтәргә вәгъдә биргән кызларының фотоәсемнәрен бер-берсенә күрсәтешеп, күңелләреннән генә яшерен фал салалар. Һәрберсендә «Көтәрме икән?» — дигән газаплы сорау. Сине озаткан сылу кыз һичшиксез сине көтәр шикелле тоела. Ә дусныкы? Ай-һай!..

Шөгер егетләрен нигәдер кара боегу баскан иде. Әйтерсең алар үзләренең җеназаларын тыңларга җыелганнар. Шыңшыйлар. Офтаналар. Арада иң кызганыч күренгәне — табак битле төссез егет. Аның төссезлеге, базда шыткан бәрәңге сабагына охшавы төшенкелекне тагын да көчәйтә иде. Төссез егет туктаусыз кабатлый: «Күккә менү белән лүтчикләрне чәкеп кенә төшерәләр икән... Күккә менеп җитү белән...» Аны дикъкать белән тыңлыйлар. Шомын уртаклашалар... ышанып бетмәсәләр дә шулай эшлиләр.

Баулы районыннан бары тик дүрт кенә егет авиациягә алынган иде. Шуларның икесе — эвакуация вакытында килгән карт чырайлы рус малайлары иде. Алар авыл егетләре белән аралашмадылар.

Якташлыкның бер сәер ягы бар. Район үзәгендә сиңа авылдашың якташ. Өлкәдә — үз районыңнан килгән кеше. Башка өлкәләргә чыгып киткәч, Татарстанның һәр кешесе синең якын туганыңа әйләнә.

Якташлык тойгысы көннән-көн ныгыды. Моңа кадәр аларның бу тойгыны татып караганнары юк иде әле.

Шул чакта Сәйрин бер сәер хәлгә очрады. Өеннән чыгып китү белән аның үлеп ашыйсы килә башлады. Ач түгел иде ул. Китәр алдыннан иптәшләре, озатырга килгән кардәшләре белән әйбәтләп сыйланды ул. Шуңа карамастан, ул юл буе тамак туйдыру турында гына уйлап борчылып барды. Әнисеннән кала, бүтән кеше пешергән ашны ашый алуына ышанып бетми иде ул.

Эшсезлек һәм билгесезлек ашыйсы килүен тагын да көчәйтеп җибәрә. Сезнең поездда баручыларны күзәткәнегез бармы? Алар юл буе диярлек туктаусыз ашап баралар. Үзен-үзе кая куярга белмичә кыбырсып йөргәннән соң, Сәйрин дә капчыгын чишеп, сохари кимерергә кереште. Коры сохаридан соң су эчәсе килеп китте.

Класс бүлмәсенең бер почмагына өч чиләк керешле зур калай бак утыртып куйганнар иде. Бакның тоткасына тимер чылбыр белән әлүмин кружка такканнар. Шушы чылбыр Сәйриннең күңеленә авыр шом салды. «Хәтта су эчә торган кружканы да тимер чылбыр белән беркетеп куйганнар» — дип уйлады ул һәм шушы минутта аңа хезмәт итү шулкадәр авыр булып кебек тоелды.

Бер кружка хөкүмәт суын эчкәч, Сәләхов баш астына капчыгын салып, идәнгә сузылып ятты. И-их, шушы билгесезлекне! Дөньяда киләчәгеңне белми яшәүдән дә авыр михнәт юктыр?

*

* *

«Без бу дөньяга ярату өчен килә торганбыздыр?» — дип куанды Разия больница ишегеннән чыкканда.

Күктә кояш. Май бәйрәме алдыннан туа торган нәзберек яз сафлыгы. Җир чиста яшеллеккә төренгән. Тирәк яфраклары балавызланган шикелле елкылдап торалар. Кояш нурлары шәһәр йортларының тәрәзәләрендә, мәйданнар уртасындагы фонтаннарда уйный. Җир йөзе нурга төренгән. Күзәнәкләрдә яңару, яңадан туу куанычы.

«Йөрәгеңдә ярату хисе, аның шифалы җылылыгы юк икән, син бер ничек тә бәхетле була алмыйсың» — дип уйлады Разия. Аның йөрәген Сәйрингә булган мәхәббәттән тыш язгы авазларга, кояш нурларына, чәчәкләр өстеннән очып йөргән ак күбәләкләргә булган ярату хисе чорнап алган иде.

Кызга гел әйбәт кешеләр очрап тора. Больницада да нинди әйбәт кешеләр белән бергә ятты ул.

Аны дәвалаган урта яшьләрдәге ханым Разияның якташы иде. Ул студент кызны баласыннан артык итеп карады. Шәфкать туташлары, нянялар — барсы да аңа ягымлы булдылар. Бәлки шундый әйбәт кешеләр арасында яту, шундый миһырбанлы кешеләр кулыннан дару эчүдән тиз терелгәндер? Саубуллашканда күңел тулудан, куркып, чыгып китте. Ул чыгуга, больница каршысына трамвай килеп туктады. Исламнурова трамвайга утырмаска булды. Шәһәрнең таныш урамнарын, андагы йортларны карап баруы шундый рәхәт. Каланы чиста итеп җыештырып, флаглар эләп, бәйрәмгә әзерләп куйганнар. Шатлык кызның эченә сыймыйча, тышка бәреп чыга иде.

Соңгы хатында Сәйрин «көтәр хәлем калмады, сугыш бетү белән кайтып алам, без гел бергә яшәргә тиешбез»,— дип язган иде. Бу татлы газап Разияга күптән таныш инде. Сәйринне армиягә озаткач, аерылышуны ул күтәрә алмыйча, түшенкелеккә бирелгән иде. Көннәрне үткәреп җибәрүе шундый авыр иде ул чакта. Яшәүнең бер кызыгы, бернинди куанычы калмаган иде. Һәм шул чакта Разия ике нәзер әйтте: Берсе — нинди генә шартларда да сөйгән ярының исеменә тап төшермәскә, икенчесе, кавышкач — аңа дүрт бала үстереп бирергә: ике кыз һәм ике малай. Малайлар Сәйрингә охшаган булырга тиешләр, кызлар аның үзенә...

Разияның хәле бетә башлады. Якын-тирәдә эскәмия күренми иде. Ул кием-салымнар кибетенең таш баскычына барып утырды, Торасалып, баскычта утыруы кеше күзеннән уңайсыз иде. Ул, сумкасыннан китап алып, шуңа текәлде.

Кыз тротуардан үткән кешеләргә күз кыры белән генә карап утыра иде. Беренче Май — шундый якты, көләч бәйрәм. Сугышның актыккы көннәре. Һәркемдә илаһи бер күтәренкелек.

Ярты сәгать эчендә тротуардан илле ике кеше узды. Шуларның җидесе ирләр затыннан — берсе аяксыз, берсе кулын муенына аскан яшь солдат һәм бишесе карт кеше, кырык бише хатын-кызлар затыннан иде. Шушы вакыт эчендә Разия янынан бала җитәкләгән бер генә хатын-кыз да узмады.— «Бу бит сугыш нәтиҗәсе,— дип уйлады Разия.— Буыннар арасындагы бушлык. Аның өзелергә җитеп нечкәрүе». Кызның сабый бала җитәкләп баручы берәр хатынны күрәсе килә иде. Үзен, шуның урынына куеп, фараз итеп карар өчен кирәк иде бала җитәкләгән хатын. Бала күрү аның киләчәге өчен кирәк иде.

Разия урыныннан торды, юлын дәвам итте. Аларның кызлары озын чәчле, сөрмәле күзле, зифа буйлы булачаклар. Егетләр Разияның испан кызына охшаганлыгы турында комплимент әйтәләр иде.

Разия кызларының чәчләренә ак ефәк тасма тагып йөртәчәк. Кыска зәңгәр күлмәк, тезләренә җитеп торган чуклы ак оек кидерәчәк. Малайларның кыяфәтен Разия күз алдына китерә алмый иде әле. Алар икесе дә Сәйрин төсле булачаклар. Уллары һәр яктан да этиләренә охшаган булырга тиешләр. Киендерү мәсьәләсе инде күптән уйланган. Аларның өстендә матрос күлмәге һәм кыска чалбар булыр. Тагын бер нәрсә

турында хыяллана иде Разия: балаларын теннис уйнарга өйрәтергә. Теннис уйнаучы балаларны ул Америка кинофильмында күрде. Шундый матур, шундый күңелле иде балаларның теннис уйнавы.

Өч ел буена зарыгып көтү җиңел булмады. Разия гел Сәйрин турында гына уйлап йөрде. Очрашуны, кавышуны көтү аның яшәү ысулына, табигатенә әйләнгән иде. Бәлки шушы сагынулар, шушы өзелеп көтүләр Сәйринне үлемнән саклап алып калганнардыр? Ул бит өч ел буена, көн саен диярлек үлем белән янәшә яшәде. Җиңү көне житеп килә — Сәйрин исән калды. Аның исән калуында Разияның да катнашы бардыр, бәлки? Кызның иң зур куанычы — сөйгән ярын саклап калуында иде.

*

* *

Йокыдан Майнагашев үзе уянды. Әйтерсең аның йөрәгенә кемдер сәгать куеп калдырган иде. Торыр вакыт житү белән күз ачылды, хәтеренә сугышчан задание килеп төште. Ул җәһәт торып киенергә тотынды.

Сәләхов тормаган иде әле. Күзе ачык, түшәмгә карап ята.

— Вакыт житте,— диде Майнагашев командиры яныннан узганда.

— Дневальныйны кисәт әле, Ялчинскийны уятсын,— диде өлкән лейтенант һәм сүлпән генә киенә башлады.

— Ильин,— диде штурман дневальный янына туктап.— Безнең укчы-радистны йокыдан уят, яме. Киенү белән ашханәгә килсен.

Максим үзе юыну бүлмәсенә үтте. Кранны ачты. Битен краннан бәреп чыккан су агымына куйды. Буыннарга сихәтле салкынлык йөгерде. Тәннең күзәнәкләре йокыдан арынып уяуланып киттеләр. Максимның күңелендә балачакның бер хатирәсе калыкты.

...Ул йокыдан уянып ята. Болан тиресеннән теккән йомшак капчык эчендә шундый җылы. Тәндә йокы тәме, йокы рәхәтлеге. Куыш янындагы учакта әнисе аш әзерләп йөри. Пешеп килгән яшь итнең хуш исе куышка үтеп керә. Әнисе җыр көйли. Салкын далалар киңлегендә туган моңлы озын көй. Ара-тирә этләр шыңшып алалар. Еракта киек казлар каңгылдый. Җыр сүзләрен Максим әле дә хәтерли: «тормышың михнәтле булса да ятлардагы рәхәтлеккә алыштырма...»

Агач табакка тутырган кайнар итне күтәреп, куыш эченә әнисе килеп керде. Иртәнге аш әзер. Ит. Кипкән балык. Болан сөте. Чәй. Тундра өстен каплап торган төпсез зәңгәр күк. Киңлек. Иксез-чиксез, рәхәт, тыныч киңлек. Һәм халыкның изге хисләреннән туган озын моңлы көй. Тирә-якта ак сыртлы күкшел таулар, яшел бәрхет тышлы киң үзәннәр. Янында әнием.

Интернатта укыганда шул киңлекне, шул тауларны, әнисе пешергән тәмле итләрне сагынып, Майнагашевның төннәрен елап яткан чаклары булды. Әле дә сагына. Ләкин сагышын тышка чыгармый. Ул түзәргә өйрәнде инде. Түзәргә һәм көтәргә. Көтәргә көч житмәгән чакларда дусларыңа елышырга. Янында якын дуслар булганда сагыну газабы бераз җиңеләя. Андый чакта түзеп була. Дөньядагы иң кыйммәтле, ышанычлы һәм кадерле нәрсә — дуслык тойгысы.

Майнагашев тәнен кызарганчы коры сөлге белән ышкыды. Эчке күлмәген алыштырды. Чиста күлмәк аның тәнен рәхәтләндереп жибәрде.

Максимның күңеле ниндидер куаныч сизә иде. Ул көткән шатлык гүя кайдадыр якында гына. Аның якын булуын җаның-тәнең белән тоеп торасың шикелле. «Нинди бөек кодрәт бу яшәү — дип сөенеп куйды Максим Майнагашев.— Командир бүген соңгарак калып торды.

Авырып китмәдеме икән?» — дип сискәнеп китте штурман. Җыенып беткәч, Максим командирын көтә башлады.

*
* *

— Сезне шушында көтәм,— диде Сәләхов ашханә янына җиткәч.— Ашыйсым килми никтер.

— Очыш алдыннан медицина көчләп булса да ашарга куша,— диде Ялчинский.— Аппетит булмаса да. Русларда: «Пусть лучше пуза треснет, чем добру пропадать» дигән әйтем бар, беләсезме?

— Белсәм дә ашыйсым килми. Иртә бит әле,— диде өлкән лейтенант.

Ашханәгә кергәч, Ялчинский штурманнан:

— Командирның кәефе начар күренә, нәрсә булган аңа? — дип сорады.

— Йоклый алмый ятты,— диде Майнагашев. Официантка Люба очучыларга бризоль, сыр һәм кофе китерде, приборларны өч кешегә әзерләгән иде.

— Сәләхов соңрак киләмени? — дип сорады ул.

— Командирның тамагы тук,— диде Марсель.— Ул төшендә сине очраткан. Бергә ресторанга баргансыз. Шунда туйганчы ашаган.

Официантка көлеп куйды:

— Сезнең укчы-радистыгыз гел шаяртып сөйләргә ярата,— диде ул Майнагашевка һәм капыл гына буфетка кереп китте. Буфеттан ул кәгазь төргәк тотып чыкты.— Карыны ачкач ашар, Люба бирде дип әйтерсез Сәләховка.

Ялчинский официантканы үртәргә җыенган иде, Максим аның аягына басып өлгерде.

— Рәхмәт, Люба,— диде Майнагашев.— Син безнең экипажны һәрвакыт шулай хөрмәтлисең инде.

— Очыш алдыннан ашатмыйча чыгармаска, дигән приказ бар бит,— диде официантка бераз кызара төшеп.

Сәләхов ашханә янына җыелган ач этләргә карап тора иде.

Алар авызларын ялап сөяк көтеп утыралар иде. «Бу сугыш этләргә дә авырлык китерде»,— дип уйлады Сәйрин. Көндез ашханә янына ач балалар, гарип-гораба, карт-коры җыела. Алар, савытларын кием астына яшереп, ашханәдән чыккан очучыларга өмете югалган күзләрен мөлдерәтеп, бер сынык ипи көтәләр иде. Шуларны күрү белән Сәләховның кәефе кырыла һәм йөрәге әрни иде. Европаны тезләндерергә уйлаган корыч солдатларның ата-аналары, балалары иде болар. Гитлер аларны җирдән аерган. Илгә килгән ачлык, хәер сорашулар шул җинаятьнең нәтиҗәсе иде. Сугыш үзе әзерләгән үлемгә ияреп ачлык, ялангачлык килә.

Сәйрин ашханә янына җыелган ач балаларга карамаска тырыша иде. Шулар күренгән чакта җиңү шатлыгына кыләгә төшә иде. Сәләхов метеослужба бинасына кереп, һава торышын белеп чыкты. Һава болытлы иде. Болытның калынлыгы һәм биеклеге заданиене үтәү өчен кулай булырга тора. Сәләхов моңа сөенде. Әйбәт башланган эш, гадәттә, уңышлы тәмамлана. Аңа эскадрильяның иң яхшы самолетын бирделәр. Хәзерләнергә бөтен эскадрилья ярдәм итте. Өстәвенә һава шартлары да әйбәт. Бу хәл аны бераз шикләндереп җибәрде. «Бөтенесе дә артык яхшы булу мине нигәдер хәвефләндерә,— дип уйлады ул.— Җил генә чыгып китмәсә ярар иде».

Заданиене уңышлы тәмамлауга тулысынча шанса да, Сәләховның күңеле бөтенләй үк тыныч түгел иде. Нәрсәдер әкрен генә аның йөрәгенә шом сала, күңелендә астыртын шик пыскый иде. Биеклеккә күтәрелгәч

шик югалачак, ачык тәвәккәллек барлыкка киләчәк иде. Сәләховның шушы халәтне нәчә тапкыр сынаганы булды. Ул һәр сугышчан заданиене гадел үтәргә өйрәнде, заданиене башкарып чыгу турында алдан ук борчылмаска үзен өйрәтә алмады.

Сәйрин ашханә бинасын тагын бер кат урап чыкты. Тәрәзә яныннан узганда туктап, бер тын ашханә залына карап торды. Түшәмгә аскан хрусталь люстрадан яктылык коела иде. Шул яктылыкка күмелеп ашханәдә ике кеше ашап утыра. Сәләховның йөрәгенә сөенеч, рәхәт бер җылылык йөгерде. Шундый якын, шундый газиз иде аңа бу ике кеше. Аларның бер табында утыруларында борынгыдан калган чын якынлык һәм көчле бердәмлек сизелә иде. «Хәзер кузгалачаклар»,— дип уйлады ул экипажы турында. Дусларының ашханәдән чыгуын Сәләхов түземсезлек белән көтә башлады.

Тәрәзә каршында ялгыз юкә агачы үсә иде. Сәйрин шул агач янына туктады. Авылда, аларның баскычы төбендә, нәкъ шуның буйлы тирәк үсә. Тирәк исенә төшкәч, Сәләховның күңелендә юкә агачына карата кардәшлек тойгысы уянды. «Чит ил. Герман җире. Кешеләре — ят, телләре аңлашылмый. Ә агачлары гел безнеке шикелле,— дип уйлады Сәйрин.— Табигать нинди даһи. Ул үзенең бәрәкәтен һәр илгә, һәр халыкка тигезләп өләшкән. Беркемне кимсетмәгән, беркемгә дә артыгын бирмәгән. Ә шушы хакыйкать кешеләрне — адәм баласының комсызлыгы — җирне күбрәк эләктерер өчен күрше өлешенә керергә, аның җирен яулап алырга мәҗбүр иткән. Сугышны комсызлык тудыра. Сәбәпсез үлемнәр, кан коюлар — бары да шуннан. Җитмәгәнмени фашистларга үз җирләре?

Балачак та шушы тирәкләр кебек садә, саф, гөнаһсыз бит. Күкрәк тутырып саф һава сулыйсың, йөгерәсең, уйныйсың. Көне буе иректә, табигать кочагында. Кояш баеганда әти-әниең эштән кайта. Малларны карап абзарга япкач, Сәләховлар гаиләсе тирәк төбенә кечке чәйгә җыела иде. Табын янында шундый рәхәт. Тирәк ботаклары аша кечке йолдызлар җемелдәгәне күренә. Сәйриннең әнисе аклы яулыгын чөеп бәйләгән, янып-пешеп чәй ясый. Башта агач кашык белән чынаякларга каймак сала, аннан соң чәйнектән чәй агыза. Чәй акканда борынга хуш ис килеп бәрелә.

Әтисе табын янында һәйкәлдәй мәгърур утыра белә иде. Әйтерсең, аны патша итеп куйганнар. Аңа карау белән, «әтиебез исән чакта дөньяда бернинди афәт, гаделсезлек һәм кимсетү булмаячак» дип ышана идең. Чыннан да, ул исән чакта гаиләгә җил-яңгыр тимәде. Күп иде авылда Сәйриннең әтисеише кешеләр. Ышанычлы, нык, чыдам нигезгә корылган бәхетле гаиләләр күп иде.

Әтисенең гаилә белән идарә итүе өстенлеккә көйләнмәгән иде. Аның һәр сүзенә, кылган эш-гамәленә аллага ышанган шикелле ихлас күңелдән ышаналар иде. «Әтиегез болай эшләгәнне ярата... Әтиегез...» Иң катлаулы мәсьәләне әнә шул сүз хәл итә иде.

Әнисенең төп бурычы — гаилә мөнәсәбәтләрен, туганлык, татулык хисен саклау иде. Бу вазифасын Сәйриннең әнисе сокланырлык итеп үтәп килде. Шунлыктанмы, Сәләховлар семьясында яшәү тыныч һәм рәхәт иде. Шундый уңайлы иде гаилә куенында көн күрү.

«Барлык илләрнең җитәкчеләрен бергә җыеп, безнең баскыч янындагы тирәк төбенә утыртасы һәм әни ясаган чәйне эчертеп карыйсы иде,— дип Сәйрин юләрләрчә хыялланып куйды.— Шуннан соң да җир йөзендә гаугалар калыр идеме икән?»

Агач янында торганда Сәйрингә тынычлык инде, аның уй-хисләре кыйбласын табып, бердәм ага башладылар.

Юкә агачыннан бал исе аңкый иде. Сәйрин якынрак килеп кәүсәгә сөялде: «Без җаваплы заданиегә очабыз,— диде ул эченнән генә,— син яз җиткәч яфрак ярасың, көзен аларны җиргә коеп, кышка әзер-

ләнәсең. Син зирәк һәм мәрхәмәтле агач. Гомереңдә бер генә бөҗәккә дә зыян китергәнең юк. Без, адәм балалары, кайчан синеңчә дөрес һәм матур яши башларбыз икән? — Егет бер тын тыңланып торды.— Ярый, мин китәм,— диде Сәләхов. — Безгә исәнлек телә. Безнең кайтканны көтеп тор. Кайткач, тагын яныңа килермен. Хуш...»

Сәләхов ашханәдән чыгып килгән иптәшләренә кушылды.

*

*   *

— Сезгә кучтәнәч,— диде Ялчинский командирына төргәк сузып.
— Нәрсә бу?
— Белмим, Люба бирде. Юмарт кыз ул. Бигрәк тә сезне күрсә...
— Бу турыда кайткач сөйләшербез,— диде Сәләхов.— Максим, без барып җиткәнче болыт таралмасмы икән?
— Таралмас шикелле. Җил юк бит,— диде Майнагашев.

Җилкәләренә парашют салып, караңгылыкны ерып баручы өч егет яланда адашып калган моңсу торналарны хәтерләтә иде.

Без туганнан бирле шушы җирне таптап йөрибез. Бер караганда, бу җир бик гади тоела, очышка җыена башлагач, ул, кинәт шундый газиз, шундый кадерле булып китә. Җиргә моңа кадәр тиешле ихтирам күрсәтә алмавыңа хәтта сабыйларча үкенә башлыйсың.

Самолет тирәсендә очыш алдыннан була торган ыгы-зыгы башланган иде инде. Электромоторлар гөжелдәве өзек-өзек ишетелеп ала. Кесә фонарьларының уты кабынып-сүнеп киткәли. Авиатехникларның саран гына фикер алышулары ишетелеп куя иде.

Менә самолет моторы зырылдый башлады. Тиздән мотор тавышы тоташ үкерүгә әйләнде. «Тизлеккә чыдый алмыйча металл елый,— дип уйлады тавышны дикъкать белән тыңлап килүче укчы-радист.— Безнең экипаж очасы машинаның моторы. Әйлән, тизрәк җылын».

Очучылар самолет янына килеп туктадылар. Самолет караучы механик, старшина Карнаухов, канат өстенә тезләнеп, бензобакның бөкесен борып кертеп азаплана иде. Сәләховны күргәч, эшен ашыгып тәмамлады да җиргә сикерде:

— Иптәш өлкән лейтенант, моторларны тикшердем. Икесе дә әйбәт эшлиләр. Бензобаклар тулы. Самолет очарга әзер.

— Иптәш өлкән лейтенант, бомбалар тагылган. Бомба ташлау механизмнары төзек. Пулеметлар тикшерелгән. Боекомплект тулы комплект,— диде техник-лейтенант Ефимов.

— Рәхмәт егетләр,— диде Сәләхов һәм машина янына килеп туктаган комэск Растопчинны күргәч, аңа әзерлек турында рапорт бирергә керешге.

— Кәефләр ничек? — дип сорады майор Растопчин.

— Норма. Һава шартлары да әйбәт. Җил булу гына әзрәк борчый. Без күтәрелгәч кенә ныклап тотынмаса инде.

— Майнагаш, син бит шаманнарның ырымын беләсең. Әйт, сез әйләнеп кайтканчы болыт таралмый торсын,— диде эскадрилья командирына ияреп килгән штурман Гусев.

— Аллага тапшырдык. Ни пуха. Ни пера,— диде эскадрилья командиры тотлыгып.

Очучылар парашютларын кия башладылар.

— Команда пунктында бүген кем утыра? — диде Сәләхов.

— Полк командиры үзе. Фронт сызыгын үтмичә радиостанцияне кабыза күрмәгез,— диде майор Растопчин.

Очучылар кабиналарына күтәрелә башладылар. Сәләхов урынына менеп утырып, педальләргә аягын сузгач, Майнагашев люк капкачын ябып, стопорга куйды.

Ялчинскийның кабинасы канат артында, фюзеляжның урта өлешендә иде. Ул җилкәсе белән күтәреп, аскы люкны ачты. Эчкә керде, люк капкачын япкач, үрелеп астролюкны ачты. Кабинага ургылып саф һава керде. Оеп торган бензин исе таралды.

— Рация эшлиме? — дип сорады укчы-радисттан радиотехник Большаков.

— Сәгать кебек,— диде Марсель һәм баш бармагын тырпайтып күрсәтте.

Яңадан моторлар кабынды. Кабиналарга бензин катнаш янгын исе таралды. Очучылар эшкә керештеләр.

Пе-2 дә штурманның үз кабинасы юк иде. Штурман өчен пилот креслосы артына, уң як бортка, җыелмалы урындык кына беркетеп куйганнар иде. Майнагашев җилкәсе белән пулеметны капшап карады. Аның тезләре бомба ташлаганда кулланыла торган прицелга тиеп тора иде. Урын кысан. Штурман приборларын көйләргә кереште.

— Максим, син әзерме? — дип сорады Сәләхов,— ә син, Марсель?

— Әзер,— диде Майнагашев.

— Барсына да әзер, заданиедән кайткач аласы орденга да гимнастеркамны тишеп урын әзерләп куйдым инде.

— Тукта, Марсель, ашыкма,— диде Сәләхов һәм кабина тәрәзәсеннән ишарә ясап, механикка шасси астындагы калыпларны алырга кушты. Карнаухов, йөгереп килеп, көпчәк астындагы калыпларны дөбердәтеп сөйрәп чыгарды.

Аэродромдагылар, самолетка юл биреп, читкә тайпылдылар. Сәләхов уң як моторга көчле газ бирде. Самолет зәһәр итеп үкерде һәм теләр-теләмәс кенә урыныннан борылып кузгалды. Сәйрин аякларын тормозлардан алуга, очкыч старт ягына таба йөгерергә тотынды.

«Башланды»,— дип уйлады штурман Майнагашев.

«Тәңре, бу гамәлемне сиңа багышладым»,— дип ярым җитди, ярым шаяра төшеп дога кылды Ялчинский.

Ә бу вакытта экипаж командиры: «Болытлар гына таралмаса ярар иде»,— дип уйлый иде.

Җирдән аерылган мизгелдә очкыч беренче адымын атлаучы сабый баланы хәтерләтә. Беренче тапкыр оясыннан чыккан кош баласы да шулай була. Әле канатлар ныгымаган, көч чамалы, тәҗрибә тупланмаган. Биеклектә гаҗәп житез, кыю самолет җирдән күтәрелә башлаганда кинәт югалып кала. Хәрәкәтләре шундый сүлпән, шундый кыюсыз тоела: күтәрелеп китә алуына шикләнеп тә куясың.

Сәйриннең оча башлаганына өченче ел тулып килә иде. Тәҗрибә житәрлек. Ул Пе-2 нең бар нечкәлекләрен үзләштерде диярлек. Ә җирдән күтәрелеп киткәндә аңа самолет таралып төшәр шикелле тоелып китә иде. Курку йөрәкне чеметеп ала. Җир ерагая башлагач кына тынычланып китәсең.

Сәләхов ашыгып шассиларны җыйды. Самолетның очуына ышаныч керде. Яшәү дә шулайрак бит: максатыңа барганда өмет зуррак була.

Моторлар гөжләве, очкыч тәненең тигез дерелдәве җанга тынычлык бирә иде. Хәзер Сәләхов мөстәкыйль һәм азат иде. Һавага күтәрелгән кешегә беркем ярдәм итә дә, комачаулый да алмый. Син мөстәкыйль. Очкыч белән язмыш аша тоташкан. Өстә чиксез зәңгәр күк. Ышанычың — сәләтең. Җир кануннары аста, еракта калдылар. Алар инде буйсындыра алмыйлар.

Кинәт тирә-якны караңгылык чорнады. «Болыт эченә кердек,— дип уйлады Сәләхов,— калынлыгы күпме икән?» Тәрәзәләрнең тышкы ягыннан нечкә җепкә эверелеп су тамчылары йөгерә иде. Тылсымлы төнге күк күренде. Таңга каршы тоныклана башлаган йолдызлар яна. Курстан уңдарак Сәләховның төнге йокысын алган тулган ай эленеп тора. Очкыч иксез-чиксез бушлык сахрасында ялгызы йөзә иде. Аның эчен-

дә өч егет — сугышчан заданиене үтәргә баралар. Бөрешеп утырганнар. Сәләхов моторларның эшләвен, приборларның күрсәтүен тикшереп бара. Кулы штурвалга яткан, аяклары борылу руленең педалендә. Майнагашев маршрутның икенче этабына күчү вакытын хисаплый иде.

Корыч пропеллерлар һаваны бораулыйлар, миллион еллар буена тупланган төнге тынычлыкны җимерергә тырышалар. Тынычлык бирешми. Аны берьюлы җимереп ташларга очкычның көче җитми. Җирдә яшәү бара. Кешеләр изрәп йоклыйлар, ял итәләр. Сугыш вакытлыча каядыр поскан, яшеренгән. Ул кешеләрнең уянганын сагалый. Сугышчылар хәл җыялар. Фашистлар да ял итә. Машиналар кузгалганчы гына саклана торган табигый тынлык.

Сәйрин сугышка кадәр тынлыкның нәрсә икәнлеген аңламый иде әле. Ул чакта машина тавышы тансык тоела иде. Ул икенчедә укыганда, тынлыкны чатнатып, авыл урамына көпчәкле трактор килеп керде. Тракторны кул чабып каршы алдылар. Картлар гына нигәдер шомлана төштеләр. «Җирне ат белән сөреп тә тамак туйдыра ала идек әле. Нигә китергәннәр бу шайтан арбасын? Коръәндәге яэҗүҗ-мәэҗүҗ шушыдыр инде? Безне дөмектерергә килә, күрерсез»,— дип сыкранды күрше карчыгы. Ә хәзер шундый кечкенә тракторлардан туган танклар җир шарын изеп йөри. Чалгы чүкегәндә яисә урамнан кыңгыраулы ат үткәндә генә ватыла торган тынлыкны самолетлар тураклап күктә оча. Сәйрин сизә, кораллар туктаусыз елдан-ел дәһшәтләнә барачак. Хәзер аның кулында гына да егерме мең ат көче. Сугышның көче, җимерү мөмкинлеге туктаусыз үсә. Ә кеше һаман шул килеш. Аны бит таяк белән сугып та үтереп була.

Бомболюкларда дүрт бомба ята иде. Бомбадагы тротилларда балачакта Сәйрин ишеткән әкиятләрдәге барлык җен-пәриләр гайрәте бардыр? Корал көче һаман арта. Бу омтылышның ахыры булырмы икән?

Бомболюктагы дүрт бомбаны штурман фашистлар өстенә ташларга тиеш. Алда әле нәрсә көткәнен беркем әйтә алмый.

Алар өчәү. Өчесе дә яшь. Аларның әле берсе дә өйләнмәгән, берсенең дә башлаган эшен дәвам итәрлек балалары юк. Алда фронт сызыгы. Сызыкның теге ягында бомба ташлыйсы объект. Шул сызык аша узганда аларны ни каршылар? Сугыш — ялкын белән ут сүндерү. Исән калу турында өметләнеп үлемгә бару. Хәер, сугышны берничек тә аңлатып булмый, аны үз күзең белән күрергә кирәк. «Юк, бүтән күрергә язмасын инде»,— дип уйлады Сәләхов һәм тирә-якны күзәтергә кереште.

*
* *

Винтлар салмак кына әйләнәләр. Прибор уклары самолет дерелдәгән ритмга сизелер-сизелмәс кенә селкенгәләп куя. Очкыч фронт сызыгына якынлашып килә иде.

— Борылыр вакыт җитте. Яңа курс ике йөз сиксән өч,—диде штурман командирга. Сәләхов сул аягын алгарак этә төште, штурвалны әз генә сул якка аударды. Самолет янтайды, вираж ясап, сулга борыла башлады. Инерция көче очучыларны уң як бортка кыса иде. Ниһаять, самолет яңа курска ятты.

— Так держать! — диде Майнагашев компас угы ике йөз сиксән өчкә килеп җиткәч. Штурманның йомшак тавышы Сәләховта ышаныч уята иде.

Ул тагын болыт турында хафаланып куйды. Билгеле, бомбаны төзәп ташлау өчен болытны тишеп чыгарга туры киләчәк. Әгәр болыт калын, җиргә якын булса? Шактый хәтәр бу. Җирне күрмичә, чәпелүең бар. Шулай да Сәләхов болыт булуын тели иде. Болыт япмасы аларны зениткалардан коткарып калачак...

Самолет фронт сызыгына якынлашып килә иде. Күңелдә тынгысызлык уянды. Нервлар тагын да сизгерләнеп киттеләр. Йөрәк тибүе ешайды. Фронт сызыгын үткән чакларда синең һәр күзәнәгең хәвефне тоеп, ялвара шикелле. «Хәзер зенит снарядлары ярыла башлаячак,— дип уйлыйсың.— Ярабби, еракторак ярылса иде! Ерактарак...» Шушындый эчке ялвару фронт сызыгы аша узган саен ихтыярсыз кабатлана.

Бәләкәй чакта булган бер вакыйга Майнагашевның хәтеренә килеп төште. Максимның сеңелесе авыргач, әнисе бала янына кам-шаман чакырган иде. Тәбәнәк буйлы бер чатан карт. Куыштан башка кешеләрне куып чыгардылар. Максимның алты яшьлек сеңелесе янында шаман гына калды. Бераздан куыш эченнән барабан кагып ырым сүзләре көйләгән тавыш ишетелә башлады. Тыңлап торучылар тораташтай катып калдылар. Тавыш һаман көчәя, көчәйгән саен ырым сүзләренең тылсымы арта иде. Бервакыт табигать җанланып киткәндәй тоела башлады. Дулкынланып аккан елга тавышы ишетелә. Урман шаулый. Таулар, куышка якынлашып, тыңлап торалар шикелле. Шаман һаман көйли.

Берничә көннән Максимның сеңелесе терелде. Ул шамансыз да савыгырга тиеш булган, күрәсең. Ләкин барыбер ырым тудырган тойгы әле һаман Майнагашевның күңелендә яши иде. Өлкәнәйгән саен ышану көче кими һәм ваклана бара. Өлкәннәрнең күбесе әкренләп үзләренә кирәкле, файдалы нәрсәгә генә ышанырга өйрәнәләр. «Балачактагы саф ышануны югалтудан түгелме икән җәмгыятьтәге күп начарлыклар?» — дип уйлады Максим.

Дошман снарядлары үлем ташып торганда, Майнагашевның күңеленә балачак ышануы кире кайта иде. Снарядның куркыныч, аяусыз икәнен ул белә, шул вакытта ук аның тими үтүенә дә ихлас ышана иде. Бәлки шушы җайланыш кешеләрне акылдан шашудан саклап кала торгандыр?

Максим самолетның кайсы ноктада икәнлеген ачыкларга кереште. Вакыт буенча алар фронт сызыгына җиткән булырга тиешләр. Җил көньяк-көнбатыштан исә. Аның көче — секундына унҗиде метр. Юнәлеше—җитмеш өч градус. Маршруттан тайпылмыйча очканда алар хәзер барасы урыннан егерме дүрт километрга уңдарак булырга тиеш иделәр. Хисап буенча шулай. Чынбарлыкта икенче төрле булуы да бик мөмкин. «Нигә чынбарлык хисапка буйсынырга теләми икән?» — дип уйлады Майнагашев. Җилнең көчен, юнәлешен үлчәгәннән соң егерме ике минут вакыт үтте. Шушы вакыт эчендә һавада әллә нинди үзгәрешләр булуы мөмкин. Җир күренеп торганда ялгышлыкларны вакытында төзәтеп барырга була. Әмма җир өсте калын болыт аша күренми иде. «Бомбаларны мин җир асты заводы өстенә ташларга тиешмен»,— дип исәпләде Максим һәм радиопеленг алу өчен эфирдан маяк эзләргә кереште.

Ялчинский дикъкать белән тирә-якны күзәтеп бара иде. Үзе радиоалгыч аша аэродромда калган команда пунктын тыңлый. Әлегә бернинди дә тавыш ишетелми иде. Аэродромда экипажның әйләнеп кайтуын көтеп торалар. Алар турында уйлыйлар. Экипаж язмышы турында кайгырталар. Шушыны искә төшерү тынычлык бирә иде.

Янәшә дулкында радиостанция музыка тапшыра. Флейтаның төче тавышына кушылып, шыңшый-шыңшый саксафон елый. Саксафон тавышыннан барабан гаеп таба, күрәсең. Ул, дөп-дөп килеп музыка коралларына фәрман бирә.

Җирдә сугыш. Җирдә аһ-зар. Ә еракта, Урта диңгезнең кояш нурларына төренгән җылы ярлары буенда, акчалы кешеләр рәхәтләнеп күңел ачалар. Саксафон айгыр тавышлары чыгарып, акчалы кешеләрне типтереп яшәргә өйрәтә. «Гомер кыска, кыска — ди ул,— ашыгыгыз, ашыгыгыз. Типтереп, типтереп калыгыз!» ...Ирен югалткан хатыннарга охшатып контрабас елый: «Эх,— ди.— Бу дөньяның ни рәхәте бар? Ашагыз, эчегез — хакыйкать шунда»,— ди.

«Ә бит Освенцим, Дахау концлагерьларында меңләгән тоткыннар

үлем көтеп утыралар,— дип уйлады Ялчинский.— Мәет яндыру өчен салынган мичләрнең торбаларыннан күккә куе төтен күтәрелә...»

Укчы-радист пулеметны сул якка күчереп куйды. Истребительләр, нигәдер, шул музыка тавышы килгән яктан һөҗүм итәрләр кебек тоела иде аңа. Гомумән, бар бәла-каза шул тарафтан килә. Инде күптән шулай. Беренче бөтендөнья сугышы көнбатышта башланды. Илебезгә фашистлар шул яктан ябырылды.

Тарих дәреслекләре яулар көнчыгыштан килгән дип язалар, ә хәзер киресенчә, каршы яктан. Куркыныч килүнең юнәлеше үзгәрде...»

*

* *

Күк йөзе әлегә тыныч иде. Болытлар сизелер-сизелмәс кенә кызара башладылар. Көнчыгыш күзгә күренеп алсулана бара. Шундый саф, сабыйлар сулышыдай нәзберәк таң беленеп килә иде. Алсулана башлаган күккә озак карап торсаң фәрештәләр очканы күренер кебек.

«Мондый күккә озак карарга ярамый — алла барлыгына ышана башларсың»,— дип Сәйрин көлемсерәп куйды.

— Фронт сызыгын үтәбез,— диде штурман Майнагашев.

Очучылар дикъкать белән тирә-якны күзәтәләр. Тәнгә киеренкелек таралган. Нидер көткән йөрәкне билгесезлек чорнаган.

Болыт арасыннан яктылык бәреп чыкты һәм шундук сүнеп тә куйды.

— Ракета аттылар шикелле,— диде укчы-радист.

— Сизми калдым. Сул яктарак күренде шикелле,— диде штурман.

— Нишләп болай иртә башладылар? — диде Сәләхов.— Объект шактый ерак бит әле.

— Ун минут калды,— диде Майнагашев.

Күк һаман тыныч иде. Болыт арасыннан ара-тирә ачыклыклар күренеп китә. «Болытлар таралмаса гына ярар иде!» — дип кабат тынгысызланып алды Сәләхов.

— Ракета аттылар. Ачык күренде,— диде укчы-радист.

«Башланды,— дип уйлады Майнагашев,— урынны ачыклап өлгерергә кирәк». Җир күзгә чалыну белән штурман ориентир эзләргә кереште.

Самолетның урынын ачыклавы читен иде. Җир болыт арасындагы ачыклыктан күренә дә күздән югала. Хисаплап тапкан нокта белән канагатьләнергә туры килде.

Беренче снаряд самолеттан уңдарак ярылды. Чаткы кабынып сүнде һәм ак мамыктан ясалган гигант бүреккә охшашлы төтен эленеп калды. Шартлау дулкыны соңгарак калып килде. Ул килеп бәрелгәч, самолет кинәт сискәнеп куйды.

Снарядлар ярылу ешаеп китте. Бераздан самолетны төрле яктан ак бүрекләр чорнап алды. Очкыч дер селкенә, як-якка янтаеп-янтаеп китә иде.

— Имансызлар, эшләргә комачаулыйлар,— диде Ялчинский.— Бөтенләй күрмичә, чамалап кына аталар, мөртәтләр.

— Борылыр вакыт җитте,— диде Майнагашев.— Курс ике йөз алтмыш җиде.

Шартлаулар һаман куера, снарядлар ярылуы самолетка һаман якынная бара.

— Булмый! Өскәрәк күтәреләбез,— диде Сәләхов һәм штурвалны алга этте. Самолеттан астарак, аның бер секунд элек барган җирендә, берьюлы өч снаряд ярылды. Һава дулкыны самолетны чөеп ыргытты.

— Марсель, кара әле, койрыкка зыян килмәдеме? — дип сорады Сәләхов, самолетны көч-хәл белән курска яткыргач.

— Исән күренә,— диде Ялчинский.

Ачыклыклар отыры киңәя, болытлар сирәгәя башлады. Зениткалар

инде төзәп атарга керештеләр. Сакланыр өчен маневр ясап барырга кирәк иде.

— Командир, боевой курска ятасы җиргә якынлашабыз, өч минут калды,— диде Майнагашев.

Бомбага тотыласы объект прицельдән күренә иде инде. Алда штаб офицеры әйткән елга җәйрәп ята. Аның дугаланып борылган җирендә түгәрәк калкулык. Калкулыкның көнбатыш очын куе урман каплаган. Урман әйләнә тотылган чәнечкеле тимер чыбыкка кадәр ап-ачык күренә иде.

Ниһаять, Максим агач тартмалар өемен шәйләп алды. Өем янында бер-ике ватык тартма аунап ята иде. Берсенең тактасы кубып төшкән. Шул урыннан зур соргылт гәүдә яртылаш чыгып тора иде.

— Кеше гәүдәсе... Юк. Түгел... Таштан ясалган сын бит бу! Мәрмәр сын! — дип кычкырды Майнагашев.

Икенче ватык тартма эченнән чыгып торган мәрмәр аякларны күреп алдылар.

— Күрәм,— диде Сәләхов ачуын басарга тырышып.— Әнә, өем артында тагын бер таш гәүдә аунап ята.

Бомбага тотасы объектның мондый булып чыгуы штурманны тетрәндергән иде.

— Сыннарны маскировка өчен генә өйгәннәрдер. Урап керәбез. Бомбаларны ташларга әзер тор! — диде Сәләхов.

Снарядлар ярылуы тагын да куерды. Алар самолет янында ук шартлыйлар иде. Шартлау дулкыны очкычны туктаусыз чөеп тора. Туры барырга ирек бирми иде.

— Тизрәк борылырга тырыш! Чәкиләр безне! Курс ике йөз сиксән бер. Сулгарак ал, командир! — диде штурман.

Нәкъ шушы мизгелдә шартлау очкычны эләктереп алды.

*
* *

Сәләхов көч-хәл белән самолетны штопордан чыгарды. Һавада ут давылы кайный иде. Иелә төшеп, прицелга береккән Майнагашев:

— Сулгарак! Өч градус, өч градус сулгарак ал, командир! — дип кычкыра иде.

— Сул як мотор ютәлли башлады. Снаряд тиде, ахыры,— диде Сәләхов.— Тизрәк ташла, Максим! Ташла! Хәзер бреющийгә чумабыз.

Биеклекне үзгәртеп, җиргә сырышу, качып котылу мөмкинлеге бар иде әле. Әмма Сәләхов машинаны объектка турылап алып бара бирде. Бомба ташлаганчы курсны үзгәртергә ярамый иде.

Беренче тапкыр үткәндә Майнагашев объектны фоторәсемгә дә төшереп өлгергән иде. Бомба ташламый кайткан очракта акланырлык дәлил иде бу. Сәләхов заданиене үтәми кайтуны күз алдына китерә алмады. Гаделлек — аның канында.

— Яхшылап төзә, ишетәсеңме? — диде ул штурманга.

Нәкъ шушы мизгелдә атакага килүче истребительләр күренде.

— Мессершмитлар! — диде укчы-радист. — Дүртәү. Утыз градус, һөҗүмгә киләләр...

«Иң вакытсыз чакта»,—дип сукранып куйды Сәләхов һәм кычкырды:

— Ут ач. Марсель, якын җибәрмә! Ышаныч синдә. Максим бомба ташлый. Якын җибәрмә, ишетәсеңме?!

Укчы-радистның пулеметы өзек-өзек тыкылдарга тотынды. Мессершмитлар һаман якынаялар иде.

— Тагын бер градус сулгарак,— диде Майнагашев.— Бер генә градус. Хәзер ташлыйм.

«Их, болыт таралмаган булса! — дип кабат үкенеп куйды Сәләхов.— Көн болытлы булганда тотар идегез койрыкны!»

— Так держать, командир! — диде Майнагашев. Ул снарядлар ярылуын да, атакага килүче истребительләр турында да бөтенләй оныткан иде. Прицель окулярына төшерелгән тәре урман өстеннән объектка таба шуышып бара. Менә ул тартмалар өеменә килеп житте. Штурман хәлиткеч кнопкага басты.

Дуңгыз борынлы соргылт фугаскалар бомболюктан калкып чыктылар. Шартлаткычка беркетелгән ветрянкалар сызгырып читкә очты. Дүрт фугас, бомба койрыкларын салмак кына кыймылдатып, объектка таба очалар иде.

— Шартладылар! — дип кычкырды Ялчинский.— Аста ут ташкыны!

«Заданиене үтәдек, тизрәк борылырга кирәк»,— дип уйлады Сәләхов. Һәм ул иркенләп тын алды.

* * *

Кинәт зениткалар атудан туктадылар. Аларның туктавын Сәйрин тәне белән сизеп алды. «Үз истребительләренә тидерүдән куркалар»,— дип уйлады ул. Ялчинский һаман ата иде. Төзи, гашеткага басып ала да, яңадан прицелны көйләп ата башлый.

— Тагын бер төркем сул якта. Мессершмитлар. Кысалар! — дип кычкырды ул.

Майнагашевның да пулеметы телгә килде. Пулемет көпшәсеннән савылып чыккан утлы трасса уң як төркемгә таба сузылды.

Сәләхов штурвалны алга таба этте. Самолет аска төшә башлауга гәүдәләр авырлыгын югалтып һавада асылынып калгандай булды. Бу ыннар йомшарды. Тәннең көче бетте. «Мессершмитлар» да Пе-2 гә нырделәр.

— Кысалар! Һаман кысалар! Патроннарым аз калды! — дип зарланып куйды укчы-радист.

Сәләхов, штурвалны үзенә тартып, самолетны горизонталь очуга күчерде. Инерция көче гәүдәне утыргычка сеңдереп куйган иде.

Дошман истребительләре калышмыйча, һаман тагылып киләләр. Шуларның икесе, төркемнән аерылып, ПЕ-2 гә якыная башлады.

Ялчинский атудан туктаган иде. Истребительләр тәмам якынлашкач, ул тагын ут ачты һәм нәкъ шушы мизгелдә аның пулеметы бөтенләйгә тынып калды. Укчы-радист патрон тартмасына үрелде. Тартма буш иде. Марсель йодрыклары белән патрон тартмасын дөмбәсли башлады.

— Их-их, иң кирәк чакта! Командир, патроннарым бетте.

Атакага килүче истребительләр укчы-радистның боезапасы бетүен сизеп өлгерделәр булса кирәк, укчы-радистның пулеметлары торган секторга күчтеләр. Ара һаман азая бара. Фашист самолетларының комуфляж канатларын үрелеп кенә тотарлык шикелле иде. Алдан килүче «мессер»ның плексиглаз фонаре [1] аша сары шлемофон кигән фашист очучысының озынча йөзе ап-ачык күренеп китте.

— Сулгарак бор, командир! Бераз сулгарак бор!— дип кычкыра иде штурман. Аның пулеметыннан сузылган ут тасмасы алдагы истребительләрнең фюзеляжын кисеп керде. «Мессер»дан ялкын бөселеп чыкты һәм аны кара төтен чорнап алды.

— Берсенә эләкте, командир. Хәзер икенчесен чәким! — дип кычкырды Майнагашев. Тирә-якта ут һәм үлем кайный иде.

— «Ко-а-о-ах! Уа-а-ах! — нәкъ шушындый тавыш шлемофонның наушникларында кабат-кабат яңгырады.

— Укчы-радист нәрсәдер әйтергә тели,— диде Майнагашев.

— Ишетәм.

---

[1] Фонарь — очучының кабина түбәсе.

Укчы-радистның кабинасын дюраль стена һәм төп бензобак аерып тора иде.
— Марсель, нәрсә булды сиңа? — дип кычкырды Сәләхов укчы-радистка.
— Ко-а-о-ах!
— Ялчинский, нигә дәшмисең, командир сорый бит! — дип кабатлады штурман.
Алда күренгән «мессершмит» капыл гына аска төшеп китте. Арттагысы һаман якыная. Истребительнең очлы борыны койрыкка терәлер дәрәҗәгә җиткәч, Пе-2 нең пушкаларыннан ут бөркелде.
— Чәкедем сволочны! Тагын киләләр! Икәү калды,— диде Майнагашев.— Тагын икәү. И-их, фашист этләре!
— Ялчинский дәшми. Аңа нәрсәдер булды,— диде Сәләхов.— Марсель, нигә дәшмисең?
Снаряд укчы-радистның ярты яңагын умырып узган иде. Марсель ярасын сул кулы белән кысып тотты. Бармак арасыннан чаптырып кан ага. Авырту сизелми. Курку да юк. Тәнне ачы әрнү чорнап алган. Миләр уттай кызган.
Бугаздан кан чаптыра. Кан белән бергә яшәү, тереклек китә бара иде. Якты дөнья әкрен генә тоныклана башлады.
«Канны... канны ничек туктатырга?!. Их!»

*
* *

«Мессерлар» кинәт үзләренең кайту ягына борылдылар.
— Командир, качалар фашистлар! — диде Майнагашев.
— Бензиннәре бетте,— диде Сәләхов.— Шуңа күрә борылдылар. Хәзер зениткалар ата башлаячак.
Аның сүзен раслагандай алда берьюлы өч снаряд ярылды. Өч гигант мамык бүрек һавага эленеп калды.
Көн яктырган иде инде. Күк йөзе чалт аяз. Зенитчыларга шундый уңай.
— Аскарак төшәргә кирәк, командир,— диде Майнагашев.
— Булмый, җиргә илле метр гына калды,— диде Сәләхов.— Сул як мотор эшләми. Өскә күтәрелергә иде. Снаряд тисә, парашют белән сикерер идек, аска төшәргә ярамый. Әз генә биеклек калсын.
Сәләхов очкычны өскә күтәрергә ниятләде. «Их, мотор көчлерәк булса иде! — дип офтанып куйды ул.— Көче җитми».
Самолет янында тагын снаряд ярылды. Очкыч янтаеп китте. Уң як мотордан нindидер ят тавыш килә иде. Винт әйләнүдән туктады.
— Марсель, ишетәсеңме? Җавап бир! Марсель,— дип ялварып сорады Сәләхов.
«Әллә арадагы кабель өзелдеме икән?» — дип уйлады ул.
Каны азайган саен Марсельнең тәненә хәлсезлек өстәлә иде. Һава җитми. Үпкәдә кан. Һава сулый башлау белән үпкәдә голт-голт кан айкала. Сулыш аласы килә. Бер генә рәхәт сулыш. Сулыш — яшәү. Яшисе килә... Бер генә минутка булса да сузасы, яшәүне дәвам итәсе килә иде.
«...Әллә музыка уйныйлар инде? Аның әнисе түгелме икән? Күзне дә ачып булмый бит ичмасам! Хәл юк. Һәр җиргә кан тулган.»
«...Әтием, әнием, алма кебек ике сеңлем әз тоелды, күрәсеңме? Мине дә үтерделәр...» — Марсель Ялчинскийның соңгы фикере һәм соңгы сулышы шушы иде. Актык мәртәбә кан йотканда ул зәңгәр күктә, илаһи биеклектә иде. Егетнең гомере күктә өзелде...
Самолет калтырана башлады. Арыган, тәмам хәл беткән йөк атыныкы шикелле гәүдәсе дер селкенә иде.

— Вибрация! Нәрсә булды? Сиңа күренмиме? — диде Сәләхов штурманга.

— Снаряд,— диде Майнагашев.— Фюзеляжның калаен куптарып ыргытты.

Штурман нәрсәдер өстәмәкче иде — икенче снаряд сул як центропланда шартлады. Тирә-якка бензин чәчрәде. Икенче мизгелдә очкычны ялкын чорнап алган иде. Кызыл телләр ашыгып кабинага таба үрмәләп киләләр. Һава агымы ялкынны өзә, сыпырып ыргыта, әмма ялкын бирешми, янә кабына.

Тагын бер снаряд ярылды. Бусы Сәләховның утыргычы астында иде. Утыргыч кыйшаеп китте, аяклар педальдән шуышып төштеләр. Ялкын телләре баш өстендә бииләр. Сәйрин, аның югалтудан куркып, штурвалны кысып тотты.

— Сикерегез! Тизрәк сикерегез! — дип кычкырды ул иптәшләренә. Җавап юк иде. Сәләхов артына борылды. Майнагашев тыныч кына радиопеленгаторны көйләп азаплана.

— Сикер, янабыз! — диде ул кабинаны ялаган ялкынга күрсәтеп. Үзе авария тоткасыннан тартып, фонарьны каерып ташлады. Кабинага янгын бәреп керде. Майнагашев командирга карап елмайды, кабина читенә таба үрмәләп килде. Аягын кыйшайган утыргычка терәп туктады да талпынып сикерде, штурманның гәүдәсе самолеттан аерылып бер мәртәбә һавада бөтерелде дә, канат кабыргасына барып бәрелде.

— Макси-и-им! — дип кычкырып җибәрде Сәләхов.— И-и-их, Максим!

Сәләхов, ут кебек кызган кабинадан үрмәләп чыгып, бушлыкка чумды. Колакка бәрелеп җил сызгыра. Җир тарта. Гәүдә һавада бөтерелеп аска оча. Тирә-якта тоташ зәңгәр күк. Күзләр йомык. Куллар тотынырга теләп, һаваны айкыйлар. Тотынасы, туктыйсы килә. Сәйриннең гәүдәсе ана карнындагы бала рәвешендә бөгәрләнгән, бөрешкән иде.

«Парашютны ачарга кирәк!» — шушы фикер аның миен айкап узды. Куллар түштәге кызыл бөҗрага үрелделәр. Сәйрин җан көче белән бөҗраны тартып чыгарды. Парашютның ефәк тукымасы ранецтан агып чыгып, өскә ыргылды. «Нигә ачылмый парашют?!»

Туракланып беткән ак ефәк бәгырьләрне ачыттырып баш өстендә җилферди иде. «Снаряд ярчыгы ерткан...» Куллар запас парашютка үрелделәр. Юк... Запас парашютны сикерергә өйрәнгәндә генә бирәләр... Тирә-юньдә бушлык иде.

Өч секунд калды.

Сәләхов талпынды, галәмне кочып алырлык итеп кулларын канат итеп җәеп җибәрде. Мәңгегә җитәрлек итеп, комсызлык белән, һава йотты. Сулыш — яшәү. Зәңгәр күк, кояш... утка пешкән битнең авыртуы, күкрәктәге кайнар тойгылар — барысы да яшәү. Аста җир. Кешеләр. Тормыш. Җир котылгысыз тизлек белән якынлаша.

Бер... Ике... Өч...

Дүртенче секундта Сәйрин Сәләхов җирдә иде. Урман буе. Яшел хәтфә чирәмлек. Тирә-якта зәңгәр чәчәкләр. Шундый матур, рәхимле яшел болын Сәйриннең гәүдәсен сытты. Җир биеккә күтәрелүне өнәми. Сөяк ярчыклары егетнең итек үкчәсен үтәли тишеп чыккан иде.

Егерме яшь туларга дүрт көн калган иде аңа. Күп нәрсә калды... Күп нәрсә.

Елганың икенче ярына сырышып үскән зирек төбендә Максим Майнагашев ята иде. Аның баш очында өзелеп сандугач сайрый. Барон утарында бикләнеп калган көчекнең керсез сабый йөрәге дә афәтне сизеп алгандыр. Эт баласы чыелдап еларга керешкәндер.

Дулкынланып торган бодай кырына бер учлам кайнар көл сибелде. Язгы җил утлы көлне бодай тамырлары өстенә таратып ташлады. Мар-

сель Ялчинскийның самолетта янган гәүдәсенең көле иде бу. Янына бер йомарлам эрегән металл төшкәндә тартай кычкырудан туктаган иде. Бераздан ул да зарын яңадан башлады. Кошлар тавышына ияреп, яшәү дә дәвам итте.

Адәм җирдән яралган диләр. Өч очучы да кире җиргә кушылдылар. Җир шары — адәм балаларының төп йорты, аларның мәңгелек торагы. Җиргә кушылучылар бер гаилә булып тату яшиләр. Бу җирдә борынгы кабиләләр, готтлар, һуннулар, кыпчаклар, ненецлар тагын әллә нинди халыкларның сугыш һәм сәясәт алып киткән вәкилләре ята иде. Шулар янына тагын өч төрле халык вәкиле өстәлде.

*

* *

Бер мең тугыз йөз кырык бишенче елның тугызынчы мае көнне Сәйрин Сәләховның әнисе Миңлезифа апа ашка карчыклар җыйган иде. Карчыклар килүенә Миңлезифа апа ишегалдын чиста итеп себерде.

Сугыш елларында карчыклар мәҗлес урынына кич утыру, капка төбенә җыелып гәпләшү белән канәгатьләнеп тордылар. Бу — сугыш беткәннән соң үткәрелгән беренче мәҗлес иде. Миңлезифа апа моңа күптән хәзерләнә башлады. Көннәр җылыну белән, өмә ясап, йорт бүрәнәләрен эчке яктан пычак белән кырып юганнар иде. Карчыклар килүенә иртән явып үткән кояшлы яңгыр бал төшереп китте. Бар җирдә саф, изге чисталык хөкем итә.

Шомырт чәчәк аткан чак. Авылны хуш ис чорнап алган. Шомырт куагы тирәсендә бал кортлары очып йөри. Алар басынкы гына шатланып гөжлиләр. Баскыч төбендәге тирәкнең баллы яфраклары кояшта ялтырап тора.

Табигатькә мул, тыныч рәхәтлек иңгән. Һәр үлән бөртеге, һәр таш, һәр матдә көр һәм ифрат куанычлы шатлыкка сугарылган.

Ашка килүче карчыклар капка төбенә җиткәч, шомырт куагы янына туктап, яулыкларын төзәтәләр, бал кортлары сузган тыныч иминлек җырын тыңлыйлар да: «Ходаның иң рәхимле көннәре,— дип көрсенеп куялар. Яшьлек искә төшә, һәркемнең шомырт чәчәк атуга бәйләнешле онытылмас якты хатирәсе була.— И-и гомерләр...»

Карчыклар баскыч янында читек-кәвешләрен салалар, күлмәк изүләрен сыпырып, җиңнәрен тартып куялар. Өйгә кеше керәсен алдан белгертү өчен, иплəп кенә тамак кыралар.

Ашка бару сылтавы аларның ярты гасыр сандык төбендә тасланып яткан күлмәкләрен калкытты. Күлмәкләр шундый шәп: әби патша чорында тукылган сәрпинкәдән тегелгән, яшел бәрхет яка, изү тирәсенә ука тотылган, аяк атлавына кушылып киң итәкләр җилфердәп киткәндә, шомырт чәчәге һәм бал исенә нафталин, такта чәй, кызыл билле прәннек исе кушыла.

Аякларда яфраклы бизәкләр төшкән кызыл сәхтиян читек. Җиңел, йомшак, аякларга иркен. Биисе килгән чакта алган аяк киеме бит. Әллә шуңа күрә, читек киеп җибәрү белән, аякларның йөгерәселәре килә башлый. Почмаклап бәйләнгән яшел кәшимир яулыклар карчыкларның иңендә җиңү әләме шикелле җилфердәп бара. Йөрәкләрдә яшьлек моңы уятып, чәчүргечкә таккан талир тәңкәләр чыңлый.

«Иншалла, ашка җыелу бәхетен дә көтеп алдык»,— дип куаналар иде карчыклар.

Бусаганы атлап керү белән, ашка килүчеләр җил-җил түргә узалар да ябык янбашларын сәке читенә тезгән мендәрләргә терәп дога кылырга керешәләр. Ярыш башлана, һәр карчык догасын озаккарак сузарга, башкалардан соңрак бетерергә тырыша. Бирчәйгән бармаклар җыерчыклы битләрне сыпырып алгач, карчыклар хуҗа хатын ягына борылалар:

— Исән-сау гына торасыңмы, Миңнедифа? Йөрибед инде шунда сине бимадалап.

— Ю-ук, бер мәшәкате дә юк. Иншалла, ач тормайбыд. Ходай рәхмәтеннән ташламый. Аллага шөкер, кичә олы малаемнан хат килде. Сугыш бетә дип ядган. Түрдән уд, түрдән уд инде, Сәүрә абыстай.

— Сәйринеңнән килдемени?

— Әй-йе, шунысыннан килде. Хат эченә кәртечкәсен дә кыстырып җибәргән. Сәләмүтенә сөялеп тора. Түше тулы урдыйн. Тач атасы инде. Суеп каплаган диярсең.

Сәләховның фоторәсеме кулдан-кулга күчеп, карчыкларны әйләнеп чыга. Ихлас күңелдән, янып-пешеп мактыйлар. Авылда иң ипле, миһербанлы, аннан да зиһенле һәм уңган малай бүтән юклыгына ышана башлыйсың.

— И-и-и, тәүфигы арткыры, гөбернатыр диярсең. Җилкәсенә нәрсә аскан ул? Әстәгъфирулла! Ике җилкәсендә дә йолдыд сурәте төшкән нәмәстәкәй. Аның дур урында утырганын белгертү өчен такканнармы икән? — дип гаҗәпләнә Бәдигыльҗамал карчык.

— Сәләмүт йөртер өчен бирелгән дуәкәмәттер инде. Ярапланн тиңелте ярапланны ядусыд беркемгә дә бирмәй торганнардыр аны? — ди остабикәлек вазифасын алып баручы Сәүрә карчык.

Миңлезифа малае кош шикелле очып һавага менәргә өйрәнгән. Шушы хәл карчыкларны чиктән тыш кызыксындыра. Әллә нинди экияти фаразлар, фикерләр тудыра. Соңыннан карчыклар менә нинди нәтиҗәгә киләләр: «Ахырдаман баласы нәрсәне дә былдырыр дигән бит китап. Ахырдаман дигәннәре шушыдыр инде?»

— Улың кайтып та җитәр инде, — диде Нәфисә карчык. — Бүген иртән сугыш бетте, теге Гитлер дигәнен оясына куып кертеп дөмектердек дип радиудан сүләделәр.

— Әйдә түргә менегед, ахирәтләр, — Сәйриннең әнисе кыстый башлый. Карчыкларны дөрес урнаштыру катлаулы һәм нечкә эш. Берсен дә рәнҗетмичә, һәркайсына лаеклы урын бирергә кирәк. Ә аларның һәммәсе үзенчә лаеклы. Аннан соң кем кемне өнәмәвен, кемнең кем белән сөйләшергә яратуын, кардәшлек ягын, күршелек тойгыларын — боларның барысын да истә тотарга кирәк. Кунакларның күңелен күреп, берсен генә дә рәнҗетергә ярамый. Миңлезифа апа шушы турыда уйлый иде.

— Син, ахирәт, түргә мен инде. Абыстай, син нигә алай кыланасың? Сәке читендә утыру килешәмени? Бер ридалыгым юк. Түргә мен, яме.

Сәкегә киез салынган... Киезгә — ак җәймә. Аның өстенә кызыл дәстархан җәелгән иде.

Карчыклар табын әйләнәсенә куелган йомшак мендәрләр өстенә менеп рәхәт итеп кунакладылар. Аякларын бөкләп, итәкләрен тез астына кыстырып җайлап утырдылар. Хәзер алар һинд йогларын хәтерләтәләр иде.

*
* *

Табынга урнашып, бергәлекне сизү белән, татулык тойгысы уянды. Карчыкларның йөзләреннән канәгатьлек балкый иде.

Остабикә вазифасын үтәп йөрүче Сәүрә карчык дога укып алды. Аны Миңлезифаның өлкән улы Сәйриннең сугыштан исән котылуы шәрәфенә багышладылар. Дога кылу башланды. Карчыклар тагын битләрен сыпырдылар.

Карчыкларның тезләре өстеннән кызыл башлы озын сөлге узды. Хәзер алар үзара тоташтылар. Бер табынга утырып, бер табактан аш

ашау, патша сарайларына җыелып, тантаналы кул куюдан көчлерәк итеп берләштерә иде аларны. Йөкләмә алу, вәгъдә бирү, берләшү мәсьәләләрен борынгылар да шушы юл белән эшли килгәннәрдер.

Табын уртасына зур агач табакка бүленгән каклаган каз шулпасы килеп утырды.

— Җитешегез, кунаклар.

Башлап үрелергә беркемнең дә кыюлыгы җитмәде. Карчыкларның берсе дә үзен бу эшкә лаеклы санамый иде. Кыстау башланды. Кыстап сыйлау Миңлезифаның апасы Мәрьям карчыкка йөкләнгән иде.

— Абыстай, үрел инде. Аш суына бит. Аштан дур булып былмый, дигән бит китап.

Сәүрә карчык, бисмилласын әйтеп, кашыгын табакка сузды:

— Телләреңне йотып җибәрерлек, Миңнедифа. Төшемдә тодлы кад шулпасы ашаганымны күреп, ымсынып уянганием. Аллаһы тагалә ашсуыңа бәрәкәт, балаларыңа миһербанлык бирсен. Балаларың янында, бергә-бергә, куаныч белән, тигедлектә торырга насыйп былсын.

Карчыклар кашык чите белән генә шулпа чөмереп алалар да, авызларына капкач, иреннәрен яулык чите белән каплыйлар.

Карчыклар ашның тәме турында сөйләшәләр иде. «Элекке чакта» нинди ашлар булуын, аш-су әзерләүнең серләрен, аның куанычын искә алып, тәэсирләнәләр. Сугышка кадәр дә кытлык чаклар бик еш булды. Шуңа күрәме, бу хөрмәт карчыкларга бик тансык иде. Чиратлап Сәйриннең әнисен мактыйлар.

— Тоды җиңелрәк былмадымы икән? Салыр алдыннан кадны чайкап алганием. — Миңлезифа апа кунакларның күңелләрен күрә алмаудан куркып, ихлас дулкынлана иде. Берәүләр тозлырак ашны ярата, икенчеләр тозның җитенкерәмәвен. Табын янында утыручыларның зәвыклары өчен тәмле сүз, ягымлы йөз белән табынны сугарып торырга кирәк. Җылы мөнәсәбәт ашны тәмләтеп җибәрә.

— Миңледифа, ашка кулың җиңел синең. Нәрсә пешерсәң дә шылай тәмле была инде, — дип мактарга тотынды күршедә яшәүче Хоснури карчык. Үзен остабикә санаучы Сәүрә карчык сүзнең эчке мәгънәсен аңлатып утырды:

— Саранлык ашның бәрәкәтен ала бит ул.

— Анысы дөрес. Дөньясы шылай бит, кысынлыкка үрәндек. — дип дәвам итте Мәрьям карчык. Аның Миңлезифаны тагын да мактасы килә иде. Үзләре икәүләп, янып-пешеп кунак кыстадылар.

— Җитешегед, кунаклар. Карап утырырга куймадык, җитешегед.

Кыстау карчыкларга ошый иде. Кыстап ашату — кыстап эшләтү түгел. Кыстап ашату — ихтирам билгесе.

Ниһаять, табынга ит тураган бәрәңге килде.

*

* *

Авыр эш эшләп, саф һавада яшәгән кеше артыгын ашый алмый. Күпме азык кирәклекне аның һәр күзәнәге белә һәм вакытында ашаудан туктата. Карчыклар арасында бер генә дә иләмсез юанын күрмәссең. Чандыр, җиңел гәүдәлеләр, хәрәкәтләре кызларныкы шикелле җитез һәм салмак.

— Карале, Миңнедифа, Сәйринең сәләмүтенә утырып кайтса, аны кая куеп торырсың? Абдарга сыймай торгандыр бит ул? — дип изге беркатлылык белән сорады Бәдигыльҗамал карчык.

— Ишегалдына гына сыярлык түгел ул, дип аңлатты бедгә теге ранный былып кайткан Фәйрүдә малае. Бед аны дират янындагы чирәмлеккә илтеп куярбыд дип торабыд, — диде Сәйриннең әнисе.

— Беләм. Чирәмлеге бик матур. Җире дә коры. Бу яктан куркыр-

лык түгел. Бала-чага берәр шөребен борып ала күрмәсен дип кисәтүем генә иде,— дип акланды Бәдигыльҗамал карчык. Ниһаять, очкычка бик уңайлы урын табылды:

— Идарә кырындагы буш урынга куеп торырга былыр,— диде Нәфисә карчык.— Кәҗүннәй урын. Каланча янында гына бит. Гаптелвәли карт күд-колак былып торыр.

Әңгәмә хәзер Сәйрин тирәсендә әйләнә башлады.

— Бигрәк тә миһербанлы былды инде Сәйринең. Әүлия дә әүлия, ул да әүлия,— диде Сәүрә карчык.— Ул бит беднең Әбелкәрәм белән уйнап үсте. Шындый дирәк, шындый ягымлы ие инде. Тәрбияле ие бит. Авыдыннан бер әшәке сүд чыкканы былмады. Чебенне дә рәнҗетмәс ие.

— Дирәклек аркасында инде. Мәктәптә укытучыларыннан уддырып укып йөрде. Атасы да шындый ие бит,— дип дәвам итте Хоснури карчык.

— Районга киткәндә, бригадир Әһлулла урынына Сәйринне куеп китә торгание. Беркөнне шылай, мәш килеп борчак утап йөрибед: жилкәсенә сажин салып Сәйрин килеп чыкты. «Бәй, ни хәтле жир утагансың икән, давай, үлчәп караем әле»,— диган была. Пыр туддырып үлчәргә тотынды. Шул көнне ике нурмы утадык,— дип өстәде Бәдигыльҗамал карчык башкалардан калышмаска тырышып.

— Дөрес, Сәйрин үлчәгәндә гел икеләтә артык чыга торган ие инде,— дип эләктереп алды, моңа кадәр сүзгә катнашмыйча тыңлап кына утыручы Мәрфуга карчык.

Мәрфуга карчыкның сүзгә катнашуы көтелә иде. Сәйринне армиягә озаткан кыз — аның кызы — Разия бит. Карчыклар моны беләләр иде.

— Синең кыдың нәрсәлеккә укый соң?— дип эләктереп алдылар карчыклар.— Аны бит дипломның иң дурысын ала икән, дип сүләгәннәр иде.

— Укытучылыкка инде,— диде Мәрфуга карчык ипле генә итеп.

Моңа кадәр әңгәмәгә катнашырга батырлыгы житмичә утырган урта яшьләрдәге Гайникамал соклануын белгертте:

— Мәрфугаттәй, кыдыңның укымаган китабы, танымаган хәрефе калмагандыр инде. Шыл хәтле ничек бер башка сыеп бетә икән? Мин дә бит өч ел буе мәптүккә йөредем. Шул чакта укыганнарымның берtеге дә хәтеремдә калмаган. Әйтсәм, ышанмайлар. Чикләвек жыйганда агачтан егылып төшеп шылай хәтерседләндем.

Мәрфуга кызын мактау да Сәйриннең базарын күтәреп, Миңлезифа апаның күңелен күрүгә чамаланган иде. Карчыкларның Сәйринне Разияга өйләндерәселәре килә иде. Аларның каннарында ил-жирне таза, матур, акыллы балалар белән баету теләге кыбырсып тора иде.

*
* *

Табак төбе күренер алдыннан, карчыклар кашыкларын куеп, авызларын сөрттеләр. Кунак сыен ашап бетерергә ярамый иде. Балалар өлеше калырга тиеш. Аннан тыш, авыл карчыклары «ризык калдыру» диган бер борынгы йолага ышаналар иде. Имеш ашыңны ашап бетермичә, калдырып китсәң, бу йортка тагын киләсең, ди. Әйләнеп килгәнче калган ризык сине көтеп тора, имеш.

Ниһаять, табынга чия катнаш балан суы килде. Әчкелтем баллы, әчкәч күңелләрне ачып жибәрә торган ширбәт иде бу. Ширбәткә иярәп төш килде. Балан суыннан соң бераз сөйләшеп утырдылар. Шуннан соң гөрләшеп чәй эчтеләр. Шуның белән сый тәмамланды.

Авыл карчыклары кунакларын Европа ысулында сыйлауларын белмиләр. Алар ата-бабадан калган йола буенча эш итәләр иде. Башта закуска, аш, аштан соң ит, бәрәңге һәм дисерт. Каян үзләштерделәр

икән Европа илләрендәге гадәтләрне? Әллә, киресенчә, ерак бабаларыбызның гадәтен Европа үзләштергәнме?

— Удган атнаны Үктәбрскийгә барганием, — дип сөйли башлады Мәрьям карчык. — Каранып барам — һушым китеп егыла яздым: бер таш пылатның ишегеннән кулына комган тотып Мәймена килеп чыкты. «Бәй, күдемә күренәсеңме әллә?» — ди. Җитәкләде дә апкереп китте. Әй менәбед баскычтан, әй менәбед. «Тукта, Мәймена, дим, үләм, башым әйләнә». Шаркылдап көлә. Җен бит ул. Фатирларына менеп җиткәндә күд алдымда әҗәлләрем тора ие. Асларында тагын биш фатир. Берберсенең баш түбәләренә басып, астагыларының түшәмнәрен таптап йөриләр. «Күгәрченнәр кебек менеп кунаклагансың икән, Мәймена», — дидем үзенә.

Карчыклар шәһәрдәге сәер тормыш турында озак гәпләштеләр. Шәһәр турындагы әңгәмәне карчыклар «анда шушылай, тәмле итеп сөйләшеп былмай» дигән нәтиҗәгә килеп тәмамладылар. Эчләр бушап, тәннәр рәхәтләнеп киткәнче сөйләшүдән дә рәхәтрәк ни бар бу дөньяда?

Хәзер яшәү максаты, җан турында гөрләшәсе килә иде. Карчыклар Сәүрә карчыкны мөнәҗәт әйтергә кыстый башладылар.

— Кая ул, ю-ук, хәтерем начарланды. Диһенем тишекләнеп бетте инде. Бер нәрсә хәтеремдә калмай.

— Җылай-җылай тыңлармын дип өметләнеп килгәнием, — диде Мәрфуга ялынып. — Инде ничә ел шылай бергә җыелып мөнәҗәтләр әйтешеп утыра алмадык.

— Көттермәче инде, ахирәт, син башласаң, мин кушылам, — диде Нәфисә карчык.

Сәүрә карчык бер тын актарынды да кулдән язган бер китап сыман нәрсә чыгарды:

— Мә, Нәфисә, укы, минем күдләрем начар күрә, — диде ул.

— Ю-ук, Хөснури укысын, аның тавышы матур, — диде Нәфисә карчык.

Хөснури карчык дәфтәрне алды, кулын алга сузып, башын артка ташлап бер тын карап торды. Почмаклап бәйләнгән яулыгын аркасына шудырып куйгач, матур тавыш белән башлап җибәрде:

Сабырлыклар саф алтын дип
Борынгылар әйтеп киткән,
Шулай ук уйлап карасаң,
Сабырлыкларга ни җиткән.

Күзләр юешләнде. Йөрәк ачы һәм сихәтле итеп сыкрана башлады. Бары тик карчыкларда гына сакланып калган мөнәҗәтләрнең җан, иман, вөҗдан хакындагы борынгы хакими сүзләре салмак кына ага, йөрәккә үтеп керә, бәгырьләрне тетрәндерә иде. Карчыклар яулык читләре белән күзләрен сөртәләр. Тойгылар сыкрануы җанга кирәкле пакьлек бирә иде. Күңел тирәнлегендә кешелеклелек тойгысы уяна. Шәфкатьле буласы, игелек эшлисе килеп китә.

Күрше йорттан җиңүчеләр кайтуына өй юу өмәсенә җыелган яшь кызларның җырлаулары мөнәҗәткә килеп кушылды:

...Энҗе лә мәрҗән кызларның кул бавы,
Авыр ла җан сөйгәннәрнең булмавы...

*1979 ел.*

*Мәскәү — Истамбул — Пирей — Басра —*
*Кувәйт — Абу Даби — Таганрог*

## Тәнзилә Сәгыйтова

### Күк гөмбәзе йолдыз атып уйный

Күк гөмбәзе йолдыз атып уйный,
Җем-җем яна затлы күлмәге.
Бәхет үзе янар йолдыз булып,
Учка төшәр кебек тирбәлеп.
Әллә ничек үз иттем дә куйдым,
Карашыңнан балкып кабындым,
Чәчләреңә, мин үзем дә сизми,
Иң татлы наз белән кагылдым.
Бу сәгадәт төнге земфирамы,
Таң атуга гомре өзелгән.
Шәһрезадә булсам, экиятемне
Башлар идем шушы мизгелдән.
Сөям дисең, җавабымны көтеп,
Сулыш алмый тора тирә-юнь.
Рәхмәт сиңа, мәхәббәтең өчен,
Ихлас булган өчен теләгең.
Тик лачыннар гына оя корган
Кыя-тауга салам сукмагым.
Сөям дигән күпләр китте миннән
Өмет өзеп, арып, уфтанып.
Җан өшерлек салкын көннәрем күп,
Миләш кебек ачы көннәрем.
Беләм дисең, барыбер сөям дисең,
Уч төбендә яна йөрәгең.
Шагыйрәнә илен калдыра да
Ак юл сызып җиргә тартыла —
Әллә безнең уртак бәхет инде,
Әллә бары йолдыз атыла.

### Белмим, ничек бүләсе

*Бер алманы бишкә әй бүләек...*

Халык җыры

Миңа юкса бер алманы
Өчкә генә бүләсе.
Әллә елыйсы бу хәлгә,
Белмим, әллә көләсе.

Барысына да бөтен кирәк,
Ә алмам берәү генә.
Сүз әйталмыйм берсенең дә
Бу әрсез теләгенә.

Берсенә биргән вәгъдәм бар.
Берсе хаклы тумыштан,
Өченчесе, миңа диеп,
Алмага ук елышкан.
Икесен ничек тә булса
Күндерер, көйләр идем.
Алманы мин ансат кына
Урталай бүләр идем.
Болай бүлү өченчемә
Тагын инде ярамый.

Өлеш ярты: алмага ул
Әйләнеп тә карамый.
Төшемдә мин түм-түгәрәк
Өч бөтен алма күрәм.
Уянам да, башым тотып,
Уй диңгезенә керәм.
... Рәнҗетми балаларымны,
Иремне, шигъриятне,
Әйтегезче, ничек бүлим
Йодрык кадәр йөрәкне?

●

Кыр буйлап йөгерә кышның
Җәяүле бураннары.
Сүткән, ахры, буран кызы
Бөдрә кар толымнарын.
Толымына җилләр кушып
Матурлап үрмәкчедер.
Әнкәмнең туган көненә
Кунакка килмәкчедер.
Юлдашың булалмыйм инде,
Ак толым буран кызы,
Озатам бары иркеңә
Кызыгып, эчтән сызып.
От әле шушы җырымны,
Куш бүләк бәйләмеңә.
Мин багышлап яздым аны
Әнкәем бәйрәменә.
Сак кына шакып тәрәзен,
Кызыңның күрдем, диген.
Буран түгел, мин ул язган
Җыр булып килдем, диген.
Гадәтенчә, кабаланып,
Ул ишек ачар сиңа.
Өр-яңа шатлык булып иң
Әнкәем карашына.
Әйләнсәң, әйлән аннары
Сөенеч яшьләренә.
Бары ак бөртекләр булып
Уралма чәчләренә.

## Венера Хәбибрахманова

●

Күңелдәге якты нурлар
Күзгә төшә, йөзгә төшә,
Халык үзе сокланырлык,
Онытылмаслык сүзгә күчә.

Күңелдәге якты нурлар
Хезмәтемнән җиргә күчә,
Киң күңелле кешеләрнең
Төсе — ап-ак шәһәр үсә.

### Табигать

Күкләр күкрәп елый микән, җырлый микән?
Җирләр тетрәп сискәнәме, үкси микән?
Күл буенда дулкыннарны күзли җилкән.
Табигатьнең бар серләрен белсәң икән.

Җиһан күзе булып кояш елмаймаса,
Төннең җылы карашы күк ай булмаса,
Эссе көнне болыт каплап, яшьнәмәсә,
Барын күреп аңламасаң — яшәү нәрсә!

Мин табигать кочагында туып үстем,
Шуңа аның бар гадәте миңа күчте.
Урман — җырын, елга — моңын, таңнар — серен,
Тау горурлык бүләк итте — мин зур, көчле!

## Фирдәвес Бәширова

### Эш

Эштән кайтам. Аш-су әзерлимен,
Кайтыр диеп тиздән сөйгәнем.
Кичке сигез үтә, һаман кайтмый.
Көтү авыр бит ул — көямен.

Балалар да ятты инде менә,
Басып йөрим шуңа шым гына.
Уйланмаган уйлар уйланыла,
Аш суына, тагын җылына...

Арып кайткан. Әмма күңеле көр.
Башлый: «Беләсеңме?» дип сүзен,
«Бер линия көйсезләнә күптән.
Җайга салдык шуны без бүген.

Кайтырга да була иде инде,
Бер тотынгач, килми ташлыйсы,
Гали дус та: кабаланмыйк әле,
Кайтмыйк, диде, серен тапмыйча...»

Эш дигәндә күзләреннән нурлар
Көлтә-көлтә булып коела.
Ашыгып, бирелеп сөйли барысын да —
Ул үзе эш булып тоела.

Хөрмәт хисе тула күңелемә.
Гел шулай бул, димен эчемнән.
Ярты бәхет бит ул яраткан эш,
Ә яртысы — сөйгән кешедән.

## Фирая Хәлиуллина

### Көрәш уты ага канымда

Котырына давыл, ярсына,
Җилкәнсезләр чыкса көймәдә.
Мин җилкәнсез түгел агымда,
Давыл, миңа сагыш көйләмә.
Юк, көйләмә еллар артында
Югалтулар, сүнү хакында.
Томаннарга урап юлымны,
Бөтерелмә янар ялкында.
Бөтерелмә янап җилкәнгә,
Озын юллар аша үткәндә.
Бу җилкәнем — сөю илемне,
Яшәү рухы еллар кичкәндә.
Күңел күгем якты, чалт аяз,
Йолдыз булып хыял кабына.
Балкый алар юлны яктыртып,
Ачыласы серләр хакына.
Юк, юрама миңа югалту,
Җанда сүнмәс йолдыз янганда,
Бер көй сузсам, таулар ишетер,
Сандугачлар көнләр таңнарда.
Бөтерелә давыл, ярсына,
Уйный гүя тынмас җанымда.
Күпме җиңү хисе кичердем,
Көрәш уты ага канымда.

### Этюд

Ак канатлы аккош сыман
Тибрәнеп күкләрендә,
Төшеп куна җиргә иртә,
Талпынып күкрәгендә.
Уралып нур юлларына,
Уралып җилләренә,
Көннәргә юнәлә таңнар —
Җиремнең йөрәгенә.
Җирдә күпме кан коела,
Күпме җан ярасы бар.
Шул хисләрдә янып, көннең
Күккә юл ярасы бар.
Шуңа ахры моң сирпелә
Шатлыклы кичләремдә.
Тетрәндереп яна шәфәкъ
Узган көн төсләрендә.

## Фәһимә Галиева

### Мактама син мине

Мактама син мине юкка-барга:
Сүтсәм дә бѐр сиңа, үрсәм дә.
Яңгырамый көннең кыңгыравы,
Уттай үрсәләнеп йөрсәм дә.

Изге ниятләрем бәргәләнә
Кояш төшмәс җирдә нур булып.
Яңгырамый көннең кыңгыравы
Кош теленә күчәр җыр булып.

Язмышымны бөтен язмыш итте
Ил күзендә хезмәт-һөнәрем.
Яңгырамый көннең кыңгыравы,
Кыңгыраусыз минем көннәрем.
Мактама син мине...

●

Исемеңне куштым йолдызларга,
Йолдызларның йөзе яктырды.
Ак каенга куштым исемеңне,
Кара урман эче яктырды.

Чишмәләргә куштым исемеңне,
Чишмәләрдә шифа су артты.
Сандугачка куштым исемеңне,
Җырларыңны җырлап юатты.

●

Үз тавышың белән ту, яңа ел.
Иминлеккә булсын яңа ел.
Шакымасын кеше ел капкасын
Моңаеп та һаман сагаеп.

Үз бәхетең белән ту, яңа ел,
Хаталарын төзәт искенең.
Мин дигәнчә булмас һәрбер көнең
Үз өлешем булсын, үз көнем.

Мин дигәнчә булмас һәрбер көнең,
Булма гына каты бәгырьле.
Күңелләргә илһам бул, яңа ел,
Җырлы булсын кеше, шигырьле.

●

Җирдәге, уйдагы юлларны
Бер итә кешенең акылы.
Юлыңнан тайпылма! Акылны
Искәртә йолдызлар атылып.

●

Энҗе җыймыйм диңгез төбеннән,
Йолдыз уймыйм дөнья күгеннән.
Ак җилкәнем җилдә талпына,
Иртәгәмне даулый бүгеннән.

## Эльмира Шәрифуллина

### Табигать җимеше

Син — минем нәнием,
Табигать җимеше.
Синдә җир шарының
Йөрәге тибеше.

Синдәдер кояшның
Якты, саф нурлары,
Шуңарга ямьледер,
Нурлыдыр җир шары.

Синдәдер яңгырның
Җылысы, шифасы,
Һәр гүзәл мизгелнең
Бар матур ноктасы.

Күлләрдәй серледер
Күзләрең карасы.
Күзеңә төбәлгән
Туган ил карашы.

Син — илем үстерер
Табигать җимеше.
Синдә җир шарының
Йөрәге тибеше.

### Иреннәр

Мин эзлим бар дөнья бетереп:
Кемдә соң гөнаһсыз иреннәр?
Агачлар, чәчәкләр, игеннәр...
Апалар, җиңгиләр, килениәр,
Сездәме гөнаһсыз иреннәр?

Уйлашыйк бергәләп, килегез,
Абыйлар, кияүләр, җизниләр.
Әлеге сорауга җавапта —
Соң сезнең иреннәр ни диләр?

Миңа да, сиңа да җан өргән
Кадерле әтиләр, әниләр.
Тукта әле, мөгаен сездәдер
Иң садә, гөнаһсыз иреннәр.

Уйлыйм да, уйлыйм мин. Уйларның
Очына чыгалмыйм ничек тә.
Чү, кинәт уйларым бүлдереп,
Сабыем уянды бишектә.

Әй, минем алтыным, күз нурым,
Ничек соң башыма килмәгән?
Иң-иң саф иреннәр синдә бит,
Аларга дөньяның яңгыры,
Җиле дә, кере дә тимәгән!

## Кызларым

Туган ягым матурлыгын
Күрсеннәр, дип, кызларым,
Туган-үскән җирләремә —
Авылыма юл алдым.

Җиргә ятып тыңладылар
Җир-ана сулаганын.
Күрсәттем басу өстендә
Рәшәләр уйнаганын.

Иртә таңнарда уяттым
Таң нурын күрсеннәр, дип.
Чык суында ялан аяк
Йөгереп йөрсеннәр, дип.

Авыл ипекәе аша
Туган җир бәрәкәте
Күчсен дидем каннарына —
Әдәбе, мәнфәгате.

Алып кайттым туган якка,
Үз итсеннәр җир ямен,
Олы җанлы кешеләрнең,
Кечесенеп сөйләвен.

Күрсен авылдашларым да:
Болар — минем кызларым,
Күзгә күренгән бәхетем —
Сезнең дәвам, җырларым!

## Бикә Рәхимова

●

Кыяк үләннең чыклары
инде күптән кипкәндер,
безнең баскан эзебезне
сулар юып киткәндер.

Түгәрәк күл буйларында
Биек камыш үсәдер,
камыш буйлы җиткән кызлар
күл чәчәген өзәдер.

Кызлар көлүе яңгырап,
күл буйлары чыңлыйдыр.
Яшел күлмәкле каен-кыз
җырлыйдыр да җырлыйдыр.

Яшьлекнең ал хатирәсе —
Йөрәктән ул китәме?
Безне алыштырган кызлар —
Матур гомер итәрме?

### Балалар белән Кырлайга, Тукай янына баргач

Чыр-чу килә бала-чага,
анда чаба, монда чаба:
Кырлай урманыннан шүрәлене
Кем алдан таба?

Чү! Менә тынды бала-чага.
Алар Тукайга чәчәк сала.
Зыңлый тынлык,
Тукайның аяк очында
гөлләр гүя чыртлап яна.

Тукайның аяк очында
тюльпан яна.
...Шүрәлене күрү иде
бөтен чара.

### Шәфәкъләр кызыл-кара

Мин күпме ярдәм сорадым,
и, җаным, ишетмәдең,
чишмәдәй аккан яшемне,
иелеп, бер сөртмәдең.
Чишмә буеннан үткәндә
сандугач озатып калды,
ялгыз каршылау читен шул,
алсу булса да, таңны.
Таңда ачкан серләреңне
кичләрен сөйләп кара;
иртәгә кичкә ярамый —
шәфәкъләр кызыл-кара.
Шәфәкъләр кызыл-кара!

●

Ничә еллар ишетәм
бер үк сүзне:
«Йөрәгемне кемгә биреп, кызым, китәсе?

Йөрәгем жәл,
Йөрәгемне кемгә бирәсе?»
Ярман сугышларын гизеп йөргән,
хезмәт-хөрмәтне күп күргән
мәһабәт гәүдәле бабай,
авылдашым әйтте моны,
ил карты.

Авылымның йөзе
гел ак,
гел пакь.
Ир-затларда Сафа бабай йөрәге тибә.
Туган авылым,
горурлыгым башы синдә.

Туган халкым!
Муса Җәлил ялкын-йөрәген
безгә бирeп китте.
Биек тотыйк ул йөрәкне!
Данко, Прометейның исемнәре
шулай ерак китәр идеме,
Җир кешесе
ялкын-йөрәкләрен
үзенә алып,
ерак китмәсә?

...«Йөрәгемне кемгә бирәсе?!»

●

Туган якның яңа елы
карлы кышлы.
Күңелләр хуш, бизәп торса,
табын кырын яшел чыршы.

Энҗе-мәрҗән, вак йолдызлар —
ак кар төшә биеп кенә:
Җир бизәнә бәйрәм кичтә,
ак күлмәген киеп кенә.

Яңа елга иске елның
бар тапларын күмеп кенә.

Иске елның әрнүләре
Яңа елның бер кичендә
бетсә икән эреп кенә —
ак күлмәкне кимимме соң,
күңел моңын күмеп китсә?

Башны булмый орып ташка:
ничәнче кат Яңа елны
мин каршылыйм —
сине сөеп, синнән башка.

..................

Нәбирә Гыйматдинова

# БЕРДӘНБЕРЕМ ХАКЫНА

ПОВЕСТЬ

## I



Күрше картның карлыккан тавышына ул башын күтәрде.

— Килен, килен. Йортына ир заты инде. Көттерсәң язык булыр.

Ярый әле аның ялгыз куышына күз-колак булып торучы картлач бар. Үз уйларыннан башка, кайгы-шатлыгын уртаклашучы бердәнбер кеше бит ул Туксанар бабай. Исеме бөтенләй Туксанар да түгел, ә Сафа. Туксанар кушаматы туксанга кадәр тугыз мәртәбә ялгышып санаган өчен тагылган.

— Ашык, килен, — диде Туксанар карт, кабаланып ызанга төшкән хатынга. — Ир-ат юк-бар сүз куып йөрмәс.

Килен, каралган куллары белән җәһәт кенә яулыгын алга төшереп бәйләде дә, арт капкадан ишегалдына үтте.

«Аһ аллам...»

Хатын бер мәлгә калтыранып куйды.

Нигә киләсе итте икән? Хәерлегә генә булсын. Юк-бар өчен йорт капкасын ачмас бит.

Ишегалдының артын-алдын дигәндәй күзәтеп торган алтмыш яшьләр тирәсендәге ир кеше дә хуҗа хатынны күреп алды.

— Исәнме, Гайшә, — диде ул, каушап калган хатынга табан атлап. — Йорт-җирең төзек икән.

— Кызым белән тишек-тошыкларны ямаштырып торабыз шунда, — диде Гайшә, кара кулларын алъяпкыч кесәсенә яшереп, — өйгә узар идең, Хәлим.

— Узышлый гына кердем. Бимазаланма, Гайшә.

— Аяк өсте сөйләшү килешмәс. Ерак юл урап йөрүеңдер.

«Үзгәргән икән. Чәчләре тәмам чаларган. Картлык кына картайтамы соң адәм баласын, ел саен күпме уй өстәлә тора бит. Елмаюы гына әүвәлгечә, бит уртасы батып китә. Ул чокыр да үзгә икән инде. Йөз җыерчыклары килеп тоташкач, әллә чокыр, әллә картлык эзе икәнен аерып булмый».

— Эшеңнән дә бүлдем бугай, Гайшә!

— Эш бетәме соң?! Керер идең, чәйләп чыгар идең.

— Әйтәсе сүземне әйтим дә китим инде мин. Зират каршыннан үттем. Рәхмәт сиңа, Гайшә. Кабер рәшәткәсен зәңгәр төскә буягансың икән. Әллә кайдан күренеп тора. Рәхмәт, Гайшә.

«Һаман онытмаган икән. Картайган хәтерендә өр-яңа килеш саклый икән, я ходай. Нигә рәхмәт, нигә? Бу рәхмәт аның башына таш булып яуганын тоя бит ул. Нигә рәхмәт, нигә рәхмәт... Шуның өчен буядымыни ул рәшәткәне. Яки акланыр, гаебен юар өченме? Юк, аның өчен дә түгел. Әллә намусы кушкангамы? Юк, юк. Болай гына, вакыт табып тотынды да буяды. Бәлки башка каберләр арасында төссез килеш монаеп тормасын диптер. Шунысы дөресрәктер күрәсең, дөресрәктер...»

Хатын чыраенда үзгәреш күреп, Хәлим сүзне икенчегә борырга ашыкты.

— Гөлсирин бик күркәм, тыйнак бала. Кызны үстерә белгәнсең, Гайшә.

— Бәхете була күрсен инде. Тиңе табылсын.

— Быел бәрәңге яклары шәптәнме соң?

Гайшә кулы белән маңгай тирен сөртеп алды.

— Бер төптә өч-дүрт бәрәңге, яралганнары да бар. Яңгыр житешми бит. Үрчеп тә китәрләр иде. Әле алабута утавым иде. Азмасыннар дим.

— Ялга Гөлсирин кайтса, бергә-бергә кайнаштырырсыз инде. Өзлегеп көтмә. Безгә сугыш күрсәткәннәр дә житкән.

— Йорт мәшәкатеннән кала йөк тартмыйбыз да бит. Йорты да авыр арба шул аның. Төзәтеп тормасаң, өстеңә ава.

— Болай гомер кичерүең әйбәт әле. Абзарларыңа ир-ат кулы тиеп торган төсле. Ярый, Гайшә, хәл белим дип кенә кергән идем, узышлый гына. Исәнлектә кал.

«Китте. Ичмасам чәйгә дә жүнләп кыстый белмәдем. Чәй әзрәк жиңеллек бирер иде. Кайтасы юлы жиде чакрым бит әле. Әллә монда берәр таныш-белешенә керәме икән? Өй бусагасын атларга кыймагандыр инде. Бер өстәлгә утырып чәй эчүне дә өнәмәгәндер. Хәлсезләнеп егылса да, эһ итмәс Хәлим шул ул».

Гайшә, кытыршы кулларын угалый-угалый баскыч иңсәсенә утырды. Яңадан бакча чүбенә тотынасы килми иде аның. Шулай ук яман уйларга да бирелəсе килми иде. Ул каралты-кураны күздән кичерде, яшелчәләргә сибәргә дип әзерләгән суга текәлеп торды һәм төпле карарга килгәндәй, оегын, чүәген салып ташлап, кулына чиләк алды да өй каршындагы бакчасына керде. Берәм-берәм кыярларга, кишерләргә су сибеп чыккач, рәшәткә буендагы чәчәк түтәленә иелде.

«Кызым, кызыкаем... Чәчәк түтәлең белән генә сөйләшергә калдымыни миңа? Әле бит үткән ел гына янымда идең, чүкердәшеп чәй эчә идек. Син клубка, уенга йөгергәч, анаң яшеренеп кенә елый иде. Шатлыгыннан, кызым. Синең акыллы, сабыр булып үсүеңнән. Кайткач, елап ятуым өчен әрли идең дә, кочаклап үбә идең. Хәзер чәчәкләрең генә... Алар телсез шул, балам. Синдәй итеп анаңны үбә дә белмиләр. Ярый инде, анаңа бусы да юаныч. Атна арасын күләгә төсле итеп уздыру түгел. Менә ял көнә житәр. Жырлый-жырлый кайтып керерсең әле. Аңа хәтле гөлләреңне су белән туендырыйм».

Гайшә, эшен бетергәч, пычранган аякларын юып, оекларын киде дә, көтү каршыларга дип, урамга чыкты. Каршыдагы тау битендә утлап йөргән малларның әле кайтыр исәпләре күренми, көтүче Шиһап та, улыннан калган мәктәп сумкасын асып, әрле-бирле йөренә иде.

Гайшә Туксанар картларга керәсе итте. Карт үзе дә урамга чыгып бара икән, артыннан бер көтү халык ияргән төсле бик каты сөйләнә-сөйләнә капкадан килеп тә чыкты.

— Көтү каршылыйсы бит. Яңа туган бәрәннәр бардыр... Ә, синме бу, килен? Көтү бушанмадымы әле?

— Кузгалмаган шул әле.

— Җарар, утласыннар. Эсседә табырдан куптара алмыйсың аларны. Килеп киткән кеше изгедән ишек кактымы, килен?

— Изгедән иде. Син онытмагансыңдыр бәлки, Хәлим атлы. Безнең Түшәрдә укытты, сугыш елларыннан соң.

— Бәрәкалла. Күз күрмәү денгә кертә, денгә кертә. Таныганнар булсам, кул җылысын тояр идем. Җатрак күрдем шул, эһ, картаю нишләтә. Хәлим дисең инде, Түшәр мөгаллиме дисең. Оныткан кая. Мөгаллимнең дә нинди бит ул. Кара, белмәдем.

Туксанар карт ух-ах килгәннән соң, тамырлары бүлтәйгән кулын каш өстенә тигезеп, тау итәгенә карады.

— Җә, җай гына атлый торыйм, — диде ул. — Яшь бәрәннәр бардыр. Сәлирәне әйтәм, карт сарыгының җонын кырыкмаган. Ул хатынның үзенә челләдә тун кигезсәң, хайван хәлен сиземләр иде, кана. Син дә күк фәрештәсе түгелсең, килен. Кәҗәң сөзгәкләнгән. Майтап малаен әүмәкләткәнен үзем күрдем. Мөгезенә агач кигез дип, әйттем түгелме соң.

— Сатып кына җибәрәсе иде. Сөт тә төшерми.

— Ашыкма, килен. Буазмы әллә?

— Җиленнәре каты болай.

— Җә, үзем кереп карармын әле. Пырдымсызланма.

Зур галошын кыштыр-кыштыр өстерәп, карт Бәхет тавына юнәлде.

«Юк, бу ил карты үлмәсен, бик-бик озак яшәсен иде. Минем әти урыныңдагы кебек бит ул».

Их, ул әтилек белән әтисезлекнең янәшәлеге. Телде, телде Гайшәнең бәгырен. Кулаклар әтисен Бәшә елгасына үтереп салгач, фаҗигане сабый әле аңламаган иде. Зурлар елады, ул туп сикертте. Ә үсеп беткәч, йөрәген кайгы авырттыруын да, дөньяда эти кирәклеген дә тойды. Ярый, әнисе... Ликбезында да укытты, ятимә дә итмәде. Бәлкем Гайшә башка хәсрәт барын белмәс тә иде, сугыш башланды... Әй, дөньялары йөз төрлегә әйләнеп бетте шул. Сугышка кадәр аның чын бәхете — Мәрдәнвәре бар иде. Мәрдәнвәр... Мәрдәнвәре... Картаеп барган хатынга яшь ир хакында уйлавы әллә ничек, чөнки сугыш Мәрдәнвәрне мәңге яшь итеп җиргә күмде. Мәрдәнвәр — Гайшәнең ире иде. Сөеп, сөелеп кавышкан ире. Нибары ярты ел яшәп калдылар. Ярты ел... Әйтерсең, язмыш ярты ел бәхет вакыты биргән дә, калганын кайгы вакытына калдырган... Ярты ел, анда санаулы алты ай. Җиденче ай толлык башы... Юк, юк, җиденче, сигезенче айлар... Мәрдәнвәрнең сугышта йөргән көннәре бит. Әле ул калдырган җылының суынмаган чагы, мендәрләрнең, юрганнарның — икесенә уртак урынның кайнар чагы, өметнең бөредә чагы...

Урам уртасына басып, ерак хатирәләрен урый-урый Гайшә көтү кайтуын көтте. Тагын ялгыз өйгә керәсе булу аны өшетеп җибәрде.

«Кич утыруны да өнәмим. Әллә кешеләрдән биздемме? Юктыр ла. Уйларым тыгызмы? Бу атна арасы бик бетерештем шул. Тиктомалдан хәсрәткә чумдым. Үтәр инде ул үтүен дә... Йөрәк әллә ни сизенә, шунысы бимазалый. Әллә ни дип... ниткән сизенү инде ул тагын? Еллар исән-имин, һавалар аяз. Берни түгелдер әле, шул куе чәй ярамаудыр. Чәйне бертуктаусыз эчсәң, йөрәкне юа диләр иде, хак күрәсең. Чәй генәдер, тагын нинди кайгы ди инде... Булмаганны. Әллә нәрсәгә юрап маташмыйм ла».

Авылны болыт сыман тузанга күмеп, сарык көтүе таралды. Гайшә ала кәҗәсенең мөгезен әллә кайдан күреп алды. Чынлап та зур икән. Эчеңне тишәр, хәерсез. Агач киертәсе иде. Кызы кайтсын инде. Бергәбергә җаен табар әле.

Усал кәҗә, хуҗасын күреп, мәэлдәп җибәрде.

«Ни йон, ни сөт синнән, хайван. Зыян гына. Әйдә, уләннәрем җыйган, капкалап алырсың».

— Килен, килен! Әллә капканны терәттең инде. Йортта шаулаганыңны ишетәм. Бала кайтмагандыр бит.

— Кәҗәм белән сөйләшәм, бабай. Ныграк төрт капканы. Кулым да каты түгел, нишләп алай ябылды икән.

— Кәҗәңне карамакчы идем.

— Абзарга яптым, бабай, ишегалдына чыгарыйммы?

— Кереп кенә карармын.

Бераздан Туксанар карт абзардан изге хәбәр белән килеп чыкты:

— Йортыңа бәхет куна, килен. Кәҗәң буаз. Шөкере белән, дин Туйга азык булыр.

— И бабай, нинди туй әле ул. Гөлсиринемнең күз аткан егет-фәләне дә юк бит.

— Табылыр, табылыр. Алдан тәүфигы йөрсен.

— Бигрәк оялчан шул. Авызыннан ярым сүз алалмассың.

— Алганы кадәр житәр, килен. Егете юк димә. Сизмисеңмени, хәзер ике сикереп атлар урынга өч сикерә бала. Ызначитсә, йөрәге сикертә. Бу тикмәгә түгел, килен. Бала кемгәдер гишык-мишык тота, ахры.

— Я хода, ялгызлар ничек яшәрмен.

— Кыз баланың тавык канаты икәнен онытма, килен. Тавык суйсаң, канатын ашата идең бит үзең! Хәзер яшь коясың.

— И бабай, бала бит, һаман бала.

— Син үз бурычыңны үтәдең, килен. Үстердең, укыттың, кеше иттең. Йөзеңне буямады, аллага шөкер.

— Гөлсирин үскән саен уткәннәрне ешрак хәтергә алам. Кабергәчә сызланырмынмы икән, бабай? Яралар төзәлми, яралар...

— Кабер сине күптән кичерде, гәрчә син сөт кебек ак булсаң да. Кабер алдында син гөнаһсыз бәндәсең.

— Бабай, ә Гөлсирин кичерерме?

— Син аның анасы, килен. Аналар гөнаһлы түгел.

Гайшәнең бу кичтә күңеле мөлдерәп тулган иде. Нәкъ елга төсле. Тик елга язлар саен ярдан ташый, суын түгә. Ә Гайшә яшь чактагы сагышларга да, аннан соңгы урта яшьтәге сагышларга да охшамаган ят бер сагыш белән газаплана. Ул шулай ук элекке көннәрдән дә битәр сагыну белән кызын сагына.

Кызын... Гөлсиринен... Гөлсирин... Сәер исем. Ике гөлдән ясалган. Нәрсәне аңлата бу исем? Гайшә өчен ул тик исем, ә аның өчен... Кабердәге кеше өчен... Мәгънәсе булгандыр. Тукта әле, нигә, кызын уйлап килә торгач, кабергә барып тоташты соң Гайшәнең уе? Оныт инде, җүләр хатын, оныт! Кичеңне бозма!

«Кызым кичен ничек уздыра икән? Китап-дәфтәрдән аерылмый торгандыр инде. Әллә бүтән яшьләргә ияреп уенга төштеме икән? Менә, аралар ерагайгач, хәлен дә белеп булмый. Тамагы да ачтыр, туйганчы йокламыйдыр. Шул авылга ни дип җибәрдем икән. Түшәрдә урын булмагач кайтыр, әлегә күршедә укыта торыр дип, ронодан кушканнар бит. Ара ераклыгы гына сәбәп түгел иде инде... Хәлим анда иде... Әгәр сөйләп куйса? Кит, кит. Хәлимгә дә ышанмаска маташам икән».

Гайшә уйларыннан арына алмыйча урын җәеп ятты. «Я хода, диде ул. — Я хода». Бу сүзләрне кабатлавына бер мәл ачуы да килде үзенең. Сүз саен алланы телгә ала башлады түгелме соң? Хәер, кычкырып йөрми дә. Кычкырса да, ни ояты бар. Гөнаһ түгел. Бушанырioктаң бар икән, бушан. Әмма алла беркайчан да синең ялваруларыңны ишетмәде. Булса, ишетмәс идемени? Ялан кырларда тәгәрәп елый-елый иреңең кайтуын теләвен күрмәс идемени?

Ялан кыр, күз яшьләре Гайшәнең әле дә хәтерендә ачылып тора.

...Мәрдәнвәренең үлем кәгазен мәктәпкә китереп бирделәр. Гайшәнең туган авылында укыта башлаган көннәре иде. Йөрәк төбеннән аһ итеп өзелгән газап авазын ул хезмәттәшләренә, балаларга ишеттермәде. Чөнки кара язу күпләрнең матча ярыгына кыстырылган иде инде.

Ләкин түземлелекнең дә чиге була икән, һай авыр чиге була икән... Җаның андый чакны күлмәгенә генә түгел, йортыңа, йортыңа гына да түгел — дөньяга да сыймый. Акырып, тилереп билгесезлеккә атыласы килә, шашып аккан суларга кушылып, хәтта алардан да уздыра төшеп яшь коясы килә. Тик Гайшә елый алмады. Бәгыре катты, катты... таш булды. Тик түзәрлек рәт калмаган, ул эчтән тынып, йончыган иде. Яктыдан мәхрүм ителгән сукыр кеше сыман ул ишегалдында таптанды. Мәрдәнвәре утын ярган балтаны да, ул утырып махра төргән агач түмәрен дә капшады. Әмма еламады. Елар өчен тәндә кайнар кан хәрәкәте кирәк иде. Ә Гайшәнең тәне бозланды. Элек Мәрдәнвәре белән бергә ябынып йоклаган юрган җылы бирсә, хәзер ул салкын туфрак сыман иде. Шунда авылның имче карчыгы Мәймүнә абыстай, бисмилласын укый-укый, аның йортына аяк басты. Электән үк им-том кылып, толлардан сәдака җыйган абыстайны Гайшә бу юлы кумады.

— Толлар юатучысы, — диде ул, бетерешкән нурсыз күзләрен карчыкка төбәп һәм ялварып, — я, юат мине дә...

— Сезне юатырга аһ-һай күп дару кирәк,— диде карчык. Һәм әле берәү дә әйтмәгән яңа сүз әйтте. — Кайтыр, кайтыр алла кушса.

Димче карчык шул кайтыр сүзе өчен дә бүләк аласы иде бит, нигә Гайшәне яман юлга этәрде икән?

— Кырга чыгып аллаһы тәгаләдән сора, балам, җиргә ятып сора. Шунда гына хак тәгалә хак эшен эшләр.

— Ансыз гына эшлә, әби җаным, алласыз гына, зинһар, дим.

— Чүпрәк баш хатын, юрамалый гына сызланасың икән. Кәтмисең дә икән әле иреңне.

— Кит, кит, әби, юкны сөйләмә. Алласыз гына булмасмы диюем, мин бит укытучы.

— Булмас шул, булмас. Кырлар фәрештә канаты белән себерелгән, бер гөнаһсыз урын.

Гайшә кырга йөгерде. Җиргә тезләнеп, авызын күккә чөеп ак болытларга пышылдады.

...Гайшә сулып, агачта эләгеп калган соңгы яфрак төсле кипте дә кипте. Ике ел чамасы «дәшмәс Гайшә» кушаматы тагып йөргәч, Мәрдәнвәре төзегән нигезне бөтенләй тузгытып, менә шушы авылга укытырга килде. Өйне сүттереп, мәктәпкә утынга тапшырды, салкын классларда укыган балаларга җылы кунар ичмасам. Гайшә шунысына да бик сөенде.

Ә ят авылда аны өнәп каршыламадылар.

— Тагын тол, — диде мәктәп директоры. — Тагын хәсрәтле күзләр.

— Мин ул хәсрәтне сабыйларга күрсәтмәм, — диде Гайшә өзгәләнеп. — Качып еларга өйрәндем инде.

— Беләм, беләм. Кипмәгән күз яшьләре белән иртән эшкә килүчеләр байтак. Ә бала күңеле сездән битәр сызлана. Ул этисен югалткан һәм башка этине белми дә. Ә сез, сез хатыннар...

Нишләп Гайшәгә ябырылды бу кеше. Болай да авыр, йөз энә күкрәккә чәнчеп торганнан да битәр ич. Әгәр директор тагын бераз дәвам итсә, яшь хатынның йөрәге өзелеп төшәр сыман иде. Почмактагы өстәл артында әлегә кадәр кәгазь актарып дәшми-тынмый утыручы ир кеше кинәт шелтәле тавыш белән:

— Кәүсәрия Салиховна, бөтен кешене дә бер үлчәү тәлинкәсенә куймагыз инде, — диде.

Әллә бу шелтә тәэсир итте, әллә үз хатасын үзе таныды. Кәүсәрия Салиховна дигәннәре башка ярсымады.

— Ярый, гафу, гафу. Ачуланма, сеңлем. Өемә кил, иркенләп танышырбыз, — диде. — Ә хәзергә укыту мөдире белән яна уку елы планнарын карагыз.

Директор хатын шулай диде дә чыгып китте.

Гайшә төенчеген әле бер, әле икенче кулына авыштырып бүлмә уртасында басып калды. Иске агач диван белән өстәлдән кала башка җиһазы булмаган бу куыш хәзер аңа үз, якын кебек иде.

— Утырыгыз,— диде мөдир, Гайшәнең уйларына нокта куйгандай.

«Нишләп бирелә утырасың, нигә сугышта түгел? — дигән төсле итеп Гайшә чибәр кара егеткә карады. — Сине фәрештәләр саклады мы, әллә үзең саклан дыңмы?»

Аның башына төшкән беренче җүләр уй иде бу. Икенче җүләр уй егетнеке иде: «Калсам ни, сез толлар бәхетенә».

Гайшә астыртын уй белән чын-чынлап көрәшә-көрәшә: «Әшәке җан, әшәке! — диде. — Тол сафлыгын югалткан дисеңме әллә? Мин Мәрдәнвәремне беркемгә дә алыштырмам, бел аны!»

«Вакыт күрсәтер анысын. Ир назына сусарсың син, яшь хатын. Гөлләргә су сипмәсәң беләсеңме нишли, беләсеңме?..»

— Юу-ук! — диде Гайшә кинәт ачынып, бер мәлгә аның зиһене таралып, күз алдында диваннар, өстәлләр биеште. — Кичерегез, — диде аннан соң ул, тәмам акылына килгәч, һәм егетнең бөтенләй гөнаһсыз күзләрен күрде.

«Бу уйларның чамасы бармы икән, ходаем. Торып та, ятып та, басып та уйлыйсың».

— Сиңа хәзер аерым класс кирәк, — диде мөдир, — яшәү урыны кирәк. Гомереңне олысы-кечесе сокланырлык итеп алып барырга тиешсең син. Чөнки безгә сынмас хатын-кызлар, рухи яктан сәламәт укытучылар бик кирәк. Сугыш күпләрне урталай сындырды. Төзәтүе кыен. Без үзебез хакында онытыйк. Чөнки ил ярасы бар. Синең боларны бәлки тыңлыйсың да килмидер, бу кеше нотык укый, акыл өйрәтә, хәтта юата дисеңдер. Юк, бу сүзләрне йөрәгемнән алып әйтәм, Гайшә. Сиңа ничә яшь?

— Егерме бер.

Гайшә үз яшенә күнеккән иде инде. Ә мөдирне, мөдирдән башка тагын бик күпләрне, аның унсигез яшьтә тол калуы тетрәндерә иде.

— Егерме бер?

— Әйе, Мәрдәнвәрем үлгәндә, дөнья миңа кара шәлен япканда, унтугызның нәкъ тулган көннәре иде. Егерменчедә тол икәнлегемне белдем.

— Тол сүзен оныт, Гайшә.

— Онытсам, иремә хыянәт итәрмен төсле.

— Хәзергә оныт... Балалар хакына оныт.

— Ичмасам төс булып аңардан бала да калмады. Үкенеч, аһ үкенеч тә соң!..

Яшь Гайшә мөдир өстәленә капланып елап җибәрде. Ә хәзер карт Гайшә ул сүзенә чынлап торып үкенә. Гөлсирин ишетсә, гомер кичермәс иде бит. Гөлсиринне... Кабат яңарган бәхете, бердәнбере, аның намусы, сафлыгы.

Ә Гөлсирингә кадәр гомер арасы!.. Я ходай. Җитте, җитте! Әнә күкеле сәгать төнге уникене суга, җитте, җитте! Бу вакытта аның кызы да йоклыйдыр. Анасының борчылулары төшенә керә күрмәсен. Мең төрле уй белән йоклап киткән иде Гайшә, таң куа да килгән икән.

— Киленчәк, иренчәк! Тормадыңмы син? Карт сөякләреңне күтәрә алмыйсың.

Тушәрдә таң белән әтәч һәм Туксанар карт кына уяна. Карт, ияләнгән гадәт буенча, Гайшәнең ян тәрәзәсен шакый. Җәй буе шулай. Чөнки иртән үк малларны көтүгә куасы бар. Хәер, Гайшәнең йорт тулы терлек-туары юк. Әмма кәҗәсен озатасы бар. Аны да капкадан чыгарып җибәрәсе генә. Калганы Туксанар карт эше. Туксанар карт маллар ярата. Шуңа күрә терлекләрне авыл башына кадәр куалау да аңа җан рәхәте. Ичмасам, урам буенча барганда үзенчә сарыклар белә сөйләшеп ала. Алар да әллә кайчан бабайны танып бетергәннәр. Кетерт-кетерт атлап, колакларын торгыза-торгыза тыңлап баралар.

— Син, ала сарык, ашыкма. Бәтиең житешә алмый бит. Күзләреңне мут уйнатасың. Мәтри, ужымга чамалама. Бәтиеңне дә харап итәрсең. Әй син, Зәйни кызы. Сиңа әйтәм, балтырлы галуш кигән сарык кыз. — Карт таягы белән йомшак кына итеп кара сыйраклы ак сарыкка төртә. — Нәстә анаңны төрткәлисең. Тәкә егетләре ияртеп йөргәч, карт анаңны санга сукмый башладың, разбуйник.

Сарыкларны олы төркемгә кушкач, Туксанар карт йокысын куа алмый азапланган Шиһапка дәшә:

— Улым, урам остабикәләрен ыздабат иттем сиңа. Гайшә кәҗәсенең кыбырсык чагы. Тегеләй-болай көтүдән читкә авышса, кума син аны. Кизәнмә дә. Җай гына әртилгә куш.

— Бәрәннәр вакыты җиткәнмени? Киленнеке дисеңме, бабай? Килен генә түгел инде ул сиңа.

— Җә, тәмсезләнмә, улым. Хатын-кызны рәнҗетмә берүк. Язык булыр.

— Болай гына инде, бабай. Кызың кебек күрәсең дию ем. Тел тидерәмме соң.

Шиһап һаваны йотардай булып иснәп алгач, иңендәге чыбыркысын яман шартлатып җибәрә. Аргы очлар, түбән очлар инде кузгала башлаган көтүгә малларын чак китереп өлгертәләр.

— Озын тал чыбыгы гына кирәк бу балага, — ди карт. — Ир-атның каеш-чыбыркы тотса гайрәтләнүе ап-ачык, кана. Гөнаһсыз хайваннарны да телер. Кая, Гайшә киленгә йомышымны тапшырыйм да, каен себеркесенә менәрмен.

Гайшә коймагын, чәен өлгертеп картны көтсә дә, озаклагач, агач кисмәккә су тутыра башлады.

— Суны кояш кыздырганда ташу мәслихәт, — көттергән карт сөйләнә-сөйләнә капкадан килеп керде. — Ниемә дип аны таңнан кисмәктә сасытып яткырасың, килен. Җә, аннан ташырсың. Мине, карт кешене тыңла әле. Районга төшсәң, ике пар галуш апкайтырсың. Кыштыр-кыштыр җир сөреп җөрерлекне алма. Тиз туза андые, табаны ашала.

Гайшә, чиләген этәреп, кулын алъпкычына сөртте.

— Ничәнче размер соң?

— Җә, бау бир дә. Ыразмирны үлчәп бирим. Җарык битлене дә алма, кызым, җәме?

— Ярар, ярар, бабай.

— Мәрхүмә Җәмилә абыстаңның урыс җәрминкәсеннән алган галушын онытмадыңмы әле?

Бәхетсезлеккә каршы, Гайшә ул галошның төсен дә хәтерләми иде. Һәрхәлдә кызыл түгел, кара булгандыр ул.

— Кая ул оныту. Кап-кара, ялт-йолт итеп күзне камаштыра иде бит.

— Вәләкин җете кызыл иде шул, килен. Җәмилә абыстаңның аягы күгәрчен тәпие була да китә иде. Син алсаң, караны ал. Менәтерәк размиры.

Карт табан астыннан шудырып җепне алды да Гайшәгә сузды.

— Ярар, бабай. Авырсынмасаң кичрәк сугылырсың. Я үзем кертермен.

— Кертерсең, кертерсең, килен. Кертеп биргән бәрәкәтләрәк була. Чәйдән соң карт Гайшәнең тупаслана башлаган балтасын үткенләп бирәсе итте.

— Бала ни хәлдә икән? — диде ул тагын Гөлсиринне искә төшереп. — Япа-ялгызы хәсрәтләнә торгандыр инде.

— Әйтмә дә инде, бабай.

— Ходай күпсенмәсә, туенда утырырга исәп. Кияү янәшәсендә.

— Күпсенмәс, бабай. Акыллы кияве генә чыксын.

— Тәүфигы аяк астында ятмас, алла боерса. Күктән фәрештәләр никах укысын. Җирдәгесе соңармас. Җә, тот балтаңны. Урманга менәм әле. Җаңа себерке белән чабынасы килә. Искесе моржада кибеп ята.

— Һава бозылып тора. Яңгыр астында калма, бабай.

— Төнлә яхшы җокладым. Кул-аяк сызламады. Җаумас.

2

— Бәлки Түшәргә кадәр озатырмын, ә, Сирин?

— Озатма, әнием күрсә, ачуланыр.

— Ачуланса ни.

— Кешене ачуландырырга ярамый.

— Озаттырмасаң мин дә ачуланам!

— Юк, юк, син ачуланма, сиңа килешми. Зәңгәр күк йөзенә кара болыт килешмәгән кебек, килешми сиңа ачулану. Кал син. Мин китим.

— Син гел китәсең. Ялыңны минем белән уздырмыйсың.

— Әнием, бабам рәнҗер бит.

— Ә мәхәббәт?

— Мәхәббәт...

Кызның күзләрен каплап, куе керфекләр түбән иелделәр. Егет аның кулларына кагылды да җавап көтте.

— Әнием кушмас... Бабай да, кешеләр дә рәнҗер. Бакчадагы гөлләрем шиңәр, болындагы чәчәкләр корыр.

— Дөнья корыса да безнең мәхәббәт яшәячәк, барыбер сулмаячак.

— Юк, дөнья яшәсен. Корыган дөньяда кешеләр үләрләр, тереклек тукталыр.

— Алайса, син яшә! Мәңге яшә, дөньяда яшә! — Егет тәмам ярсып кызның кулларын ычкындырды. — Әнием дип һаман авылга таясың. Әниең синнән башка да чәй эчәдер әле.

— Алай димә. Әниемнең бердәнбере ич мин. Юанычы, куанычы, аның баласы. Әнием минем бик-бик әйбәт кеше. Теләсәң, сиңа да күрсәтермен. Ошатырсың үзең дә.

— Миңа сине ошату да җиткән.

— Син әүвәле әниемне ярат. Ул мине тудырган, үстергән. Ярат, яме.

— Бала син. Синең белән ничу сүз озайтырга. Хуш иттек. Трай тибеп йөрмә, тиз кил.

Егет борылды да, китеп барды.

— Азамат... Азамат, китмә, — дип пышылдады кыз.

Ләкин Азамат ишетмәде. Китеп барды. Егет урманга кереп күздән югалганчы карап торды Гөлсирин. Аннан соң юл читендәге тузанлы түмгәккә утырды. «Борылып та карамый. Ә үзе яратам, ди. Үзем дә тупасрак сөйләштем бугай. Кайтсын иде авылга. Ләкин әни рәнҗер шул. Ә аны рәнҗетергә ярамый. Аның турында авыл халкы матур сүзләр генә сөйли. Ул укыткан да, урман да кискән, мине дә тәрбияләгән».

Бервакыт Гөлсирин әнкәсенә ияреп урман кискән җиргә барган иде. Кечкенә генә әнисенең зур-зур агачларны аударганын күргәч,

әнкәйне беркайчан да рәнҗетмәм дип үз-үзенә ант иткән иде ул. Чыгарылыш кичәсенә әнисе ак күлмәк бүләк итте. Затлыдан булмаса да, тегелеше бик матур иде. Гөлсирин киеп карауга аһ итте. Күлмәк тапмаган һәм үтә дә килешле иде.

— Әнием, кайдан алдың? Яшереп тектем дияр идең...

— Синең өчен сакладым, кызым. Бер генә кигән идем.

— Нигә, әнкәй? Нигә бер генә мәртәбә? Ошатмадыңмыни?

— Ошаттым, кызым. Туем бер генә булганга, бер генә кигән шул.

— Аһ, әнкәй, әнкәй. Безне әти күрсә, ишетсә икән! Алтын бит син. Юк, алтын гына түгел, чәчәк син! Мәңге сулмый торганы. Сине мин, әти өчен дә яратырмын, яме. Һәм бер дә рәнҗетмәм.

— Кешеләргә мәрхәмәтле бул, кызым. Кешеләрне рәнҗетмә.

— Мин беркемне дә рәнҗетмәм, әнкәй.

Рәнҗетмәм дигән иде Гөлсирин. Менә рәнҗетте түгелме соң? Ничек? Яратуы белән. Нәрсә соң ул ярату? Гөлсиринга моны Хәлим абыйсы аңлатты. Башта егетең бармы, диде. Бар, диде кыз. Ә чынлыкта сөйгәне дә, сөелгәне дә юк иде. Алдашты. Хыялындагы батыр, матур егет ерак-еракта яшәсә дә Гөлсиринне табар төсле иде.

— Ярата белү көчле нәрсә, — диде Хәлим абыйсы.

Җүләр кызый, аңламаган иде. Инде һәммәсе дә аңлашыла ул сүзләрнең. Чөнки ул гашыйк! Кемгә? Зоотехник Азаматкамы? Их, ул шатлыклы, рәхәт беренче танышу киче. Төнге күз яшьләре... Гөлсириннең йөрәге әле дә чымырдый. Чөнки бер кечкенә генә йөрәктә шатлык белән хәсрәт кысрыклашалар. Берсе дә җиңә алмый... Ә ул кич искиткеч иде. Дус кызлары аны клубка дәшә керделәр. Өйдә бикләнеп ятма, янәсе.

«Сезнең һәркайсыгызның егете бар, мин артык сан булып йөрмим, кызлар», дисә дә, Гөлсиринне җилтерәтеп кенә алып киттеләр. Клубта, кызлар әйткәнчә, «вичыр» иде. Кичәнең дә үзгәсе. Монда көнбагыш чиертеп, ләчтит сатмыйлар, бииләр, җырлыйлар һәм, иң мөһиме, егет күзлиләр икән. Гөлсирин белән килүчеләр мич янына барып бастылар да, икесе дә мутланып, төркем-төркем торган егетләрне караштыра башладылар. Гөлсирин ишек янында япа-ялгызы бераз басып торды. Ләкин болай читләшү, сәбәпсез-нисез кызлардан аерылып калу ничектер уңайсыз иде.

Егетләрнең күз карашлары үзенә төбәлгәнне тоеп, ул дусларына таба атлады. Түгәрәк уртасыннан чыгып барганда аның кинәт тез буыннары калтырап китте.

— Нигә шуларга елмаймадың? — диде Назыйләсе. — Ыбыр-чыбыр сине килештергәндә.

— Әй, нигә кирәк алар миңа.

— Тилемсә, җегет үпмәгән җан. Безгә карама. Без синең кебек чакта көненә икешәрне ияртә идек, сугыштырып бетерә идек.

— Әйтмә дә, апаем. Яп-яшь килеш китап-дәфтәргә кадалып ятмасаң.

Кинәт кызлар шып булдылар. Ишекне каерып ачып бер егет килеп керде.

— Азамат... — диде Назыйлә, дус кызына төртеп.

— Яңа зоотехник, — диде Рәхимәсе дә, күзләрен мут уйнатып.

— Фермадагы кызларны аракысыз исертә, шайтан. Әнә биреге дә килә. Яңа кунакларны тиз күрә үзе. Очлы күз.

— Кичнең айлысы, нурлысы сезгә, Назыйләләр, Рәхимәләр. Ә миңа теләк теләп маташмагыз, нурлыларым. Иптәш кызыгызны биергә җибәрсәгез, миңа шул җиткән.

Алар вальс әйләнделәр. Әйтерсең клубта икәүдән икәү генә калып бәтереләләр. Икәү генә...

Гөлсириннең колагына:
— Бергә кайтырбыз, — дигән сүз дә ят тарафтан ишетелде кебек.
Азамат аны капка төбенә хәтле озатты. Үпмәкче иде, Гөлсирин, үзендә көч табып, читкә тайпылды.
— Аһа, — диде Азамат. — Син кыргый икәнсең.
— Беренче кичтән үк үбәргә үрелмиләр!
Хуҗа хатын аларның сөйләшүен ишетеп торган икән, соңыннан Гөлсиринга якын итеп:
— Саклан, кызым, өйләнгән кеше ул, — диде.
— Өйләнгән? Юктыр ла... ул яратам димәс иде бит, Сабира апай.
— Син яшь әле. Җүләр чагың. Тәмле телгә алданма, — диде Сабира апасы.
«Алданма, имеш, Азамат өйләнгән, имеш!»

...Гөлсирин тузан туздырып килгән машина тавышына башын күтәрде. Машина аны бераз уза төшеп туктады.
— Миңа Түшәр авылы кирәк иде, — диде тубал хәтле башын кабина тәрәзәсеннән тыккан шофер егет.
— Мин Түшәр кызы. Әйт йомышыңны.
— Миңа кызы түгел, авылы кирәк, — диде егет киреләнеп.
— Башта утырт. Күрерсең Түшәрне. Моннан өч чакрым булыр.
— Һы, җәяү кайтасың килми инде, ә? Минем машинаны шәһәр трамвае дип белдеңме әллә?
— Алайса утырмыйм, егет.
— Утыр инде, утыр, кызый. Я, утыр. Күтәреп утыртканны көтәсеңме әллә.
Кыз кабинага менеп утырды.
— Син кем? — Егет күзен әйләндереп кызга карады. Аның күзләре бик ямьсез, йөзе дә, чәчләре дә килбәтсез, борыны да зур иде.
— Ике аяклы, ике куллы кеше.
— Түшәрнең сылуы синме димәкче идем.
— Җырланган җыр.
— Җырладылармыни инде минем җырны. Вәт иманнан җәяү качкан бәндәләр. Исемең ничек?
— Гөлсирин.
— Минеке Марат Галич.
Шофер егет җор телле иде. Юл буена тәкелдәп кайтты. Һәм Гөлсиринне авыл башында төшереп калдырды.
— Мин сезгә командировкага. Әгәр очрасаң, утыртырмын, бушлай, бер тиенсез, — дип шаяртты.
Гөлсирин тубал башка йодрык селкеде.
Моннан ун-унбиш минут элек кызның күңеле Азамат турындагы уйлар белән тулган булса, туган авылында ул онытылып китте. Һәм ашыга-йөгерә авыл читендәге яшел капкалы өйләренә атлады.
Әнисе, капка төсендәге яшел күлмәген киеп, капка төбендә аны көтә иде инде.
— Әнием, — диде ул йөгергән шәпкә. — Әни җаным.
— Саумы, бердәнберем.
Ана ябык куллары белән кызын кочты. Аһ, бу бала җылысы! Бала йөрәгенең типкән тавышы! Анага тагын нәрсә кирәк соң?
— Кызыкаем. Ябыккансың димме. Күзләреңдә яшь белән хәвеф күрәм.
— Әни, мин гашыйк булдым.
Гөлсирин, әнисе кочагыннан аерылып, ишегалдына керде, пыр туздырып тавыкларны куарга кереште, этәч булып кычкырды. Анага болар тансык, бик тә тансык иде.

— Кемне яратасың? — диде ул чак кына ишетелерлек итеп, — кем ул?

— Телисеңме, әни, аның исемен өй түбәсенә менеп өч мәртәбә кычкырам.

— Акылсызым. Ярамый. Син инде укытучы.

— Ә яратырга ярый бит, әни?

— Ярый, кызым. Ул гөнаһ түгел.

— Теләсә кемне дәме, әни?

— Үзеңә тиңне, кызым.

— Ә Азамат миңа тиң, әнием. Ул чибәр. Чәче дә, күзләре дә бик матур. Өйләнгән дә бит...

— Нәрсә дисең?!

— Аера ул хатынын, теләсәм бүген, иртәгә...

Гайшә аналарча сабырлык белән:

— Тагын кабатла әле, кызым? — диде.

Кыз, күзләрен зур ачып, әнисенә карады:

— Ярату гөнаһ түгел дидең. Үзең әйттең ич, әнием.

— Тиңме соң ул сиңа, әй бала. Тиңме?

— Матур. Мин дә матур ла. Синең бердәнберең ич мин, әнием.

— Кызым. Рәнҗисемне бел. Син бала атасын тартып аласың. Син сабый авызыннан сөтен тартып аласың. Үзеңнең әтисез үскәнеңне, «әти кайтамы?» дип сораваңны хәтерлә.

— Әгәр мин яратсам?

— Андый яратуны ишетәсем дә килми.

— Их, әни, әни! Син дә аңламадың. Минем бабам гына калды.

Туксанар картларга йөгереп кереп киткән кызы артыннан озак карап торды ана. «Каны, — дигән куркыныч бер уй узды Гайшәнең башыннан. — Әгәр анасына ошаса? Ана каны балада диләр бит. Юк, юк, ул моңа түзә алмас, хурлыгыннан, көчсезлегеннән егылып үләр».

Каны... Каны ошаса! Их, Гайшә, Гайшә. Син бу очракта көчсез, бик-бик көчсез. Каны... Бу сүз аны ерак хатирәләренә тарта. Ул, бу турыда бүтән уйламаска дип, хатирәләрен хәтер сандыгына салып куйган иде бит инде... Кызы ачты... Кайтты да, Азамат өйләнгән диде, яратам диде.

## 3

...Мәктәптә Гайшәне бик теләп кабул итмәсәләр дә, ул рәнҗемәде. Беренче тормыш каршылыгы түгел иде инде.

Укыту бүлеге мөдире Хәлим, аның бишенче класска җитәкче булуын, аннан тыш дүрт класста ана теле дәресләре укытачагын әйтте. Инде Гайшәне борчыган соңгы нәрсә — фатир мәсьәләсе иде. Хәлим monысына да ачыклык кертте:

— Кәүсәрия Салиховна янына сугылырга кирәк, Гайшә. Ул берәр сүз әйтер, — диде.

— Рәхмәт инде.

— Бәлки сезне озатып куяргадыр.

Гайшә авыл уртасына салынган мәктәптән кала бер урамны да белми иде, шуңа күрә ризалашты.

Тыныч, шау-шусыз урамнардан үтеп, авыл читендәге өй каршысына туктадылар.

— Кәүсәрия Салиховна шушында тора. Ул көтәдер, мөгаен.

Ул да булмады, урам яктагы ачылмалы тәрәзәдән карт укытучының ябык, җыерчыклы йөзе күренде. Кәүсәрия Салиховна мәктәптә күргәндәге кебек салкын түгел, ә җанны эретердәй итеп елмая иде.

— Керегез, җан кисәкләрем. Нәрсә, сатлык өй караган кебек карап торасыз.

— Мин кереп тормыйм, Кәүсәрия Салиховна, вакытым юк.
Шулай диде дә Хәлим китеп барды.
— Үтте инде шул азгын янында көнең, — дип карт укытучы аны тиргәп алды.
Кәүсәрия Салиховнаның өе ярлы иде. Пыяласыз табак-савыт шкафы, китап-дәфтәрләр өелгән озын өстәл, өстәлгә каршы куелган артсыз ике урындык. Кечкенә тартма, тартма өстендә чын хуҗаларча кукраеп утырган филтәсез лампа. Кәүсәрия Салиховна китереп куйган самавар артында, пардан төссезләнә башлаган ир-ат фоторәсеме...
Кәүсәрия, Гайшәнең рәсемгә туктальуын күргәч, аклангандай:
— Бергә чәй эчкән күк тоям. Башка урынга кадакласам, гаилә исәбеннән сызып ташлаган төсле, — диде. — Я, сеңлем, чәемнән авыз ит. Юл алҗыткандыр.
Гайшә күздән кичергән өйдә башка бер нәрсә дә күренмәде. Почмак ягы, юып төсе уңган чаршау белән бүленгән, анда да олы яктан узып куелган әйбер юктыр кебек.
Ләкин ялгыз хатынның өе җылы, чиста иде. Ул Гайшәгә туган авылын, Мәрдәнвәре белән алты ай яшәп калган өен искә төшерде. Кинәт аның күзләренә яшь килде. Хәтта Кәүсәриянең үзенә каравын да сизмәде.
— Әле син туйганчы еламагансың икән, Гайшә, — диде карт укытучы, аны әллә кызганып, әллә шелтәләп.
— Кичерегез, Кәүсәрия апа. Өемне сагындым. Нигезен ташып бетереп киләләрдер инде.
— Сугыш яралары тиз генә төзәлмәс шул. Я, Гайшә, утыр. Аннан фатирыңны күрсәтермен.
Чәй янында сүз төрләндерә торгач, Гайшә кыенсынып кына бая укытучы Хәлимгә әйткән «азгын» сүзенең хикмәтен сорады.
— Рәшидә исемле. Бергә торачаксыз.
— Бергә дисезме?
— Бергә, сеңлем.
Икесе дә нигәдер тынып калдылар.
— Тол, — диде кинәт Кәүсәрия Салиховна, Гайшәне сискәндереп.— Укыта. Күптән куар идем, җәллим. Сыеныр урыны юк. Ә бозыклыгыннан һич бизми. Авылдагы ирләрне аздырып, хатыннар каргышын алып, балаларны ятим итеп яши. Сорауга җавабы әзер: «Әнә сугыштан сорагыз» — ди. Сугышка сорау бирә алмыйбыз без. Сугышка җавап кына бирәбез.
— Туган-тумачалары да юкмы соң?
— Түшәрнеке түгел, читтән килде. Үзе турында ләм-мим. Менә бит, сеңлем, сугыш кыры ирләребезне сынады, ирләребез үлделәр, әмма дошманга бирелмәделәр, ә без, хатыннар, тылда чәчләребезне йолкып елыйбыз. Ирләребезнең батырларча үлеменә азгынлык белән җавап кайтарабыз. Кайда безнең горурлык? Әле бит киләсе яшь буын бар. Балаларыбыз моны гафу итәрләрме? Син, Гайшә сеңлем, дөрес аңлый күр мине. Мәктәптә берләнбер ир заты Хәлим. Аның да сул кулы протез.
— Протез?
— Әйе, сугышта өздерде.
— Сизмәдем.
— Менә шул Хәлимнән кала барысы да хатын-кыз. Өчесенең генә ире ярым-йорты килеш әйләнеп кайттылар. Дәрес алдыннан укытучылар бүлмәсендә булам. Андагы ачы тамаша, тамаша! Кайберәүләренә дәрескә кермәскә кушам. Чөнки Рәшидәнең мәҗлесеннән соң алар айнымаганнар. Елаш-кычкырыш башлана. Һәркем бәхетсезлеген өскә куя. Кайчагында өч класста берьюлы укытам. Балалар күзенә карарга оят, оят! Алар аңламый дисеңме?

— Берәр чара күрергә кирәк!

— Ничек, сеңлем? Актив, җыелыш беләнме? Оялтыпмы. Юк-к, һич тә. Вакыт кына төзәтер. Ә Рәшидәне Хәлим юлга бастырыр, бәлкем. Ярата, ахрысы. Һәр көнне өенә сугыла. Хәер, аннан ни файда?! Алдан ук характеристика бирүемә гаҗәпләнмә, сеңлем. Син Рәшидәне мин сөйләгәнчә бик бозык кеше дип тә санама. Үз йөрәгең ничек кабул итсә, шулай күр. Инде соңгы сүзем шул: булыш син аңа, ярдәм ит.

— Тырышып карармын.

Гайшә төшкән фатир укытучылар өчен салынган кызылга буялган калай түбәле өй иде. Бу өйне «укытучылар йорты» дип йөриләр икән. Анда гел яңа килгән мөгаллимәләр торган.

Җил капкадан керә-керешкә Гайшә ишегалдына игътибар итте. Ишегалды шыр-ялангач иде. Йортның икенче башындагы койма артыннан ишетелгән бака тавышлары гына аны җанландыра кебек. Гайшә ихатаның түренә барып койма ярыгыннан карады. Алдында сирәк-мирәк күренгәләп киткән сары бака чәчәкле күл җәйрәп ята иде.

— Күле матур икән. Юкка гына койма белән каплап куйганнар.

— Күл матур иде, аккошлар да кайта иде. Инде матурлыгын җуя бара. Суы да кимеде. Бакчалар уртасында ятканга, карамыйлар да. Кибә-нитә калса, бәрәңге чәчәргә җир була бит. Бакалар да күл коруын сизенгәндәй әрнеп, шашып сайрыйлар... Бар, син кер инде.

— Хушыгыз, Кәүсәрия апа.

Гайшә өйалдына керде, күн белән тышланган ишекне шакыды. Ник шакыды? Хәтерләми. Бәлки хуҗаның үз кулы белән ишек ачуын теләгәндер. Эчтән тонык кына булып: «Кем анда?» — дигән тавыш яңгырады. Гайшә батыраеп ишекне ачты.

— Сез Гайшәме? — диде караватта чалкан яткан Рәшидә.— Сез минем фатирдашыммы? — һәм сикереп торды да, Гайшәнең кулындагы төенчегенә ябышты.

Гайшә аңа бер генә күз сирпеп алырга өлгерде. Рәшидә чандыр гәүдәле, зәп-зәңгәр күзле, иңнәренә үреп салган кара толымлы сөйкемле генә хатын иде.

— Хәлим әйтте миңа. Ялгызлыктан туйган идем чистый. Серләшергә сердәш тә кирәксенә идем.

— Мин бакаларны тыңладым әле, — диде Гайшә сүз ялгар өчен.

— Яратасыңмыни?

Рәшидә янә, нур өстенә нур өстәлгәндәй, балкып китте.

— Мин дә яратам, җаным. Алар гел бер төсле җырласалар да барыбер күңелле. Һай, нишләп ишек төбеннән кузгалмыйсың әле. Тереләп торма, әйдә, чишен. Ул арада мин самавар яңартыйм. Ай, шайтан тәпие, вакланган шакмак та беткән ләбаса. Хәзер, момент эчендә әмәллим аны. Син урнаша тор, җаным. Кем китерде бирегә үзеңне?

— Кәүсәрия апа.

— Ә, теге вобла балыгы.

— Олы кешегә алай димә инде, Рәшидә. Рәнҗетерсең.

— Рәнҗетерсең, тот! Камбала балык түгел, мишәр халык түгел, җаным. Монда мишәр хатыннарының явызлыгы! Ирләрен бәйгә куярлар иде, көчләреннән килсә.

Кич булып күз бәйләнгәнче алар табында авыл хәлләрен сөйләшеп утырдылар. Рәшидәнең күптән хатын-кыз белән сөйләшмәгәне сизелеп тора иде. Аннан соң ул аны күл буена чакырды.

— Йоклар алдыннан рәхәт була. Теләсәң җырларбыз да. Түшәрдә җырлауны гаеп санамыйлар.

Рәшидә кызлар төсле, койма аша җиңел генә күл ягына сикерде, ә Гайшә сикерергә кыймыйча торып калды.

— Көчеңнән килмәсә эшкә тотынма, диләр. Хәзер әмәллибез. — Ул

ике куллап ябышты да бер рәшәткәне кадагыннан суырып чыгарды. Ябык Гайшә бу ярыктан иркенләп сыя иде. Ул Рәшидәнең кыюлыгына сокланып та куйды. Ләкин моны телдән әйтергә ашыкмады.

Ике яшь хатын түмгәк өстенә утырдылар. Икесе дә беркавым дәшмәделәр. Туктаусыз бытбылдап торган Рәшидә кисәк кенә туктый да белә икән. Менә ул чирәмгә сузылып ятты да, күзләрен йомды. Гайшә аның керфекләре тибрәнүен күреп гаҗәпләнде, алар озын, дуга сыман бөгелеп торалар иде.

— Җырла, Гайшә, — диде Рәшидә, иреннәрен сизелер-сизелмәс кенә кыймылдатып, — бердәнбер юанычым җыр минем. Күзгегә карап елаганың яисә җырлаганың бармы? Яшь тамчылары синең моңнарыңа кушылып идәнгә тама. Әмма күз яшеннән күл җыелмый. Күз яшеннән соң кайгы таралган сыман була. Минем алай елап сагынып әйберем дә юк. Ә югалтканым бар. Син тыңлыйсыңмы, Гайшә. Сиңа ничә яшь.

— Миңа егерме бер яшь.

— Их, кызый, кызый. Әле сабый икәнсең. Ә миңа егерме сигез. Картайдым инде.

— Киресенчә. Синең янда мин картрак күренәм бугай.

— Эчтән сызма син, кызый. Күңелеңә җыя барсаң, йөзгә бәрә ул. Очраган берәүгә лыгырдап йөр. Аңламаганы чуртыма кадалсын. Аларны сүгеп тә җибәр. Күзге каршына ешрак баскала. Җырларга димим. Үзеңне җыйнарга. Сөйгәнең бармы?

— Бар иде.

— Ташладымы җир бит? Төкер шуңа. Түшәрдә менә дигән асыл егетләр бар. Бөтенесе дә синең ишеләр.

— Кирәкмәс, Рәшидә. Минем бар бит инде.

— Артыннан иярә килмәгәндер бит?

— Сугыштан кайтмады...

Рәшидә торып утырды.

— Толмы? — диде ул сакланып кына, кайнар шулпа капканда авызын пешермәскә теләгән кебек.

— Ие.

— Алайса без пар килгәнбез икән, җаным. Оныталмыйсыңмы?

— Ие.

— Мин дә. Таңнарын уянам да сызланам, төшкә керсә, озаклап елыйм. Мендәрнең мамыгына хәтле чылана. Ә минем хәл бит икенче, ул кайтып та без кавыша алмадык. Өч балалы тол хатынга йортка керде. Дустының гаиләсе иде. Үпкәләмим. Сугыш булмаса, без болай тилмерер идекмени. Ә менә мин җүләр маһы бирмәдем. Әй, типтердем дөньясында, әй типтердем... Авылның иң затлылары минеке иде. Ул түзмәде, бичара, бер кичне минем тәрәзәне какты. Кер дим. Керде. Туктат, ди. Юри аңламамышка салындым. Нәрсәне, дим. Чуалуыңны, ди. Син нәрсәгә миңа катышасың, әнә хатыныңа бәйлән, дим. Их, Гайшә җаным, белсәң иде шул минутларда ничек янганымны. Мин калырга куштым. Ул оялтып маташты. Хакым юкмыни дип кычкырдым да, күкрәгенә дөмбәсли башладым. Үзем тукмыйм, үзем елыйм. Кызганды мине, кызганды. Таңга хәтле назлап чыкты. Шундый-шундый иркәләде, әле дә иреннәремдә, муенымда аның кайнар сулыш эзен тоям, билләһи. Иртәгәсен авылдан үз-үземне куарга тиеш идем. Ә калганы... Сөйләмим әле аңысын, Гайшә. Кайчан да бер сөйләрмен. Артык катлаулы әйбер ул. Берәү дә белмәгән әйбер. Синең ирең юк шул, ирең булса, тыңламас идең әле. Әнә, Түшәр мишәрләре мине күрсәләр йөзләрен чыталар. Исәнләшмиләр дә. Әйдә, җырлыйк ичмасам. Яңгырасын Түшәрдә толлар җыры!

Рәшидә тирән итеп сулады да, җырлап җибәрде. Аның тавышы табигатьтән генә яралган саф, моңлы иде.

Уфа юллары пыяла,
Таш булса таймас иде лә.
Минем йөрәккәем яна,
Син булсаң янмас иде лә.

Кинәт өй ягыннан баскычка капланган чиләкнең дөмбердәп төшүе, ул да түгел каты-каты баскан аяк тавышлары ишетелде. Гайшә куркып Рәшидәгә сыенды.

— Әллә караклар инде, Рәшидә?

— Әй, сеңлем. Болар Түшәр агайлары. Минем ялгыз түгеллегемне белмиләр, күрәсең.

— Син аларны кумыйсыңмы?

— Дөнья бу, Гайшә.

— Дөнья имеш. Җитәр сиңа. Чынлап җитәр. Хәзер мин ул төнге каракларга әйтәм. Йөрмәсеннәр, эзләре суынсын!

Гайшә коймага табан атлаган иде инде, Рәшидә куып тотып кочаклап алды.

— Тимә, җаным, тимә. Тыныч кына китсеннәр! Син яшь әле, яшь.

Матур кичнең хәерсез тәмамлануы Гайшәнең кәефен бозды. Рәшидә ятакка урын җәйгәч тә мендәрләргә, ак җәймәләргә чирканып карады. Теләмәсә дә чирканды.

— Миңа аерым җәй, — диде ул.

Гайшәнең кемнәрдер аунаган караватта йоклыйсы килми иде.

Рәшидә идәнгә матрас ташлап Гайшәгә урын хәзерләде. Бераздан үзе дә Гайшә янына төшеп ятты. Аның шәрә тәне кайнар һәм тыгыз иде. Нинди хатын бит үзе, дип уйлады Гайшә аның турында, таза да түгел, чырадай ябык та түгел. Уртача. Артык чибәрлеге дә юк, әмма сөйкемле. Кочагыннан битәр елмаюы эретәдер моның. Мин тупас, назсыз идем. Кыз чагында ярый инде, ояласың, тартынасың. Егетеңне кочакларга кыюлык җитми. Уңайсыз кебек тоела. Ә хатын булгач... ирләргә кирәк наз үзеннән-үзе туа икән ул.

Гайшә үзе Мәрдәнвәрен рәтләп иркәли дә белмәс иде. Соңгы көнне генә сулышы беткәнче иренең ялангач тәненнән, муеннарыннан үпте.

— Үлсәм назларыңны тоймый үлгән булыр идем, — дип шаяртты ире, аннан үзе Гайшәне үбәргә тотынды...

— Нәрсә уйлыйсың, Гайшә?

— Болай гына. Җыен җүләр уй.

— Миңа кара әле, җаным. Күзләрең акыллы синең. Матур да. Апак йөзеңдә теп-тере кара күзләрең генә икән синең. Чәчең коңгырт, күзең кара, сиңа карап йөрәгем яна.

Сары ай тәрәзәнең зур өлгесеннән нәкъ алар өстенә карый иде. Гайшә ай нурына чумган Рәшидәне тагын да чибәррәк итеп күрде.

— Матур ла син, — диде ул, тамчы да көнләшмичә. — Шул гына харап итәдер сине.

— Юк, Гайшә, азгынлыгым. Әйт әле, Гайшә, балаң булса, нишләр идең? Бөтен гомереңне аңа багышлар идеңме?

— Баламда беренче иремне таныр идем. Балам алдында саф килеш калыр идем. Балам мине начарлыктан саклар иде. Ә син?

— Мин?.. Синдәй матур итеп әйтә алмыйм. Нигә синең балаң юк соң, Гайшә? Димәк, якынлыгыгыз шул хәтле, ташка үлчим генә булган. Иеме?

Гайшә кинәт кенә Рәшидәнең кинаясенә кушыласы итте.

— Берең идәндә, икенчең караватта йоклагач.

Икесе дә рәхәтләнеп көлделәр.

Шул кыска гына төндә Гайшә гаҗәеп төш күрде. Имеш аның Мәрдәнвәре чияләргә су сибә. Үзе ап-ак күлмәк кигән. Чияләр дә ак чәчәккә күмелгән, имеш. Гайшә чия чәчәген өзмәкче. «Өзмә, — ди Мәр-

дәнвәре, — әгәр өзмәсәң, безгә бу чия өчен зур бала бирәчәкләр». Гайшә тыңламый, өзеп ала, имеш. Кинәт, куак эченнән акка төренгән карчык килеп чыга да, баланы Гайшәгә суза. «Мә, ал, чия өзүче, кулыңның катылыгы өчен баланы кечерәйтеп бирәм», — ди. Гайшә биләүне ала, имеш. Анда кыз икән. Нәни генә кыз бала. «Үлмәсме соң?» — ди Мәрдәнвәр. «Анысын хатыныңнан сора инде», — ди карчык һәм томандай эреп күздән югала.

Иртән күзен ачса, баланың өндә түгел, төштә икәнен тоеп Гайшә авыр сулап куйды.

— Нигә офтанасың, кызый? — диде, инде табын әзерләргә житешкән Рәшидә. — Төшеңдә оҗмах егетләре үптеме әллә?

— Юк ла. Бер карчык бала бирде, тере бала.

— Хәзер үзең дә тере балалар янына барасың, лабаса.

— Әйе, шул. Ләкин үз куагыңнан өзелгән алма кортлы булса да тәмле бит.

— Хәсрәтләнмә, берне түгел, бишне табарсың әле.

Алар, чикмәнле бәрәңге ашаганнан соң, киенеп-ясанып мәктәпкә килделәр. Мәктәп эче шау-гөр килә, Ә Гайшә күкрәгеннән ташыган шатлыгын күтәрә алмас дәрәҗәдә дулкынлана иде. Беренче дәрескә чакырып звонок шалтырауга ул дулкынланып үзенең классына керде.

— Исәнмесез, балалар?

— Исәнмесез, апа.

Ике сүздән танышлык, якынлык башланды. Гайшә берәм-берәм һәр балага тукталып, озаклап сорашты, онытылмасын өчен блокнотына кайбер нәрсәләр теркәп барды.

Төштән соң аның башы мең төрле яңа уй, мәшәкать белән тулы иде инде. Өенә кайткач, блокнотын өстәлгә куеп, язмаларын кабат күздән кичерде. Менә анда нәрсәләр теркәлгән иде:

«Мәгъсүмәнең әтисе юк. Көзгә аягыма итек юк, ди. Тагын дүрт балалары бар». «Арсланың әнисе авыру». «Гөлҗамалның күлмәге иске». «Иркә җиңел бии, биюче булам, ди». «Шиһап дару үләннәре җыя». «Сәвиянең дәфтәрләре юк».

— Нәрсә казынасың анда? — Рәшидә караваттан тавыш бирде. — Ходай өчен ял ит. Кил, узган гомерләр турында гәп сатыйк.

— Сөйләштек бит инде, Рәшидә. Хәзер бүгенгене, иртәгәне кайгыртыйк.

— Нуҗәли балаларга тәмам бикләнмәкче буласың?

— Әйе, бердәнбер юанычым шулдыр, күрәсең, миңа.

— Төкерәм андый юанычларга. Аларны багам дип, кабергә керәсем килми әле.

— Ялгышмыйсыңмы соң?

— Карт көнемдә үкенмәм. Әй, бастым дөньяның майлы йөрәгенә диярмен. Җылынасың килсә, атыл син кайнар утка, гомер буе туңып йөргәнче әзрәк җылы той да — үл, үл, үл! Намус, намус имеш. Намус белән базарда сату итәләр. Ә мин сатулашмыйм. Мин теләгәнемне бирәм дә, алам да.

Шунда алар беренче мәртәбә сүзгә килделәр. Кич житте исә Рәшидә янына кемнәрдер килеп чыш-пыш сөйләшәләр дә Рәшидәне алып чыгып китәләр иде. Бер көнне ачылмалы тәрәзәдән Гайшә ачык ишетте.

— Синең белән кем? — диде калын ир-ат тавышы.

— Укытучы, — диде Рәшидә. — Яшь укытучы.

— Ияртмисеңмени?

— Иярер әле, вакыты житкәч.

Гайшә ачынып иренен тешләде. Аскы иренен канатканчы тешләде. Мәсхәрә, мәсхәрә... Вакыты житкәч, имеш...

Тик хәсрәтле уйларга батарга ярамый, аны иртәгә балалар көтә иде. Ул төенчеген актарып ике пар күлмәк алды һәм ашыгып сутәргә ке-

реште. Үзе сүтте, үзе уйлады. «Гөлҗамал көннәр җылы чакта кияр ичмасам. Укуын калдырмас. Салкынайта төшкәч, җылы кофтамны бирермен. Зур зурын да, ярар. Үскәч таман кофталар кияр әле. Мәгъсүмәгә ни кигезергә соң? Бәлки мәктәп ярдәм итәр. Мәктәпнең дә хәле мөшкел шул. Утыны аз икән. Завхоз Туксанар кискән утын гына җитәме инде. Әллә Гайшәгә дә урман эшенә баргаларгамы? Дәресләрдән соң өч-дүрт сәгать кайнашса да файда ич. Урман кисмәгән кеше түгел».

Рәшидәгә үзенең фикерен белдергәч, тегесе кычкырып көлде.

— Җитмеш яшьлек әби хәлендә каласың киләме әллә, җүләр хатын?!

— Аның нинди авырлыгы бар?

— Хатын-кызга бер килограмм йөк тә авыр, җанашым.

— Ләкин сугыштан соң...

— Чуртыма кадалыгыз инде, акыллы сүзләрегез белән!

Кадалмады билгеле Гайшә. Урман эшенә дә йөрде. Анда Туксанар кебек киң күңелле кешеләр белән танышты. Ахырдан бик тә булышты аңа бу карт. Һич онытмас Гайшә.

Яшь хатынның тормышы җай гына ага, күп вакыт балалар арасында үтә иде. Дөрес, ул да төннәрен еш сызланды. Мәрдәнвәре белән саташты. Күңеле белән очып-очып авылына кайтты. Күрәсең, йөзенә сары булып сагыш иңә торды. Моны сизгер йөрәкле Рәшидә сизеп тә алды.

— Абау, Гайшә, абау җаным, сары чире иярдеме әллә үзеңә?

— Соңгы айларда кәефсез чагым шул.

— Хет берәрсен ярат, тилебәрән орлыгы ашаган нәстәкәй, иләәштерсәң мишәйт итми ул. Җаныңны талаганчы типтереп кал.

— Үтәр әле. Баш авыртуы гына бу.

— Төннәрен мендәреңне чәйнәвең ашыйсы килгәннән диярсеңме?

— Теш сызлаганнан.

— Пешмәгән, мулла кызы.

Гайшәнең икенче сызланган җире дә бар — ул Рәшидә үзе иде. Тәкәббер хатын җае чыккан саен Гайшәгә бәйләнде. Хәер, Рәшидә өчен мазаланган Хәлим дә бар иде. Ул протез кулын селкеп, һәр кичне килеп җитә, һәр кичне Рәшидәне очрата алмый, ләкин сер бирми иде. Тора-бара бу акыллы егетне Гайшә сагынып көтә башлады. Аның белән сөйләшеп утырулары бик рәхәт иде. Алар киләчәк турында сөйләшергә яраталар иде. Хәлим кайтып китсә, Гайшә ямансулап кала һәм куркынып: «Әллә ошата башладым инде, я ходай»,— дип уйлый иде. Аның бу мәхәббәте Мәрдәнвәрне яратканга һич .тә охшамаган, әллә нинди серле, томанлы иде.

«Юк, бу мәхәббәт җавапсыз булып тик үз йөрәгемдә генә калыр, аны беркем дә сизмәс, хәтта Хәлим дә. Мин Мәрдәнвәрнеке ич. Мәрдәнвәрне онытмам, исеме белән яшәрмен дип ант иттем, ләбаса. Аһ, барыбер, бу Рәшидә миннән бәхетлерәк бугай. Ичмасам тизрәк кавышсыннар иде».

— Син Хәлимгә кияүгә чык,— диде ул бер көн Рәшидәгә.

Рәшидә исе китеп:

— Протезгамы? — диде. Ул Хәлимне санга сукмый иде.

— Хәлим сине ярата бит.

— Ярата бирсен.

— Ут белән уйныйсың син.

— Акыл өйрәтергә син яшь әле. Хәлимне кызгансаң, үзеңә бирәм, ал.

— Рәхмәт, кеше белән шаяра белмим.

— Фәрештәдер син. Алланың уң кулы астындагы фәрештәседер, билләһи. Бу дөньяны син генә тигезләрсең инде. Ай-һай, дөнья чокыр-чакырлы бит, җаным.

Гайшә әрләшүләргә иләшмәгән иде. Ул Рәшидәне аңларга тырышты. Түшәр халкы аңардан тәмам йөз чөергән иде бит.

Рәшидә терәк барлыгын сизде, сизмәде түгел. Вакыты-вакыты белән ул Гайшә янына килә, беренче танышкан көндәге кебек уйлап, һәвәсләнеп сөйли иде. Ләкин Рәшидә талпынырга азапланган яралы кош сыман иде. Ярасын төзәтергә кешеләргә бирмәде, кулга иялəшмәде. Аның ике көн буе авылдан югалуы Гайшәдән кала берәүне дә борчымады. Рәшидәнең юлы бер генә дип уйладылар, күрәсең. Алар хаклы да иде.

Рәшидә белән Гайшә арасында тагын әрләшүгә охшаган сүз булып алды.

— Кая югалдың, Рәшидә? Классында тәрәзә пыяласын ватканнар.

— Хет башларын җимермиләр шунда! Барасы җиремә бардым, урманда йөрдек.

— Син миңа карата нык үзгәрдең. Ачуланасын димме. Юньле-башлы җавабың да юк.

— Хан кызымы син? Әллә допросчымы? Я дирекция шымчысымы? Алай дисәң, доложить иткәнең булмады. Болай әйбәт кеше син.

— Әйбәтлегемә төкерәсең бит.

— Төкерәм, дөрес Гайшә. Ирләр белән йөрмәгәнең өчен, пешмәгәнең өчен, төннәрен ялгыз йоклавың өчен! Җитәрме!

— Мин булдыралмыйм. Әгәр була калса, бергә кунган йортны яндырырмын, үзем шул утка ташланырмын кебек.

— Кайдан килгән саф җан! Болытлар да гел ак булмый, җаным. Бел аны!

Рәшидәнең ялыктырган ягы әнә шулар иде.

Бер кичне Рәшидә өстәлгә чиста спирт чыгарып утыртты.

— Дус-ишләр киләсе, бергәләшеп җырлап утырырбыз,— диде ул Гайшәгә.— Чыгып китә күрмә. Табын әзерләш.

— Рәхмәт, эчү мәҗлесенә калмыйм. Туксанарларга кич утырырга барам,— диде Гайшә.

— Кал инде,— дип ялварды Рәшидә.— Кал инде, җаным. Янәшәмдә бул. Бүген тыныч түгелмен.

— Эчкәч тынычланасың бит син.

— Алайса берәүне дә кертмибез, китмә генә.

— Чакырган кунакларыңны борма син,— диде дә Гайшә киенеп чыгып китте.

— Җаным, җаным,— дия-дия Рәшидә аны ялварып озатып калды.

Их, ул ялварулы зәп-зәңгәр күзләр... Мөлдерәп Гайшәгә ялварып караган күзләр. Һаман да ялваралар әле, һаман да...

Туксанарларга кермәде Гайшә. Урамда йөрде. Хәлимнәр өе каршыннан да үтте. Хәлимнең үзенә булган мөнәсәбәтен ачыкларга тырышып карады. Ләкин Хәлим Хакимов ягыннан мәхәббәт җилләре исми, ә бары хөрмәт, олылау хисләре генә сизелә иде шул.

Аннан соң Гайшәнең йөрәге сулык-сулык итеп авыртырга тотынды. Ул адымын тизләтеп өенә борылды. Өй янына җитәрәк, колак салып тыңлады. Тып-тын, берниндн тавыш та юк иде. Таралыштылар микәнни?

Гайшә каударланып ишекне ачты.

— Рәшидә, Рәшидә! Нишләдең бәгърем,— диде ул шомланып. Хатын кара кан эчендә ята, матур йөзе күмердәй янган иде. Гайшә аны тиз генә ятагына күтәреп салды.

— Төшердем... баламны... хәзер үләм,— диде Рәшидә саран гына елмаеп. Аның бер дә болай елмайганы юк иде.— Китмә дидем бит. Берәү дә кунакка килмәде. Янымда торсаң, булышкан булыр идең. Мин дә исән калыр идем.

— Сөйләшмә, тынычлан,— диде Гайшә.— Хәзер врачка йөгерәм.

— Син врач чакырма, соң инде. Җаным чыгарга ике-өч минут кына калгандыр.

Гайшә нишләргә белмичә еларга тотынды.

— Елама, матурым. Кызганма мине. Мин бик матур дөньядан китәм. Ләкин мин гаепле түгел бит, сугыш, аны гаепләгез. Яшисе иде әле. Яшәүнең ни икәнен соңлап, үләр алдыннан гына аңладым. Соңгы васыятемне тыңла, Гайшә. Син нык хатын. Мин сиңа сокланып үләм. Минем бер яшьлек балам бар. Адресы сумкада. Кызның исеме Гөлсирин. Тәрбиялә аны. Кызың ит! Әнисе мин икәнне ускәч тә әйтмә, бераүгә дә әйтмә. Бала минеке диң, яме, яме?

Рәшидәнең сулышы шул сүзне әйткәч өзелде. Гайшә ак салфетканы аның битенә япты да, хәлсезләнеп Хәлимнәргә йөгерде. Ярты юлны ике аяклап, яртысын абына-сөртенә дүрт аяклап диярлек үтте.

— Хәлим! Рәшидә үлде!

— Кит аннан?!

— Мин гаепле. Күрә торып ялгыз калдырдым.

...Гайшә ул чакта нәкъ бүгенге төсле ярым үле Гайшә иде. Тик ул вакытта яшь иде, ә хәзер картайды Гайшә. Ул чакта баласыз Гайшә иде, хәзер балалы Гайшә. Кайда соң аның кызы Гөлсирин? Әйе, Туксанар картларга кереп китте бит әле. Әнә чыгалар да инде. Туксанар карт та килә.

— Әнием, борчуым өчен гафу ит, яме!

Гөлсирин зәңгәр күзләрен тутырып әнисенә карады.

— Их, син, бердәнберем. Бар, тамагыңа капкала да, чишмәдән су алып кайт.

— Мин бабайларда сөтле чәй эчтем. Суга барам. Чишмә юлларын сагындым.

— Ишетәсеңме, бабай. Кызым яратам, ди. Әнисе кебек ялгышмас микән?... Түзмәм бит, бабай.

— Шомланма, килен, бозык һавада үсмәде бит.

— Ул бала өчен мин бер нәрсә дә кызганмадым. Урман кистем, иремнең документларын яндырдым. Мәрдәнвәрнең кайчан үлгәнен күрсәтмәс өчен шулай эшләдем. Чөнки Гөлсириннең туган елы белән туры килми иде. Аны сугышта кан коеп түгел, тыныч чакта суга батып үлде, дип алдадым. Гөлсиринне кагарлар, чит итәрләр дип, кияүгә чыкмадым. Ләкин болай дөнья көтүемә үкенмим. Тик Гөлсирин юмасын иде шуларны. Их, бабай, юмасын иде...

## 4

Ул чакта... Гайшә күпме генә ашыкмасын, куе караңгылык аның эзләренә баса килде. Юл буенча йөгрде дә йөгерде ул. «Таңга кадәр әйләнеп кайтсам иде. Дәресләргә өлгерсәм иде... Әйтеп китәсе калган. Җибәрмәсләр идеме? Юк, юк мин дәрес калдырырга тиеш түгел». Урман авызына җитәрәк коеп яңгыр яварга тотынды. Көндез үк куерып йөргән иләмсез болытлардан рәхим-шәфкать көтеп булмый иде. Гайшә өстендәге күлмәген салып нәни Гөлсиринне төрде. Тәненә юеш бака сыман салкын яңгыр сыланса да, Гайшә түзде. Чөнки аның күкрәгән Гөлсирин җылысы җылыта, йөрәген ачы бәхет, соңлап килгән бәхет, рәхәт авырту телә иде. Ул ничәнче мәртәбә Рәшидәне уйлады. Рәшидәнең коточкыч үлемендә үзенең гаебе юклыгын исбат итмәкче булды.

«Рәшидә яшәсә, Гөлсирин үләр иде. Рәшидә үлде, Гөлсирин яшәр...»

...Гөлсиринне алып калган күрше авыл карчыгы аны Рәшидә итеп таныды.

— Килдеңме, җир себеркесе, төпсез чиләк, азгын эт. Баланы алсаң да үкенечкә алырсың. Мулла абзый өч тапкыр өшкереп карады, бу-лырлык түгел, ходай урынын оҗмахта әзерләсен,— диде.

— Мин Рәшидә түгел, әби. Аның тарафыннан җибәрелгән кеше,— диде дә, Гайшә агач сәкедәге курчак кадәрле генә балага ташланды.

— Әтисе кем?— диде ул кызчыкны күкрәгенә кысып.

— Әтисе бер өстерәлчек,— диде карчык.— Рәшидә чоланда тешен кысып тапты да, ташлап качты. Күкрәк сөтен көчекләргә савып бирдеме, нишләтте?

Гайшә тыңламады. Баланы алды да, бәреләсугыла чыгып йөгерде. Хәер, карчык та куа чыкмас иде. Кумас иде... Куарлык рәте калмаган иде инде аның.

Тушәрнең иң яшерен почмагы — бакча артыннан керәсе итте Гайшә. Бакча белән янәшә күл иде. Күлне ерып чыгар өчен баланы ярда калдырырга, ә үзенә, кулына таяк тотып, су тирәнлеген үлчи-үлчи чыгарга кирәк. Дымсу җиргә сабыйны кую, кабергә тыгу белән бер икәнен уйлап, Гайшә кире чигенде. Һәм ул урманнар уртасыннан атлап, өенә кайтты. Әчке күлмәктән килеш бала кочаклаган Гайшәне күреп: «шашкан», «тиле» дисәләр дә инде барыбер иде, барыбер, барыбер иде... Бердәнбере хакына ул шулай эшләде. Чөнки кызчыкның гомере — «шашкан», «тиле» дигән сүзләрдән мең мәртәбә өстен иде.

Туфрагы җиңел булсын мәрхүмнең, врач Саттар Гөлсирингә икенче ярдәм күрсәтте. Беренчесе — кырык чакрым араны йөгереп узган һәм баланы үлемнән тартып алган Гайшәнең үзе иде.

...Гөлсирин терелде. Атналар, айлар төштә күргән кебек кенә үтә башладылар. Бер көнне Җәмилә түти белән Гөлсирин Гайшәне капка төбенә хәтле озата чыктылар. Гайшә саубуллашып ун-унбиш адым җир киттеме — юкмы, Гөлсирин яңгыратып кычкырып җибәрде:

— Әннә!

Гайшәнең тәненнән кайнар дулкын йөгереп узды, ул бер мәлгә туктап калды, аннан соң аның кулындагы дәфтәрләре җиргә коелды.

— Балам!— диде тол хатын,— кызчыгым!

Ул, Гөлсиринне күтәреп, табан асларына кадәр үпте, йотардай булып, татлы итеп бөтен җирен үпте. Кызчыгы чырык-чырык килеп, кулларын бутый-бутый көлде.

— Син бит минеке түгел,— диде ана ачыргаланып.

Бер читтә күзәтеп торган Җәмилә түти:

— Я ходай, сизгән идем аны,— диде.

— Нәрсәне?— диде Гайшә икенче кат, кинәт уянып китеп.

— Баланың синеке түгеллеген, хода бәндәсе.

— Кемнеке соң, түти?

— Приуттан алгансыңдыр.

— Әйтмә, түти, көфер сүз, әйтмә. Бала минеке. Охшамаган мыни? Әтисенә охшаган, әтисенә.

Гайшә янды, пеште. Гөлсиринне күкрәгенә кысканнан-кыса барды:

— Авызымнан вәгъдә сүзе алып үлде, Рәшидәнеке,— диде ул хәлсезләнеп.

— Ходай! Бир түзем! Бир түзем бу хатынга!

— Аллаһтан түзем сорап ни кылырсың, түти. Серне син дә бабай гына белегез. Мин Гөлсиринне үз кызым итеп күрсәтергә тиеш.

— Җир убылсын, бәбкәм. Тәмуг кисәве булырга телимме соң инде. Бар мәптегеңә, калдыр оланны.

Гайшә «укытучылар өеннән» Туксанар картларга күчкән иде. Хатынның теге өйдә каласы килмәде. Рәшидәнең үлемен, коточкыч төнне хәтерләткән өй аңа караңгы тирән баз сыман тоела иде. Ә ике елдан соң Гайшәгә Туксанар картлар янәшәсендә яңа өй салып бирделәр. Кызы белән матур гына гомер кичерәм дигәндә...

— Өйләнешик, Гайшә.

— Нигә, Хәлим? Син аны үлсә дә оныталмыйсың. Ул синең өчен һаман исән: сөйли, көлә кебек. Ә мин синең тормышка бер күләгә булып килермен. Бер-беребезгә караган саен сискәнербез. Икенчедән, минем кызым бар. Бөтен күз нурымны аңа гына түгеп, бөтен җанымны аңа гына бирәсем килә.

— Гомер буе тол яшәрсеңме?

— Җанымда Мәрдәнвәремне саклыйм мин. Бу тол булу димени?

— Нык син, Гайшә сеңел. Я, үстер кызыңны, кеше ит.

Хәлим бу ачык сөйләшүдән соң, нигәдер күрше авылга күчте... Ә Гайшә үстерде кызны. Айлар, елларның суы белән аның да гомере акты. Мең төрле тормыш каршылыкларына кушылып аның да бәхете ташыды. Бәхете — Гөлсирине иде. «Әгәр дөреслекне ачып бирсәм, зәңгәр буяулы кабер янына алып барсам... Никадәр ачы булмасын, дөреслекне белергә тиеш Гөлсирин. Гайшә аңа тик чынын, бизәксез чынын гына сөйләр. Үзен акламас та, акланмас та. Әллә бераз түзсенме? Рәшидә бит мине белмәсен диде. Нигә алай әйтте әле? Сугыш гаепле, ләбаса. Тукта, Гайшә, нигә бөтенесен сугышка аударасың әле. Сугыш, имеш. Сугыш дип без барысына да юл куярга тиеш идекме? Юк, юк, башыма чүбек уйлар тутырганчы Гөлсиринем хакында уйлыйм. Дөреслек, дөреслек кирәк».

Ана уйлардан авыраеп иелгән башын күтәргәндә, аның алдында Гөлсирин зәңгәр күзләрен тутырып карап тора иде.

— Син борчылма, әни,— диде кыз.— Борчылма. Бәлки бу күңелемдә булган ташкындыр. Язгы ташкыннарны хәтерлисеңме? Үрсәләнеп ярдан ташыйлар да, тагын үз хәлләренә кайталар. Тып-тын аккан елгаларны күрәсең бит син, әнием? Нигә дәшмисең? Мин әле генә Караяр елгасын карадым. Бер генә дә дулкынланмый. Тын гына ага да, ага... Әни, дәш инде.

Гайшә кызының иңнәреннән кочты.

— Кинәт... хәбәрең кызым,— диде ул.— Болай йомшармый идем әле. Сөйләшерлек рәтем дә калмаган, уй бетерә. Сиңа артык сүз ычкындырмагаем дип шүрлим. Йөрәгеңә якын алырдай кинәттәннәр күп шул, балам. Ярый ла елга сыман тынсаң. Ярый ла...

Гайшәнең карашы инде кызында түгел, алсуланган офыкларда иде. Офык читендә ул гүзәл Рәшидәне күргәндәй булды, кинәт тәненә салкын йөгереп, дерелдәп куйды да:

— Син үз җаным бит, балам,— дип пышылдады. Һәм күңеленнән генә: «Кичер, Рәшидә, кичер. Гаебемне еллар да юа алмый, хәтта үлем дә... Кичер, тик этәрмә Гөлсиринне яман юлга, калдыр үземә»,— диде.

Ул да түгел, офыкның ал бизәге җуелып яшел юл күренде. Бу юл түгел, болын икән, әнә, аның Мәрдәнвәре печән чаба. Чалгысы нинди үткен, теземнәр елан сыман сузылып кала. «Мәрдәнвәр... гомер уза... Сине чакырган төннәрем бихисап иде... Инде килмә. Күрәсең, кызым бар. Ул миңа синнән дә кыйммәтлерәк. Юк, юк килмә... Син дә кичер, кичер мине. Килмә, уйларыма килмә...»

## 5

Адәм эш белән юана да, куана да. Гайшә түти, чалгычылар төркемена кушылып, борчак чабарга төште. Алар иртәдән кичкә кадәр кырда кайнашалар. Ә Гөлсирин өйдә ялгызы, аның җәйге ялы. Ул түзем-

сезлек белән күк йөзенә ай калыкканын көтә. Юлда танышкан теге ямьсез шофер егет аны Азамат янына илтә. Һәркөнне тузан туздырып алар Карлыга ашыгалар.

Ямьсез егет Азаматны яратмый. Гадәттә, ирләр бер-берсенә кыек карамыйлар, һәр очракта килешәләр иде. Ә Марат килешмәде. Ул аны «Куян аягы» дип атады.

— Алай әйтмә,— диде Гөлсирин. Кыз Азаматны әүвәлгечә ярата, энисенә сиздермичә генә очрашкалый иде.

— Әйтмәм алайса,— диде ямьсез егет.— Алыш-бирешем юк бит. Сине ничәнче кат илтәм әле?

— Унбишенчесе.

— Йөз мәртәбә алып барсам да рәнҗетмәм, бел,— дип җавап кайтарды Марат.

Бүген егет кызны тагын Карлыга илтәчәк. Кичә Азамат төксе генә сөйләшкән иде, башым авырта, диде. Әле эшләмим, ял итәм, диде. Гөлсирин сөйгән кешесенең күңелен күтәрер өчен яңа күлмәк тә текте. Менә каршысына басып бер әйләнер дә, Азамат ирексездән сокланып елмаер. Кичә тикмәгә сүзгә килделәр бугай.

— Кал янымда,— диде Азамат.

Төн караңгы, ә алар очрашкан урман алдында рәхәт иде. Гөлсирин тәвәккәлләгән дә иде инде, тик Маратның калын тавышы аны сискәндереп җибәрде.

— Сөйләшеп туйгач кыз кире кайтачак!

— Әй, син, машинаңда тик утыр,— дип янады Азамат.— Ул калачак! Китергәнсең, рәхмәт. Кабыз моторыңны да, шыл.

— Шылам,— диде ямьсез егет һәм кабинасыннан сикереп тә төште.— Әмма Гөлсиринне кайтарып куям. Үз өенә!

— Кем соң бу, имгәк?— Азамат батыраеп Маратның якасына ябышты.

— Тимә, ул минем дустым,— дип кыз арага төште дә егетләрне ике якка аерды.

...Ямьсез егет. Гөлсирин аны шулай дип атап һич тә мыскылларга җыенмый. Егетнең җаны изге икәнен белә бит ул. Караңгы юлда күпме бергә булдылар. Күпме бәхәс кузгалып, күпме сүз сөйләнде, ләкин Марат беркайчан да түбәнлеккә төшмәде, әйтерсең ул кызның мәхәббәт сакчысы иде. Әнә бүген дә соңгы рейсны ясагач, аларның капка төбенә килеп туктаган. Гөлсирин көзгесеннән кыяфәтен карагандай итте дә, чыгып йөгерде.

...Сөйгәнеңә ашыкканда секундлар сәгать күк тоела икән. Бер чакрым юл да диңгез иңе чаклы күренә, ә йөрәк бер урынына өч тибә икән. Тәгәрмәчләр очрашу көенә тәгәри, очрашу алда, нибары берничә чакрым алда икән. Урман шаулавыннан туктап көтә, төнге кошлар да сайрауларыннан тынганнар икән. Тын икән, бик тын икән биредә, урман алдында.

— Килми,— диде Марат өченче мәртәбә.— Әйдә, соң инде, кайтыйк.

— Көтик,— диде кыз, аңа өченче кат җавап биреп.

— Ә син дөреслектән куркасыңмы? — диде кинәт ямьсез егет.

— Юк,— диде кыз төн пәрдәсе аша Маратның күзләрен эзләп.

— Ул бөтенләйгә китте... Көтмә син аны.

— Марат, ялганлама!

Урман сак тынлыгын онытып шаулап куйды, карт агачларда йокымсыраган кошлар, куркып, тирә-якка очтылар, ай болытлар арасына кереп качты.

— Ял-га-а-а-нла-а-ма-а!
— Әйе, көндез чемоданын тотып шушы юлдан китте.
— Аһ, Марат, нигә әйттең? Нигә?— Кыз Маратның киң күкрәгенә капланып үксергә кереште.— Авыр миңа, бик тә авыр, дөреслек тә авыр бит. Яратмады ул мине, сиздем дә югыйсә. Өйләнгәнен дә белдем. Җанымда аклык иде, миңа бары тик ярату гына кирәк иде, тамчы гына ярату кирәк иде,— дип үкседе ул бертуктаусыз.
Моңарчы тау хәтле кайгы-хәсрәтне иңнәрендә күтәрә алырдай күренгән шаян кыз кинәт күз яше түгә башлагач, Марат югалып калды. Сүз тапмады.
— Елап озаткан мәхәббәт мәхәббәт түгел инде,— диде ул бераздан әкрен генә.
— Ә бит адәм баласы ялгышулары белән кабат ялгышмаска өйрәнә,— диде Гөлсирин башын күтәреп,— Син миңа ышан, Марат, ышан.
Урман яңадан тынды. Ай яңадан нур сипте. Табигать гүя мәңгелек сер көтә иде.

*1976 ел.*

## Укучының күңел дәфтәренә

**Таҗик мәкальләре һәм әйтемнәре**

***Ашаганда — кит балыгы, ә эштә — аксак ишәк.***
***Казылмаган канау сусыз була.***
***Су кизләүдән болгана.***
***Дуслар — дусның көзгесе.***
***Эшкә ярамаган белем — яңгырсыз болыт кебек.***
***Пычак үзе сабын кисми.***
***Сиңа кеше килсен дисәң, кеше ишеген шакы.***
***Сөтсез сыер каты мөгри.***
***Сүз өстенә бизәк сызып булмый.***
***Тере ялкау үлудан мәет булуың артык.***
***Эчемлек төсе — йөземнән, ә зирәклек — күрше холкыннан.***

## Рәдиф Гатауллин

### Йөзүчеләр

Диңгездә — шторм бүген, давыл... Алты баллдан
Һич ким түгел! Үзем сорап белдем дулкыннардан.
Диңгездә көчле шторм. Ә кем анда, йөзә
Бик еракта? Куркынычтыр! Ул — эчтә, диңгездә.
...Кара диңгез, сиңа килдек — иң зәңгәр диңгезгә,
Нинди гыйбрәтләр бирерсең бу юлы син безгә?
Дулкыннарың бер-бер артлы ярны коча торсын,
Бәлки яңа җыр китерер тугызынчы дулкын?
Ярдан эчкә кермик, улым, юк, ярамый безгә;
Йөзеп күнекмәгән... Кем соң анда — һаман йөзә?
Дулкыннар белән көрәшә? Дәрт, дәрманы зурмы?
Яшьтән диңгездә үскәнме? Бер романтиктырмы?
Без дә коендык, уйнадык, күмелеп дулкында;
Ардык бик тиз, ярга чыгып ятабыз без комда.
Ә йөзүче... чын диңгезче! Ул, шашкан җан, йөзә...
Ник шундый көч, дәрт, кыюлык бирелмәгән безгә?
Хәер, син яшь әле, улым, син йөзәрсең алда;
Син тик сөенеп карыйсың көчле дулкыннарга.
Кайсы ир җанын соң диңгез ашкындырмас икән?
Ир җанында — иярле ат, яки кораб, җилкән...
(Әллә җилкән ул хыялның ак ялкыны микән?)
Корабларда түгел, ләкин, син диңгездә арма,
Колач салып йөзеп, ышан, күмел дулкыннарга.
Үзеңне киңлек, чиксезлек хуҗасы исәплә. —
Улым, йөзәрсең зур үскәч шулай, киләчәктә.

Әй, йөзегез батыр җаннар, йөзегез диңгездә!
Мин җыр язам — рухланудан, соклanудан сезгә;
Бүген уем шаһлары — сез һәм Геллеспонт[1] — уйда.
...Борынгыдан калган, яшь шундый бер легенда.

●

Грециядә яшь бер егет — Леандр[2] Герога —
Яшь бер кызга гашыйк, ә кыз яши каршы ярда.

---

[1] Геллеспонт — хәзерге исеме Дарданелл — Европа белән Азияне аерып торучы бугаз.

[2] Леандр — грек мифы буенча, Геллеспонтның Азия ярында, Абидоста яшәгән егет. Аның сөйгәне Геро бугазның Европа ярында — Сестоста яшәгән. Автор.

Мәхәббәте ташлый аны һәр көн дулкыннарга:
Һәр кичтә дәрьяны йөзеп тиеш ул чыгарга.
Аларны, әйе, Геллеспонт — бугаз аерып торган,
Бер ярны икенчесеннән, ә егетне кыздан.
Леандр ул Азиядә, Геро — Европада.
Килешкәннәр: кыз һәркөнне ярга учак яга;
Төнен диңгездәге гашыйк утны күреп йөзсен!
Һәм яшь егет күрә, йөзә ярга таба кичен...
Тау-тау дулкын булганда да, давылда, салкында
Ул — диңгез иркендә, йөзә, сөйгәне янына.
Ул шул бугаз аша йөзә... Аннан — уз ягына...
Ул ярларны ялгый көн дә, тоташтыра гүя:
Азиядән Европага илче булып йөзә.
Гүя күпер ул диңгездә — ялгасын мәхәббәт! —
Сөю хакына диңгезне кичә ничә кабат.
Шаһит булгансың, Геллеспонт, бөек мәхәббәткә!
Ничек бирдең аны ләкин бер көн һәлакәткә?
Ачуландың ник, Посейдон, син, диңгез алласы?
...Сөйгәненә йөзә чын ир — көч һәм хис баласы.
Ярда ут күренми бер көн... Дошманмы сүндергән?
Йөзгән Леандр ул төндә, соң чиккәчә йөзгән.
Кайда Геро? Яр күренми. Давыл тик — диңгездә...
Баткан Леандр... Ә җаны — һаман исән, йөзә.

●

Легендалар исән һаман, белә йөзүчеләр,
Батырлыкта Леандрны үрнәк күрүчеләр.
Көнчыгыштан — Көнбатышка, илләрдән илләргә
Илчеме син? Хәбәрчеме? Тиешсең йөзәргә,
Кабатлаган күпләр шулай Леандрның юлын,
Бер кыйтгадан — икенчегә тере күпер булып.
Ә дөньядан үткән күпме яулар, яулар... утлар.
Күп Леандрларны көткән яңа Геллеспонтлар, —
Куркынычлар... Сынау аша йөзгән, һәлак булган
Күпләр шулай: батыр булган, әмма харап булган.
Байрон, йөзүче бөек ир, ул да баскан ярга,
Геллеспонтны йөзеп узгач, охшап Леандрга [1].
Элладага гашыйк җанын сынаган дулкында, —
Азатлык факелын тотып, килгән Элладага.
Һәлак булган ул шул юлда... Мәңгелек дан аңа!

●

Кыйтгаларны кыен хәтта уйда гына ялгау...
Әй, Геллеспонт, синең исемең әйди һаман алга.
Йөзүчегә һәрчак кыен, төн кара, айсыз күк,
Ярда ут яккан дус булса, сүндерүче дә күп. —
Арада — гел караңгылык, арада — төн, томан...
Ничә гасыр, әй, Геллеспонт, синдә шулай булган?
Азиядән Европага, Европадан — тагын
Азиягә меңнәрнең син ирек сөйгән җанын

---

[1] 1810 елның май аенда бу бугаз аша Сестостан Абидоска бөек инглиз шагыйре Байрон йөзеп чыккан. Автор.

Юнәлткәнсең... Хәзер инде ул чор ерак, узган, —
Тоташтырып кыйтгаларны, илләр күпер сузган.
Дарданелл дип аталгансың син, Геллеспонт, үзең.
Тик шагыйрьләр өчен яши борынгы ул исемең!
...Әй, тәбриклим, бүгенге яшь Леандрлар, сезне!
Кыйтгаларны тигез сөйгән чын шагыйрьләр, сезне!
Ялгагыз сез йөрәкләрне нык бердәмлек өчен.
Телләр, фикерләр үз итсен тизрәк берсе-берсен.
Йөзүчеләр әнә күпме — кара син диңгезгә!
Нинди максат белән алар кая бүген йөзә?
Нинди көрәш, идеаллар чакыра соң аларны?
Бармы, яшиме аларда Байроннарның җаны?

●

Әй, күрәсе иде шундый батыр егетләрне!
Якташларым, әллә алар безнең кебекләрме?
Бездә — җырда, моңда — диңгез, каян килде димсез?
Диңгез яраткан дусларым, сез соң ни әйтерсез?
Бәлки шушы минутларда Мәрмәр диңгезденме,
Я Босфордан узасыздыр, илем егетләре!
Дарданеллдан бәлки инде күп тапкырлар узган
Шагыйрь җанлы диңгезчебез Юныс Миргазиян!
Мин көнләшәм синнән, туган... Одиссей юлында
Син дә уйлыйсыңдыр, бәлки, Леандр турында?
(Дөресен яздым, шулай бит, диңгезгә җырымда?)
Әй, диңгезләрне күп күргән Мәһди Мөхәммәте,
Нинди хисләр иде синдә? Чиксез мәхәббәтме
Йөзүләргә? Бүген тагын кем анда, диңгездә?!
...Беләм, горур уйлар яши, якташларым, сездә!

●

Хат алдым бүген менә мин Югославиядән,
Анда сәяхәттә йөргән бер яшь дустым язган:
— Әдрәндә без, күп җырларда җырланган диңгездә —
«Култыклары йөз дә сигез, әй, йөз дә сигез»дә.
Тик ятмыйбыз без дә монда — йөзәбез һаман да.
Шундый рәхәт дулкыннардан юл ярып барганда.

Ә кайда минем Геллеспонт? Ярым яккан учак?
Минус җиделе күзлегем зәңгәрлекне коча.
Йөзәргәме? Кычкырыргга: — Таласса, Таласса!
(Диңгез дигән сүз икән ул борынгы грекча.)
— Кочагыңа ал мине! — дип әйтимме татарча?
Юк, йөзәргә тиеш мин дә, соң түгелдер, түгел...
Юккамыни, улым, монда тартты безне күңел.
Әй, йөзәргә кирәк ерак, йөзәргә диңгездә,
Ярдан еракта... Армаска! Уем күптән йөзә.
Гизә, дәрьяларны урый... Җанымда Хыял-Ут.
Китмә миннән, Романтика! Көт мине, Геллеспонт!

*1980*

# Афзал Шамов

# СОРЫ МӘЧЕ

**хикәя**



Тулы койрыклы, тырпаеп торган озын мыеклы, землянкага иялəшкəн соры мəче сержант Сафин отделениесе тормышында шактый зур күңелсезлекләргә сәбәпче булды. Хәер, сугышчылар бу күңелсезлекләрнең берсен дә читкә чыгарырга, командованиегә белдерергә теләмәделәр, шулай да ул бөтен отделениене зур борчуга салырлык гадәттән тыш вакыйгага, хәрби тел белән әйткәндә, ЧПга сәбәпче булды.

1943 елның февраль ахыры иде. Дивизия каты, авыр һөҗүм сугышларыннан соң, дошман частьларын тар-мар итеп, берничә авылны, район үзәге дип аталган кечкенә бер шәһәрне азат иткәч, ике урман арасындагы ачыклыкта оборонага урнашты. Частьлар, подразделениеләр җиргә тирәнрәк казып урнашырга, ныгырга приказ алдылар. Дивизия сирәк атышлар, дошманны өзлексез капшап, тынычсызлап торудан гыйбарәт булган вак сугышлар алып бару белән бергә авыр физик эшкә, оборонасын ныгытуга кереште.

Сержант Әхтәм Сафин отделениесе, взвод белән берлектә, яңа гына азат ителгән авыл читенә туры килде. Бу авыл хәрби карталарда һәм югары командованиегә бирелгән донесениеләрдә Дятлевка дип аталып йөртелсә дә, аның авыллыгы калмаган иде инде. Фашистлар чигенер алдыннан аны җир белән тигезләгәннәр, йортларын, каралтыларын яндырганнар, бөтен авылда бердәнбер таш бина булган мәктәпне, астына мина куеп, шартлатканнар, урамнардагы, бакчалардагы агачларны кискәннәр, урманга, партизаннар янына качып китәргә өлгермәгән эшкә яраклы кешеләрне һәм терлекләрне үзләре белән бергә куып алып киткәннәр, эшкә ярамаган карт-корыны һәм балаларны атып үтергәннәр. Авылда хәзер бер җан иясе дә юк, хәтта каңгырып йөрүче этләр белән мәчеләр дә күренми, алар я качканнар, я кырылып беткәннәр булса кирәк. Тик бу җирдә кайчандыр кешеләр яшәгәнлеген, тормыш иткәнлеген белдереп, анда-санда нигез ташлары аунап ята да исән калган шәрә мич калдыклары гына шомлы булып ыржаеп торалар. Аннары шул хәрабәләрнең барысы өстендә, тирә-юньдәге бернәрсәгә, утка да, ялкынга да игътибар итмичә, башын горур рәвештә һавага күтәреп, чылбырлы чиләген җилдә талпындыра-талпындыра бер кое сиртмәсе басып калган.

Оборонага урнашкач, сугышчылар көн-төн окоп казыдылар, дошман-

ның өзлексез атып, тынычсызлап торуына карамастан, аны тирәнәйттеләр, ныгыттылар, тик шуннан соң гына землянкаларга тотындылар.

Сафин үз отделениесенә землянка урыны итеп бер өйнең идән астын сайлады. Уңай урында, траншея буенда гына иде ул. Әгәр казып ныгытсалар, отделениегә бик житәчәк, хәтта иркен дә булачак. Чөнки отделение зур түгел, бары жиде кеше генә калган иде.

Бер көнне караңгы төшү белән отделениенең постта булмаган сугышчылары эшкә керештеләр, төн буе идән астын чүп-чардан арчыдылар, казыдылар, тирәнәйттеләр, өстенә өч кат бүрәнә җәеп, калын итеп балчык өйделәр, дошманга күренеп тормасын өчен маскировка ясадылар. Төнлә берничә тапкыр тревога булып, аларга, көрәкләрен, кәйләләрен ташлап, кулларына коралларын алырга, окопка йөгереп чыгып, үз урыннарына барып басарга туры килде, әмма таң сызылганчы землянканы тәмамладылар, ишеккә плащ-палатка корасы гына калды.

Әхтәм Сафин аны инде кора да башлаган иде. Ул арада ефрейтор Энәс Сибгатуллин, каты кара чәчле, шундый ук кара кашлы, өй җанлы, нечкә күңелле уйчан карашлы егет, каяндыр яңаклары белән бусагасы гына сакланып калган бер кечерәк ишек өстерәп алып кайтты да, балаларча куанып:

— Иптәшләр, әйдәгез менә бу ишекне куйыйк, — диде. — Чын йорт сыман булсын. Плащ-палаткалар белән күп яшәдек. Җитәр.

Егетләр хуп күрделәр. Командир, ныгытылып бетмәгән плащ-палатканы йолкып алып, туфрак коелмасын өчен түшәмгә беркетергә булды. Сибгатуллин исә, балтасы белән каккалап-суккалап, юнасы урыннарын юнып, кисәсе җирен кисеп, ишекне землянкага җайлый башлады. Аның бу эшне бик яратып эшләве, кулыннан эш килүе, балтасының йөрешеннән үк күренеп тора иде. Ул, эш бетте дип, ишекне бер ачып, бер ябып карады да, бик канәгатьләнеп:

— Менә ичмасам бераз өйгә ошады, — диде.

Отделениенең башка сугышчылары да ишеккә килеп, ачып-ябып карадылар, ишекне әллә ни мактамасалар да, ошаттылар, жылы озаграк сакланыр диештеләр. Яктырганчы, дошман күзенә чалынмаслык чакта, янып, кызып калсын дип, тимер мичне инде тергезеп тә җибәргәннәр, эчендәге коры агач кисәкләре, бераз төтен чыгарып, тыныч тормышны, өйне хәтерләтеп, күңелле генә чатнап яналар иде. Тимер мич өстенә котелок белән чәй һәм жылынсын дип кичтән калган ботканы да куйдылар. Снаряд гильзасыннан ясалган лампаны да кабызып җибәрделәр. Землянка эче яктырып, җыйнакланып, матурланып китте. Фронт матурлыгы, аның үзенә хас тынлыгы, тынычлыгы иде бу. Чөнки тыштагы аратирә кабынгалап киткән атышлар, пулеметларның ачуланып, ярсып такылдаулары, аерым винтовкаларның һава ярып шартлаулары, хәтта минометларның уфылдап ярылулары да монда, яңа землянкада тоныкк булып, кайдадыр еракта атышалардыр шикелле булып ишетелә иде. Дошман ягыннан да, безнең яктан да төн буе һавага күтәрелгәләп торган ракеталар яктысы ишекне япканнан соң күренмәс булды.

Чәй дә кайнап чыкты, ботка да җылынды, төтен исе аңкытып торган землянкага, җанны рәхәтләндереп, дымсу җир исе, аш исе, чәй исе таралды.

Егетләр (хәзергә дүртәү генә иде алар) бу тынлыкның, рәхәтнең тәмен татып калырга теләгәндәй, кружкаларына кайнар чәй агызып сәкекырыена урнаштылар, кесәләреннән, капчыкларыннан шикәрләрен, ипи кисәкләрен чыгардылар. Аларның күптән болай җылы урында, тынлыкта җыелышып утырганнары, ашап-эчкәннәре юк иде. Шуңа күрә күңелләре дә күтәренке иде. Ничек күтәренке булмасын, бер төн дигәндә землянка булдырдылар, кереп ятарлык, җылынырлык урын ясадылар. Җитмәсә, ишек тә әмәлләделәр. Сугыш башланганнан бирле аларның әле ишекле землянкада торганнары юк иде.

Сафинның да канәгатьләнүе йөзенә чыккан иде. Ул авызына чәйне алганчы, землянканы тагын бер кат күздән кичерде дә, канәгатьләнүен яшерә алмыйча:

— Менә тагын бер йорт салдык, — дип куйды. — Торырлык. Җыйнак кына.

Әнәс Сибгатуллин да, чәен эчә-эчә, үзе ясаган ишеккә, гильза-лампа менеп кунаклаган шүрлеккә моңсу күзләре белән караштыргалап ала иде. Сафин сүзен ишеткәч, ул кулындагы чәен сәке кырыена куйды да.

— Дөрес әйтәсең, тагын бер йорт салдык, — дип, аның сүзен кабатлады. — Син моны бик матур итеп әйттең, старшой. Чыннан да, безнең йортыбыз бу. Ничектер, землянка казып кергән саен күңелем рәхәтләнеп, җылынып китә минем. Яратам ла соң мин шундый күзгә күренә торган эш эшләүне. Беләсеңме нәрсә, землянка казып кергән саен өем күз алдына килә минем. Сугыш башланыр алдыннан гына бик матур итеп җиде аршынлы йорт салып чыккан идем. Иртәгә сугыш башланасы дигән көнне туен үткәрдек. Кунаклар килде, дуслар җыелды...

Отделение командиры Сафинның, араларындагы иң өлкән егетнең, бу турыда берничә мәртәбә ишеткәне бар. Шуңа күрә ул аны, тыңлагандай булып, күңел хакы өчен генә булса да җөпләп торуны кирәк тапмады. Аннан соң ул, гәрчә үзенең туган авылында баласы белән хатыны калса да, алар турында күп сөйләшүне, сагышка бирелүне өнәп бетерми иде. Алар турында күп сөйләшсәң, сагышка бирелсәң, сагынуыңны җиңә алмасаң, солдатларның күңелләре йомшара, батырлыклары кими дип саный иде. Шуңа күрә ул сүзне икенчегә борырга теләде. Әллә бәхетенә, әллә бәхетсезлегенә каршы, нәкъ шул минутта тыштан нечкә генә, моң гына итеп чыелдаган тавыш ишетелеп куйды. Егетләр, гаҗәпләнеп, ишеккә борылып карадылар.

— Туктагыз әле. Нәрсә бу? Нәрсә чыелдый анда? — диде Сафин. — Ишек шыгырдыймы әллә?

Тавыш яңадан кабатланды. Бу юлы инде аның мәче тавышы икәне ачык ишетелә иде. Менә ул ишекне тырный-тырный, бик кызганыч тавыш белән елап, җылыга кертүне сорап кычкыра башлады.

— Мөгаен, землянканы котларга килгәндер ул, — диде Сафин елмаеп. Аның сугышчылар күңелендә туа башлаган сагышны, моңсулыкны бетерәсе килә иде. — Кертегез әле үзен. Күрик, бәлки, кем белә, котлап аракы да алып килгәндер.

Сибгатуллин, урыныннан торып, ишекне барып ачты. Аннан тышкы салкын һава белән бергә ябык кына, өтек кенә бер мәче килеп керде. Ул бик туңган, бөтен гәүдәсе белән калтырый, ялынулы күзләре белән сугышчыларга карый, кызганыч тавыш белән өзлексез мияулый иде.

— Мәче! — диде Сибгатуллин, бик шатланып. — Соры мәче!.. Яхшы билге бу, егетләр, валлаһи, яхшы билге! Пес-с, пес-с, әйдә, рәхим ит, мияубикә, түрдән уз.

Мәче аның чакыруын аңламый иде булса кирәк, ишек төбендә баскан хәлдә, ямь-яшел күзләре белән аңа куркып карап тора иде. Сибгатуллин, иелеп, аны кулына алырга, иркәләргә, башыннан сыйпарга теләгән иде дә, мәче, аңардан куркып, бер читкә тайпылды.

Отделениедә сакал-мыек җибәргән, шуның белән бераз мактанырга торган бик өй җанлы Василий Николаев исемле бер чуваш егете дә бар иде. Мәченең кыргыйлыгын күреп:

— Тимә, тимә син аңа. Бераз иләшсен, күнексен, — диде ул. — Ботка бир син аңа, ботка. Тукта әле, капчыгымда колбаса кисәге бар иде шикелле. Шуны биреп карыйк әле.

Сибгатуллин тимер мич өстендә торган котелоктан ике кашык ботка алып мәченең алдына салды. Хуш ис бөркеп торган ботка әле бераз кайнаррак иде. Шулай да песи куркулы карашын солдатлардан боткага күчерде, шиңеп төшкән колаклары да тырпайды. Бик ачыккан иде ул.

бернечә көннән бирле ризык кермәгән иде аның авызына. Песи бер боткага, бер сугышчыларга караштыргалап торганнан соң, сакланып кына ризыкка аягын тидереп алды. Ботка инде суына төшкән, ашарлык иде. Песи кыюланып ашарга кереште. Солдатлар өйне, гаиләне, тыныч тормышны хәтерләткән бу җанның землянкага килеп керүенә шатланып, куркытмыйк ашасын, дип, урыннарыннан да кузгалмыйча, хәтта тыннарын да алмыйча гаҗәпләнеп аңа карап торалар иде. Тик ефрейтор Сибгатуллин гына кунак песи белән сөйләшкәләп, землянка уртасында басып торды.

— Әй, песи, песи, нигә куркасың син бездән, — диде ул аңа. — Аша, аша, курыкма. Тимибез без сиңа... Әй, песикәй, песикәй, кыерсытканнар булса кирәк сине. Бөтенләй кыргыйлангансың... Ярар, без синең белән дуслашырбыз әле...

Әнәс Сибгатуллинның йорт хайваннарын, мәчеләрне, этләрне бик яратуы, йомшак күңелле кеше булуы бөтен ротага билгеле иде. Этләрне, мәчеләрне төрле уеннарга өйрәтә белә иде ул. Аның мәчеләре, этләре алга сузылган кул аркылы да, таяк аркылы да, кыршау аркылы да сикерәләр, арткы аякларына басып торалар. Хәтта гармунга да биләр иде. Ашарга бирсәң, рәхмәт әйткән сыман башларын ияләр, кирәксә, алгы аякларын биреп, күрешәләр дә иде. Кыскасы, аларның телен, холкын белә иде ул. Хайваннар да аның ягымлы, йомшак күңелле кеше икәнен тиз сизеп алалар, аңа ияләшәләр, яраталар, аерылырга теләмиләр иде. Шуның аркасында иптәшләре аңардан еш кына дусларча көләләр, хәтта үртәп, котыртып та алалар иде. Ләкин Сибгатуллин үпкәләми иде аларга.

Алдына салган боткасын мәче бик тәмләп, иреннәрен ялый-ялый ашап бетергәч, Сибгатуллинга карап, нечкә, моңлы тавыш белән тагын мияулап куйды. Бу аның тагын ашарга соравы иде, җитмәгән иде, күрәсең.

Сибгатуллин аңа ягымлы гына итеп:

— Әй, җитмәдемени соң әле, мияубикә, — диде. — Җитмәсә, тагын салып бирербез. Әйдә, рәхим ит, тамагың туйсын...

Василий Николаевич та капчыгындагы колбаса кисәген сузды. Төн кунагы аны да ялмап куйды. Шуннан соң ул сугышчыларга карап тора башлады. Бу инде аның ашарга соравы түгел, ә землянкадан куып чыгармауларын үтенүе иде. Шуның белән бергә ул җылы бөркеп торган тимер мичкә дә караштыргалап ала иде. Бусы инде мич янына барып ятарга рөхсәт соравы иде.

— Я, нишләтәбез моны, егетләр? — диде Әхтәм Сафин, иптәшләренә карап. — Куып чыгарабызмы, әллә калдырабызмы?

Әхтәм командир иде, шуңа күрә моны хәл итәргә кирәк иде аңа. Егетләр барысы да калдырырга дигән фикерне әйттеләр. Ә Сибгатуллин:

— Ничек итеп аны шундый салкынга, япан кырга куып чыгарасың, — диде. — Катып үләчәк ул анда, яки пуля тиячәк. Үзегез уйлап карагыз. Бу авылдан калган берданбер җан иясе бит ул. Кем белә, бәлки әле ул безнең землянка урынында торган өйнеке дә булгандыр. Өемә кайтам, дип кергәндер мескен. Алар шундый, өйләреннән бизмиләр, кая илтеп ташласаң да өйләренә кайталар. Гадәтләрен беләм мин аларның...

Мәче солдатларның аңа тимәвен, киресенчә, аны иркәләргә, сыйпарга теләүләрен күрсә дә шикләнеп, мич янына үрмәләде. Һәм, аның артына кереп, йомарланып ятты, бераздан йокыга да китте.

Мәченең көтмәгәндә землянкага килеп керүенә, авыр окоп тормышын аз булса да үзгәртеп җибәрүенә барыннан да бигрәк ефрейтор Сибгатуллин куана иде. Өстәвенә соры мәче аның туган авылын, андагы җиде аршынлы яңа йортын, акшарлы мич буенда ялкауланып, наз-

ланып яткан шундый ук соры мәчене хәтерләтә һәм бу хәтерләү аның җанына рәхәтлек бирә иде.

Кичкә таба мәче землянкадагы кешеләргә тәмамияләште, инде аркасыннан сыйпата, иркәләтә дә башлады, хәтта, ашап туеп җылы мич янына барып яткач, мыраулый да иде.

Отделение землянкасында Борис Михайлов исемле снайпер да тора иде. Хезмәте белән ул отделение командирына түгел, ә турыдан-туры рота командирына буйсына. Соңгы вакытларда Сафин отделениесендә кеше аз калганлыктан, рота командиры аңа шунда торырга кушкан иде.

Ул «аудан» үзенең кулдашы белән караңгы төшкәч кенә кайта, төн буе ял итә, йоклый, аннары бик иртә торып, таң сызылганчы яңадан шул ук егет белән алгы кырыйдагы окобына чыгып китә иде. Отделение землянка казыганчы ул рота командиры янында ял иткәләп йөрде, ә инде землянка тәмам өлгергәч, стеналары беркадәр кипкәч, Сафиннар янына кайтырга булды.

Ул бөтен ротаның, алай гына да түгел, ә бөтен батальонның кадерле сугышчысы иде. Чөнки снайпер иде ул, ходайның һәр бирмеш көнендә фашистларның я берсен, я икесен, кайчак, бәхетле көн дип саналган аерым көннәрдә, өч-дүртен дә дөмектереп кайта иде. Егетләр аны кадерләп кенә торалар, окоп янсә землянка казыганда, кулына көрәк тоттырмыйлар, фашистка төзәгәндә кулының сизгер булуын, калтырамавын телиләр. Ау уңышлы булган көннәрдә ул землянкага күтәренке күңел белән кайта һәм ишектән килеп керү белән үк ничә гитлерчыны теге дөньяга җибәргәнен бармаклары белән генә күрсәтә.

Землянкага ул мәче пәйда булганнан соң ике-өч көн узгач кайтып керде. Иптәшләре аның землянкага ничек килеп керүеннән, күз карашыннан һәм бармаклары белән бернәрсә дә күрсәтмәвеннән үк бүген ауның уңышсыз чыгуын сизеп алдылар. Гәрчә бу тәбәнәк буйлы, сап-сары чәчле егет сабыр холыклы булса да, мондый көннәрдә каралып, кашларын җыерып кайтып керә иде. Моны сизгән иптәшләре аңа мөмкин чаклы игътибарлырак булырга, аның күңелен табарга тырышалар, үзләренчә аңа немецларны алдар өчен төрлечә киңәш итәләр.

Бүген дә аны егетләр ачык йөз белән каршы алдылар. Ул килеп керү белән үк диярлек аш белән ботканы тимер мич өстенә җылытырга куйдылар.

Гел шат күңелле, шаян телле кулдашының да йөзе чытык иде бүген. Ул бик чыланган, пычранган, шуңа күңелсез иде булса кирәк.

Ашарга утыргач, Борис Михайлов мәчене күреп алды:

— Нәрсә бу? — дип сорады ул җирәнеп.

— Мәче,— диде Сибгатуллин һәм землянкага ничек килеп керүен сөйләп бирде.

Михайлов мич янында, портянкалар, чүпрәкләр арасында изрәп йоклап яткан мәчегә тагын бер тапкыр күз салды:

— Яратмыйм мин мәчене, җенем сөйми. Әти дә минем гомердә мәче асрамады. Кемгә кирәк соң бу үләксә?

— Миңа, — диде Сибгатуллин, аннан соң: — Барыбызга да, — дип өстәде.

— Барыгызга да. Бары тик миңа гына түгел. Мине кушып сөйләмә, зинһар.

— Нигә яратмыйсың син аны? Файдалы хайван ич ул.

— Файдалы! Нинди файдасы булсын аның! Әгәр эт булса, бер хәер иде. Яхшы ау эте булса, билгеле. Ә бу үләксәне, минемчә, яхшы чакта тиреслеккә чыгарып ыргытырга гына кирәк, — диде снайпер. — Менә күрерсең, бөтен землянканы сасытып бетерер... Пычратып кына карасын, валлаһи, шунда ук ботыннан тотып, башы белән баганага бәрәчәкмен... Яратмыйм мин мәчене, җенем сөйми...

Мәче дә сүзнең үзе турында барганын, снайперның аңа карата явыз уйлар саклаганын сизгәндәй, күзләрен ачты, сагаеп, урыныннан торды. Аннары ул, Михайлов үзенең ашын, боткасын ашап бетереп йокларга ятканчы егеттән күзен алмады. Михайлов урыныннан кузгалып, авыр итекләре белән землянка буйлап үткәндә, мәче һәр нәрсәгә әзер килеш мич артына кача иде. Ләкин төн тыныч үтте, мәчене кыерсытырлык бер нәрсә дә эшләнмәде.

Бер-ике атна эчендә мәче тәмам тазарып, матурланып житте. Аның кайчандыр таркауланып, тырпаеп, кул тию белән үк очарга әзер торган йоны шомарды, ыспайланды, сырт буенча матур гына, тигез генә булып сузылган карасу сызыгы тагын да ачыклана, ялтырый төште, койрыгы да күпереп китте, ә мыеклары арслан мыегыдай тырпаеп тора башлады. Ул үзе дә бик шаян, уйнаганны, сыйпаганны ярата торган мәче булып чыкты. Аны землянкада Михайловтан башка бөтен кеше яратты. Берәрсе землянкага килеп керү белән үк сикереп сәке өстенә менә, яки яннарына килә, койрыгын таяк шикелле тырпайтып, аларга дусларча ышкына, иркәләнә, мыраулый һәм үзен иркәләүләрен, сыйпауларын көтә иде. Ә Сибгатуллинның алдына менеп яту белән генә чикләнмичә үзенең юка теле белән кулын да ялап ала.

Бары Михайлов белән генә килешә алмады ул. Михайлов яратмады аны. Мәче дә аның тирәсендә буталмаска тырыша, ул өйдә чакларда сәке өстенә менмәскә, аяк астында йөрмәскә тырыша. Хәтта ул снайперның кәефсез, ачулы чакларын да сизә иде шикелле. Андый көннәрдә ул тышта йөрүне, землянкада булса, мич артында ятуны яхшырак саный. Аларның бер-берсен яратмауларына сәбәп тә бар иде, билгеле.

Михайлов кулдашы белән ауда чакта аларга дип китерелгән аш белән ботка көнозын өсте капланган килеш шүрлектә яки сәке өстендә тора һәм аннан аңкып торган тәмле ис мәченең борынын ярып керә, тынычлап йокларга ирек бирми, хәтта ул аның хуш исен йоклап киткәч тә сизеп ята.

Мәче тормышта анысын-монысын күп күргән иде. Ул ашамлыкларга тияргә ярамаганлыгын, тисәң, кешеләрнең аны я чыра, я чыбык белән кыйнаганнарын белә иде. Үз гомерендә ул шактый чыраларны, чыбыкларны күргән һәм моның нинди авыр икәнен дә онытa алмый иде.

Аның тыйнаклыгын, чисталыгын, ашамлыкларга тимәвен күреп, Сибгатуллин иптәшләренә аны мактап та алды. Әллә инде мактау ярамады, әллә ул көнне котелоктагы ит кисәгеннән аеруча тәмле ис аңкып мәчене исертте, кыскасы, бер көнне землянкадагы сугышчылар кинәт игълан ителгән тревога белән окопларына, үз участокларына чыгып йөгергәч, мәче әкрен генә урыныннан торды һәм бик тәмле итеп киерелгәч, тәпиләре белән йомшак-йомшак басып, җир сәке янына килде. Бер сикерүдә ул инде сәкедә, хәтта шүрлек янында иде. Ә шүрлектә майланып-корымланып беткән өч котелок тора. Уртадагы котелокта, мәченең авыз суларын китереп, аның тынычлыгын җуеп, майлы ит кисәге ята.

Дөресен әйтергә кирәк, мәче аны ашарга уйламады, бары тик бер күз кырые белән генә карарга теләде, әмма карау белән, барлык чыраларның, чыбыкларның зәһәр сызгыруларын онытты.

Берничә минуттан инде ит ашап бетерелгән, мәче иреннәрен, алгы тәпиләрен бик тәмләп ялап утыра иде.

Аның бу хыянәтен землянкадагылар әллә сизмәделәр, әллә инде сизеп тә бер юлга гафу итәргә уйладылар, чөнки чыбык чыжылдамады, хәтта аңа, аяк тибеп, ачуланып кычкыручы да булмады. Шуннан соң инде мәче шүрлеккә кыюрак менә башлады.

Бер көнне кич, отделение постта чакта, Михайлов землянкага арып-талып, баштанаяк пычранып, бик күңелсезләнеп кайтып керде. Салкын тиеп температурасы күтәрелү сәбәпле землянкада калган Сибгатуллин

 

аның аяк тавышыннан, ишек ачып керүеннән үк бүген юлы уңмаганын, бер фашистны да үтерә алмаганын сизде.

Землянкага килеп кергәч, Михайлов бер сүз дә әйтмичә винтовкасын почмакка сөяде дә маскхалаты һәм шинелен ачу белән сәкегә ыргытты, аннары авыр гына сәке кырыена килеп утырды.

— Ашың сәкедә, төреп куйган, — диде Сибгатуллин. — Әнә анда чәй дә бар. Шикәрең капчыкта. Өч кенлек.

Михайлов ашы белән боткасын сүзсез генә сузылып алып сәкегә куйды. Ашын ашап бетергәч, кулына боткасын алды.

— Ә моның ите кайда? — диде ул. — Әллә бүген дә ит булмадымы?

— Белмим, мин күрмәдем. Старшина китерде.

— Ит булдымы соң бүген? Ашагансыңдыр бит?

Сибгатуллин ялганлый торган егет түгел иде, дөресен әйтте:

— Булды. Боткада булырга тиеш.

— Юк бит монда ит — диде снайпер, аңа текәлеп. — Әллә бүген дә синең шул каһәр төшкән мәчең ашаганмы? Нәрсә бу? Нинди мыскыл итү? Ни өчен мин аны үз паегым белән туйдырып ятырга тиеш? Мин бер төннән икенче төнгә кадәр яңгырга, буранга карамыйча, урынымнан да кузгалмыйча окопта ятам, немецларны кырам. Ачыгам, туңам, чылам, пычранып бетәм. Ә монда синең үләт мәчең мина дигән итне ашый, үзенең әшәке аякларын ашыма тыга. Моңа кадәр мин тавыш чыгармадым. Аңларсың, бу кадәр миңгерәү түгелсең дип уйладым... Ләкин аңламыйсың икән син... Ачуымны гына китерәсең. Бүген минем болай да җен ачуларым чыкты, — диде ул, кызганнан-кыза барып. — Ничә көн инде бер фашистны да дөмектерә алганым юк. Ә монда, уч иткән шикелле, синең мәчең... Кайда әле ул кабахәт җан?..

Шул сүзләрне кычкырып ул билендәге калын тимерле каешын чишә дә мәчегә таба атлады. Бу шау-шуны ишеткән мәче инде урыныннан торган һәм яшел күзләре белән Михайловка текәлгән иде.

— Ах, каһәр суккан нәрсә! — диде снайпер, аңа мич аша селтәнеп.— Син әле минем паекны ашыйсыңмы?!

Мәче аңа караганда җитезрәк булып чыкты, күз ачып йомганчы утыннар, капчыклар артына кереп посты. Снайпер анда да җитешергә уйлаган иде, ләкин Сибгатуллин үзенең зур, таза гәүдәсе белән аңа аркылы төште. Тыныч кына, кызмыйча гына аның селтәнергә әзерләнгән каешыннан тотып алды:

— Тукта, аны кыйнаудан файда юк. Ул гаепле түгел.

Сибгатуллинның каршы төшүе һәм шул хәлдә дә тыныч калуы снайперның ачуын соңгы чиккә җиткерде.

— Ничек гаепле түгел?! — диде ул, җикеренеп. — Менә мин аңа күрсәтим әле гаебен!..

Михайлов, ярсып, почмактагы винтовкасына сузылды, ләкин ул арада Сибгатуллин ишекне ачып җибәрде, һәм шуны гына көтеп торган мәче, яшен шикелле атылып, чыгып китте.

— Син аны! — диде снайпер, каты итеп сүгенеп, һәм винтовкасын тоткан килеш аның артыннан тышка атылды.

Тышта караңгы, — качкын мәчене табарлык түгел иде.

Михайлов землянка алдында туктап, берникадәр вакыт як-ягына карангыргалап торды. Дөм-караңгы, бернәрсә күренми, хәтта өй хәрабәләре дә күренми. Бары моңсу, кайгылы йолдызлар гына күзгә чалына. Алары да сирәк, алары да кара болытлар арасыннан гына күренәләр.

Алгы кырыйда сирәк-мирәк атышлар бара, төнге караңгылыкны кисәп ертып, һавага ракеталар күтәрелә, түбәннән генә эз калдыргыч пуляляр сызгырып үтә. Ара-тирә, төнге тавышларны басып, туплар улап ала. Аларның гөрселдәү тавышлары каядыр еракка-еракка, каршыдагы

таулар, урманнар артына китеп югалалар. Шуннан соң пулемет һәм винтовка тавышлары янадан ачыграк булып ишетелә башлый.

Михайлов бераз алгы кырыйдагы тавышларга колак салып торды. «Немец тынычсызлана», — дип уйлады ул.

Сугышның табигый авазлары, салкын җил, саф һава Михайловның нервларын бераз тынычландырды. Хәтта ул үзенең шулай кинәт ярсып китүенә дә гаҗәпләнде. Боларны ул соңгы вакытларда уңышсыз үткәрелгән, аның фикеренчә, бөтенләй әрәмгә китеп бер фашистны да дөмектерә алмаган көннәр нәтиҗәсендә туган борчылуларга сылтады. Борчылмаслык та түгел. Күрше полктагы танышы Орловның счеты инде йөз уникегә җитте. Ул һәр көнне, табигый бер юлга салынгандай, берике гитлерчыны, хәтта кайвакытларда өчне үк теге дөньяга озата тора. Ә аның, Михайловның, моңа кадәр дивизия күләмендә беренчелекне бирәүгә дә бирмәгән себер аучысының счеты соңгы көннәрдә бик акрын үсә, ә соңгы көннәрдә бер фрицны да дөмектерә алганы юк. Аның алгы сызыкны узып, яшеренгән килеш немецларны күзәтеп ятуы, кулыннан килгән барлык осталыкны, барлык хәйләләрне куллануы, — барысы да бушка китте. Немецлар соңгы атна эчендә, үч иткәндәй, үзләренең окопларыннан башларын чыгармыйлар, Михайлов пулясы алырлык участокта күренмиләр. Әгәр берәр нәрсә уйлап табып аларның бу саклыкларын онытгырырга, югалтырга мөмкин булса, снайпер аңа әллә ни бирер иде. Юк, ул дошман солдатын үтермичә, аны теге дөньяга җибәрмичә яши алмый. Фашистны мушкага алмаган көн — бушка, әрәмгә үткән, мәгънәсез көн.

Күп булса, бер атна, ике атна үтәр, снайпер Орлов үзенең исәбендәге фашистлар саны белән аны куып җитәр, хәтта узып китәр. Менә нәрсәгә борчыла иде Михайлов. Ул моны берәүгә дә әйтмичә эченнән генә яна. Җитмәсә, шушы каһәр төшкән мәчесе килеп чыкты. Әгәр мәче булмаса, ул Сибгатуллин алдында алай ярсып, ташып чыкмаган булыр иде.

Михайлов бераздан землянкага кире керде. Инде аның нервлары тынычлана төшкән иде.

Снайперның моннан соңгы көннәре дә уңышсыз булып чыктылар. Ул инде төшенкелеккә бирелеп, каралып, эченнән янып йөри башлады, хәтта кеше белән сөйләшмәс дәрәҗәгә җитте. Рота командиры белән батальон командирлары да аны үзләре янына ике тапкыр чакырып алдылар, уңышсызлыкның сәбәбен сораштылар. Иптәшләре дә аның бу хәлен күреп торалар, аны мөмкин булган кадәр тынычландырырга тырышалар. Сибгатуллин исә мәчене, аның күзенә күрсәтмәс өчен, кич белән күрше землянкаларның берсенә кертеп куя торган булды.

— Тәмам башым катты, — диде Михайлов бер көнне иптәшләренә,— һич кенә дә хәйлә таба алмыйм. Никадәр вакыт узды, ә счетым һаман бер тирәдә. Оят, валлаһи!.. Көнозын күзәтеп ятасың, туңып, өшеп бетәсең, ә окоптан бер немецның да башы күренми. Ни булды аларга? Ничек башларын чыгартырга?.. Ике-өч секундка гына булса да... Миңа шул да җитәр иде...

Егетләр аңа карачкы ясап, фашистларны шуның белән алдарга тәкъдим иттеләр.

— Юк, хәзер аның белән алдырып булмый,— диде снайпер, кулын селтәп.

Шуннан соң аңа дуслары консерва тартмалары, көзге һәм башка шуның кебек нәрсәләр белән хәйлә оештырырга киңәш итеп карадылар. Ләкин снайпер аларны да кире какты, чөнки инде ул алардан файдаланган һәм, шулай итеп, берничә гитлерчыны юк иткән иде.

Сибгатуллин тәмәкесен тарта-тарта бер читтә уйланып утыра иде.

— Бәлки мәче белән берәр нәрсә эшләп булыр, — диде ул.

Михайлов аңа гаҗәпләнеп карап куйды.
— Нәрсә? Мәче белән дисеңме?
— Әйе, мәче белән.
Снайперның соргылт күзләренә мыскыллап көлү чаткылары бәреп чыкты.
— Синең үләтең ул землянканы пычратырга гына ярый. Ачуымны китереп, шаяртып утырма әле, зинһар.
Ләкин Сибгатуллинның шаяртырга исәбе юк иде.
— Мин чынлап әйтәм, — диде ул. — Тукта әле, тыңлап тор бераз, кире шайтан! Аннары чәпчерсең. Менә нәрсә... Әгәр мин аны, бик әкәмәт киендереп, сиңа бирсәм ничек булыр? Син аның белән немецларны алдый аласыңмы? Әйтик, напарнигың аны берәр урыннан аларга таба ыргытса, мәче, куркуыннан нишләргә белмичә, арлы-бирле чабып йөрер иде. Бәлки, фрицлар аны күреп, башларын калкытырлар. Ә син ул арада, кем белә, бер-икесен чәкеп алырга өлгерерсең. Шулай итсәк, ничек булыр икән, ә?..
Сибгатуллинның сүзләрен мыскыллы елмаю белән тыңлап торган Михайлов бу сорауга сүгенеп, шаркылдап көлеп җавап бирде:
— Ничек булыр, дисеңме? Фашистлар минем кайда ятканны сизеп алырлар да бөтен утны минем өскә юнәлтерләр. Менә шул булыр. Моны эшләргә юләр дип белдеңме әллә син мине?! Ташла әле шул мәчеңне! Саруымны кайнатып, такылдап утырма әле, зинһар! Болай да башым каткан. Ыргытасың килсә, син аны хәзер үк ботыннан тот та землянкадан чыгарып ыргыт. Шулай итсәң, яхшырак булыр.
Моңарчы аларны тыныч кына тыңлап торган чуваш егете Василий Николаев та сүзгә кушылды:
— Тукта әле, ул чаклы кызма, — диде ул Михайловка. — Кирәкмәгәнгә сүгенмә дә. Әнәс бик кызык нәрсә әйтә шикелле. Чыннан да, аның белән немецларны алдап булыр кебек. Тыныч кына уйлашып карыйк әле.
— Алдарсың, авызлары пешкән аларның.
— Шулай да мәче белән алдап караганың юк бит әле синең?
— Анысы дөрес, — диде Михайлов, бераз тынычлана төшеп, — мәче белән алдалап караганым юк. Тик фрицларны шаккатырырлык итеп киендерсәгез генә инде. Ул чакта, бәлки, сынап карарга ярар. Ыргыткач карда аунап ятмасмы соң ул?
Сибгатуллин, снайперның ачуы басылганын, хәтта бу мәсьәлә белән кызыксына да башлавын сизеп алып, күңелендә йөрткән планны бик рухланып сөйләргә кереште:
— Нигә карда аунап ятсын ул? Коерыгына кыңгырау тагам мин аның. Күрерсең менә, немецлар траншеясы тирәсендә ут кебек атылып йөрер. Кая керәсен белмәс. Мәче гадәтен беләм мин. Коерыгына берәр әйбер генә так син аның...
Михайлов бераз уйланып торганнан соң:
— Кыңгырау бармы соң? — дип сорады.
— Табабыз аны, — диде Сибгатуллин. — Бүген иртә белән бер урында күргән идем. Шалтыратып та карадым. Шәп шалтырый.
— Ә өстенә нәрсә кидермәкче буласың?
— Өстенәме? Каурыйлардан берәр нәрсә әмәлләрбез шунда.
Бусын чуваш егете бик ошатты, хәтта ул:
— Дикобраз шикелле була бит бу! — дип кычкырып ук җибәрде. — Валлаһи, шәп була! Африка җәнлеге кинәт Россиядә, кар өстендә. Фашистлар моңа шаккатырлар. Валлаһи шаккатачаклар!
Бу киңәш белән Михайлов чынлап кызыксына башлаган иде инде. Тимер мич янында тыныч кына йоклап яткан соры мәчене ул инде ап-ак кар өстендә, кая керергә белмичә шашып чабып йөргәндәй күз алдына китерде.

— Кара каурыйлар белән бизәсәк яхшырак булыр иде, — диде ул.— Кар өстендә ачыграк күренер иде. Тик монда каурыйлар табып булырмы икән соң? Елап эзләсәң дә бер тавык калмагандыр бу тирәдә. Фрицлар барысын да кырып, ашап бетергәннәрдер.

Егетләр моның белән килешеп бетмәделәр, кайда да булса берәр тавык качып калгандыр әле, диделәр. Тавык булмаса, карга белән чәүкә каурыйлары да ярый. Алар яхшырак та булыр, дигән фикергә килделәр.

Берәр әйбер табу мәсьәләсендә Василий Николаевтан да булдыклы кеше юк иде. Кирәк әйберне ул җир астыннан да табып кайта. Бу эшне дә аңа тапшырдылар.

Ике көннән таң сызылып килгән чакны Михайлов белән Сибгатуллин алдан әзерләнгән окопларда маскхалатларын кигән хәлдә яшеренеп яталар иде инде.

Бу урынга алар төнге караңгыда ук килеп урнаштылар. Окоплары маскировать ителгән булса да, тагын бер тапкыр бик җентекләп күздән кичерделәр. Немецлар сизәрлек булмасын. Бәхетләренә каршы, төнлә белән бераз кар сибәләп киткән, бөтен дөньяны ак җаймә белән каплаган иде.

Фронт тыныч. Немецлар да ерак түгел. Яктырткыч ракеталар һавага күтәрелгәндә траншея сыртлары да күренә. Каршыда еракта түгел кара шәүләләр чагылгалап китә. Наратлар булса кирәк. Көндез ул тирәдә наратлар утыра иде. Әнәснең бөтен өмете шуларда. Мәче, коты очып, бераз арлы-бирле атылып йөргәннән соң шунда таба качар, дип өметләнә иде ул. Немецларның игътибарын җәлеп итмичә калмас, дип уйлый иде.

Хәзергә соры мәче капчыкта, Сибгатуллин янында ята, сизелер-сизелмәс кенә калтырый, ара-тирә кызгандырырлык итеп мияулап та ала.

Яхшылап урнашканнан соң, Сибгатуллин капчык авызын бераз бушатып, кулын тыкты да мәчене әкрен генә сыйпарга кереште.

— Туңасыңмыни, мескенем,— диде ул аңа пышылдап кына. — Салкындыр шул. Кил, жылын. — Һәм ул аны капчыгы белән бергә үзенең куенына, шинеле эченә тыкты.

Берничә минуттан мәче, җылынып, тынычланып, әкрен генә мырлый башлады.

Мәченең җылысын Сибгатуллин да тоя иде. Аның әкрен генә, тыныч кына мырлавы, гимнастерка аша бәреп торган җылысы, тәнгә рәхәтлек бирә торган йомшаклыгы Сибгатуллинның тартылган нервларын тынычландырганнан-тынычландыра бара иде.

Әкрен генә, ашыкмый гына яктырды, алтын нурларын сирпеп, кояш күтәрелә башлады. Офык итәгендәге вак, таркау болытлар, канга манчылгандай, алсуланып киттеләр. Табигать уянды.

Фронтның бу участогында кичәдән бирле тынлык хөкем сөрә иде.

Сибгатуллин, каяндыр ерактан ишетелгән артиллерия гөрелтесенә колак сала-сала, дошман траншеясын күзәтүендә дәвам итте. Окоп алларындагы пулялар белән тетелеп беткән таллар, узган елдан калган әремнәр һәм шайтан таяклары арасыннан дошман траншеясының өсте, урыны-урыны белән борылышлары ачык күренә иде.

Читтәрәк яткан Михайлов Сибгатуллинга сизәрлек итеп кенә сигнал җебен тартканда кояш инде шактый күтәрелгән, немецлар траншеясында да хәрәкәт сизелә башлаган иде. Сибгатуллин сакланып кына мәчене капчык эченнән чыгарды, аның каурый җайланмасын рәтләде, кыңгыравын коерыгына тиеп торырлык, борчырлык итеп такты. Мәче каурыйлары тырпаеп торган дикобраз сыман гаҗәеп әкәмәт җәнлеккә әверелде. Аны инде алга, немецлар ягына таба ыргытасы гына калды. Сибгатуллин, мәче куркудан коерыгына тагылган кыңгырауны шалтырата

шалтырата кыр буйлап атылып чабып йөргәне агач башларына үрмәләп менәргә һәм шуның белән дошман траншеясында гаҗәпсену, кызыксыну уятырга тиеш иде. Мәчене ыргытыр өчен ул урыныннан бераз күтәрелә төште, ләкин ыргытмады. Нәрсәдер уйлап, аны тагын бер тапкыр башыннан сыйпады, күкрәгенә кысты.

— Мескенем, мескенем!

Михайлов сигнал җибеп яңадан тартты. Аның тартуында ашыктыру, кисәтү бар иде. Хәзер үк, шушы секундта ук ыргытырга кирәк! Югыйсә соңга калуың бар, бөтен эшне харап итүең мөмкин! Бу кисәтү Сибгатуллин күңелендәге кызгану хисләрен таркатып җибәрде. Менә ул тизләнеп, окоптан башын чыгармыйча гына күтәрелә төште дә мәчене уң кулы белән тотып алга, немецларга таба ыргытты.

Бер-ике секундтан инде мәче чыннан да куркып, котырынып, койрыгына тагылган кыңгыраудан котылырга, аны ташлап калдырырга теләп, дошман траншеясына таба уктай атылды. Кыңгырауның төшеп калмавы, өзлексез шалтыравы мәчене ярсытканнан-ярсыта иде.

Немец күзәтүчеләре, кыр буенча атылып чабып йөргән гаҗәеп җәнлекне күреп, кычкырып җибәрделәр. Шундук траншеяның төрле җиреннән бик сакланып кына немец каскалары, күс соры пилоткалар калкынды. Һәм шул секундта ук снайпер Михайловның винтовкасы, үлем сорап, коры-коры гына шартларга тотынды. Сибгатуллин да инде бик тырышып үзенә баш эзли иде.

Мәче, койрыгына ут капкандай шашынып, немецлар траншеясы каршында арлы-бирле атылып йөрде дә бер читтә үсеп утырган наратларга таба ташланды. Кайбер урында кар бата, аңа иркенләп чабарга ирек бирми, шуңа күрә ул баткан саен, бөтерелеп, һавага сикерә, читтән караучыларны үзенең хәрәкәтләре белән бик гаҗәпләндерә иде.

Бу мизгелдә Әнәс Сибгатуллин траншеядан күренгәләп киткән каскаларга, пилоткаларга бик тырышып төзәп атса да, күңелендә бер генә уй: «Мәче окобыма кире кайтмаса гына ярар иде... Кире кайтмаса гына ярар иде...», — дигән уй иде.

Шөкер, мәче кире кайтмады. Агачларга йөгереп барып җитеп, беренче туры килгән нарат башына үрмәләп менеп китте. Тик шунда гына фашистлар алданганлыкларын сизделәр булса кирәк, траншеяларында нәрсәдер кычкырып, каты сүгенеп, мәчегә винтовкалардан, автоматлардан ут ачтылар.

Мәче агач башына менеп җитә алмады, пуля тиеп булса кирәк, кыңгыравы-ние белән һавада бөтерелә-бөтерелә җиргә егылып төште.

Немецлар снайперларның кайдан атканлыгын чамалап алдылар, күрәсең. Мәче агач башыннан егылып төшү белән автомат утларын снайперлар окопларына таба юнәлттеләр. Аларга пулеметлар да кушылды, кар, җир актарылып, уфылдап, якын тирәдә миналар ярыла башлады.

Егетләребез инде, урыннарын алмаштырырга теләп, запас окопларга таба шуышалар иде. Баш очларыннан пулялар, мина кыйпылчыклары өзлексез очып торса да, алар исән-имин икенче окопларга шуышып барып җиттеләр һәм икесе ике урында, тыннарын да чыгармыйча, посып ята башладылар.

Ул арада гитлерчыларның артиллериясе дә эшкә кереште.

Озак та үтмәде, немец ут нокталарын басарга, снайперларны арапарга теләп, үзебезнекеләр дә бөтен участок буйлап ут ачтылар. Дөнья үкерергә, уларга тотынды.

Көн тынычсыз үтте. Немец пулеметчылары, минометчылары аларны күп урыннан эзләп, каппап карадылар, ләкин барлык эзләнүләре бушка китте. Егетләр окопларында посып ята бирделәр.

Михайлов кайтыр өчен Сибгатуллин янына шуышып килгәндә инде тәмам караңгы төшкән, күктә йолдызлар җемелди башлаган иде.

— Киттекме? — диде Михайлов, аның окобы янында туктап.

Сибгатуллин, окобыннан күтәрелә төшеп аңа сорау белән җавап кайтарды:

— Ә мәчене нишләтәбез? Калдырабызмыни шулай?

— Тагын мәче! — диде Михайлов тупас кына итеп. — Ташла, зинһар, шуны. Әллә аның үләксәсен өстерәп кайтмакчы буласыңмы?

Снайпер бик туңган, бөтен гәүдәсе белән калтырый, тешләре, берберсенә бәрелеп, шакылдый иде. Аның соңгы окобы сулы булып чыкты. Ул көнозын сулы окопта бик уңайсыз чүгәләп утырды, тезләре тәмам катты, бернәрсә сизмәс булды. Шуның өстенә ул үзенең икмәген дә элеккеге окобында онытып калдырган. Көнне ул ачыгып, туңып һәм тәмәке тарта алмыйча газапланып үткәрде. Шуңа күрә ул Сибгатуллинның урынсыз соравына, тизрәк өйгә кайтырга, җылынырга торганда мәчене эзләп йөрергә теләвенә каты һәм тупас җавап кайтарды. Өстәвенә, немецлар инде яктырткыч ракеталарын һавага тондыра башлаганнар иде. Мондый хәлдә мәчене эзләп йөрү бик куркыныч иде.

Алар үзләренең землянкаларына кайтып җитәрәк кенә бераз җылындылар. Җылыну, тәмәке тартып җибәрү снайперның нервларын тынычландыра төште һәм ул бая дустына каты, тупас итеп җавап кайтаруына үкенә башлады.

— Бүгенге ау бу кадәр уңышлы булыр дип көтмәгән идем мин. Молодец икәнсең. Рәхмәт сиңа, — диде ул, аның күңелен табарга теләп. — Ике-өч минут эчендә биш фриц теге дөньяга китте. Сизми дә калдылар. Менә бит ул хәйлә нишләтә.

Әнәс Сибгатуллин, аның сүзләрен ишетмәгәндәй, тын гына бара, нәрсәдер уйлана, үзенең юан итеп төргән тәмәкесен комсызланып суыра иде.

— Син дә икене дөмектердең, — дип, снайпер сүзен дәвам иттерде. — Аз түгел. Димәк, без синең белән икәү бүген дөньядагы фашистлар санын җидегә киметтек... Ташла, зинһар, уйлама шул мәче турында, — Михайлов аны култыклап алды, аның күңеле күтәренке иде. — Бер мәче үлгән икән, әллә ни түгел, кеше дә үлә. Сугыш ул... Уйлама, исән булсак, сугыштан соң без синең белән икәү бөтен өебезне мәче белән тутырырбыз. Исән-сау кайтыйк кына. Сорысын да, сарысын да, карасын да, агын да табарбыз.

Култыклап алу да, юмалап әйтелгән сүзләр дә Сибгатуллинның телен ачмадылар. Алар, шулай итеп, землянкаларына сүзсез генә кайтып керделәр.

Снайперның уңышы турындагы хәбәрне отделениедә ишеткәннәр иде инде. Сафин аларны котлап каршы алды: «Туңгансыз, җылыныгыз тизрәк», — дип алар өчен махсус бирелгән йөзәр граммны чыгарды.

Егетләр, кружкаларын бушатып, ашый башларга да өлгермәделәр, ашамлык белән эчемлек күтәреп, старшина да килеп керде. Ул аларны мактый-мактый табын уртасына ике консервы белән бер шешә китереп куйды:

— Батальон командиры җибәрде боларны, — диде ул. — Беләсезме, сезнең хәйләгез аркасында батальон бүген ничә фашистны юк итте? Егерме икене. Немецларның ике пулемет, бер миномет точкаларын да һавага очыруны исәпкә алсак, шәп булды бу! Менә сезгә соры мәче!. Молодец егетләр!

. Кружкаларга яңадан аракы салдылар, мәҗлес җанланып китте. Землянка хуҗалары бүгенге сөенечләреннән күп сөйлиләр, бер-берсен шаярткалап алалар, көлешәләр иде. Тик Әнәс Сибгатуллин гына сүзгә кушылмыйча, кашларын җыерып, уйланып утыра бирде. Салганны эчә, әмма тамагына бернәрсә капмый. Гадәттә ул үзенә тиешлесен дә ни-

гәшләренә бирә иде. Бу юлы ул сыйдан баш тартмады, салганның берен озата барды, чөнки көнозын тар окопта хәрәкәтсез ятып бик туңган, хәтта хәзер дә әле җылынып җитә алмый иде. Бер заман егетебез сизелерлек исереп китте. Аңа ятарга, ял итәргә киңәш иттеләр. Әнәс карышты. Һәм шуның белән бергә аның кинәт теле ачылып китте.

— Туктагыз әле, нигә сез мине ятарга кыстыйсыз? Ят та ят дип йөдәтәсез, — диде ул иптәшләренә. — Ятарга теләмим мин. Мәчене барып алып кайтасым бар минем... Мин алып кайтмасам, кем алып кайта аны? Берәү дә алып кайтмый... Әллә сез аны үлгән дисезме? Юк, үлмәгән ул. Мин аның тавышын анда көнозын ишетеп яттым. Көнозын ул сызланып, кычкырып, мине үз янына чакырды. Мине чакырды, мескенем... Мин аны караңгы төшкәч, барып алмакчы да булган идем, менә бу шайтан җибәрмәде, — диде ул һәм бармагы белән снайперга төртеп күрсәтте. — Шушы таш йөрәк җибәрмәде...

Егетләр аны сыйпаштыргалап, юмалап яткырырга маташып карадылар, — бусы да барып чыкмады, ул, аларны, кулы белән бер читкә этеп, Михайлов каршына барып басты һәм иңбашыннан ике кулы белән кысып:

— Ник җибәрмәдең син мине?! — диде. Аннары, кинәт йомшап китеп, Михайловка бармагы белән төртә-төртә сүзен дәвам итте: — Дус дисең син. Дуслык шулай буламыни?.. Әйт, шулай буламы?.. Беләм, син — снайпер. Атаклы снайпер. Синең пуляларың фашистларны җир тишегеннән дә эзләп таба, йөрәкләренә барып керә. Бусы өчен молодец син. Шуның өчен мин сине яратам, ихтирам итәм. Ләкин синең йөрәктә бары нәфрәт кенә яши. Аңлыйсыңмы, бары нәфрәт кенә... Син ярата белмисең, сөя белмисең. Җылы, йомшак күңел юк синдә. Фашистны кыр син, үтер. Юк ит. Кызганма. Шулай кирәк аңарга. Тамырын корыт. Ә мәчене кызган син. Кызган, ул безнеке. Ул гөнаһсыз мәхлук... Йомшак күңел юк синдә...

— Миндәме? — диде Михайлов гаҗәпсенеп һәм шул ук вакыт аны көйләргә, тынычландырырга теләп. — Миндәме? Мин йомшак күңелле түгелме?

— Әйе... Күңелең таш булып каткан синең. Боздай салкын. Көлмә син миннән. Мин сиңа дөресен әйтәм. Көләргә түгел, ә рәхмәт әйтергә тиеш син миңа. Син туганчы мин бер телем ипи ашаган кеше... Беләсеңме, ул нинди мәче иде? Минем өйдәге мәче төсле иде бит ул. Шуңа күрә бик кызганыч ул миңа...

Әнәс Сибгатуллин әйтәсе сүзен әйтеп бетерде, күңелен бушатты булса кирәк, — тынып калды. Нәрсәдер уйлап, землянка уртасында бераз басып торганнан соң, кашыгын кулына алып, ашарга утырды.

Егетләр икенче сүзгә күчтеләр. Сөйләшер сүзләр күп, сугышчылар көнозын бер-берсен күрми торганнар: кайсы постта, кайсы эштә булган, рота өчен йөрү юллары казыганнар, ә Василий Николаев, взвод командирының кушуы буенча санчастька барып кайткан. Өстәвенә, бүген ике кешегә хатыннарыннан хат килгән. Тик бу сүзләргә Сибгатуллин гына кушылмады. Ул һаман нәрсәдер турындадыр уйланып утыра иде.

Бераздан ул урыныннан торды, шинелен, бүреген киде, каешы белән билен кысып буды, кулына винтовкасын алды һәм, бөтен формасын китереп, отделение командирына мөрәҗәгать итте:

— Иптәш сержант, миңа бер-ике сәгатькә землянкадан чыгып торырга рөхсәт итегез әле.

— Кая барасың? — дип сорады сержант.

Сибгатуллин әйтергәме, әйтмәскәме дигән сыман бераз икеләнеп торды да:

— Мәчене алып кайтмакчы булам, — диде.

— Рөхсәт итә алмыйм, — диде аңа Сафин. — Беркая да бармыйсың. Хәзер үк ят. Ял ит.

— Ә мәче?
— Мәче беркая да качмас. Исән булса, кайтыр. Кайтмаса да берни булмас.
— Бәлки рөхсәт итәрсез, старшой? — диде Сибгатуллин, үтенечен кабатлап.— Алып кайтасы иде ул мескенне.
Сафинга берәр шәхси йомыш белән мөрәҗәгать иткән чакларда ул, әллә аның күңелен табарга, әллә болай гына якын итеп, аңа старшой дип эндәшә иде. Бу сүзне ул иптәш командир яисә иптәш сержант дию-гә караганда җылырак, ягымлырак дип саный иде. Ләкин бу юлы җылы сүзнең дә файдасы тимәде, сержант кырт кисте:
— Юк!
Сибгатуллин ишек катында торган килеш күзләрен кыса төшеп аңа бераз карап торды да, кинәт, үзе дә сизмәстән, ярсып:
— Шулаймыни, берни булмасмыни? — дип кычкырып җибәрде. — Мин сине кешегә санап йөри идем. Син дә шундый җансызлардан икән-сең. Алай булгач, рөхсәтеңә төкерәм мин синең, — диде ул һәм ишекне каерып ачып чыгып та китте.
Землянка бер мәлгә тынып калды. Иптәшләре аның кайчак кызып киткәләвен белсәләр дә, бу кадәр үк кызганын күргәннәре юк иде әле. Беренче булып чуваш егете урыныннан сикереп торды, өстенә дә кимичә аның артыннан чыгып йөгерде.
Бу инде ЧП иде, хәрби тормыш өчен гадәттән тыш хәл, командирга буйсынмау, аның приказын үтәмәү, аны хурлау, җитмәсә, бу вакыйга старшина күз алдында булды. Әгәр ул булмаса, бәлки, болай гына, үз-ара гына үткәреп җибәрергә булыр иде. Ә хәзер нишләргә?.. Менә шул уй отделение командирын борчый иде. Өстеннән рапорт язып бирсән?.. Штрафной батальонга җибәрүләре мөмкин. Яхшы сугышчы, батыр егет. Кызганыч. Язып бирмәсәң, старшина шаһит?.. Командованиегә бу ту-рыда ул ничек хәбәр итәр?.. Әйтмичә, хәбәр итмичә калмас мөгаен.
Утны-суны кичкән, бик күп сугышчыларны күргән, берничә тапкыр яраланган, үлем алдында да каушап калмаган бу кара тутлы, базык гәүдәле сержант хәзер аптырашта иде. Билгеле бер карарга килмәсә дә, старшина алдында Сибгатуллинга карата каты торырга булды ул. Шул ният белән урыныннан торып, бил каешын рәтләде, гимнастерка итәген тарткалап, җыйнаштырып куйды, якасын төймәләде, бүреген киде, хәр-би устав таләп иткән рәвешкә килде.
Старшина белән Михайлов сүзсез генә сәке кырыенда утыралар иде. Тик старшина гына гаҗәпләнүеннән ара-тирә башын чайкап ала. Ахыр-да ул снайпердан:
— Һәрвакыт шулаймы бу ефрейторыгыз? — дип сорады.
— Юк, — диде Михайлов. — Мондый гадәтен күргәнем юк иде әле. Дисциплиналы егет ул болай. Нәрсә булгандыр, мондый хәл беренче тапкыр... Аракы ярамаган, күрәсең.
Ниһаять, Василий Николаев ефрейтор Сибгатуллинны, артыннан төрткәли-төрткәли, нәрсәләрдер әйтеп юмалап, землянкага алып керде. Егет инде үзе дә салкын һавада бераз айныган, чамадан артык кызып китүенә, отделение командирына кирәкмәгән сүзләр әйтеп ташлавына үкенә башлаган иде. Шуңа күрә ул землянка ишегеннән төче йөз, гаеп-ле кыяфәт белән килеп керде.
Отделение командиры Әхтәм Сафин аны коры гына каршы алды, ул килеп керү белән үк «Смирно!» дип команда бирде, аннары яхшылык вәгъдә итмәгән салкын тавыш белән:
— Бил каешыңны чиш! Бир монда! — дип өстәде.
Бу инде хәрби җәзаның башлануы иде. Ефрейтор карышмады, ку-лындагы винтовкасын ашыкмыйча гына почмакка сөяп куйды да, бил каешын теләр-теләмәс кенә чишеп, Сафинга сузды. Отделение команди-ры әлеге салкын, кырыс тавыш белән:

— Хәзер ук урыныңа ят! Бер минут вакыт сиңа. Калганын иртәгә сөйләшербез, — диде.

Ул аңа уставны бозуның, командир приказын үтәмәүнең нәрсә белән бетәсен дә әйтергә теләгән иде, ләкин әйтә алмый калды, старшина, аның беләгенә орынып:

— Әйдә әле, сержант, чыгыйк, постларыңны да тикшерәсең бардыр, — диде.

Алар чыгып киттеләр.

Берәр сәгатьтән землянка тынычланды. Сугышчылар, тирән сулап, бик тәмләп йоклыйлар, ара-тирә саташып, сөйләнгәләп алалар, бары тик Михайловның күзләренә генә йокы керми. Ул шүрлектәге гильза лампаның сүнәр-сүнмәс янган саргылт утына, тыштагы часовойның аяк тавышына, йоклаучы иптәшләренең саташуларына, аеруча Сибгатуллинның йокы аралаш нидер сөйләнүенә, ара-тирә уфтанып, ыңгырашкалап алуына колак салып, озак тыңланып ятты. Кайбер минутларда аңа Сибгатуллин ыңгырашмый, ә иптәшләренә сиздермәскә, ишеттермәскә тырышып, әкрен генә елый, үксидер шикелле тоелды.

Төн тыныч иде. Сирәк-сирәк такылдап алган пулемет тавышлары белән миналарның ара-тирә гөрселдәүләре генә ишетелеп куя.

Бераздан снайпер Михайлов сак кына урыныннан торды, киенде, почмактагы автоматларның берсен кулына алды һәм, аяк очларына гына басып, чыгып китте.

Иртәгесен яктырып килгәндә Борис Михайлов белән Әнәс Сибгатуллин әле күмере сүнеп бетмәгән тимер мич янында дусларча тәмәке тартып, сөйләшеп утыралар, ә аяк астына җәелгән фуфайкада соры мәче ята иде. Аның арт саны ап-ак марля белән урап бәйләнгән, аннан сизелер-сизелмәс йод исе аңкып тора.

— Ярасы әллә ни түгел, пуля ботын гына сыдырып киткән, тиресен генә тырнаган, — диде Михайлов, мәчегә ымлап. — Мин кайтышлый ук аны санитардан бәйләттем. Озакламас, төзәлер... Көчкә эзләп таптым үзен. Әле ярый, кыңгыравы ботаклар арасына кысылган булган. Ычкына алмаган. Югыйсә, әллә кая качар иде мәчең.

Михайлов тәмәкесен тирән итеп суырды да күзләрен бер ноктага текәгән килеш нәрсәдер уйланып, йоткан төтенен ашыкмыйча гына өреп, нечкә итеп кире чыгарды.

— Нигә син аның үз мәчегезгә охшаганын башта ук әйтмәдең, — диде. — Әйткән булсаң, калдырмаган булыр идек.

— Әйтмәдем инде.

— Әйтергә кирәк иде. Сине аңлыйм мин. Без барыбыз да өйне сагынабыз, беребез дә таш йөрәк түгел. Өйне, семьяны хәтерләткән әйберләрне изге нәрсә кебек итеп саклап йөртәбез... Минем дә әнием, әтием, хатыным бар. Кырыгынчы елда гына өйләнгән идем. Яшь кызга. Күреп туймассың, валлаһи, менә. Төнлә төшләремә керә, мине чакыра: «Кайчан кайтасың инде?» — ди. Шундый чаклар була, кайбер көннәрне бөтен нәрсәгә аның шәүләсе аркылы карыйм. Тавышын да ишеткән шикелле булам. Чынлап әйтәм, валлаһи. Менә бит ничек. Кайчак аның янына шундый кайтасым килә: чыпчык булып кайтып, тәрәзәдән карап торырга да риза. Ә син мине таш йөрәк, дисең, йөрәгең боз булып каткан, дисең. Белмисең икән син мине,дускай. Мин дә бит синең шикелле үк кеше, миндә дә җан бар, нечкә хисләр бар, сагыну бар. Тик мин аны кешеләргә генә сиздермим. Йомшарып, җебеп китәрмен дип куркам. Йомшасаң, сугыш авырлыкларын күтәрә алмавың бар. Менә бит ул ничек. Шуңа күрә мәхәббәтемне, күңелемдә сакланган барлык изге хисләремне дошманга карата нәфрәткә әверелдерергә тырышам... Юк, син мине аңлап бетермисең...

Әнәс Сибгатуллин үзенең кичә тавыш күтәрүенә, кирәкмәгән нәрсәләр сөйләве, барыннан да бигрәк, отделение командирына каты сүз әйтүе өчен бик борчыла, үкенә иде. Шуңа күрә ул Михайловка күтәрелеп тә карамый, кулындагы чыра белән землянка идәненә аркылы-торкылы сызыклар сызгалап, башын игән хәлдә утыра бирә һәм дустына нәрсәләр әйтергә тели, ләкин һаман әйтә алмый тора.

— Син мине гафу ит, Боря, — диде ул, ниһаять, һәм буыннары калкып торган зур кулын дусларча снайперның тезенә салды. — Кичә мин кирәкмәгәнгә кызып киттем, сиңа да, Сафинга да каты сүзләр әйтеп ташладым. Хәзер менә алар монда утыралар, — диде ул, йөрәк турына күрсәтеп. — Тырнылар, әрнетәләр... Кичер син мине, үпкәләмә мин җүләргә. Мин бит аны кызмача баштан, мәченне бик кызганганга. Үпкәләмә, зинһар. Ярыймы?..

Әнәс Сибгатуллин дулкынлана иде. Бу минутта аның күңелен иптәшләренә булган ихтирам һәм чиксез рәхмәт биләп алган иде. Әгәр кирәк булса, алар өчен ул, элеккечә җанын кызганмаска, утларга керергә, үлемнең күзенә карап барырга әзер иде. Әлеге хисләрдән булса кирәк, аның күңел кыллары тибрәнеп китте, карасу күзләре дымланды. Каршында утырган дустына бу йомшаклыгын күрсәтмәскә теләп, ул сөйләвеннән туктады, бер читкә борылды һәм, идәндә яткан коры утын кисәкләрен сайлап алып, тимер мич авызына ыргытты. Утыннар кабынып киттеләр, күңелле генә чатнап, землянка эчен нурландырып, дөрләп яңа башладылар.

## Укучының күңел дәфтәренә

**Тува мәкальләре һәм әйтемнәре**

*Эш яраткан — тормышка гашыйк.*
*Әгәр бердәм чукысалар — кошлар да дөяне җиңә.*
*Джуттан этләр симерә, чирдән монахлар баый.*
*Мул хәзинәң булганчы, якын дустың күп булсын.*
*Якын дуслар мәхәббәте кыя таштан нык була.*
*Кулыңда таяк булса — усал этләр яратмый.*
*Кипкән агачта җимеш юк, буш сүздә мәгънә булмый.*
*Соңга калып үссә дә — мөгез колактан озын.*
*Үрдәккә эләкмәсә дә, укны кулга тидерә.*
*Тау күрми торып итәк күтәрмә.*
*Су күренгәнче өстеңне салма.*
*Итәкка салып ут йөртмә, көтүгә бүре кертмә.*

*Капчыкка энә яшермә.*
*Ташкын суында балык юк, мәкаль ялгансыз була.*
*Киез киңәя, ә кеше үсә.*
*Биек тау да ишелә, тирән диңгез дә кибә.*
*Кызгану — җәза түгел.*
*Корыч суда чыныга, кеше — газап кичереп.*

Шамил Анак

## Шат шигырьләр чоры

Кердем шат шигырьләр чорына —
Күкрәгемдә яз, дөнья яшел, мин яшь.
Гаҗәеп көйләр килеп керә җырыма...

Урамнардан атлыйм, як-ягыма күз ташлыйм,
үз-үземне онытып,
агачлар, трамвайлар белән сүз башлыйм,
«Саумысез!» дим,
һәм алар шундый шат җавап кайтара.

Балкый йортлар, әкияттәге бәллүр сарайлар кебек...
Бу нинди урам? Бу кай тараф?

Регулировщик кызлар янына киләм чатта,
тылсымлы таякларына карыйм:
«Сез хәрәкәт алиһәсе, буйсына сезгә дөнья,
әйтегез, кай якка барыйм?»
Ә алар —
йөзләрендә җитдилек, елмаю бергә катышкан —
күрсәтәләр көньякка, төньякка,
көнчыгышка, көнбатышка.

Моңарчы беркайчан мин ирекле булмадым бу кадәр
уйда һәм гамәлемдә —
һәр башлаган яңа көнем алып килә шат хәбәр!

Кызлар узалар урамнан,
урамнан кызлар узалар.
Бәлки, алар кызлар да түгелдер —
күз явын алган лаләләрдер, мәкләрдер,
ә бәлки, шундый зур күзле күбәләкләрдер...
Гашыйк булам, гашыйк булам —
янымнан узган сылу сынлы шул кызларга,
урам аша чыккан әбигә,
бишек-арба этклән яп-яшь әнигә,
арбадагы бәбигә,
бетон, пыяла кигән зәңгәр өйләргә,
шат чырайлы яңа урамга,
озын кызыл томшыклы гаҗәеп кошка —
тимер кранга...

Кем уйлаган шулай булыр дип
иллегә җиткәч яшем —
тиеш идем күз чорына керергә,
ә миндә яз, кошлар сайрый, дөньям яшел!
Кердем шат шигырьләр чорына,
гаҗәеп көйләр килеп керә җырыма.

## Хакимлек

Бетон джунглилар баса дөньяны.
Табигатькә һәм гакылга буйсынудан чыгып,
шәрә ботакларын җәя тимер агачлар,
үлән булып ята җиргә тутлы тимер чыбык.

Күкләр киңлегенә тула тимер кошлар,
диңгез суларына тимер балыклар —
барсы бер ысулда, бер үк калыпта.

Нинди коточкыч язмыш көтә дөньяны?
Әйләнерме яшәү кара тәмуг төшенә?
Һәм йөрерме
тимер урманнарда тимер кешеләр?
Һәм саңгырау, сукыр булып калырмы
назлы, яшел бу кырлар?
Юк булырмы мәңгегә
икмәк, сөю һәм җырлар?
Бу кояшлы якты, рухи хәят
төссез, нурсыз, рухсызга
әйләнерме, ниһаять
һәм «кит!» диеп адәм улларына,
җансыз Калып
хакимлекне алырмы
тимер кулларына?
Ничек мөмкин китерергә моны күз алдына?
Кем соң торыр тере җаннар сагында?
Кем чик куяр машинача уйлау ысулына?
Кем кешелек ягында?

## Карт трагик

Пәрдә төште. Залда алкышлар. Менә тагын
бер гомерне тәмам иттем мин горур көлеп.
Тагын күпме калды?
Инде ардым мин тәмам
сәхнәдә башкалар өчен яшәп һәм үлеп.

Йөземдәге грим — грим түгел, үлем маскасы
минем йөздә шулай котылгысыз чагылган.
Ләкин мин сәхнәдә уйнаган бөек үлем түгел,
ә чын үлем кырыс кулы белән кагылган.

Үз сәнгатем миндә хәзер нәфрәт уята,
бу эфемер хакимлек бирми сөю җылысын
О, тик бер сәгать яшисе иде үзем булып
һәм туйганчы көләсе иде яки елыйсы!

Фаҗигаләр уйнап, күңлем шундый нечкәргән,
шатлыкмы, газапмы — чын яшь тама күземнән;
ә еласам, көлсәм, тиле кебек шашынып,
мин бит елыйм, көләм — язмышымнан, үземнән.

Бөтен рольләремне уйнап чыктым инде мин,
тик юк әле үз-үземне уйный алганым.
Шуңа күрә һәр Гамлетта уйныйм үземне —
менә нидә сәнгатьнең
        бөек чынлыгы һәм бөек ялганы.

Кайда минем үз язмышым һәм үз фаҗигам?
Ник уйнамыйм аны, биреп рух көчем?
Кемне без уйныйбыз гомер буе
        сәхнәдә һәм тормышта?
Кемне? Ни өчен?

һәр кич залдан тын да алмый күзәткәннәрнең
тетри җаннары елаганда мин яки көлгәндә.
Сәнгать — һәм хакимлек, һәм коллык, котылу юк;
үз-үземә кайтырмын мин
соңгы тапкыр — үзем өчен үзем... үлгәндә.

●

Ишегемне килеп какмый әле ялгыз кичләрдә
үткәннәрнең сагышлы тонык шәүләләре,
йөрәгем сөеп туймаган әле.

Тормыш элеккечә ымсындыра һаман, елмая,
такмы-җөпме, бушмы, я тулымы учлары —
бөтен әйе-юкларына калмыйм җавапсыз.

Күзләремдә җуймаганнар әле ачык төсләрен
ни балкыган үләннәр, ни көзге тын сулар,
ни карлар аклыгы кышкы аяз иртәдә.

Тигез кабул итәм көн яктысын һәм төн карасын —
шул дәрәҗәдә кадерле миңа җир бүләкләре...

һаман әле тантаналы чыңлый колакларымда
тормыш чаңнары,
кичке зәңгәр тынлыкның ялгыз утравына
китмәдем әле,
тик көннән-көн якынлашам җиргә...

Яшьлектәге кебек хыялларым килер турында,
йөрәгем сөеп туймаган әле
һәм мин китәм иң соңгы, иң гүзәл сөюне.

•

Көзге тын сарыларда япа-ялгызым
басып торырмын ак каеннар төбендә,
кояр алар тын гына яфрак йолдызын;

чыңлар күңлемдә сагышлы бер кыл,
килер хәтеремә артта калган, үткәннәр,
еллар томаны аша изәр миңа кул,

ә дөнья гүзәл булыр, мин таң калырмын
җирләр күркенә, күкләр пакьлегенә,
юар күңелемне көзге бәрәкәт,
һәм мин тыныч җан белән
керермен тәүге карлар аклыгына,
ә бәлки — тәкъдир нидер? — соңгы кышыма.
Бәлки, шулай килер җан тәслимем.

Ә бу зур дөнья, бу шатлыклы дөнья,
җибәрәсе килмәс, җибәрәсе килмәс мине.

•

Көн, ниһаять, сүрелеп узып китте тын гына.
Кичке күк читендә сүнде шәфәкъ шәүләсе...
Ни китерер яңа төн? Юанычмы, газапмы?
Әллә үткәннеңме соңлап килгән тәүбәсен?
Ниләр килер хәтергә бу төнге тын сәгатьтә —
гомеремнең ерак калган яшел язымы?
Кызлар көлүеме еракта, елау тавышымы?
Әллә мине күптән оныткан нның назымы?

## КПССның XXVI СЪЕЗДЫ КАРАРЛАРЫН — ТОРМЫШКА!

# ТАТАРСТАН МОГҖИЗАСЫ

*СССР Нефть эшкәртү һәм нефть химиясе промышленносте министрлыгының Түбән Кама «Шин» производство берләшмәсендә автомобиль шиннары җитештерүче комплексны төзүдә һәм сафка кертүдә катнашучыларга*

•

*Кадерле иптәшләр!*

*КПСС Үзәк Комитетында Түбән Кама «Шин» производство берләшмәсендә автомобиль шиннары җитештерүче эре комплексны төзүнең төгәлләнүе һәм сафка кертелүе турындагы хәбәр зур канәгатьләнү хисе белән каршы алынды.*

*Сезне бу гүзәл хезмәт җиңүе белән чын күңелдән котлыйм.*

*Кама автозаводы автомобильләрен комплектлау өчен гадәти шиннардан ныклыгы белән 1,3 тапкыр артыграк булган радиаль конструкциядәге югары сыйфатлы автомобиль шиннары производствосын сафка кертү Ватаныбыз шин промышленностенда техника прогрессы юлыннан алга таба мөһим адым, КПССның XXV съезды карарларын тормышка ашыруга реаль өлеш булып тора.*

*Ирешелгән уңышлар — төзүчеләр, монтажчылар, машина төзүчеләр, эксплуатациячеләр, проектчылар һәм төзелештә катнашкан барлык башка кешеләрнең фидакарь хезмәте, Татарстан АССРның партия, профсоюз һәм комсомол оешмалары үткәргән зур оештыру һәм политик эш, киң җәелдерелгән социалистик ярыш нәтиҗәсе ул.*

*Партиябезнең XXVI съездын лаеклы каршылау өчен алган социалистик йөкләмәләрегезне намус белән үтәрсез һәм сафка бастырылган производствоны тизрәк үзләштерү өчен бөтен көчегезне, белем һәм тупланган тәҗрибәгезне бирерсез, дип ышанам.*

*Сезгә, кадерле иптәшләр, хезмәттә яңа казанышлар, сәламәтлек һәм шәхси бәхет телим.*

**Л. БРЕЖНЕВ.**

Иң элек нефть ташкыны шаулады. Татарстан сыек ягулык чыгаруда илебездә ун елдан артык вакыт беренче урында торды. Бу җир хәзинәсенең шифасы халык хуҗалыгына чәчүдән соң яуган язгы яңгырдай тәэсир итте. Республикада нефть химиясе промышленносте зур тизлек белән үсә башлады: Казанда «Органик синтез» заводы салынып бетте, чал Чулман буенда Түбән Кама дигән мәшһүр ак шәһәр калыкты. Аннан соң КамАЗ. Түбән Кама территориаль-промышленность комплексы әнә шулай барлыкка килде. 1978 елның көзендә Экономик Ярдәмләшү Советының нефть һәм газ промышленносте Даими комссиясенең Түбән Камада үткәрелгән чираттагы утырышында аны хаклы рәвештә гигантлар йолдызлыгы дип атадылар. Бу индустриаль йолдызлыкның бер таҗы — шин җитештерү куәтләре.

— Бер вакыйга хәтергә сеңеп калган: 60 нчы еллар иде. Колхозлар инде шактый ныгыган, һәрберсенең үз техникасы бар, авылда төзелеш тә киң җәелгән чак. Актаныш районының Ленин исемендәге колхоз идарәсендә шул күркәм үзгәрешләр ту-

рында сөйләшеп утырабыз. Бүлмәгә борчылган кыяфәтле инженер килеп керде.

— Җир шарын әйләнеп чыга яздым, барыбер табып булмады,— диде ул председательгә.

— Нн эшлибез соң алайса? Тиздән уракка төшәсе ләбаса. Тапмыйча һич тә ярамый.

Аннан соң председатель миңа карады да ачынып әйтеп куйды:

— Автомашиналар тик тора, шиннар юк.

Чыннан да, ул вакытларда шиннар җитешми иде. Читтән тапсаң да, ике-өч бәясен түләп алырга кирәк. Хәзер мондый кытлык юк. Алай гынамы, республикада илебезнең иң зур шин берләшмәсе оештырылды. Татарстан маркасы куелган шиннарны Болгария, Польша, ГДР, Чехословакия, Венгрия, Куба һәм башка илләрдә дә яхшы беләләр. Быел завод продукциясе халыкара ярминкәдә, Лейпцигта күрсәтелде. Берләшмә заводларында җиңел һәм йөк автомобильләре, тракторлар, «Нива» һәм «Колос» комбайннары, трактор тагылмалары өчен 12 төр шин эшләнә.

1968 елның 10 маенда экскаватор Түбән Кама шин заводы төзелеше мәйданында беренче чүмеч балчык алды. Ул вакытта КамАЗны төзү урыны сайланмаган иде әле. Кайберәүләрнең шундый сорау бирүләре мөмкин: шин заводы ни өчен Түбән Камада корыла башлады соң? Моңа җавап бирүе авыр түгел. Беренчедән, чималны әллә кайдан ташыйсы түгел, ул койма аша гына, аны «Нефтехим» берләшмәсе җитештерә. Икенчедән, әзер пордукцияне кулланучыларның күбесе шушы төбәктә. Алар: Волга, Ульяновск, Ижевск автомобиль заводлары. Өченчедән, биредә теләсә нинди авыр бурычларны да уңышлы үтәрлек төзелеш оешмалары тупланган иде.

Беренче заводта 1973 елның 29 апрелендә беренче продукция алынды. Ел ахырына кадәр предприятиенең тәҗрибә цехларында ярты миллионнан артык «Жигули» өчен камералар җитештерелде. Завод хәзер тулы куәтенә эшли. Бу хәлендә дә тармактагы зур предприятиеләрнең берсе булыр иде ул. Әмма индустриаль йолдызлыкның үсеш колачлары, илебез халык хуҗалыгында ул тоткан роль әлек уйланылган планнарга үзгәреш кертте. Нигә дип әле КамАЗ батыр өчен «аяк киемнәрен» читтән ташырга? Бәлкем КамАЗ өчен Түбән Кама җирлегендә икенче завод төзү уңайрак булыр? Шулай уйлыйлар планлаштыру оешмалары. Дәлилләр ныклы, шуңа күрә ул бертавыштан кабул ителә. Һәм 1973 елның октябрендә КамАЗ машиналары өчен шин җитештерәчәк икенче заводны кора башлыйлар.

Кама буендагы бу үзгәрешләр безнең тормышка шундый зур тизлек белән кереп киттеләр, аларны ил мәнфәгатьләре, дөньякүләм социаль экономик әһәмиятләре биеклекләренә менеп караганда күзаллап бетерә алганыбыз юк әле. Автомобиль короле Генри Фордның совет чынбарлыгы алдында үз көчсезлеген (моны Американың көчсезлеге дип аңларга кирәктер, мөгаен) тануы илебез экономик куәтенең зур мөмкинлекләре турында сөйләмимени? Киләчәк буыннарга 70 нче еллар һәйкәле булып калачак бу гигант корылмаларның әкияттәгедәй «күз ачып йомганчы» калкып чыгуын могҗиза дими нәрсә дисең инде? Икенче шин заводын гына алыйк. Иң беренче чиратта, ул үзенең киңлеге, зурлыгы белән кешеләрне таңга калдыра. Экономик Ярдәмләшү Советы утырышына килгән кубалы Орэстэс Гарсиа болай диган иде:

— Уи ел әлек бу гигант корылмалар урынында тигез җир булган дигән сүзгә ышануы авыр. Чын мәгънәсендә могҗиза бу!

Әйе, могҗиза. Тик әлеге завод нефть химиясе комплексының бер өлеше генә.

— Төп корпус үзе генә дә 160 мең квадрат метр мәйдан били,— диде заводның партия оешмасы секретаре Ардинад Хөсәенович Хәсәнов,— яңа чиратның икенче җыю цехы җиһазлары 25 гектар җиргә урнашкан.

Яңа чират дигәннән, заводның беренче чираты 1978 елда сафка баскан иде. Хәзер менә дәүләт комиссиясе аның икенче чиратын «бик яхшы» билгесенә кабул итеп алды. Бу зур җиңү. Илебез шин промышленносте флагманы нибары алты елда төзелеп бетте. Белешмә өчен шуңысын да әйтик: гадәттә, мондый предприятиеләр унуникс елда төзелә иде.

Заводны «Татэнергострой» идарәсе коллективы салды. Бишьеллыкны тәгалләү елында гына да бу коллектив Түбән Камада куәтле изопренлы каучук заводын, этилен окисе производствосын, нефть химиясе куәтләрен арттыру комплексларын, 2 нче ТЭЦның чираттагы агрегатларын сафка бастырды. Республиканың бер генә төзеле-

шендә дә халык хуҗалыгы өчен зур әһәмияте булган һәм быел сафка кертелергә тиешле бу кадәр санда объект юк. Әлбәттә, бу зур төзелеш программасын тормышка ашыруда башка төзелеш һәм кору оешмалары да актив катнашты. Төзелеш мәйданында җәмгысе 6 миллион кубометр җир эшләре эшләнде, 150 мең кубометр монолит, җыелма бетон һәм тимер-бетон җәелде, 30 мең тонна тимердән җыелган корылма, 2600 берәмлек төрле җиһаз корылды.

Кем соң ул шин заводын төзүче кеше, аның социаль портреты нинди?

...Рәшит Сәмигуллин Түбән Камага 60 нчы елларның уртасында килә. Күкрәк кесәсендә комсомол юлламасы. Моңа кадәр Хабаровскида эшли, чирәм җирләрне үзләштерүгә катнаша. Килүгә хатыны Равиләгә хат юллый: «Биредә әлегә өч йорт, бер мәктәп. Әмма шәһәр тиз үсәчәк. Ә сиңа төзүче булып эшләргә туры килер, чөнки тәрбиячеләргә караганда, төзүчеләргә ихтыяҗ зур...»

Равилә дә куркып тормый. Өч яшьлек Ренатын алып, шул арада Рәшите янына килеп җитә. Ташчы булып эшли башлый.

Рәшит белән Равилә, йөрәк кушуы белән удар комсомол төзелешенә дип килгән хезмәттәшләре, яшьтәшләре кебек, алны-ялны белми эшлиләр. Авыр димиләр, торырга урын юк димиләр — яшьләргә хас омтылыш һәм тырышлык белән завод коралар, шәһәр салалар. Шәһәребездә хәзер 150 меңгә якын кеше яши, заводларның уннарча гектарларга җәелгән көмештәй ак колонналарында кояш нурлары уйный... Моның белән ничек горурланмыйсың...

Дүрт елдан соң аны бригадир итәләр. Ул үзен яхшы эшче генә түгел, оста оештыручы итеп таныта. Исеме бөтен төзелешкә таныла. Аны танышлары да, таныш булмаганнары да сәламләп үтә. Хезмәтенә күрә — хөрмәте. Рәшит Сәмигуллин — Октябрь Революциясе, «Почет билгесе» орденнары кавалеры. Аның осталыгы бигрәк тә икенче шин заводын төзегәндә күренә. Ул җитәкләгән коллектив «Иң яхшы бригада» исеменә лаек була. Бишьеллыкны дүрт елда тәгаллап, коллектив биргән вәгъдәсенә турылыклы булуын тырыш хезмәте белән исбатлый. Марсель Латыйпов, Сәетгәрәй Мостафин, Лиза Шәрипова, Елизавета Никонорова кебек унганнар булганда таулар күчерергә мөмкин. Һәрберсе берничә һөнәр иясе, коммунистик хезмәт ударникгы.

Хәзер Рәшитнең шатлыклы да, җаваплы да көннәре. Шин заводының икенче чиратын сафка тапшыру алдыннан бригадир партия оешмасы секретаре янына килгән иде.

— Гариза язган идем, партиягә керергә. Ничек карарсыз икән?— диде ул әчке бер тыйнаклык белән.

— Күптән көтә идек синең бу сүзләреңне, Рәшит! — дип ике куллап каршы алды аны секретарь.

Коммунистлар алдынгы бригадирның бу изге теләген хуп күрәләр. Шулай итеп, Рәшит өчен имтиханның иң җитди башланып китте.

Бөек төзелешләр яшь күңелләрне көчле магниттай һәрчак үзенә тартып торды. Магнитка, Днепрогэс, Турксиб, Амурдагы Комсомольск, ниһаять, КамАЗ, БАМ, Атоммаш — боларның һәркайсы яшьлек дәрт-дәрманына һәйкәл. Аларны Рәшит Сәмигуллин кебек алтын куллы егетләр һәм кызлар төзеде һәм төзи. Шунысы матур, яшьләр үзләре төзегән шәһәрләрдә яшәп калалар, үзләре күтәргән заводларда эшкә керешәләр. Шин заводын коруда катнашкан шактый кеше, мәсәлән, яңа һөнәр үзләштереп өлгерде инде. Завод эшчеләре дә кул кушырып утырмадылар: төзеделәр, җиһазлар кордылар. Шуңа күрә бу җиңү аларга икеләтә шатлык.

Заводның вакытыннан алда сафка басуы — төзүчеләрнең, монтажчыларның, файдаланучыларның һәм төзелештә катнашкан барлык кешеләрнең фидакарь хезмәте нәтиҗәсе ул.

— Төзелештә эш бердәм график нигезендә оештырылды,— дип искә ала ул көннәрне «Промстрой» идарәсенең баш инженеры С. Тимербулатов.— Вакытлы партия группалары оештыруның, берләштерелгән партия җыелышлары үткәрүнең файдасы зур булды. Кыскасы, төзелеш барышында кулланылган алдынгы хезмәт алымнары, яңа башлангычлар уңышлы сынау үтте.

Түбән Кама гигантлары йолдызлыгында юл алган яңалыкның иң әһәмиятлесе — төзелеш барышында ук куәтләрне өлешләп үзләштерү һәм әзер участокларда про-

дукция җитештерү дисәк, хата булмас. Шинчылар, әйтик, икенче завод җиһазларын көйләп эшләтә башлау чорында меңләгән покрышка җыйганнар.

Заводның үзенчәлеге нәрсәдә, ул башкалардан кайсы ягы белән аерылып тора соң?

Без 3 нче җыю цехында. Якты, киң, һәр җирдә тәртип. Сафтагы гаскәриләр кебек, станоклар тезелеп киткән. Аларның тигез гүләве самавар шаулап утырган авыл өен хәтерләтә. Тик бу беренче тәэсирләр генә. Әлбәттә, фән-техника прогрессының иң соңгы казанышлары нигезендә корылган завод цехларын авыл өе һәм самавар белән чагыштыру бик урынлы да түгелдер. Ләкин сүз, беренче чиратта, уңайлылык турында бара.

— Станоклар тавышсыз диярлек эшли, алар белән электроника идарә итә,— дип аңлатма бирә цех начальнигы Б. Латынин.

Ул электрон блоктан перфолента ала. Аңа «техника телендә» тугыз технологик эш язылган. Станок-автомат бу эшләрне зур төгәллек белән үти. Брак булуы мөмкин түгел. Чөнки кайсыдыр узел уйланганнан читкә тайпыла икән, станок үзеннән-үзе туктала.

Биредә, башка заводлардагы сыман, станокларга чималны электрокарлар ташымый, традицион кисүче кебек массовый һөнәрләр дә юк. Конвейерлар алдан билгеләнгән программа нигезендә, кеше катнашыннан башка, чималны станокларга китерәләр, әзер шиннарны тиешле урыннарга озатып торалар. Операторларның вазифасы станок-автоматларның эшенә күзәтчелек итүдән гыйбарәт.

Предприятиене чын мәгънәсендә завод-автомат дип әйтергә була. Бу катлаулы техника белән идарә итү өчен, һичшиксез, югары квалификацияле, белемле эшчеләр, белгечләр кирәк. Шуңа күрә биредә кадрлар әзерләүгә әһәмият зур.

Аңлашылганча, мондый завод төзү үзмаксат түгел. Ул эшләп чыгара торган продукция дөньякүләм таләпләргә җавап бирергә тиеш. Биредә, әйтик, шиннарның принципиаль яңа моделе — радиаль конструкциядәге шиннар җитештереләчәк. Андый «аяк киеме» 200 мең километр юл үтәргә сәләтле. Хәзерге шиннарның 70—80 мең чакрым йөрүен искә алсак, бу күрсәткечнең фән-техника прогрессында зур яңалык икәнлеген аңлату кирәк түгел.

Түбән Камада шушы күренекле вакыйгага уңае белән тантаналы митинг булды. Митингта КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Р. М. Мусин чыгыш ясап, болай диде: «Түбән Кама «Шин» берләшмәсенең эксплуатацияләүче коллективлары автомобиль шиннары эшләп чыгару буенча яңа сафка кертелгән куәтләрне вакытыннан алда үзләштерергә сүз бирәләр. Бу зур канәгатьләнү хисе уята».

Шинчылар яңа производствоны билгеләп куелганнан өч айга элек проект куәтенә җиткерү өчен социалистик ярышны киң җәелдерделәр. Бу — аларның партия съездына лаеклы бүләкләре.

**МАРАТ ӘМИРХАНОВ.**

Рөстәм Кутуй

# ЯШӘҮ ОРЛЫГЫ

Кайбер нәрсәләрне уртак аршин белән үлчәп, без еш кына: «Кеше үз гомерендә иң кимендә бер бала тәрбияләп үстерсен дә бер агач утыртсын», — дигәлибез. Янәсе, яшәвеңне шул чакта гына аклый алырсың һәм гомерең заяга узмас. Әнә шул «иң кимендә» дию гафу үтенгән кебегрәк итеп әйтелә.

Гомумән, яшәү үзе орлыкның тишелеп чыгып үсүенә охшаш ул. Турылай әйткәндә дә, фәлсәфи мәгънәдә дә. Җир буыннан буынга ашлык бөртеге, орлык, тамыр белән бергә мирас булып күчә. Маркс әйткәнчә, җир исән-сау килеш, имгәтелмичә тапшырылырга тиеш. Орлыкның куәтен югалтырга, нәселлеген көчсезләндерергә ярамый. Чөнки буш башак белән чебен дә куа алмыйсың...

Мәһабәт табигать көчен җуймый, аның әле карчыклар хәленә төшеп картайганы юк. Ул бары тик кешене үз омтылышларына сакчылрак караш ташларга, тын алуны үзенең үтәсе юлына карап көйләргә кирәклеген генә кисәтеп тора.

## Өй

Татарстанның Актаныш районындагы «Таулар» колхозы председателе Инсаф Заһретдин улы Камалетдинов тормыштан зарланмый. Ул җирнең үз кешесе, тыныч. Бөтен гомеренең кырда үткәнен һич онытмас. Кая караса да, хәтерендәге кырны, басуны гына күрә, кая гына бармасын, юлы кыр белән очлана. «Туганымнан бирле гел шул кырны гына күрәм...» Иксез-чиксез зур биләмә: бусагасыннан офыккача — басу. Адым белән генә үлчәрлек түгел. Маяклар тезеп, чикләрен билгеләп куймасаң, адашасыңны көт тә тор. Басу аның төшенә дә керә. Матурлык өчен әйтелгән сүз түгел бу. Җан ризыгы — эш. Сугышка крестьян бусагасын атлап чыгып китте, үзе генә түгел, аңа басуы да иярде. Ихтимал, шул саклап та калгандыр. «Синсез нишләрмен, әйләнеп кайт, исән-сау бул»,— дип теләп торгандыр. Бөтен сырхауларын шул башаклы кыр дәвалагандыр. Кырда җан түзми, йөрәк кага. Мәгънәсен белеп яшәгәндә гомер тиз узып китми ул. Мәгънәсен белеп яшәгәндә гомер су белән тулы чиләк кебек ташып тора һәм шуның һәр тамчысы кыр сусавын басуга тотылган.

— Буш кешенең күпме йөрсә дә эзе калмый. Аның эзе язгы су белән юыла да китә. Һәркемнең яратуы үзенчә. Кайсысының итәктән итәккә, кайсысының кирәктән кирәккә кадәр. Бабай васыять иткән, әти җаныбызга салып куйган, ә мин үз балаларыма һава белән бергә биргән яратуның иң зурысы — җирне ярату турында. Иң зур мирас. Шул мирасны үз тормышыңның нигезенә куйсаң гына уңарга була. Бураннарга, юл өзеклекләренә, корылыкларга зарланып яшәрлекме соң? Чын хуҗа зарланмый ул. Егерме бер ел буена председательлек

кылам инде, чит зарларны да үземнеке шикелле җанга якын итеп тынламый булдыра алмыйм. Җирдә кеше дә, хайваннар, икмәк, сөрелгән җир, агачлар да бергә тыгыз береккән. Чиксезлеккә кадәр санарга була. Өйне генә ал: ул иң беренче эш сыман, гомер итү шуннан башлана ич инде. Тик өй — син буралап кергән нәрсә генә түгел әле ул. Болдырга чыгып баскач, күзең житкән бар нәрсә дә синең өең ләбаса. Мал да шулай, теләсә нинди төенчек кенә түгел. Аны ана сөте белән бергә кабул итәсең, ачы күз яшьләренә әйләндереп кайтарып бирерсеңмени? Өй ул Мәхәббәт, Ышаныч, Хыял, Яхшылык дигән өрлекләргә салына. Тагын күпме корылмалары бар! Барысы да эштән башлана... Безнең яклар матур, иркен, әнә шул иркенлек тулы — эш. Эш тыгыз чакларда көнгә өч йөз илле чакрым җир әйләнеп чыгасың,— хуҗалык зур — өч мең гектар. Өйгә йолдызлар калыккач кына кайтып авасың, ә уянганда алар сүнмәгән дә була әле. Авыл тормышы йокыга мул түгел ул. Бала чактан йокыга туйган юк. Малай вакытта иректә йөреп каласы килгәндер, яшьлекне сугыш алып калды, ә хәзер сәгать урынына эш уята. Төштә дә сикәлтәләрдә сикергәләгән газигында тирбәләсең шикелле. Ә тирә-юнендә кырлар киңлеге генә. Колхоз биш авылны берләштерә, һәм аларның һәркайсы кулыңдагы биш бармагың шикелле үк кадерле. Шәрип, Куян, Мораса, Уразай, Илчебай... Безнең болыннарыбыз ягымлы, күлләребез бар. Агыйдел турында әйтеп тә торасы юк инде. Без республикабызның чигендә утырабыз, Агыйделнең теге ягында — Башкортстан җирләре. Уфага чаклы йөз сиксән чакрым, Казанга хәтле — дүрт йөз дә илле, Чаллыга кадәр — ике йөздән артык... Мин шәһәрдә дә яши алган булыр идем, язмышның шундый мөмкинлеге бар иде. Сугыштан өлкән радиотелеграфчы булып кайттым. Берлинга барып җиткәч, өйгә борылдым. Юк, тагын ике ел буена хезмәт иткәнмен икән әле. Әти сугышка хәтле вафат булган иде, мин гаиләдә баш кеше. Шулай итеп, егерме ике яшемдә әйләнеп кайттым, кырык җиденче елның көзендә, шуннан туп-туры — элемтә техникумына. Укуымны дәвам итә алмадым: әни дәшеп алды. Тагын өй, кыр. Авыр чаклар. Ачлык, ялангачлык. Мичәүләп җигелдем. Күнегеп торасы да юк, сугышта да шундый ук кырлар аша үттек, аермасы бер генә — ут, үлем аша. Мин, болай, җиденче классны тәмамлагач ук эшли башлаган идем, авырлыклардан куркып үсмәдем. Техникумда ахыргача түзсәм, бәлки бүтән урын табылыр иде, инде берәр почтада башлык та булып торыр идем. Әле дә ярый ялгышмаганмын. Йөри торгач, барыбер авылга кайтыр идем мин. Өебезгә турылыклы калдым. Бригадир булып йөрдем. Ә кырык тугызынчы елдан бирле «Алга» председателе. Күнегеп торасы да булмады, тормыш ничек кушса — шулай: кирәк, кирәк! «Таулар»да уналты ел хуҗалык итәм инде. Председательләр мәктәбен дә тәмамладым, авыл хуҗалыгы институтын да. Хәзер кайчак саннарны янәшә куеп, чагыштырып карарга туры килгәли. Тормыш үз җаена ага да ага шикелле, бер генә ел да төшеп калмый янсә артык түгел, ә менә саннар төрледән-төрле.

1965 ел — сөт — 6000 ц., ит — 1237 ц., йон — 37 ц. Уңыш — бер гектардан 12 ц. Бер хезмәт көненә 2 сум да 26 тиен түләнгән.

1981 ел (без бишьеллыкны дүрт елда төгәлләдек бит!) — сөт — 14800 ц., ит — 3100 ц., йон — 125 ц. Уңыш — гектарыннан 22,5 ц. Хезмәт көненә 3 сум 77 тиеннән түләдек.

Ике тапкырдан артык — әз түгел ләбаса! Кыяр утыртып, карбыз алган шикеллерәк. Хуҗалыкта өй малы арту шул була инде ул. Акыл җыя башлаганбыз, эшләргә өйрәнеп җиткәнбездер. Ни хисабына артык дигәндә — күп уңыш бирә торган сортлар, ашлама, механикалаштыру, сугару. Дүрт йөз гектар җиргә су сиптереп торабыз, ике йөз гектары — культуралы көтүлек. Буалар будык, аларсыз ярамый да, булмый да. Беренчедән, җирне ныгытырга кирәк. Колхозыбыз да «Тау-

лар» ич. Мең гектар җиребез үрләрдә ята. Шул җирләрне дә эшкә җигәсе иде дә бит, махсус техникасы юк. Аннан соң ташулар белән ундырышлы катламнарыбыз агып китә. Кырлар арасына урман полосалары утыртып чыгасыбыз бар әле, урман хуҗалыгы белән егерме биш гектарын утыртырга килешү дә төзеп куйдык. Аннары чокыр тирәләрендәге җирләребезне барлап чыгарга чамалап торабыз. Эрозия ашый, чыраен да сытмый ичмаса. Бөтенесенә дә өлгерәсе иде дә бит... Ашыкмыйча гына өлгерәсе иде. Ыгы-зыгы шәһәргә генә килешә ул — анда көзгегә каранырга кирәк, модасына пярмичә дә ярамый торгандыр, кул-аякларны да ешрак юасың дигәндәй... Иң мөһиме — көз яшьләре белән юынырга язмасын. Быел, әнә, июньдә киптек, июльнең яртысында яндык, аннары инде яңгыры кирәгеннән ашып китте. Кырда калдырмадык, ярыйсы гына җыеп алдык. Мал күз карасы белән бер. Күккә үпкәләп ятып булмый ич инде. Һәр нәрсәгә әзер торырга күнегергә кирәк. Стихия дигән сүз үзе генә дә ни тора — хәвеф! Өченче ел җиде гектарлы алма бакчабыз өшеп харап булган иде. Хәзер үсентеләрне каян тапмак кирәк? Идарә бинасы тирәли өч яшьлек алма агачлары утыртып чыктык, сынап карау дигән сыманрак бер нәрсә. Зур йортның мәшәкате күп. Дәүләт мәшәкате. Мин хуҗа лабаса, миңа сынатырга ярамый. Әнә кырлар: чип-чиста, җанга рәхәт. Тик кәеф һава торышларына да бәйле, хәер, аңа гына да карап торып булмый. Хәзер инде октябрь, биргәненә шөкер, һавалар әйбәт тора. Азык чөгендерен җыеп аласыбыз бар әле. Өлгерербез шикелле. Календарь белән яшәмибез, безнең өчен 81 нче ел узган көз үк башланды. Өй зур, җир күп. Юк, безне беркем дә план дип өстән басып тотмый, үз көнебезне үзебез күрәбез. Хәзер инде беркем дә башта тормый. Элек кенә иде ул, урыннарда җир кешеләре утырмады микәнни, әллә кадрлар җитенкерәмәде микән? Хәзер аңлап эш итәләр. План, анысы, хәзер дә өстән килә, тик хәлгә кереп, мөмкинлекләргә, җиргә карап. Без көлсу туфрактан да 22 ярым центнер алдык. Кайберәүләр кара туфракта утырсалар да шуның кадәрлегә канәгать. Үз эшеңне читләр кайгысы белән үлчәмә инде син. Күрмәсәң, агач башына менеп кара, оялма, төшәргә кешеләр булышыр.

## Өй исе

Авыллар биш бармак шикелле таралышып утыра. Бер-берсеннән бишәр чакрым. Төрлечә утырганнар: Шәрип авылы — тигезлектә, Уразай — тау астында, иңкүлектә.

Көн башында җирдән бөдрә пар күтәрелеп тора — кырау эри. Кая гына караш ташласаң да, кояш алтынлаган томанны гына күрәсең.

— Кайсы авылыгыз баерак?— дип сорадым мин председательдән. Ул нык итеп:

— Бездә ярлылар юк,— дип җавап бирде.— Хәзер авыл кай яктан карасаң да җитеш яши.

Колхоз инде ничәмә еллар тотрыклы хуҗалык итә. Зур су гына шулай тыныч, тотрыклы ага.

Бер урыннан икенче урынга күчеп йөргән председательләр заманы бетте, хәзер алар утрак, бер җиргә турылыклы, күчмә председательләр... Каян китереп чыгарганнар икән аларны? Хуҗалык эше алныартны карамыйча йөрүне яратмый лабаса. Үткән елларның буш башаклары шуннан килеп чыккан булгандыр ул. Председательнең ышанычы кешеләрнең йөрәгенә май булып ята. «Таулар» колхозында башка председательне күз алларына да китерә алмыйлар. Монда аның бөтен-

ләйгә килгәнлегенә иманнары камил. Билгеле инде, «бөтенләй» дигәндә йөрәк хакында онытырга ярамый. Председательнең йөрәге кага башлагач, врачлар:

— Аритмия,— дигәннәр.— Эчке киеренкелек белән яшәү бәласе. Тынгылык кирәк... Бәла. Ләкин председательнең йөрәк бәласе беркайчан да җир бәласе булмаган. «Таулар» колхозы кешеләре шуның белән бәхетле. «Тынгылык»ны да председатель бары тик «Васильево» санаториеннән генә эзләп караган. Ләкин таба алмаган. Аның бар тынгылыгы — авылдашларының бәхете. Аларның тәрәзә яңаклары берсеннән-берсе нәкышлерәк, бизәклерәк икән, өйләрендә бәхет булмый ни булсын ди.

Мин пенсионер Ситдыйковларда тордым. Биш балалары да Шәрип белән саубуллашып чыгып киткән, картлар ялгыз калган. Хатхәбәрләре килеп тора, зарланмыйлар. Уллары хезмәте белән очучы икән, Мурманскида. Кайсысы Чаллыга, кайсысы Түбән Камага, ә кайберсе Урта Азиягә үк китеп барган. Кыскасы, кайсы кая таралышып беткән. Авыл өчен гадәти бер хәл, нишләмәк кирәк. Сервантта күзен йомгалый торган курчак тора, кемне көтә икән? Аның янында фотолы альбом.

Авыл көне тиз тәгәри. Сәгать бишләргә киң, авыр канатларын җәеп, караңгылык иңә башлый. Көтү да кайтып житә, ишегалды тынып кала. Өй артында, фаралары белән җилпенеп, шоссе яшәп ята, утлары белән тәрәзәләрне сыйпап уза. Өйдә бар да бар кебек, бар да житеш — жылы, тын. Стенада суган бәйләме алтынланып тора, коры ис. Тыныч кына гүләп, суыткыч эшләп тора. Шикәр сыман ап-ак мич. Почмакларны пар белән жылыткыч торбалар терәткән. Газ плитәсе дә бар, ләкин электр самавары да юк түгел, телевизордан ни күрсәткәннәрен шул самавар битенә карап та белеп була. Бөтен нәрсәдә — кул жылысы, һәм ул озакка, учагы сүнгәнчегә кадәр дип исәпләнгән.

Колхозда эшләүче кеше айга уртача 120 сум хезмәт хакы ала. Шуңа тагын шәхси хуҗалыгыңны да куш, колхоз ярдәмен дә өстә. Ә ярдәм кечкенә түгел: икедән алып, өч тоннага кадәр сенаж, шуның кадәрле үк азык чөгендере, эш кешесенә бер тонна да өч центнер исәбеннән ашлык. Гадәти хуҗалыкта сыер, бозау, бер дистәләп сарык, өч дистә каз, үрдәк, тавык тоталар. Сөте, катыгы, эремчеге — бар да үзеңнеке, алар өстәлдән төшми. Җиләк-җимеш, яшелчә дә. Мирзанур агай белән Бибинур апа Ситдыйковлар үз хуҗалыкларын белеп алып баралар Уртак эш кайгыларны тарата. Тормыш тыныч кына көтә белгәнне дә ярата. Тамырлар кәүсәдән аерым үсмиләр ләбаса,— бәлки кайтырлар әле, кайтырлар да төшәрләр...

Сигезләргә табан телевизорны сүндерәләр дә йокларга яталар. Уянулары — таң белән бергә. Бу тәртип кагылгысыз төстә саклана. Кичләрен Мирзанур агай белән сөйләшеп утырабыз, мин аның тормыш хәлләрен сорашам, яшәү мәгънәсенең орлыгын табасым килә. Сүз гади, көндәлек тормыш хакында, йокларга вакыт житкәндә анысы да өзелеп кала.

— Авыр диюгә күнеккәнбез. Каян килеп чыккан сүз диген. Әгәр кулың җирне һәм терлекләрне яратса, ник авыр булсын ди? Станок янында җиңел микәнни? Басуга яки фермага хәзер колхозчы сәгать тугызларга гына барып житә, үз бакчасының күнелен күргәннән соң гына. Анда инде әйләнеп карарга да өлгерми — төш житкән була. Өенә кайтып, жылынып килгәнче, ике сәгать үтә дә китә. Бишкә инде кайтып та житә. Чәчү белән урып-жыю вакытын әйтмим инде анысы — анда чынлап та авырга килү дә таман гына. Чәй эчәргә дә вакыт тар.— Мирзанур үз сүзен никтер: «Бездә сирәк авырыйлар»,— дип тәмамлый.

— Теге пәрдәсез тәрәзәле өй нинди өй ул?— дип сорыйм мин дә кинәт кенә.

Анда бер карга тора. Миче-ние юк. Өен буржуйка белән җылыта. Кирпечтән мич салып куярга кулы җитми. Миңа әйтеп караган иде — тыңламадым. Карга!

— Ник карга соң ул?

— Оратор ул. Эчкече. Йөз грамм салса, доклад сөйләргә тотына. Бүген тын тора әле, одеколон, я шунын нише берәр нәрсә җибәргәндер. Төне буе утын сүндерми чыга. Хатыны юк, биш-алты сарыгы гына бар. Иртән капкасын ачып чыгарса ярый әле, көне буе абзарда. Сарык түземле хайван ул. Карганың анда эше юк, башындагы тавышны тыңлый да урман шаулый дип сөйләнә. Кайда гына эшләп карамады—терлекче дә булып торды, сөт тә ташып бакты. Пычрактан трактор белән тарттырып алалар иде. Хайван булып хайваннар да батмый, ә ул бата. Май заводыннан: «Ораторны җибәрмәгез!»— дигән язу килде. Хәзер урман кисүдә йөри әле, аннары тагын нишләр. Аракыны кешедән узындырырга ярамый аны...

Тавышы ук әйтеп тора: кешенең шул хәлгә төшүенә кайгыра Мирзанур бабай.

Бер генә авылда да мин бүтән исерек кеше күрмәдем. Ни тораклар янында, ни юлда, ни басуда очратмадым. Инсаф Заһретдинович үзе шампански гына эчә, билгеле инде, тәмен белеп, рәхәтләнеп. Кайбер чакны кешегә сәбәпсез-нисез дә бәйрәм кәефе килеп керә ич — кырлар саргаеп уңа, ерак офыклар тынычланып кала, тормыш, яшәү, өлгереп җиткән чикләвек төше кебек, искиткеч бер мизгеле белән куандырып куючан. Шул чакны Агыйдел, я булмаса каен урманлыгы чакырып ала. Мин аның «Кара урман»ны җырлаганын карап, тыңлап тордым. Ул күкрәген киереп җибәрә дә булдыра алганча күп итеп саф һава сулый һәм яшь, көр тавыш белән җыр суза, ә аның аяк астында учак күмере көйри.

> Кара да гынай урман, караңгы төн,—
> Яхшы атлар кирәк үтәргә-ә-ә...

Карангы инеп, каеннар бер-берсенә тыгызрак елыша. Җырчының күзләре исә җемелдәп тора, сулышы киң — ул бар күңеле белән җырга бирелгән, шуннан арынмаслык булып онытылган.

Аның җырлавы минем күңелемнең бер дөньясы белән тәңгәл, көзге моңсулык, бу борынгы җыр белән кочаклашып, кырлар өстеннән очып килә дә җанымдагы җылы ояга кереп сыена...

Инсаф Заһретдиновичның ике бүләге бар — берсе «Батырлык өчен» медале, икенчесе Хезмәт Кызыл Байрагы ордены. Әтинең хатларыннан укып, «Батырлык өчен» медале белән ничек горурланганын беләидем. «Ул минем, аннары соң халкымның батырлыгы турында сөйли бит...» Батырлык дигән сүз күрер күзгә генә гадәти ишетелә ул. Ә туган ил өчен хәлиткеч мизгелләрдә ул сүз тормышның үзенә торырдай булып яңгырый. Үз халкы белән бәйләп торырдай көче белән «Батырлык өчен» медале председатель өчен дә чиксез кадерледер. Моны сорап та торасы юк. Ә Хезмәт Кызыл Байрагы ордены миңа хәзер Камалетдинов та бүләкләнсен өчен булдырылган кебек, моңа аның бөтен гомере дәлил.

•

— Эчкечелек мәсьәләсе безнең өчен проблема булудан туктады,— диде председатель.— Без ул мәсьәләне аягында чайкала башлау белән бугазыннан эләктереп алдык. Мәкерле мәсьәлә иде ул. Ул чагында идарә бинасы түбәндә тора иде, ә каршысында гына — кибет. Күп эчә иделәр, яшереп торуның хәзер кирәге дә юк. Кerә бер заманны берәү: «Председатель, өч тәңкә акча бир әле».— «Ник алай бик аз сорыйсың?— мәйтәм.— Илле итеп ал». Бухгалтерның күзе акаеп килде, тик

мин «бир» дип ым кагам. Теге кул куя да председательнең яхшылыгына исе китеп чыгып та югала. Акчасын ул шундук эчеп бетерә, билгеле, бик тиз. Аның каравы озак саный инде. Үзе санамаса, хатыны санап күрсәтә аны. Шулай итеп, егермеләп кешене кинәндердем. Нәрсәнең нәрсә икәнен яхшы аңлый башладылар. Эчкән килеш миңа бер сүзләре дә үтмәслеген шуннан соң төшенделәр. Акыллы кеше эчәргә тиеш түгел. Эчү — ни черетү ул. Хайваннан йон, ит, сөт алып була, ә исеректән ни мәгънә?

...Мирзанур агай йокларга икенче бүлмәгә кереп китә иде. Әле генә сөйләшеп торган була, сүзенне йотарга өлгермисең — югала. Караңгыда эримени.

Мин дә авыл сәгате белән яшәргә тырышып карадым. Соңгы сигаретны йолдызлар калыкканда тартып бетерә идем. Җир өстендә мәңгелекнең мәңгелек икәнен белдереп торган ниндидер бер тойгы. Дулкын-дулкын булып салкын һава бәреп тора. Яктылык белән караңгылык бер-берсен сизелер-сизелмәс кенә итеп алмаштыра, көндезге уйларның очына чыгып өлгермисең, кичкеләре килеп чыга, алар хәтта бәйләнешми дә калгалыйлар. Мин, дөнья гаменең серенә төшенергә теләп, икенче бер ритм, көй, бүтән бер үлчәм белән яшәп карамакчы булам. Авыл тормышының агышында колач йөзеп карыйм. Миңа аның кешеләре, кешеләренең юмартлыгы охшый.

Кичке һавада үземнең Җидегән йолдызымны эзләп табам. Тын. Әйтерсең лә, салкынча һавага кушып, әллә кайлардан килеп җиткән һәм мине әллә кайларга чакырып торган ниндидер бер курай моңын сулыйм кебек.

## Пычракка кире мәдхия

Еш кына минем күз алдымда йөзе яктырып торган ниндидер бер хатын-кыз гәүдәләнә. Ул алма бакчасының җылы туфрагында басып тора, имеш, һәм нигәдер карт, ләкин куәтле алма агачына охшаган икән. Ул хатын тере җан иясе, уңышны гәүдәләндергән рәсем генә түгел. Ул кышка, салкыннарга чыдам тугыз алмагач сорты китереп чыгарган, төньякта шул алмагачлар гөрләп торып үсеп, ярашып киткән. Әгәр һәр сортны уйлап, сынап чыгарыр өчен утыз ел гомер кирәклеген истә тотсаң, кеше гомеренең дә 270 елга сузылганын күреп-ишетеп була икән. Тормышның туклыклы орлыгы шулай барлыкка килә һәм ныгый...

Шосседан чак кына читкә янтайсаң да, тиздән пычракка кереп батасың. Җирнең тиресен шулай мунчалаландырыр, теткәләр, тискәре ягын кайтарып салыр өчен күпме яңгыр яварга кирәк икән соң? Юл кайдадыр тирәндә, елга төбе сыман аста, ә син пычрак боткасы ерып йөрисең. Газик танк кебек үкереп кенә калмый, ул иркә бала кебек шашып елый, бичара: ул тешләшә, тырмаша, ул әле укшый, ул әле бишектә тирбәлә, аны шундук ыргытып та бәргәндәй итә, ул аптыравыннан нишләргә дә белмичә тукталып кала, көчсезлегенә ачуы килеп кызыша, калтырый.

Председательнең шоферы Абелгас машинасы хакында болай ди: «Кулы булса, мине нишләтәсез, каһәр суккырлары, дип, ул безне тукмап ташлар иде. Моторны ачып карарга куркам, билләһи: берәр гайкасы белән биткә төкерсә?..»

Тәгәрмәчләр астында, янартау лавасы сыман булып, салкын пычрак кайный. Юл машинада йөрергә генә салынмаган лабаса! Ул җәяүлеләр өчен дә хезмәт итәргә тиеш. Капкадан чыккач, нинди дә булса

берәр сукмакка төшәрмен дип өмет итмә. Кысыр өмет. Пычрак шул мәлдә барлык тешләре белән итеккә ябыша. Кая инде ул туфли дигән нәрсә! Карашны соры боткадан аерып, ерак офыкка төбисе килә: анда матур, анда шәп — урләрдән урләргә баганалар атлап киткән, кырларның төсе уңып бетмәгән әле, анда яшел кыр читләрендә сары дөяләр — салам богыллары бөкерәеп тора, күктән яктылык сирпелгәнен дә ишетердәй тынлык хөкем сөрә.

Кибет сигез генә өй аркылы булса да, аңа разведчикка хас могҗизалар ярдәме белән генә барып җитә аласың. Шиннар изеп бетергән пычрак кантарлары синең артыңнан кара бер ыржаю белән көлеп кала.

Иртәләрен болдырга аяк басу белән, беләкләргә каз тәне чәчрәп чыга. Ишегалдындагы эскәмияне акшарлап куйганнар диярсең, өй түбәләре сөткә манчып алган ипи кыерчыгы шикелле булып калган, карлыган куакларына яңа ел чыршысының көмеш ялтыравыкларын ябыштырып куйганнармыни! Бар нәрсә иртәнге салкынлык белән өртелгән.

Тик кояш торган саен җылытарак төшә, пычрак кантарларының өсте эреп юешләнә, иртәнге кырау, мичкә яккач юкка чыккан кышкы тәрәзә бизәкләре сыман, еларга керешә.

Такта койма артында яңгыравыклы бер көлү авазы канат кагып куя. Авыл урамы буенча бер малай белән бер кыз мәктәпкә бара. Тизтиз генә җыенып алганнардыр да, кулъюгычта битләрен чылаткалагач, сөтле чәй эчеп куйганнардыр. Инде менә йөгерә-атлый ашыгалар. Авыл баткаклыгын үткәч, өелгән юлдан соң аларның шоссега кадәр чыгып җитәселәре бар, аннары Куяндагы сигезьеллык мәктәпкә чаклы биш чакрым, сәгать ярымнарда барып җитәрләр микән? Шәһәр балалары белән авыл балалары язмышында да никадәр аерма. Бу балалар кире әйләнеп кайтырга пычрак тәмам җебешер инде.

Инсаф Заһретдиновичның пычракка әллә ни исе китми: ел авыр, мәшәкатьләр тавык чүпләп бетермәслек, күзгә баткаклыктан башка авыл — авыл мыни инде ул?

— Балалар адашмас. Тамаклары тук, өсләре бөтен. Без чабатадан чыкмый торган идек әле. Хәзер ул юл алар өчен сулу алу белән бер. Ныгып үсәрләр, авырлыклардан өрекмичә, иренмичә,— ди ул.— Өлкәннәрнең эшләре күбрәк. Әнә, сыер абзары төзелеп бетмәгән килеш ята, чөгендер җыелмаган. Санап та бетермәле түгел.

Авыл мәктәпләре — өчьеллыклар гына. Сигезьеллык мәктәп Куянда. Уртасы Теләкәйдә, тик анда хәтле ун чакрым. Кышкы бураннарда, язгы ташуларда нишлиләр икән? 81 нченең ахырына бәлки Уразайда урта мәктәп өлгермәсме диләр, нигезен салып куйганнар икән инде.

Моның бер сере бар иде: Уразай су астында калачак авыл дип йөрелде. Берни төзетмәделәр. Хәзер бүтәнчәрәк килеп чыккан. Уразай үзәк авыл итеп корылачак. Балаларны колхозчы итәргә мәктәптән үк әзерли башларга кирәк. Югыйсә, булдыксызлар кала, акыллылар һәм көчлеләр таралышып бетә. Техника торган саен катлаулана, хәйләкәрләнә бара, гайка ачкычы тота белү белән генә ерак китеп булмый, миең ялтырып торса гына эш күрсәтә аласың. Шушы арада укытучыларга бер үпкәмне сөйләп кайттым әле. Һөнәрләр турында бер стенд ясап куйганнар да монтажчы 200 сум ала, төзүче — 170, ат караучы — 60 дип язганнар. Каян килгән ат караучы ди ул? Бездә җаваплылыгы белән себер китәрдәй эшләр, һөнәр нияләре тулып ята. Болай ярамый, мәйтәм. Авыл һөнәре ат караучыдан гына тормый, алай гына китереп кую ярамый. Хан кызлары шуннан куркып качып бетә дә инде.— Председательнең кашлары җыерылып килде.— Менә шундыйрак пычрактан арынасы иде.

Бар нәрсәгә күнегеп була диләр. Тик пычрак белән юл өзеклегенә

күнегү кешенең омтылышларын сүрелдерергә мөмкин, вакыт уздырыр өчен яшәү шуннан башланмый микән? Әгәр яшьләр үзләренең авыр күнитекләрен салып ташлап, киләчәкләрен шәһәр белән бәйлиләр икән, моңа пычракның катнашы юк дип кенә котыла алмассың. Яшьләр авырлыктан курыкмый, яшьләр уңайсызлыклардан һәм төссезлектән качалар. Ел буена әллә нишә килсә дә, пычракның бәһасе шулай күтәрелә аның. Ул котылгысыз бер юлдашка әйләнгән.

Исле ромашкалы (алма-үләнле) урамнар истәлекләрдә, сагынып сөйләр өчен генә калган. Авыл белән шәһәр проблемасы бар икән, аның артында шушы пычрак елгасы ага, ә хәзергә исә яшьләр асфальт ягын каера.

Татар өенең чисталыгы болдыр бусагасы төбеннән башлана. Калушлар белән күнитекләр беренче тактага баскан килеш салына. Пычрак бусагадан бер карышка да эчкәре үтми. Мәгънәсе бар моның, бар.

## Мәшәкатьләр

Авыл хатынының иртәләрен уйланып, зарланып ятар вакыты юк. Эш дигәндә — аягы идәндә. Юынып та тормастан, ишегалдына чыгып китә, таң белән казлары кычкырырга керешкән була. Аларны чыгарып җибәрә дә койма буендагы кулъюгычта кулын чайкап, битенә салкын су сирпеп җибәрә. Инде сыер янына ашыгасы. Ул, күзен тутырып, хуҗа бикәне күптәннән көтеп тора бугай.

— Ул хәтле түземсезләнмә,— дип сөйләнә-сөйләнә, ул сыерның җиленен сулы чүпрәк белән сөртеп ала да саварга керешә.

Авыл хатынының уйланып торыр вакыты юк, ул бары тик өзлексез хәрәкәт итеп кенә тора.

Өйгә битьяулыгы белән каплаулы чиләк тотып керә. Плитәгә кичтән калган ашны җылытырга куя, чәй ясый. Аннан соң кире ишегалдына чыгып китә. Сыеры инде капканы ачып чыгарып җибәргәнне көтеп тора. Хуҗа хатынның йөзенә елмаю җәелеп китә — киләчәк бозау турында уйланып куймады микән? Сыеры артыннан сарыкларны да чыгарып җибәрә. Үрдәкләр урамга атлыгып тормыйлар, ишегалдында гы күлдәвектә быкырдыйлар. Хатын аларга ипи турап бирә.

Өйдә бала-чага да уянышып бетә. Шау-гөр килеп киенешә башлыйлар.

Ә юынган-киенгән аталары, болдыр култыксасына таянып, тәмәке төтененә уралган килеш бүген эшләнергә тиешле эшләрен күңеленнән барлап, хәтер җебенә тезеп куя.

Ә бу вакытта аларны кыр көтеп тора инде. Ашыйлар да кайсы кая таралышалар.

## Инженер фикере

Сыер абзары салырга председатель бер ел әзерләнеп йөрде. Сызымнарын караштыргалады, файдасын чамалады, чыгымын исәпләде, керемен барлады.

Безнең кеше табигате белән эшчән, өлгер, кыю. Кесәгә сүз эзләп түгел, ә фикер эзләп керә. Идея матур кәгазьсез дә яхшы. Әгәр ул чыннан да яхшы булса, әлбәттә.

Бүгенге авыл аппаратлар белән тулы. Техниканы ул кызлар күлмәк алыштырган сыман гына алыштырып тора. Күтәрү краны да бар, селектор да тынып тормый, галәмәт дәү көпчәкле сары «Кировец» та кая теләсәң шунда ыргылырга әзер. Кыскасы, авыл ишегенә кайчандыр боегып кына ишек каккан техника бүген инде хуҗага әйләнеп бетте.

Мин председательне кулына циркуль яки реесфедер тоткан килеш күзәлларга тырышып карасам да будыра алмадым. Куллары артык крестьяннарча дип әйтимме соң, алар саллы, уйчан. Кыяфәте, кешеләргә мөнәсәбәте, тормышка карашы белән ул чын интеллигентка тартым. Фикерләре әллә ни тәэсирле дә түгел кебек, хисләре шаккатырмалы дип әйтеп булмый, әмма сөйләмендә дә, хәрәкәтендә дә, килеш-торышында да тәфсилле бер ышаныч ялтырап ята. Идарәнең тыйнак бизәлеше аңа бик килешеп тора. Стенада — дүрт портрет: Маркс, Ленин, Горький, Җәлил. Буялмаган идәнне кояш нурлары җылыта. Тәрәзә пыяласында шөпшә зыңгылдый. Аңа:

— Һава көзлекләр өчен суйган да каплаган инде: иртән кырау, аннары зәһәр кояш. Җанга каймак яккан шикелле,— диган үз сүзләре дә килешеп тора шул.

«Председатель әйткән икән, эшли инде. Колхозны ул күтәрде ләбаса. Аннан башка дуңгыз да караусыз йөри иде, хәзер лагерьда» дигәнгә охшаш сүзләрне миңа бик еш ишетергә туры килде.

Тик циркуль... Ул бер чама сүзләрен үлчәп тора (шундый үлчәү дә була), аларның кибәкләрен аера, селекционер сыман, иң өлгергәннәрен генә сайлап ала. Хәзер чын хуҗа инженерларга хас фикерсез аягын да атлый алмый. «Укып чыктым, өйрәнеп җиттем, чагыштырып карадым»,— бу сүзләр артында ниләр генә ятмый икән? Никахлашу сарае салдырырга җыенмый лабаса, нибарысы дүрт йөз башлык сыер абзары гына. Азыгы килеп торсын, ашлыгы да бер түбә астына сыенсын, азык цехына тегермәннән фуражы тоташлый ага торган булсын, һәр сыерның ятагы ялтырап ятсын. Сөте баш очындагы пыяла торбалардан гөжләп агып торсын. Вентиляциясен ул аерым кайгыртуга алды, үз җаваплылыгына: түшәмдәге дымнан коткара алырмы, юкмы? Сыерга микроклимат күкрәк баласына ана сөте кирәк булган шикелле үк хаҗәт нәрсә.

Шулай итеп, председатель башына килгән фикерен бала киендергән шикелле төпченеп киендерде: салкынга да чыдам, эсселеккә дә түземле итте. Иң искитәрдәе шунда: барысын да үз көчләре белән эшләргә керештеләр, беркемгә дә ялынмадылар, чит бусага төпләрендә таптанмадылар. 400 мең сумлык эшне 176 мең сум белән ерып чыктылар. Ә бу колхоз бюджеты өчен сизелерлек мая калдыру иде.

Хәзер ике сыер абзары бер-берсенә терәлеп, сыенып тора, сигез йөз сыер — бөтенесе швиц токымыннан — ышыкта гына түгел, бәлки җылыда, чисталыкта көн күрәләр.

Терлекчелек комплексы ике елда күтәрелеп чыкты. Шуның өстенә алтмыш машинага исәпләнгән җылы гараж салынды, терлекчеләр һәм механизаторлар йортлары калкып чыкты.

Председательнең идеясе тормышка ашты. Ә ул һаман киләчәк турында хыяллана. Аның Уразай авылында 81 нче елда өч квартирлы алты йорт салдырасы килә. Аның чын хуҗаларга гына хас ышанычы, күз карашы, өмете һәм хыялы булганда «Таулар»да нигә генә тотынсалар да булдырасыларына шикләнмәскә була. Бу аның мактанычы түгел, ә дәрәҗәсе, абруе, кешелек йөзе.

Кеше тормышын фикерләр, уйлар бизи. Уйлы кеше эчтән яктырып тора ул. Маяк шикелле. Шуңа күрә барысы да аңа тартыла. Җиргә күмелгән орлыкның кояшка үрләгәне кебек.

## Гаилә

Авылда бәйрәмнәр сирәк була. Булган шәттә ул барысы өчен дә уртак, кадерле, бердәнбер. Чәчү белән урып-җыю бер-берсенә каршы

чыккан, берсеннән-берсе башланып киткән таңнар кебек. Менә шул таңнар арасында һәммә кешене дә Агыйдел болыннарына әйди торган сирәк көннәр булгалый.

— Әкертен генә митинглап куябыз, нәтиҗәләр чыгарабыз. Рәсми итмичә генә. Бүләкләр өләшәбез дә гармун иркенлегенә биреләбез, җырга буйсынып алабыз. Сирәк-мирәк кенә булса да, гаиләне бергә җыйнап алу гаеп эш түгел лә. Шуның ише...

«Гаиләне җыйнап алу...» Кыяларны җимереп ташлардай куәтле булса да, океан да тамчылардан җыела лабаса.

Гаилә... Аның хакындагы бәхәсләрнең очы-кырыена чыккысыз. Гаиләләр кояшлы үрләргә чәчрәп чыккан гөмбәләр шикелле оешып торалар. Шул ук вакытта, чәчәген койган гөлләр сыман, күпмесе уңа, җимерелә... Гаиләдәге ертык ерактан күренә. Хикмәтле мәсьәлә ул — гаилә.

Безнең туган як авылларында тормыш тирәнрәк агымлы, тамырлар тазарак, ызгыш-талаш әзрәк.

Гаилә... Аның хакындагы бәхәсләрнең очы-кырыена чыккысыз. Гаилә. Нәрсәсе беләндер — тирән мәгънәсе белән микән соң, әллә ачы сагышы белән микән — ул мине гаҗәпкә калдырган иде.

Яшь кияү белән килен адым саен әрләшергә генә торалар икән. Җыен юкка-барга. Кайсысын гаепләргә дә белми аптырыйлар ди. Әбиләре янына килгәннәр дә:

— Син ничек торган идең ул бабай белән? — дип сораганнар.— Сезнең дә кайчандыр туегыз булгандыр лабаса.

— Яшәгәнемә үкенмәдем,— дип җавап биргән әбиләре.— Ирем мине алмага җиккән атта килгән иде. Утыртты да толыбы белән каплап алып кайтып китте. Капкабызны чыгарга өлгермәдек, моның аты абынып китте. «Бер!» дип куйды минем җанкисәгем. Мин колагыма кертләп куйдым. Урман аша чыкканда моның аты тагын абынып куйды. «Ике!» ди бу. Тыңлыйм, дәшмим-эндәшмим. Авылларына кайтып, капка төпләренә җиткәч, аты тагын бүрәнәгә сөртенде. «Өч!» дип әйтүе булды, читәннән бер казыкны суырып алды да атын бәреп тә үтерде... Ничек яшәдек дисезме? Дуслыкта, татулыкта. Аның «Ике!» дигәнен көтеп тормадым, бар хикмәте менә шунда...

Берзаманны Инсаф Сабан туена киткән. Арбасына басып, атын дилбегәсе белән куалап, шөлдерләре белән шаулап. Каны кайнап торган чаклар. Ерактан ук юлдан җәяү барган бер кызны күзләп алган да, куып җитеп, арбасына менгереп утырткан. Ул кыз мәйданга барып җитү белән сикереп төшкән дә кызлар арасына кереп югалган.

Ә кире кайтыр чак җиткәч, атлар бәйләп куелган җиргә килсә, атының җиз таңкәле йөгән кидерелгән башы янында шул кызның яулыгы төсмерләнә. Ул атын сугарырга да оныткан булган, хәерсез, ә теге кызыкай онытмаган, кайгырткан. «Тырыш нәрсә күренә бу»,— дип уйлап куйган ул үзенчә. «Чын хуҗабикә булырга да ярыйсы». Татар егете өчен моннан да зур бәя кую юктыр да.

— Ни атлы син? — дип сораган ул.

— Клара,— дигән кыз.— Мин сине озак көттем, атың сусаган.

Шул Сабан туеннан уртак тормышка килеп кергәннәр дә.

Инсаф Камалетдинов зур гаиләне аякка бастырган кеше. Бүгенге көндә ул бигрәк тә күзгә ташланып тора. Ун баласы аны учларына салып һавага чөя ала. Ә ул әле егетләргә биргесез гайрәтле, башын бер чөеп җибәрсәме? Аңа нибарысы илле биш яшь. Хатыны ике яшькә кечерәк, нык рус хатыны, чәченә чал төшәргә уйламаган да әле. Герой-ана: көчле канатлары астына ун баласын сыйдырып яшәгән. Җиде ул, өч кыз бала — һич кенә дә бүлгесез байлык, карап туйгысыз матурлык. Игезәкләре дә бар — Рәшит белән Фәритләре, төпчекләре Гөлназны алып кайтыр алдыннан дөньяга килгәннәр. Табигать кинәнсеннәр әле

дигәндер күрәсең. Матур җыр лабаса бу! Ә яхшы җыр үзгә бер килешү, татулык һәм яратусыз җырланмый. «Балалар күлмәгән йортка җеннәр иярәшә», дигәннәр. Ә балаларның күз яше чылтыраган һәм шөлдер булып көлүләре янгыраган өй хакында ни диярга? Андый өйнең түбәсендә йолдызлар ял итәдер.

Алар, баягы мәзәктәгечә, кем хаклы, кем гаепле икәнен эзләп тормыйлар, андый сүзне балалар үз колакларына бик тиз киртләп куючан. Алар бары тик йөрәкләре кушканча гына яшиләр. Йөрәкләрен тыңлап, инде теге дөньяга күчкән ата-аналары васыять иткәнчә.

— Балаларга тискәре үрнәк күрсәтергә ярамый,— дип сөйли аталары.— Яхшылык онытыла ул, чөнки ул ана сөте белән керә. Ул сулар һава белән бер. Мәшәкатьләр артыннан куып, ызгышырга вакыт та калмый. Балалар — гаилә саулыгы ул, гаилә хөрмәте, ата-ана дәрәҗәсе. Кайберәүләр әз булсын дип тырыша, ыгы-зыгыдан шүрли, андыйларга үз рәхәтләре генә рәхәт. Иркенлек кирәк, имеш. Әүвәле начаррак хәлдә яшәсәләр дә ишле гаиләләр күбрәк булган. Хәзер киемне бар дип тә белмиләр, ашарга теләнеп йөргән кешеләрне кинолардан һәм китаплардан гына белә баралар. Һәр авылда диярлек балалар бакчасы. Безнең әнкәсе пешекче булып тора, балаларны сыйлый. Гомере буена эштән аерылганы, авырлыктан өзлеккәне юк. Зур гаиләдә балалар бер-берсен тәрбияләп үсә. Иң өлкәннәре Дауттан башлап, барыбыз да көрәшне ярата. Кушканым юк, тик барысы да спортчылар. Мин үз һөнәремне мактап торган булам, алар тыңлаган була. Әмма һәркем үз юлын үзе сайлый, тыяр хәл юк. Кыек юл һәм кыңгыр эш кенә булмасын. Калган һәр нәрсәгә миннән рөхсәт. Газинур белән Дилшат очучы булам дип йөри. Артекта парашюттан сикергәннәр. Юныс ГДР да хезмәт итә, Гөлүс Сахалинда йөзеп йөри, кызыбыз Рәмзия Казанда заводта эшли, Әлфия медицина хезмәткәре, ә төпчек кызыбыз Гөлназ үзебез белән, мине кырга озатып кала, каршы ала... Балалар иркенлектә үсә, матурлыкка өйрәнә. Сау-тазалар. Матурлык, иркенлек һәм сәламәтлек бер туганнар. Хуҗалык эшенә бергә өйрәнәбез. Гаиләдә шатлыктан оялмыйлар. Кара эштән куркырга, чирканырга язмасын...

Аларның өлкән уллары Даут белән мин аэропортта таныштым. Ул да Бөгелмәдән Актанышка очып төшкән, хатыны бала табу йортына кергән икән. Кыз бала көтәләр бугай. Беренчеләре малай; икенчегә кыз тансыктыр, күрәсең.

Шушы көтү аларның өйләрендә дә сизелеп тора. Югыйсә биш оныгы председательнең тезеннән төшми йөдәтәләр.

Якшәмбе көне иде. Хуҗабикә коймак пешерә. Олы кызлары Рәмзия ялга кайткан. Ире белән бергә Әлфия дә шушында. Гаилә язгы ташкын сыман булып тора. Купшыланмыйча, сабыр гына дөньяга яңа кеше килүен көтәләр. Ата кеше өстәл башында — шампански белән коймак каршында утыра. Басу кырларыннан аерылып торган мондый тын мәлләрдә аның күңеленә нинди уйлар килә икән соң?

Мин алар турысында тормыш ябалдашының тигез генә шаулап торганын ишетеп, төп кәүсәнең куәт туплап утыруын, җир астындагы тамырларның кыймылдавын, көчәнмичә-нитмичә генә аларның өскә таба чишмәдәй киеренке басым белән тормыш сутларын кууын, үзагачтагы яшәү орлыгының, киләчәк орлыгының ышанычлы сакта торуын ишетәм шикелле.

**ӘХӘТ ГАФФАР** тәрҗемәсе.

*Магнитка һәм Днепрогэс, Уралмаш һәм Братск ГЭСы, чирәм җирләрне үзләштерү кебек, КамАЗ да бик хаклы рәвештә совет халкының зур эшләре елъязмасына керер.*

**Л. БРЕЖНЕВ.**

# ЯКТЫ ТӨН

Пип-пип-пи-и-ип, пип-пип-пи-и-ип!..

Күкрәк кесәмдәге мультитонның йомыркадан яңа чыккан каз бәбкәсе кебек өзеп-өзеп пипелдәп куюы мине кинәт уйларымнан арындырып җибәрде. Ике кыска һәм бер озын сигнал! Ашыгыч төстә диспетчерлык үзәгенә чакыралар иде.

Ул арада конвейер белән идарә итү пультындагы микрофон аша баш диспетчерыбыз Райнур Гайнуллинның салкын тиюдән бераз карлыга төшкән кырыс тавышы ишетелде:

— Диспетчер Кәбиров! Кичекмәстән ЦДС[1]ка кирәгез! Диспетчер Кәбиров!..

Тиз генә сәгатемә карап алдым да адымнарымны тагын да кызулата төштем. Төнге ике тулып килә. Бер-бер ашыгыч эш килеп чыкты микәнни соң? Алай дисәң... Бер сәгатьлек төнге ял башланырга да санаулы минутлар гына калып бара бит инде.

Ләкин, мультитон пипелдәве өстенә, сине микрофон хәтле микрофон аша дәшеп алырга карар иткәннәр икән — ашыкмый да ярамый иде. Эш шунда: баш конвейерның диспетчерлык үзәге белән даими бәйләнеш тоту өчен бик уңайлы булса да, бер уч төбенә сыеп бетерлек бу мультитон дигәннәрен безнең ише диспетчер халкы бик өнәп бетерми иде. Чөнки ул эшләп торганда үзеңне гел аякларыңа тышау, башыңа нукта кидереп җибәрелгән ат хәлендә тоясың. Бу конвейер ыгы-зыгысыннан аз гына бушанып торырга теләп, бер-ике адым читкә атлый башласаң — күкрәк кесәсендә, димәк, йөрәк турысында гына йөргән әлеге «пипелдәвек» хәзер үзенең сигналларын җибәрә башлар һәм гайка боргыч пистолетлар белән конвейерга кендегеңне кабат беркетеп куяр кебек.

Дөрес, ул сирәк пипелди. Ләкин ни генә булмасын, аяк астыннан килеп чыккан борчу-мәшәкатьтән (ә баш конвейерның барлык нерв җепләре бергә килеп төйнәлгән диспетчерлык үзәгендә оператив хәл, ачуым килмәгәе, минутында йөзгә алышына!) ераграк торганың хәерле дип, кайбер хәйләкәррәк диспетчерлар аны сүндереп кую ягын карый. Бигрәк тә үлеп йокы килгән төнге сәгатьләрдә. Әгәр «аквариум»нан чакыру сигналлары җибәрелеп тә, «ишетми» калган диспетчерлардан җавап таләп итә башласалар «мультитон ватылып торды», «батареясы утырды», фәлән-фәсмәтән... Кыскасы, ниятеңә керешсәң, йөз төрле җавабын табарга була.

Ләкин конвейер пультында утыручы житәкче агайның да башына тай типмәгән! Үтә ашыгыч һәм мөһим йомыш килеп чыкса, кайдадыр йөргән диспетчер кесәсендәге мультитонга чакыру сигналлары җибәрү өстенә, гадәттә, ул үз боерыгын конвейер микрофоны аша да кабатлый. Бар, «ишетмәдем» дип, акланып-бәхәсләшеп кара син аннары аның алдында! Безнең «Б» сменасы баш диспетчеры Райнур Хәкимович кебегенә туры килсәң, хәзер үзеңне утлы табага бастырачак!

Ашыгуым юкка булмаган икән. Райнур Хәкимович минем тизрәк килеп житүне диспетчерлык пунктының тимер болдырлы баскычында түземсезләнеп көтеп тора иде инде. Аның бая гына болытлы күк төсле караңгы йөзе бу юлы инде бераз яктырып киткән кебек күренә. Ияк асларына хәтле кыйгачланып төшкән дага мыеклы бер таныш шофер да янәшәсендә басып тора. Әзмәвердәй таза бу егет янында Гайнуллин-

---

[1] ЦДС — үзәк диспетчерлык службасы. Ул урнашкан будка, стеналары тоташ пыяладан торганга күрә, КамАЗның конвейерында эшләүчеләр телендә «аквариум» дип йөртелә.

ның болай да кечкенә һәм юка гәүдәсе тагын да бәләкәйләнеп калган шикелле күренә иде.

— Ял вакыты җиткәнлектән, ПРЗга[1] барып кайтуны синнән бигүк таләп итеп тә булмый инде. Нишлисең обед икән обед: тамак ялгыйсы, аннары бераз гына булса да черем итеп аласы бар... Шулай да хәлне аңларга тырыш әле, Виктор!—дип, мена ул бер кулы белән әлеге шоферның биек иңбашына җиңелчә генә сугып куйды.— Минскидан 020 нче гидроусилитель кайтып җитмәү аркасында, баш конвейер болай да бер сәгатьләп тик торды. Димәк, кимендә ун «КамАЗ»ны югалттык дигән сүз! Инде менә әле генә Бигеш аэропортыннан шалтыраттылар. Һава ачылган: Минскига очкан самолетыбыз тиздән кайтып җитәчәк. Тагын кырык-илле минуттан — ял азагына әлеге деталь баш конвейерда булачак... Кыскасы, инде хәзер конвейер үзебезнең аркада тагын да туктап тормасын дисәк, эш башланганчы 021нче ПРЗдан тиз генә апкайтып өлгерергә кирәк...

Райнур Хәкимович сөйләвеннән туктады да, калын кашлары астыннан сөзеп, йокысызлыктан кан сава башлаган күзләре белән миңа таба карап куйды: кызым, синә әйтәм — киленем, син тыңла, янәсе! Ләкин, соңгы «021» саны колакка чалынуга, мин барысын да аңлап алган идем инде.

«КамАЗ» автомобиленә куела торган сигез меңнән артык детальнең һәркайсы үз кодына ия. Сүзне озакка сузып, тege яки бу детальнең тулы исемен әйтеп торыш юк. Һәм ул мөмкин дә булмас иде. Әйтик, фәлән модельле автомобильнең фәлән җиренә куела торган фәлән кронштейн дия башласаң, бик озынга китәчәк. Шуның өстенә әле сүзнең кайсы деталь турында баруын да тиз генә аңлап бетереп булмаячак. Чөнки нибары бер автомобильгә куела торган кронштейннарның саны гына да йөздән артып китә. Ә болай детальнең код санын гына атыйсың да — шул җитә! Тиз дә, аңлаешлы да! Шуңа күрә без еш кына үзара кодлар телендә аңлашабыз:

— Фәлән Фәләневич, 114 нче кирәк иде.

— Фәлән Фәләнович, янабыз,— зинһар, тизрәк 014 не китереп җиткерә күр!..

Сөйләшкәндә, мөмкин хәтле кыскарак һәм җайлырак булсын өчен, гадәттә, деталь кодының соңгы өч саны гына атала. Ә алдагыларын инде, тәҗрибәсе һәм «чорма»сының ничек эшләвенә карап, һәркем үзе чамалап белә. Үз номенклатурасындагы барлык детальләрнең тулы саннарын хәтердә тоту-тотмавына карап, диспетчерлар һәм, гомумән, конвейерда эшләүчеләрнеңниндирәк белгеч икәнлекләрен дә бик төгәл чамаларга мөмкин.

Ә Райнур Хәкимович сораган детальгә килгәндә, аның тулы «исем-фамилиясе» 5320-8403021 иде. «КамАЗ» автомобиленең сул яктагы ал көпчәге өстенә 56 нчы позициядә куела торган канат, ягъни мәсәлән! Беренче сан деталь беркетелергә тиешле автомобиль моделен[2], икенчесе детальнең кодын белдерә.

8403021 номерлы канат та бик «куркыныч» детальләр рәтенә керә. Ул бетеп китсә, канатсыз кош оча алмаган шикелле, баш конвейер да шунда ук туктап калачак.

Ә бу минутларда 56 номерлы позициядә, дөрестән дә, нибары берничә автомобильгә генә җитәрлек канатлар калган иде. Алар гына ай азагында, гадәттә, иң зур тизлек белән хәрәкәт итә башлый торган баш конвейерның кече теленә дә йокмаячак, әлбәттә. Әлеге детальне, соңгы көннәрдә штамп ватылып тору аркасында, пресс-рам заводы безгә әзерләп өлгертә алмый башлаган иде. Бу заводның 951 номерлы складында баш конвейерга озату өчен әзерләп куелган берничә әрҗә канат бар иде барын. Телефон аша моннан бераз гына элек булып алган сөйләшүдә склад мастеры Шамил Латыйпов, әлеге әрҗәләрне йөк машинасына төяп башлаулары турында әйтеп, тынычландырып та куйган иде инде. Бу сөйләшүдән соң инде ярты сәгать узып бара. Тик без ике күзне дүрт итеп көткән деталь генә һаман юк та юк!

Эшләр болайга киткәч, төнге ял вакыты белән исәпләшеп торырга ярамый иде, билгеле. Белоруссия хәтле Белоруссия җиреннән кирәкле деталь кайтып җитеп тә, үз

---

[1] ПРЗ — пресс-рам заводы.

[2] Хәзерге вакытта КамАЗның баш конвейерында барлыгы 6 модельдәге автомобильләр җыела. Алар түбәндәгеләр: бортлы йөк машинасы «КамАЗ-5320», иярле тягач «КамАЗ-5410», унбер тонналы үзбушаткыч «КамАЗ-5511», суыткычлар, цистерналар урнаштыру өчен рамнары махсус озайтып эшләнгән йөк машиналары «КамАЗ-53212» һәм «КамАЗ-53213», ун тонналы тягач «КамАЗ-54101».

борып астыбыздагы деталь бетеп китү аркасында, баш конвейер күпмедер минут туктап торса, моның оятын кая куеп бетермәк кирәк? Тик, Райнур Хәкимовичның күпме озак «нотык» укуына карамастан, һаман тиешле эзгә төшәргә теләмәгән шофер егет кенә:

— Ял вакытында ПРЗ склады барыбер эшләми. Погрузчикларны инде әйтеп тә торган юк. Шулай булгач, бушка вакыт уздырып йөрүдән ни мәгънә? — дип, кәҗәләнеп маташа бит әле.

Гайнуллин «гайкаларын тыгызлап бора» башлагач, ниһаять, ул ыңгырашып кына риза булды.

Мәнә без утырган «КамАЗ» автомобиле жиде төн уртасында гадәти булмаган рейска кузгалып китте. Китүен киттек, ләкин сизеп торам: икебезнең дә күңелләре үз урынында түгел. Ярый ла, шофер әйтмешли, һәркемнең оеп йокысы килгән бу төнге тәнәфестә конвейерга буш кул белән борылып кайтырга туры килмәсә. ПРЗ складындагы кызларны, булдыра алганча көйләп-юкәләп дигәндәй, чираттан тыш рейс документларын тутырып бирергә ризалатып та булсын ди. Әле бит аннары, кирәкле деталь салынган әрҗәләрне машинага кую өчен, электр төягечләрендә эшләүчеләрен эзләп табасы бар. Ә аларның күбесе ял сәгатьләрендә ашханәгә китеп беткән була. Складта калганнары исә, тиз-тиз генә коры-сары авыз итеп алалар да, башларын рульгә салып, хәзер изрәп китәргә генә торалар. Графиксыз килсәң, төнге ял вакытында түгел, эш сәгатьләрендә дә алар белән уртак тел табуы үзе бер әҗәл! Әйтерсең, әрҗә-әрҗә детальләрне үз куллары белән күтәрәләр!

Хәер, күбесе мәктәп бусагасыннан гына чыгып килгән бу яшь-яшь кызларга әллә ни үпкәләп тә булмый. Смена буе бетон идәндә, кат-кат өелгән тимер арасында калтыр-колтыр тегесен төяп, бусын бушатып йөреп, эттәй арыйлардыр, мөгаен...

Автомобиль җыю һәм пресс-рам заводлары кул биреп күрешерлек арада гына урнашкан. Бер капкадан чыгып, ике-өч минут баруга, безнең «КамАЗ» икенче капкага якынлашып килә иде инде.

Кинәт Виктор Суматохин, шатыр-шотыр китереп, тормозга басты: каршыбызда, кулын күтәреп, яңгырда чыланып беткән бер егет басып тора иде. Ул нәкъ безгә кирәкле детальләр төялгән машинаның шоферы булып чыкты.

Соңгы көннәрдә, ниндидер кабельләр сузу өчен, пресс-рам заводы каршында канау-чокырлар казып бетергәннәр иде. Чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, әлеге машина әнә шул чокырларның берсенә арт көпчәкләре белән төшкән дә утырган! Без аны, үз «КамАЗ»ыбызга тагып, тарттырып карадык. Юк, каты утырган! Бирелә, берәр трактор-фәлән тапмыйча, эш кырып булмаячак иде.

Бер килсә килә бит ул! Ул арада кичтән бирле туктамаган яңгыр тагын да катырак яварга тотынды. Ә конвейерга синең яңгырың ни дә, канау-чокырың ни! Конвейер, ашыктырып, үзенә канатлар көтә!

Инде эш башланырга да санаулы минутлар гына калып бара. Нишләргә соң?!.. Икенче капкадан кереп, ПРЗ цехыннан сыерчык канатлары кебек ялык-йолык килеп торган 021ләрне кул белән төяп булса да алып кына чыгар идең — алар әле әзер түгел. Хәлне баш диспетчерыбыз Райнур Хәкимовичка сөйләп бирү өчен кире кайтып китер идең — конвейерга моннан нәкъ менә бу мизгелдә ни файда? Берәр чарасын эзләп тапкаанчы, күпме алтын вакыт әрәмгә китәчәк: һәр минуты гына түгел, хәтта һәр секундына тикле күз карасыдай кадерле ай азагы бит! Барлыгы 6200 автомобиль җыеп, айлык планны уңышлы үтәп чыгу өчен, инде дүрт сәгате узып киткән бу төнге сменада әле тагын алтмышлап «КамАЗ»ны конвейердан төшереп өлгерергә кирәк. Хәзер баш конвейерның ике линиясендә сәгатенә уртача унике автомобиль җыела. Димәк, без алып кайтып җиткермәгән 8403021 номерлы канат аркасында биш минут кына туктап торылса да, тулы бер «КамАЗ» хәтле «КамАЗ» автомобиле туган ил киңлекләренә озатылмый кала дигән сүз! Баш конвейерда күпме инженер-диспетчер булып эшләп, минем бу кадәрле дә җаваплы, бу кадәрле дә тиз хәл итәлергә тиешле мәсьәлә алдында япа-ялгызым торып калганым юк иде әле.

Алманың авызга өзелеп төшүен көтеп ята торган чак түгел: ПРЗ складына керергә дә, йөк төягеч руле артында йокымсырап утырган кызның аягына егылып, ял вакыты булуга карамастан, коеп яуган яңгыр астына чыгуын һәм баткан машина кузо-

ындагы әрҗәләрне безнең «КамАЗ»га күчереп куюын үтенүдән башка чара юк әле. Дөрес, инструкциядә идән транспортына урамга чыгып эшләү каралмаган. Ләкин «шайтан гына өметсез», диләр ич!

«КамАЗ» шоферлары, төнге юл уртасына басып, каян да булса трактор-фәлән килеп чыгуын көтеп калдылар. Ә мин ПРЗ капкасыннан уктай эчкә атылдым.

Эш пешкән очракта, әлбәттә, иң әлек 951 иче склад кызларының тиз генә безнең «КамАЗ»га яңа пропуск әзерләп бирүләре иде. Чөнки машинасы бүтән булгач, тиешле документтагы сан-номерлар да үзгәрәчәк. Шуларның берсе туры килмәсә дә, автомобиль җыю заводы капкасыннан үтеп булмаячак.

Мин килеп кергәндә, башларын кайсы кая төртеп, склад кызлары «мәрткә китеп» беткәннәр иде. Өстәлдә чәч-баш килеп яткан кәгазьләрне җыйнаштырып куярлык та хәлләре калмаган — йокылары шулкадәр килгән, күрәсең. Хәер, бүтән төннәрне бу минутларда минем үземнең керфекләргә дә гер тагылган кебек була торган иде. Тик бүген генә йокы турында уйларга вакыт юк.

— Тыныч йокы! — дидем мин, бусагадан кера-керешкә үгезне мөгезеннән эләктереп алырга чамалап. — 021 кирәгие бит, кызлар, ә?..

Склад будкасы эчендә чебен очканы да ишетелми.

— Ашыгыч кирәк...

Кызларым авызларына һаман су капкан килеш йокымсырап утыра бирәләр.

Болай булгач, инде теге сыналган алымны кулланып карамыйча ярамый иде. Көймәбез бик комга терәлеп калган чакларда, без, диспетчер халкы, гадәттә, сүзне баш конвейер белән очлап куярга яратабыз. Чөнки белеп торабыз: аның КамАЗ заводларында эшләүче теләсә кемгә тәэсир итә ала торган әллә нинди сихри көче бар. «Сезнең фәлән деталегез аркасында баш конвейер фәлән минутка туктап калачак»,—дисәң, теләсә нинди калын-калын ишекләр дә ачылмый калмый.

Әлбәттә, кирәксә дә, кирәкмәсә дә күпләр тарафыннан күп мәртәбәләр кабатлана торган мондый сүзләргә склад кызлары инде күптән иял әшеп беткән иде. Ләкин алар минем баш конвейердан килүемне, нәкъ менә төнге ял вакытында килүемне яхшы белеп торалар лабаса!

— Кызлар, 021 аркасында баш конвейер...

— Ә-ә-ә, канатларны әйтәсеңме? — дип бүлдерде мине, ниһаять, өстәлгә баш төрткән кызларның берсе. — Баягынак җибәрдек ич инде, абый!

— Әйе, җибәрүен җибәргәнсез... Тик ул сез төятеп җибәргән машина, ПРЗ капкасын чыккач та, канауга батып калган.

— Калмагае... Деталь бездән киткәнме? Киткән... Иясенә барып җиткәнме-юкмы, анысын инде бүтәннәр кайгыртсын!

— Шулаен шулай да...

Миңа әйтеп бетерергә ирек бирмәделәр. Өстәлгә башлары иелеп төшкән башка кызлар да бер-бер артлы телгә килделәр:

— Ял вакытында нинди бетмәгән канат инде ул, таманагай?

— Конвейер, да конвейер, тамагы туймый торган ул нинди әйбердер...

— Шул конвейер аркасында, тынычлап ял итәргә дә рәт юк бит, әнекәем!..

Склад будкасына ник кергәнемә үкенердәй булдым: кызларның теле телгә йокмый — ләтчә кебек, чәт-чәт итеп кенә торалар!

Болай сүз көрәштерү минем файдага түгел иде, әлбәттә. Әле ярый склад мастеры Шамил Латыйпов үзе килеп керде:

— Тузгыталармы кызлар йонынны? Менә шулай — икенче мәртәбә ял вакытында килеп йөрмәссең. Кызларның йокысын бүлеп...

— Ә баш конвейер туктап калса?

— Беләм, беләм... Без төяп озаткан машинаның ПРЗ капкасыннан чыккач батып калганын да беләм,— диде ул, бармагын изи-изи, мине тәрәзә турысына дәшеп алып. — Ә-әнә, складның теге ышык почмагында йөк төяүче кызлар нинди дер бик кызык журнал укып утыралар. Гомергә булмаган хәл — шул журналларына алданып, хәтта бүген ашауларын да оныттылар... Бар, ризалатып кара үзләрен! Әгәр барып чыкса, эш бездән тормас — яңа пропуск кисәндә булыр!

— Рәхмәт инде, Шамил!

— Тик, ай-һай, ризалата алырсың микән, дускай! Завод каршындагы теге чокырга баткан машинаның шоферы да кодалап караганые инде аларны. Ул вакытта әле эш сәгатьләре чыкмаган була торып та бармадылар. Нишләтәсең, инструкция: үгетләү түгел дегетләсәң дә урамга чыкмаска тулы хаклары бар!

Нишлим, бөтен кыюлыкны эшкә җиктем дә, ятып калганчы — атып калырга кирәк дип, киттем бу «кире беткән» кызлар янына. Алар, корыч мөгезле, тупык корпуслы сап-сары электртөягечләрен ярым түгәрәк итеп тезеп куйганнар да, руль артында утырган килеш кенә, бөтен дөньяларын онытып, ниндидер калын журнал укыйлар иде. Дөресрәге, уртадагысы — ак башлыгы астыннан бер көлтә маңгай чәче бөселеп чыккан сипкелле битлесе укый. Калган икесе, тын да алмыйча, тыңлап утыра.

Мин килеп җитә-житешкә, сүзне читтәнрәк башлап җибәрергә теләп:

— Бүген ашханәгә дә барып тормагансыз икән, кызлар! — дип куйдым.

Хужа атын дагалаганда, бака ботын кыстырган кебек килеп чыкты инде бу! Йөк төягүче кызларның ник бер, ичмасам, керфек очлары селкенеп карасын! Аларның бөтен игътибары сипкелле кыз кулындагы журналда иде шул.

Мин бүтән бер сүз дә дәшмәдем. Ә бары, тизрәк укып бетергәннәрен түземсезләнеп көтеп, тыңлап кына тора башладым.

«...Байтимер гомере буе караңгы авылларга китап ташыды, халыкка гыйлем нуры чәчте,— дип кычкырып укуын дәвам итте теге сипкелле кыз. Китапчы Байтимер исеме колакка чагылуга, мин шунда ук аңлап алдым: кызлар күңелен Гомәр Бәшировның «Казан утлары» журналында басылган «Кара төндә нур чәчеп» исемле хикәясе әнә шулай сихерләгән иде, әлбәттә. — Инде хәзер шул изгелеген үзе үк аяк астына салып ташласынмы? Ул сикереп торып дилбегәгә ябышты:

— Ярар, энекәш, кайгыртуларыңа бик рәхмәт. Тик булмый болай! Кайтыйк авылга! Заһит кулын селтәп:

— Их, абзый, аңламыйсың бит, үз аягың белән бит... — дип сукранды»

Хикәянең шушы турысына җиткәч, сипкелле кыз да укуыннан бераз бүленеп торды. Китапчы Байтимер карт кузгаткан изге хисләрдән тыела алмыйча калтыранган иреннәре бу минутта:

— Үз аягы белән бит, кызлар!.. Үз аягы белән... — дип пышылдыйлар иде.

— Йә, тынычлан инде, Фәүзәриякәем! Тынычлан да тизрәк укып бетер, малай! Китапчы картны ыстражниклар нишләттеләр икән?

— Күп тә калмаган икән... Бир, Фәүзәрия, булмаса, үзем генә укып бетерим...

Шулай хикәя укылып бетте.

Әдәби әсәрнең йөк төяүче кызлар күңеленә бу дәрәҗәдә көчле тәэсир итә алуын күреп торудан мин дә дулкынланган идем. Ләкин үзенә канатлар китергәнне дүрт күз белән көтеп торган баш конвейер бар бит әле. Әлеге хикәя кузгаткан изге хисләрдән соң, сүзне ничек җайлап кына тагын шул төнге урамда батып яткан машинага, канаучокыр һәм көзге яңгырга китереп бәйләргә? Минем күңелдәге бу икеләнүле уйларны инде тынычланып өлгергән Фәүзәрия дә сизеп алды, күрәсең. Ул тыңлаусыз маңгай чәчләрен ак башлыгы астына кыстыра төште дә:

— Сез, абый, баш конвейердан килдегез инде, шулаймы? — дип сорап куйды.

— Шулай, Фәүзәрия!

— Сезгә, абый, ашыгыч деталь апкайтырга кирәк булгандыр инде, шулаймы?

— Шулай...

— Сезнең машинага, абый, теге баткан «КамАЗ» дагы канатларны күчереп куярга кирәктер инде, шулаймы?

Җавап урынына мин бу юлы нигемне генә кагып өлгердем.

— Баш конвейер дигәндә — безнең дә аяк идәндә инде. Әйдә, абый, утыр минем төягечкә! Киттек чыгып яңгыр астына!

— Үз аягың беләнме? — дидем мин, әле һаман колакларыма ышанып бетә алмыйча.

— Үз аягым белән, абый! — дип, сипкелле битенә кинәт ялкын йөгергән Фәүзәрия елмаеп куйды.

Бәхет басты — фәрештәләрнең бигрәк амин дигән сәгатьләренә туры килеп торам бит әле, болай булса!

Тагын бер мизгелдән, шакмаклы тимер плитәләр тезелгән завод идәненнән келтер-келтер тәгәрәп, Фәүзәрия белән мин утырган йөк төягеч 951 нче склад будкасы тәрәзәсе каршыннан үтеп бара иде инде. Мастер Шамил Латыйпов һаман йокламаган иде әле. Ул үз турысыннан безнең җилдәй узып киткәнне күргәч, гаҗәпләнүдән, башын селкеп калды.

8403021 номерлы канатларны без утырып килгән машинага төяп бетергәндә (мица, никтер, аларны Фәүзәрия белән бергә китапчы Байтимер карт та төяшәдер кебек тоелды!), әзер пропуск күтәреп, мастер Латыйпов та килеп җитте. Нечкә күңелле, саф йөрәкле йөк төяүче кызга чын күңелдән рәхмәт әйттек тә, без тиз генә кузгалып киттек.

Янгыр һаман туктамаган иде әле. Завод түбәсенә тияр-тимәс аккан болытларны куып тарата алмавына үчеккәндәй, көзге җил тагын да көчәя төшкән.

Үзе карангы, үзе салкын һәм шыксыз төн!

Ләкин бу минутларда безнең күңелләребездә бик якты һәм җылы иде.

Әнә, бу чираттан тыш рейска ыңгырашып кына риза булган Виктор Суматохин да кабина тәрәзәсеннән тубал чәчле башын сузып:

— Ничектер, төн яктырып киткән кебек күренә. Әллә таң да ата инде? Алай дисәң иртәрәк шикелле әле, — дип куйды.

— Әйе, Виктор, якты, бик якты төн! — дидем мин, аның шикләнүләрен юкка чыгарып.

Без утырган машина 56 нчы позициягә барып җиткәндә төнге өч тулып килә — эш башланырга санаулы секундлар гына калган иде инде.

Төнге смена тәмамланганчы, баш конвейер инде бүтән туктап тормады. Бер позициядән икенче позициягә, бер бригададан икенчесенә күчә-күчә, кызу канлы Кама елгасыдай акты да акты ул!

**РАВИЛ ВӘЛИЕВ.**

**А. М. Котов,**
ТАССР Министрлар Советы Председателенең урынбасары

# ХӘЕРЛЕ ЮЛ!

Яңа бишьеллыкны да юллардан башлыйсы килә. Чөнки транспорт һәм юлларсыз халык хуҗалыгы үсешен күз алдына да китерүе читен. Илебез экономикасы автомагистральләр төзеклегенә дә бик нык бәйле.

Татарстанда гына да ел саен дистәләрчә промышленность һәм авыл хуҗалыгы объектлары сафка баса. Шәһәрләр зурайганнан зурая, авыл һәм поселоклар яңара бара. Автотранспортта йөк ташу күләме дә арта тора. Бу төр транспорттан файдалануның нәтиҗәсе елдан-ел яхшыра. Моңа хәзер КамАЗ автомобильләре дә зур өлеш кертә. Тугызынчы бишьеллыкта автотранспорт белән ел саен уртача 200 миллион тонна чамасы йөк ташылган булса, унынчы бишьеллыкта ул 300 миллион тоннага җитте. Соңгы вакытта кешеләрнең шәхси машиналары да күбәйде. Боларның һәммәсе дә шоссе юллары челтәрен киңәйтүгә игътибарны көчәйтергә кирәклеге турында сөйли. Бу мөһим эш республикабызның партия һәм совет органнары җитәкчелегендә тормышка ашырыла.

Тугызынчы бишьеллыкта яңа юллар салуга һәм гамәлдәгеләрен төзекләндерүгә 182 миллион сумнан күбрәк акча тотылган иде. Мең ярым километрдан артык юл салынып файдалануга тапшырылды.

Унынчы бишьеллыкта республикабызда юллар салуга тагын да күбрәк — 300 миллион сумлык чамасы эш үтәлде. Аерым алганда, Казан—Чаллы магистрале сафка кертелде, Чаллы—Минзәлә, Казан—Чистай—Әлмәт—Оренбург өлкәсе чиге, Казан—Ульяновск, Чистай—Норлат, Түбән Кама—Чистай һәм башка юллар яхшыртылды, яңа күперләр салынды. 36 район үзәгеннән төп юлларга кадәр вак таш түшәлгән юл сузылды. Алабуга — Удмуртия АССР чиге, Минзәлә елгасы аша салынган яңа күпердән уза торган Коноваловка — Качкын автомобиль юллары халык хуҗалыгына бик кирәкле иде.

Тугызынчы бишьеллык белән чагыштырганда, унынчы бишьеллыкта асфальт, цемент-бетон һәм вак таш түшәлгән юллар биш тапкыр күбрәк салынды. Хәзер республикабызда 9600 километрдан артык каты юл бар, шуларның 4100 километрдан күбрәгенә асфальт яисә бетон җәелгән. Бу яктан Татарстан АССР РСФСРдагы 71 автономияле республика һәм өлкә арасында 18 нче урында тора.

Соңгы елларда юлларны төзекләндерү оешмаларының материаль-техник мөмкинлекләре тагын да яхшыра төште, юлларның файдасы әйтеп бетергесез рәвештә артты. Тукай, Бөгелмә, Актаныш һәм башка районнарны бу яктан үрнәк итеп куярга мөмкин.

КПССның XXV съездында иптәш Л. И. Брежнев: «Безгә алдагы чорда транспортны, элемтәне, материаль-тәэминат системасын — инфраструктура дип атала торган нәрсәләрнең бөтенесен тиз үстерү өчен күбрәк ресурслар бирергә туры киләчәген дә исәпкә алмый ярамый. Үткән чорда без бу сфераларның күбесенә аерым алганда юл төзелешенә... тиешле игътибар бирә алмадык. Хәзер моның белән шөгыльләнергә туры киләчәк»,—дигән иде. (КПССның XXV съезды материаллары. Казан, 1976, 44 б.).

Бу мәсьәлә Татарстан АССР Верховный Советы, партия өлкә комитеты һәм республика Министрлар Советының игътибар үзәгендә тора. Әйтик, 1974 елның маенда Татарстан АССР Верховный Советы үзенең сессиясендә дә шушы мәсьәләне караган һәм автомобиль юллары салу, аларны төзек тоту буенча, юл, төзелеш оешмалары, промышленность предприятиеләре, колхоз һәм совхозларның төгәл программасын билгеләгән иде. 1977 елның сентябрендә КПСС өлкә комитеты һәм ТАССР Министрлар Советы «Республикада автомобиль юллары төзүнең барышы турында» карар кабул итте. Моның белән күпчелек районнарның партия һәм совет оешмалары да җитди

тестә шөгыльләнә. Юл төзелеше шулай ук район Советлары сессияләрендә, башкарма комитет утырышларында даими рәвештә тикшерелә, аларның карарларын гамәлгә ашыруга депутатлар һәм совет активы киң җәлеп ителә. Моның уңай нәтиҗәләре күз алдында. Мәсәлән, зур эзерлек эшләреннән соң, Актаныш районында халык депутатларының район Советы сессиясендә юлларны яхшырту хакында карар кабул ителде. Хәзер район Советы башкарма комитеты юл төзүдә җирле кирәк-яраклардан отышлырак файдалана, шуңа өстәп, моңа промышленность предприятиеләре, колхоз һәм совхозларның булышлыгын арттыруга да зур әһәмият бирә башлады. Хәзер биредә автотрассалар салу һәм төзекләндерү җәй буе өзлексез рәвештә дәвам итә. Язгы чәчүдән соң игълан ителә торган ике айлык вакытында эш тизлеге аеруча көчәеп китә. Җир казу техникасы һәм районлагы автомобильләрнең байтагы махсус юл отрядлары карамагына тапшырыла. Төзүчеләр кыр шартларында тору урыны, җылы ризык белән тәэмин ителә, аларга медицина һәм культура хезмәте күрсәтелә. Кыскасы, кешеләр күтәренке күңел белән эшләсен өчен күп көч куела. Хәзер Актаныштан районның барлык колхозларына һәм совхозларына каты өсле юллар сузылган.

Унынчы бишьеллыкта Әлмәт, Баулы, Балтач, Минзәлә районнарында да юл төзү эше яхшы оештырылды.

Гомумән, юл төзүдә ел саен игълан ителә торган ике айлыклар билгеләнгән планнарны уңышлы үтәүгә күп булышлык итә. Халык депутатларының күпчелек район Советлары башкарма комитетлары зур оештыру һәм аңлату эшләре алып баралар, кеше һәм материаль ресурсларны бер максатка туплыйлар. Нәтиҗәдә районнарның күпчелеге ике айда юл төзүнең еллык планын уңышлы үтәп чыга.

Хәлбуки, һәр урында да болай түгел әле. Кайбер районнар үз бурычларын елның елында үтәп җиткермиләр. Аерым алганда, халык депутатларының Апас, Арча, Биектау, Кама Тамагы, Чүпрәле район Советы башкарма комитетлары РСФСР Верховный Советы Президиумының «Колхозлар, совхозлар, промышленность, транспорт, төзелеш һәм башка предприятиеләрнең һәм хуҗалык оешмаларының автомобиль юллары төзүдә һәм төзекләндерүдә катнашулары турында»гы карарында күрсәтелгән хокуклардан тулысынча файдаланмыйлар. Ә бу районнарда юллар начар, көзен-кышын күп кенә хуҗалыклар белән транспорт элемтәсе өзелеп торучан.

КПСС Үзәк Комитетының июль (1978 ел) Пленумында иптәш Л. И. Брежнев: «Авыл хуҗалыгы җитештерүен тагын да күтәрү, авыл халкының тормыш хәлен яхшырту автомобиль юллары челтәрен — төп транспорт юлын, әйтергә мөмкин, авылның тормыш артерияләрен үстерү белән турыдан-туры бәйләнгән.» — дигән иде (СССР авыл хуҗалыгын тагын да үстерү турында, Казан, 1978, 42 б.). Менә шуңа күрә авыл юлларын төзекләндерүгә аеруча нык игътибар итәргә кирәк.

Хәзер алда колхоз һәм совхозларның үзәк усадьбаларын төп юллар белән тоташтыру, авыллар арасындагы юллар челтәрен киңәйтү бурычы тора. Инде бу җаваплы бурыч тормышка аша башлады: республикабызда «Дорколхозстрой» тресты оештырылды. Ул унынчы бишьеллыкта ук вак таш түшәлгән өч йөз километр юл салып файдалануга тапшырды. Трест унберенче бишьеллыкта 700 километр чамасы юл салырга тиеш.

Авыл автомобиль магистральләрен уңышлы төзү өчен, юл салуны проектлау һәм финанслауны планлаштыру мәсьәләләренә кагылышлы зур проблемаларны да хәл итәргә кирәк иде. Барыннан да элек, авыл, поселокларны тоташтыручы һәм шулай ук эчке юлларның төп схемасын булдыру мөһим. Шул нигездә, беренче чиратта, район үзәкләреннән барлык колхоз һәм совхозларга кадәр каты өсле юллар салырга кирәк. Хәзер республикабыздагы 800 дән артык колхоз һәм 700 ләп совхоз үзәгендә бу мәсьәлә хәл ителгән дип санала инде.

Ләкин авылларда бу эш колхоз һәм совхозларның юл төзелешенә тотардай чаралары җитмәве аркасында тоткарлана. Шуңа күрә ТАССР Авыл хуҗалыгы министрлыгына, югары органнар белән килештереп, юл төзелешен кредитлау мәсьәләсен кичекмәстән хәл итәргә кирәк.

Агымдагы һәм еллык планлаштыру, проект документлары эшләү, юл төзелешен финанслауны вакытында хәл итү күп яктан заказчы эшчәнлегенә бәйле. Әмма әлегә бердәм хуҗа юклыгы сәбәпле заказчы ролен турыдан-туры колхоз һәм совхозлар үзләре үти.

Хәзер, Брянск өлкәсе үрнәгендә, ТАССР Авыл хуҗалыгы министрлыгында колхоз һәм совхозларда юл төзүнең республика дирекциясе оештыру күз уңында тора. Аңа юл төзү чараларын һәм ресурсларын туплау, проект-смета документлары хәзерләү, юллар салуны даими тикшереп тору вазифалары йөкләнәчәк.

Юл төзү тизлеге һәм күләме арта бара, димәк, автотранспорт, механизмнар һәм юл төзүнең махсус техникасыннан файдалануны яхшырту таләп ителә. Моңа әлеге техниканы специальләшкән эре подразделениеләрдә туплаганда гына ирешеп була. Шушы максатта «Дорколхозстрой» трестында автотранспорт предприятиесе оештырылып, механикалаштырылган идарә булдырыла. Аңа механизмнарны файдаланудан тыш, автомобиль юллары төзелешендә эшне агым тәртибендә оештыру бурычы да йөкләнә.

Кул астындагы материаллар (вак таш, ком белән таш катнашмасы) чыгару куәтләрен үстергәндә генә юл төзү бурычларын уңышлы үтәп була. Әлегә, «Дорколхозстрой»ның мондый материаллар ала торган үз чыганаклары юк, шуңа күрә унберенче бишьеллык ахырына трестка бер елда 600 мең кубометр таш материалы бирерлек карьерлар ачу бурычы йөкләнә. Шушы чараларны тормышка ашыру авылларда юл төзү планнарын уңышлы үтәргә мөмкинлек бирәчәк.

Республикада юллар төзүдә предприятиеләр һәм оешмаларның ярдәме зур. «Татнефть» һәм «Татнефтестрой», «Камгэсэнергострой» һәм «Татэнергострой» производство берләшмәләре, «Гидромонтаж» трестының 3әй участогы тырышлыгы белән, республикабызның нефть районнары һәм КамАЗ шәһәр яны зонасы яхшы юллар белән тәэмин ителде.

Предприятие һәм оешмаларның юл төзелешендә катнашулары куанычлы бер уңай күренешкә әверелеп бара. Ул очраклы хәл түгел, чөнки алар юлсызлыкның кыйммәткә төшүен яхшы беләләр. Мәсәлән, РСФСР Автомобиль юллары министрлыгы мәгълүматларына караганда, «юлсыз» районнарда авыл хуҗалыгы продукциясе үзкыйммәтендә транспорт чыгымнары өлеше 40 процентка кадәр җитә. Реализацияләнгән продукция еш кына юл чыгымнарын да каплый алмый. Юллар өзеклеге аркасында ел саен һәр төзек автомобиль уртача 40 көн эшсез тора.

Колхоз һәм совхозлардагы трактор паркының 60 процентка якыны автомобильләрне тарттырып йөрүгә, йөк ташу кебек җитештерүчән булмаган эштә файдаланыла. Юл начар районнарда авыл хуҗалыгында «саф продукт» җитештерүдә тигез үсешкә ирешү өчен юллары яхшы булганнар белән чагыштырганда, һәр берәмлек продукция җитештерүгә хезмәт чыгымнары 15 процентка күбрәк тотыла. Мондый районнарда промышленность предприятиеләре, халыкка сәүдә, көнкүреш һәм коммуналь хезмәт тармаклары да зур югалтуларга дучар була.

Шуңа карамастан, кайбер районнарның колхозлары, совхозлары һәм предприятиеләре юл төзелеше белән тиешенчә шөгыльләнмиләр, бу мөһим эшкә бик аз көч куялар. Үзәк усадьбаларга, терлекчелек комплексларына һәм ындыр табакларына, предприятиеләргә һәм оешмаларга бару юллары салу эше аеруча сүлпән алып барыла.

Район Советы башкарма комитетларына, хуҗалык җитәкчеләренә РСФСР Верховный Советы Президиумының югарыда күрсәтеп үтелгән Указы таләпләрен тормышта дөрес кулланырга һәм тулырак гамәлгә ашырырга кирәк. Анда җирле автомобиль юллары төзелешендә һәм төзекләндерүдә барлык колхоз-совхозларның, промышленность, транспорт, төзелеш предприятиеләре һәм оешмаларының да катнашуы күздә тотыла. Указ күрсәтмәләрен үтәмәүче җитәкчеләрне катгый җаваплылыкка тарту сорала. Мәгълүм булганча, әлеге документта предприятие һәм оешмаларның юл төзелешендәге эшләрне үз исәпләренә — хуҗалык ысулы белән — башкарырга тиешлекләре күрсәтелә. Бары тик гадәттән тыш очракларда гына юл эшләрен турыдан-туры башкаруның акча взносы кертү белән алыштырылуы ихтимал.

Иптәш Л. И. Брежнев күрсәтеп үткәнчә, беренче чиратта, югары таләпчәнлек, оешканлык, эшкә иҗади мөнәсәбәт булдыру шарт.

Идарә итү дәрәҗәсен яңа баскычка күтәрү, хезмәтне оештыруны максатчан камилләштерү, төрле службаларның эшен көйләп тору, аларның һәркайсының үз эшен төгәл һәм вакытында башкаруына ирешү гаять әһәмиятле.

КПСС Үзәк Комитеты һәм СССР Министрлар Советының 1979 ел, 12 июль карарында күрсәтелгәнчә, планлаштыруны камилләштерү һәм хуҗалык механизмы эшчәнлегенең ахыргы нәтиҗәләренә йогынтыны көчәйтү чараларын мөмкин булганча тизрәк тормышка ашырырга кирәк.

Бишьеллыкны тәгәлләү елында республикабыз юл төзүчеләре 359 километр юл салдылар һәм 1020 километр араны ремонтладылар, 25 яңа тимер-бетон күпер кордылар. Болардан, тыш, Казанны төньяктан әйләнеп үтү өчен 45,2 километрлы юл һәм Идел аша олы күпер салу өчен әзерлек башланды. Бу юл Татарстан башкаласын транзит автотранспорттан бушатырга мөмкинлек бирәчәк. Шулай ук Казан—Ульяновск, Казан—Пермь, Казан—Оренбург һәм башка юлларны реконструкцияләү эшләре алып барыла.

Автомобиль юллары челтәрен тагын да киңәйтү, алардан файдалануны яхшырту республикабыз экономикасын һәм культурасын тагын да үстерүгә, КПССның XXVI съезды билгеләгән бурычларны уңышлы рәвештә тормышка ашыруга булышлык итәчәк.

РСФСР Министрлар Советының «РСФСРда автомобиль юллары төзү, ремонтлау һәм карау эшен яхшырту чаралары турында»гы карарын тормышка ашыра барып, унберенче бишьеллыкта автомобиль юллары челтәре шактый нык киңәячәк. Татарстанда каты һәм камилләштерелгән өсле 1777 километр юл төзеләчәк, 4204 километр трасса өр-яңадан яхшыртылачак. Шулай ук Башкортстан АССР белән чиктәш Минзәлә ягында Казан—Уфа, республикабыз киңлекләрендә Алабуга—Ижевск, Казан—Ульяновск, Чистай—Норлат кебек мөһим автомагистральләрне салу эше дәвам иттереләчәк. Казанны төньяктан урап уза торган 45,2 километрлы юлны төзүгә 45 миллион сум акча билгеләнде. Аны сафка кертү өчен дә күп көч сарыф итәргә туры киләр. Быел Казан янында Идел аша күпер салына башлый. Бу — зур һәм гаять җаваплы объект.

Гомумән, унберенче бишьеллыкта күперләр төзүнең зур программасы күздә тотыла. Шушы чорда барлыгы 3,5 мең погон метр күпер салыначак. Болардан тыш, юлларда хәрәкәт иминлеген тәэмин итү, автомобиль трассаларын төзекләндерү һәм яшелләндерү дә зур эшләр көтә.

Кыскасы, яхшы юлларда сәфәрләр уң булачак. Хәерле юл, яңа бишьеллык, хәерле юл сезгә, юлдашлар!

# ТАТАРСТАН — ЛЕЙПЦИГ ЯРМИНКӘСЕНДӘ

Алты йөз мең кеше яши торган Лейпциг — зурлыгы ягыннан Германия Демократик Республикасында, Берлиннан кала, икенче шәһәр, экономикасы һәм культура багланышлары белән бай тарихлы. Аның промышленносте бик күп төрле продукция — катлаулы машиналардан алып, зиннәтле мехларга кадәр житештерә. Иң яхшы типографияләре, нәшриятлары, китапханәләре, фәнни-тикшеренү оешмалары һәм уку йортлары Лейпцигны дөньякүләмдә «китаплар шәһәре» итеп таныттылар. Лейпциг университетының тарихы биш ярым гасыр белән исәпләнә. Сәүдәнең борынгы юллары үзәгенә урнашкан бу шәһәр ГДРда иң эре транспорт ноктасы булып житте. Һәр елның март һәм сентябрь айларында үткәрелә торган язгы һәм көзге халыкара ярминкәләр Лейпцигка дөньякүләмендә сәүдә даны китерде.

Күренекле революционерларның исемнәре һәм эшчәнлекләре дә шәһәр тарихы белән аерылгысыз бәйләнгән. Егерменче йөз башында биредә бөтендөнья пролетариатының юлбашчысы В. И. Ленин яшәгән, 1900 нче елда Ленин «Искра»сының беренче саны Лейпцигта басылып чыга.

Менә шушы тарихи шәһәрдә 1980 нче елның 31 августыннан 6 сентябренә кадәр традицион халыкара ярминкә үткәрелде. Советлар Союзы аның иң зур катнашучысы иде. Мең квадрат метрлы залларда, үзенең 60 еллыгын билгеләп үткән Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы экономикасының һәм культурасының үсеше, казанышлары турында бөтен дөньяга сөйләп торды.

Ярминкә ачылу тантанасында Татарстан АССР Министрлар Советы Председателе Г. И. Усманов житәкчелегендә республикабызның хөкүмәт делегациясе катнашты. Культура эшлеклеләребез делегациясенә Татарстан АССР культура Министры урынбасары М. Т. Низамиев житәкчелек итте. **МӨҖИП ТАҖИЕВИЧ НИЗАМИЕВ** безнең сорауларга җаваплар бирде һәм укучыларыбызны Лейпциг ярминкәсе, Татарстан экспозициясе һәм анда республикабызның сәнгать осталары чыгышы белән таныштырды.

— Лейпциг ярминкәсенең сигез гасырлык тарихы бар. Ул сугыштан соң социалистик экономика интеграциясенең көзгесе булып китте, дәүләтләрнең үзара экономик элемтәсен ныгытуда, аларны якынайтуда гаять зур роль уйный. Журнал укучыларны 1980 нче елгы көзге ярминкә эчтәлеге белән таныштырып үтсәгез иде.

— Ярминкә «Гомуми сәүдә һәм техника прогрессы» дигән девиз белән үтте. Ул Германия Демократик Республикасы төзелгәннән соң илле сигезенче ярминкә иде. Анда 52 илдән алты мең экспорт предприятиесе һәм тышкы сәүдә оешмасы катнашты. Залларына техниканың һәм халык куллануы товарлары житештерүнең 25 тармагыннан сигез меңнән күбрәк экспонат куелган иде. Аларның байтагы продукциянең бүгенге көндә эшләнә торган төрләрен тәшкил итте. Тематикасы ягыннан ярминкә В. И. Ленинның тууына 110 ел тулу билгесе астында үтте, СССР һәм ГДР, «Социалистик экономика интеграциясе хәрәкәттә» дигән чакыру астында СЭВ илләре хезмәттәшлегенең үсеш нәтиҗәләрен ачык күрсәтте. Совет күргәзмәсе СССР һәм ГДР арасында дуслык, үзара хезмәттәшлек һәм ярдәмләшү турында Договорның уңышлы төстә тормышка ашырылуын чагылдырды. Безнең илебез экспозициясенә куелган йөздән артык экспонат СССРның башка илләр белән үзара файдалы хезмәттәшлегенең ачык чагылышы иде. Лейпциг экспорт предприятиеләре һәм тышкы сәүдә оешмалары өчен коммерция эшчәнлеге, күпъяклы информация алмашу һәм яңа контактлар урнаштыру урыны булды. Моның өчен биредә бөтен мөмкинлекләр бар. Әйтик, Лейпцигта киң күләмдә һәм төрле хезмәт күрсәтүнең информацион фәнни-техник үзәге оператив эшләве белән хаклы рәвештә абруй казанды.

Ярминкәнең гомуми мәйданы 290 мең квадрат метр иде. Ул 22 күргәзмә залын, 30 павильонны, 16 бина һәм махсус территорияне берләштерә. Ярминкәне карарга кешеләр җир шарының йөз иленнән килде.

Лейпциг ярминкәсе халыклар арасында дуслык элемтәләрен ныгыта. Ул Көнбатыш белән Көнчыгыш арасында сәүдәне үстерүдә традицион үзәк булып санала. Бу исә социаль стройлары төрле булган илләр арасындагы мөнәсәбәтләрне яхшырту, халыкларның үзара аңлашуы, дөньяда тынычлыкны ныгыту өчен уңай шартлар тудыра.

Көзге ярминкәдә, мәсәлән, 13 социалистик, 30 дан артык капиталистик һәм 8 үсеп килүче ил, Көнбатыш Берлиннан уннарча рәсми оешмалар, предприятиеләр катнашты.

Безне СЭВ илләренең уңышлары аеруча куандырды. Социалистик хезмәт бүленешенең бу формасы үзенең тормышчанлыгын күптән исбат итте инде. Хәзер алар арасында 120 күпьяклы, 660 ике яклы килешү бар. Химия предприятиеләре төзү өлкәсендә ГДР һәм СЭВ членнары, бигрәк тә ГДР һәм СССР арасында экономик хезмәттәшлек киң чагылыш таба. 12 нче павильондагы кумәк экспозиция әнә шуны раслый. В. Ламберц исемендәге «Полиграф» комбинаты эшләп чыгара торган станокларның 75 проценты халыкара килешүләр нигезендә специальләштерелде. Алар СССР, ЧССР, Болгария, Польша, Венгрия, ГДР полиграфия промышленностенда уңышлы кулланыла.

Германия Демократик Республикасының экспорт мөмкинлекләре елдан-ел арта. Ярминкәгә ГДР предприятиеләре 5 мең яңа һәм камилләштерелгән әйбер үрнәкләре тәкъдим иткәннәр.

Продукцияләр ярминкәдә аерым тармаклар буенча куелган. Мәсәлән, җитештерү чаралары секторында «Химия һәм химия корылмалары» тармагы бар иде. Анда 25 ил экспонатлары күрсәтелде. Ул махсус химия ярминкәсеннән һич тә ким түгел иде. Текстиль машиналарын — 20, юл транспорты чараларын 15 ил күрсәтте. Халык куллануы товарларына урын аеруча зур бирелгән. Күргәзмә залларында һәм павильоннарында 45 илдән китерелгән үрнәкләр күрдек. Текстиль әйберләре һәм кием-салым, көнкүреш химиясе, косметика һәм фармацевтика продукциясе, пыяла һәм керамика, электр приборлары һәм уенчыклар дөнья экспертларының игътибарын үзенә җәлеп итте.

— Мөжип Тажиевич, 1980 елда, беренче тапкыр буларак, Лейпциг ярминкәсендә безнең илебездән бары тик бер генә автономияле республика аерым күрсәтелде. Моңа безнең Татарстан лаек булды. Шунлыктан Татарстан АССР экспозициясенә тулырак тукталу урынлы булыр.

— Совет Татарстаны — алга киткән индустриаль-аграр республика. Бездә халык хуҗалыгының фән-техника прогрессын билгеләүче иң мөһим тармаклары югары үсеш алды. Кайбер саннарга мөрәҗәгать итик. Республиканың промышленность структурасында машина төзелеше һәм металл эшкәрту — 39,1, химия һәм нефть химиясе — 22,8, ягулык — 10,2, электр энергетикасы — 4,7, җиңел промышленность 9,6 процент тәшкил итә. Татарстанда эшләнә торган 80 төрле әйбер чит илләргә чыгарыла.

Республикабыз промышленносте җитештергән әйбер үрнәкләре халыкара ярминкәнең матур бизәге иде. Туган якларыбыздан еракта алар белән танышу Татарстаныбызны тулысы белән күз алдына китереп бастырырга мөмкинлек бирде. Үзенең 60 еллыгын билгеләп үткәндә, В. И. Ленинның тууына 110 ел тулган елда республикабызның халыкара аренага зурлап чыгуы безнең өчен аеруча зур шатлык һәм чиксез горурлык хисе тудырды. Экспозициябез Совет дәүләтенә нигез салучы В. И. Ленинның Казандагы тормышына һәм эшчәнлегенә багышланган бүлек белән ачылды.

Ярминкәгә килүчеләр «КамАЗ» автомобильләре янында озак тукталып торалар иде. Кама берләшмәсе инженерлары машиналарга тулы техник бәя бирделәр, предприятиенең киләчәге белән таныштырдылар, КПССның XXVI съезды ачылуга КамАЗның икенче чираты сафка басачагы, шуннан соң аның елына 150 мең авыр йөк машинасы, 250 мең двигатель эшләп чыгарачагы турында сөйләделәр.

Көнелләдә бер вакыйга уелып калган. Ачык стендлар янына бер төркем яшьләр килеп басты. Арадан берсе автомобиль гигантын төзүдә үзләренең өлеше булуы турында сөйләп китте. Таныштык: «Роботрон» комбинаты техник-наладчиклары ял көнне Татарстан күргәзмәсен карарга махсус килгәннәр. КамАЗның автоматлаштырылган идарә итү системасы өчен алар бригадасы электрон-хисаплау машиналары корган булган икән.

ГДР һәм Совет Татарстаны предприятиеләренең шундый хезмәттәшлеге үрнәген ярминкәдә республикабыз экспозициясе белән танышканда бик еш очратырга мөмкин иде. Дөньядагы иң озын «Дуслык» нефть үткәргече, Татарстанда башланып, Германия Демократик Республикасына килеп җитә. Аның аша тугандаш ГДРга берничә миллион тонна нефть кудырылган инде. Экспозициябез уртасында Татарстан экономикасы үсешенә нефть индустриясенең нинди зур йогынты ясавын хәтерләтеп, нефть вышка-

сы макеты басып тора. В. В. Куйбышев исемендәге Казан «Тасма» берләшмәсе стендлары янында технолог Римма Нуруллинаны халык сырып алган. Ул төрле-төрле сорауларга тулы җаваплар бирә. ГДРдагы дусларыбызны берләшмәнең яңа продукцияләре, планнары кызыксындыра.

Республикабызның СЭВ илләренә чыгара торган продукциясе ассортименты гаять күп төрле: автомобильләр, сәгатьләр, вакуумлы насослар, компрессорлар, медицина җиһазлары, нефть химиясе промышленносте әйберләре һәм башкалар, һәм башкалар. Республикабыз экспозициясе социалистик экономика интеграциясенең тормышчанлыгын күрсәтүче ачык мисал иде.

Көзге ярминкәдә Хөсәен Ямашев исемендәге Татарстан мех берләшмәсе экспонатлары килүчеләрнең күз явын алып торды. Иң зур халыкара күргәзмәләрнең иң югары бүләкләренә лаек булган мех киемнәр янында тукталмыйча һич мөмкин түгел иде. Казан осталары кулы белән эшләнгән мех әйберләргә Парижда, Нью-Йоркта, Копенгагенда, Монреальдә, Варшавада һәм дөньяның башка шәһәрләрендә үткәрелгән халыкара күргәзмәләрдә тиң киемнәр табылганы юк әле! Моның белән ничек горурланмыйсың.

Казан «Аромат» фабрикасында эшләнгән «Геракл» хушбуена хәтта французлар да таң калды. Атаклы парфюмер, фабриканың производство начальнигы Сания Хөсәенова җитәкләгән коллектив аны Мәскәү Олимпиадасына багышлап чыгарган. Тартмасын һәм флаконын ГДР предприятиеләрендә эшләгәннәр. Арча милли аяк киемнәре фабрикасында чигелгән читекләр дә экспозициябез горурлыгы булды. Казан компрессор заводында җитештерелгән суыту машиналары, җәнлек тиреләре ярминкәгә килүчеләрдә соклану хисләре уятты.

Татарстан АССР экспозициясен карарга Германия социалистик бердәм партиясе Үзәк Комитеты Генеральный секретаре, ГДР Дәүләт советы председателе Э. Хонеккер килде һәм республикабыз промышленносте казанышларына югары бәя бирде.

Туган Татарстаныбызда эшләнгән әйберләргә мактаулы бүләкләр тапшыру минутларын һич онытырлык түгел. Компрессор заводында эшләнгән суыту машинасы, Арча осталары чиккән милли читекләр, Казан мехчылары җитештергән бүрекләр ярминкәнең иң югары бүләгенә — алтын медальләренә лаек булды. Бу бөтенебез өчен чиксез зур сөенеч иде. Безнең илебезгә тапшырылган ун алтын медальнең өчесе Татарстанга кайтты.

Лейпциг ярминкәсендә Совет Татарстанының милли көне дә үткәрелде. Анда республикабыздан барган сәнгать осталары, иҗат коллективлары чыгыш ясады. Бу көнне ярминкәдә уннарча мең кеше республикабызның культура тормышы белән тагын да якыннанрак танышты.

— Мөҗип Таҗиевич, журналыбыз укучыларына Татарстан сәнгать осталарының культура программасы турында ниләр сөйләр идегез?

— Лейпциг ярминкәсенең культура программасы да бик бай иде. Аны оештыручылар ГДРның һәм чит илләрнең танылган артистларын чакырганнар. Гевандхаус оркестры, Лейпциг радиосының симфоник оркестры һәм башка коллективлар махсус программа белән чыгыш ясадылар. Шәһәр театрларының репертуары социалистик чынбарлыкны чагылдырган һәм классик әсәрләр белән тулы иде. Ярминкәнең культура тормышында аның дирекциясе тарафыннан катнашучылар өчен оештырылган тантаналы кичә мөһим вакыйга булды. Анда Лейпцигның опера һәм балет театры Лео Делибесның «Копеля» балетын күрсәтте.

Татарстан АССРның культура эшлеклеләре делегациясе 45 кешене берләштерә иде. Үзебез чыгыш ясаганчы, ГДРның культура тормышы белән таныша башладык. Ярты миллионнан күбрәк кеше яшәүче Дрезден шәһәре үзенең тарихи һәйкәлләре белән соклану уятты. Ул архитектурасының гүзәллеге, картиналар галереясында, музейларында һәм культура сарайларында тупланган нәфис хәзинәләре белән дә дан тота. Шуңлыктан аны Германия Демократик Республикасында «Эльбадагы Флоренция» һәм «Сәнгатьләр каласы» дип йөртәләр. Бөек Ватан сугышында җимерелгән галерея һәм музейлар инде торгызылган, халык өчен ачык. Татарстан вәкилләре Потсдамда булдылар, XVIII гасырның архитектура һәйкәле — Яңа сарайны карадылар. Без Цвингер сараена бардык, анда атаклы Дрезден галереясы картиналары белән таныштык. Бөек немец язучылары Гете, Шиллер исемнәре белән бәйле урыннарга экскурсияләр яса-

дык. Лейпцигка ярминкә ачыласы көнне — 31 нче августта килеп төштек. Шәһәр безне кунакчыл, бәйрәмчә һәм тантаналы шартларда каршылады.

1 нче сентябрьдә Татарстан АССР Министрлар Советы председателе Гомәр Исмәгыйлович Усманов чит ил журналистлары өчен матбугат конференциясе үткәрде, аларга республиканың экономикасы һәм культурасы турында сөйләде. Аннан соң кабул итү мәҗлесе булды. Делегациябез үзенең чыгышын шушы мәҗлестә башлады. «Казан кунаклары» дигән хореографик композиция Оренбург, Рязань, Ульяновск, Астрахань өлкәләрендә, Себердә һәм Татарстанда яшәүче татарларның этник группалары фольклор материалы нигезендә төзелгән иде. Аны Бөтенсоюз һәм Бөтенроссия конкурслары лауреаты, Габдулла Тукай исемендәге Татарстан Дәүләт премиясе лауреаты ТАССР җыр һәм бию ансамбле башкарды. ТАССРның халык артисты Гай Таһиров постановкасын тамашачы җылы кабул итте. ТАССРның халык артисткасы Нәфисә Василова җырны башлап җибәрә.

**Кәккүк кычкыра урманда, яз килгәч,**
**Җир яшәргәч, кырларда гөл үскәч;**
**Чут-чут итеп тирәкләрдә сандугач сайрый,**
**Шул чагында йөрәкләрдә яңа дәрт кайный...**

Сәхнәгә ТАССРның атказанган артисты Равил Хәлиуллин уктай атылып чыга. Аңа Татарстан җыр һәм бию ансамбленең бию группасы кушыла. Алар егетләр биюен башкаралар. Бию тәмамлануга, Бөтенсоюз һәм Бөтенроссия конкурслары дипломанты, ТАССРның атказанган артисты Рәшит Мостафин гармунда татар халык җырларына фантазияләрне суза. Аны Татарстанның атказанган артисткасы Халисә Шәрәпова һәм Равил Габдрахманов алыштыра. Алар «Кияү» дигән көлкеле бию башкаралар.

ТАССРның атказанган артисты Фердинанд Гыймадиев һәм Рузалия Мостафина «Әпипә»не такмаклагандай салмак кына биеп китәләр. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе композитор Бату Мулюков Саратов гармунында татар халык көйләрен уйный. Ул, башына татар кәләпүше киеп, ярминкәдә республикабыз экспозициясендә дә гармунын кулыннан төшермәде. Җырчыларның Бөтенсоюз конкурслары һәм Гавана фестивале лауреаты Татарстанның атказанган артисткасы Вафирә Гыйззатуллина җырлавы да тамашачыларны әсир итте. Татарстанның халык артисты, Габдулла Тукай исемендәге ТАССР Дәүләт премиясе лауреаты Ринат Ибраһимов чыгышын тамашачы кабат-кабат алкышларга күмде. Танылган артистыбызның «Дуслык — Фройндшафт» җырын концертта катнашучылар барысы да күтәреп ала иде. Бу җыр Лейпциг сәхнәләрендә чын дуслык, туганлык, хезмәттәшлек җыры булып яңгырап торды. РСФСРның атказанган, Татарстанның халык артисты, Габдулла Тукай исемендәге ТАССР Дәүләт премиясе лауреаты Айрат Арсланов чыгышлары безнең концерт программабызга ямь өсти, аны баетып җибәрә иде. Бөтенсоюз смотры лауреаты, «Орфей» вокаль — инструменталь ансамбле һәм филармониянең халык музыка кораллары оркестры чыгышлары зур уңыш белән барды.

Без Лейпциг ярминкәсендә чыгыш ясау белән генә чикләнмәдек. Германиядәге Совет гаскәрләре группасында, госпитальдәге чыгышларыбыз чын дуслык бәйрәме, интернациональ бәйрәм төсендә үтте. Татар артистларының чыгышын һәркайда җылы каршыладылар, сәнгать осталарыбыз җирле тамашачылар һәм совет кешеләре алдында дан казандылар. Концертлар татар сәнгатенең күп милләтле совет гаиләсендә туктаусыз үсүе, чәчәк атуы турында сөйләүче дәлил иде. Ярминкә ябылгач та, концертларыбыз туктамады. Мәйданда илле илдән килгән туристлар белән җырлап-биеп ярминкә тантанасын һәм рухын дәвам итүдә катнаштык. Павильон директоры Л. С. Губирия соңыннан безгә зур рәхмәт белдерде, һәркайсыбызга ареым-аерым истәлек бүләкләре тапшырды. Татар артистларының чыгышлары Лейпциг матбугатының игътибар үзәгендә булды. Җирле газеталар Татарстан сәнгать осталарына багышлап мәкаләләр, рецензияләр басып чыгардылар, татар артистларының иҗатын югары бәяләделәр. Шәһәр музееның симфоник музыка залындагы чыгышларыбыз һәркемнең күңелендә озак сакланыр.

Лейпцигтагы көзге ярминкә, СЭВ илләренең үзара хезмәттәшлеген елдан-ел киңәйтә, тирәнәйтә барып, барлык дәүләтләр белән үзара файдалы экономик һәм сәүдә элемтәләрен үстерергә омтылуларын тагын бер кат күрсәтте. Башкача булуы мөмкин дә түгел иде. Чөнки сәүдә — тынычлык юлдашы ул, киеренкелекне йомшартуны тормышка ашыруның үтемле формасы. Советлар Союзы һәм социалистик бердәмлекнең башка илләре җир йөзендә ныклы тынычлыкны тәэмин итүдә, халыкларның үзара тату яшәү мөнәсәбәтләрен ныгытуда һәм хезмәттәшлеген үстерүдә тырышлыкларын кызганмыйлар. Татарстан сәнгать осталары, Германия Демократик Республикасы җирендә чыгыш ясап, шушы мөнәсәбәтләрне ныгытуга өлеш кертүләре белән үзләрен бәхетле саныйлар.

## Укучының күңел дәфтәренә

### Төрекмән мәкальләре һәм әйтемнәре

*Халык көче — зур ташкын.*
*Һәр кешедән берәр төк — сакалсызга зур сакал.*
*Эш күп чакта — күмер юк, оста барда — тимер юк.*
*Кәкре казык кагар өчен кәкре тукмаклар кирәк.*
*Быел уңыш алалмасаң, килер язда тирес чәч.*
*Кешенекен кичен тапканчы иртән үзеңнекен югалт.*
*Өендә тынычсыз затлар урамда да тәшвишле.*
*Юмарт яртысын бирер, ә куркак — бөтенесен.*
*Чәчәк яратсаң, чәнечкедән курыкма.*
*Белемсез эш эшләп булмый, эшләмәсәң ашау юк.*
*Бер белем — ярты акыл.*
*Караңгыда атлаучы юлда күбрәк сөртенә.*
*Дорфа остазың булганчы, үзеңне үзең өйрәт.*
*Акылдан зур байлык юк.*
*Матурлыкны күз күрә, ә акыл җанга кирәк.*
*Ашыккан ат таш вата, лыгырдык зат баш вата.*
*Хак сөйләсәң — гөл булырсың, ялганласаң — көл булырсың.*
*Тишек колак күпне ишетә.*
*Ялганчының шаһитлары мәетләр генә була.*
*Начар аяк юлны боза, начар сүз илне боза.*
*Таягың җитмәгән төшкә йодрык белән китереп сук.*
*Кошны кош белән тоталар.*
*Катырак итеп суксаң, казык тирәнрәк керә.*
*Елмаеп сөйләгән ирдән, елаган хатыннан курык.*
*Ассаң биек дарга ас — аяк җиргә тимәсен.*
*Дөяне авыр йөк боза, ә кешене — чиксез дан.*
*Үз кимчелегеңне белсәң батыр була аласың.*
*Корган агач бөгелми.*
*Тартсаң өзмә, төртсәң аударма.*
*Тау түбәсенә менгәч тә тау итәген онытма.*
*Артык данның кадере булса — карт үгезне суймаслар иде.*
*Чәнечкесез чәчәк булмый, балда да ачы тәм бар.*
*Сакалдан алып мыекка куйма.*
*Елга ярында кое казыма.*
*Этле авылга таяк тотып кер.*
*Дошманыңны кызгансаң — дошман колы булырсың.*
*Аш савытта күренер, дус киңәштә беленер.*
*Үзең пешкән ут белән бүтәннәрне пешермә.*
*Дуслар югында дошманнар җыңә.*
*Озатучылар юлдаш булалмый.*
*Этләр уйнаган чакта бүре сарык ботарлый.*
*Дуссыз кеше — тозсыз аш.*
*Корт агачны эчтән кимерә.*

## АФЗАЛ ШАМОВКА 80 ЯШЬ

# КӨРӘШЧЕЛӘР ТОКЫМЫННАН

Совет властеның беренче елларында гражданнар сугышы кырларыннан, авыллардан һәм завод-фабрикалардан әдәбият мәйданына бер төркем яшь язучылар килеп керә. Инде танылып өлгергән әдипләр белән бергә алар татар совет әдәбиятының нигез ташларын салышалар, аның киләчәк үсешендә дә мөһим роль уйныйлар. Бу буын вәкилләре арасында без Афзал ага Шамовны да күрәбез. Барыннан да элек, аның гыйбрәтле һәм күркәм тормыш юлы игътибарны җәлеп итә.

Язучының балачагына күз ташласак, без иң әүвәл революциягә кадәрге Татар Танае авылын (хәзер Зеленодольск районында), аның җирсезлектән интеккән кешеләрен күрер идек. Шуңа күрә авылның ир-егетләре бәхет эзләп Урал якларына чыгып китә торган булганнар. Ишле гаиләне туйдыру өчен Афзалның бабасы, әтисе һәм абыйлары һөнәрчелек белән дә шөгыльләнгәннәр. Бабасы итек тегү остасы булып киткән һәм бу эшкә улларын да тарткан.

Афзалны да кечкенәдән үк эшкә өйрәтәләр. Җиде яшеннән ул апалары һәм җиңгиләре белән уракка йөри башлый, абыйлары исә аны үзләре белән җир тырмаларга йөртәләр. Бераз үсә төшкәч, ул хуҗалыктагы барлык эшләрдә катнаша башлый.

Алты яше тулгач, Афзалны укырга бирәләр. Ике ел ул мәзин өенә укырга йөри. 1914—1915 елларда Афзал күршедәге Кулабердино исемле рус авылындагы өч класслы земский школада укый, аннары Акъегет авылындагы русча-татарча мәктәпкә керә, аның татарча дүрт классын, русча өч классын тәмамлый. Бу мәктәптә аны шул чордагы күренекле педагогларның берсе Фатих Сәйфи Уфалы укыта. Заманасы өчен киң белемле булган бу укытучы Афзалга зур гына йогынты ясый, аның әдәбиятка мәхәббәтен үстерә.

Бөек Октябрь революциясен Афзал Казандагы «Касыймия» мәдрәсәсендә каршылый. Мәдрәсәне тәмамлап бетермәстән, ул кире туган ягына кайта һәм хәзерге Зеленодольск районындагы Ислам авылында укыта башлый. Җәмәгать эшләрендә дә актив катнаша. Зөя өязе укытучылары тарафыннан оештырылган драма труппасы спектакльләрендә, әдәби кичәләрдә, концертларда чыгыш ясый.

1919 елдан булачак язучы «Эш» газетасына авыл хәбәрчесе сыйфатында язышa башлый. Шул ук елда Казан хәрби хуҗалык курсларына укырга керә, әмма аларны тәмамлый алмый: берничә айдан аны курсантлар бригадасы составында фронтка җибәрәләр. Башта акполяклар белән көрәш фронтына эләгәләр, аннары Врангельгә каршы сугышка җибәреләләр. Врангель гаскәрләре Кара диңгезгә себереп түгелгәч, кызылармияче Шамов 1921 елның мартына кадәр Махно бандасына каршы сугышларда катнаша. Армиядән кайткач, 1922 елның сентябрендә Казан дәүләт университеты рабфагына кереп, аны 1925 елда тәмамлый. Шул ук елларда Казанның Тукай исемендәге балалар йортында клуб мөдире булып эшли, зурлар мәктәбендә укыта. Ул Казанның әдәби тормышында да актив катнаша. 1926—30 елларда А. Шамов Беренче Мәскәү университетының әдәбият һәм сәнгать факультетында укый. Казанга кайткач, 1931—1932 елларда татар совет язучылары оешмасының секретаре булып эшли. 1939 елда Татарстан Язучылар союзы идарәсе члены итеп сайлана.

А. Шамов Бөек Ватан сугышында катнаша. Сугышчан батырлыклары өчен Кызыл Йолдыз ордены һәм медальләр белән бүләкләнә.

Сугыштан соң, ул «Совет әдәбияты» журналының җаваплы редакторы, Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе вазифаларын башкара.

А. Шамовның әдәби эшчәнлеге 1919 елдан башлана. Башта ул үзен шигырьдә сынап карый, шуннан соң прозага мөрәҗәгать итә. Ул бер-бер артлы «Очрашу» һәм «Кызыл корбан» дигән хикәяләр яза. Алар «Эш» газетасында басылып чыгалар. 1925 елда исә аның «175 номерлы паровоз», ә 1927 елда «Дулкыннар арасында» дигән хикәя җыентыклары дөнья күрә. Давыллы чорның кызыклы күренешләренә багышланган бу хикәяләр әле әдәби яктан шактый йомшак булалар.

А. Шамовны язучы итеп таныткан һәм әдбиятның олы юлына чыгарган беренче әсәре — «Рәүфә» повесте (1926). Күп кенә яшь әдипләр төрле «изм»нар белән мавыккан вакытта бу әсәр аның авторының баштан ук үз иҗатында реалистик тасвирга турылыклы булуын күрсәтте.

Менә үз эченәрәк бикләнеп яши торган гадәти татар авылы. Яз җитә. Крестьян халкын ел саен кабатлана торган борчулар баса: «Әнә авыл башына тимерче алачыгы янына бер төркем халык җыелган. Аларның кайберләре төзәтергә китерелгән шинсыз көпчәкләр, ватык сабаннар өстенә утырганнар, ә кайберләре, тула оеклы, чабаталы аякларын җыйнак кына бөкләп, алачык буена чүгәләгәннәр,— бик тәмләп, ләззәтен белеп, тәмәке тарталар һәм ашыкмый гына сөйләшәләр. Алар тау башыннан җемелдәп күренгән уҗымнар турында, озакламый башланачак сабан чәчүе турында, гомумән, ничек итеп тормыш алып бару турында сөйләшәләр».

Яшь егетләр өчен исә яз — кыз чыгару, ягъни өйләнү вакыты. Яз көне өйләнүнең, мәхәббәттән тыш, крестьян егете өчен материаль сәбәпләре дә бар. Бердән, кыш буе келәшне икмәк ашатып чыгарасы түгел, икенчедән, ул җәйгә эш кулы була. Бу язда шундый ук сәбәпләр белән авылның беренче бае Шәмгун картның Сафасы да ярлы Мифтах кызы Рәүфәне хатынлыкка ала.

Менә шулай автор укучыны әкренләп әсәрнең төп вакыйгаларына алып килә. Рәүфәнең Шәмгун карт йортындагы тормышы күз алдына баса. Ул күп яктан Г. Ибраһимовның «Татар хатыны нинди күрми» романы героинясы Гөлбануның Шибай карт семьясындагы тормышын хәтерләтә. Сюжет үсеше буенча да бу әсәрләр бер-берсенә шактый охшаганнар. Шәмгун карт икенче мәртәбә өйләнүче улына болай ди: «Бу юлы туйлап-нитеп тормабыз. Үзеңнең күңелең төшкәнне шунда авылдан гына чыгар да кил. Бары тик сүз тыңлый торган, эшли торган гына булсын...» Сафа да әтисенә бары хуҗалыкта эш кешесе кирәк булганга гына өйләнүен әйтә.

Шушындый ук шартларга эләккән Гөлбану кебек, Рәүфәгә дә ир йортында иң авыры — рухи газап. Явызлыгы чамадан ашкан Мәликә карчык, Ибраһимовның Сабирасы шикелле үк, киленнең җелегенә үтә. Әнисенә карап, Сафа да хатынына бик тиз карашын үзгәртә, аны төрлечә кыерсыта башлый.

Шушы моментка кадәр Рәүфәнең хәлен Гөлбануныкыннан аерып карап булмый. Ир йортында бераз шулай газап чигеп торгач, ике героиня да бүтән болай яшәп булмасын аңлыйлар. Аларның моннан соңгы язмышы исә әсәрләрдә конкрет социаль шартлар белән бәйле рәвештә төрлечә хәл ителә. Г. Ибраһимов романында героиня капиталистик тәртипләр корбанына әверелә: әлеге газаплы тормыштан котылу юлын Гөлбану бары үлемдә генә күрә һәм елгага ташлана.

А. Шамов повестенда исә Рәүфәгә Совет власте ярдәмгә килә. Һәм аның рухи уянуына, политик аңы үсүгә сәбәпче була. Дөрес, героиня рухындагы һәм дөньяга карашларындагы мондый үзгәреш тиз генә һәм җиңел генә барлыкка килми. Автор вакыйгаларны ашыктырмый, тормыш дөреслегенә турылыклы булып кала. Танышбелешләре ир йортында бик тә интегеп яшәве турында авыл советына барып әйтергә киңәш биргәч тә, Рәүфә әле мондый адым ясаудан курка: «Бераз чыдыйм әле...— ди,— Өлешеңә чыккан кәмешең, диләр ич. Урланып-фәлән ителеп килгән булсам, бер хәер иде. Үзем теләп, үзем чыгып килдем бит. Ничек барып әйтергә кирәк. Оят».

Күренә ки, монда әле иске гореф-гадәтләр, язмышка буйсынучанлык героиняга хәлиткеч адым ясарга ирек бирмиләр. Бары Сафа өйдән куып чыгаргач кына, Рәүфә баштагы икеләнү-шикләнүләрен җиңә. Аңарда горурлык хисе уяна. Хәзер аның өчен иң әһәмиятлесе — үзеңнең намуслы исемеңне саклап калу.

А. Шамовның бу повестенда 20 нче еллар башы авылының реалистик күренешләре, аның тормышына социалистик тәртипләрнең үтеп керә башлавы һәм аларның беренче чиратта татар хатын-кызын иҗтимагый рухи коллыктан азат итүе, гражданлык хисләрен уятуы зур ышандыру көче белән гәүдәләнә.

«Рәүфә»дә А. Шамов иҗатының бер сыйфаты ачык чагылды. Ул чынбарлыкны һәм геройларны җирдән торып сурәтләүдән, детальләрнең капшап карар дәрәҗәдә конкрет бирелүеннән гыйбарәт. Шул сыйфаты белән А. Шамов иҗаты 20 нче елларда әдәбиятка килгән күп кенә яшь прозаиклар әсәрләреннән шактый аерыла иде. Мәгълүм ки, бу чорда прозада революция утында туып килүче яңа чынбарлыкны һәм геройларны абстракт рәвештәрәк тасвирлау, детальләр аныклыгына аз игътибар бирү, массачылык, гомумилек күренешләрен чагылдыру тенденциясе үзен шактый сиздерде.

А. Шамовның конкрет һәм дәлилле тасвирга омтылуы «Рәүфә»дән соң чыккан «Днепр буенда» повестенда (1927) гражданнар сугышы геройларының тулы канлы образларын тудыруында чагыла. Әсәрнең тормыш җирлеге дә игътибарга лаеклы. Ул чордагы башка күп кенә әдипләрдән аермалы буларак, А. Шамов үз геройларын дәһшәтле сугыш кырында, ут эчендә түгел, бәлки тынычрак тормыш шартларында, госпитальдә күрсәтә. Анда да игътибар геройларның сугышчы сыйфатларыннан бигрәк әхлакый сыйфатларын ачуга юнәлдерелә. Үзәк персонажлар — яралы кызылармияче Хәлим белән медсестра Рахиль башлыча мәхәббәткә мөнәсәбәттә күрсәтеләләр. Бу яктан да А. Шамов повесте 20 нче еллар прозасы өчен шактый үзенчәлекле әсәр иде. Чөнки ул вакытта кайбер әсәрләрдә революцион аскетизм идеясе нык чагылды. «Днепр буенда»да заман героен күрсәтүдә мондый тенденция белән полемикага керү сизелә.

Рахиль баштарак яңа кеше идеалын тимер кебек нык ихтыярлы булуда күрә һәм андый кешеләрдә «сагыну, сагышлану, хәтта мәхәббәт тойгылары да башкалардагыга караганда кимрәк, азрак» булырга тиеш дигән карашта тора. Аның башта яраткан егете дә шундыйрак зат булган. Ул егет турында Рахиль болай ди: «...Мәхәббәт заманы түгел, диде ул миңа. Сугыш заманы, каты күңеллелек заманы хәзер, тимер кебек нык булырга кирәк, диде». Рахиль үзе дә шундый кеше булырга тырыша. Күренә ки, монда героиняга шул заманның революцион аскетизм идеясе йогынтысы сизелә. Әмма госпитальдә Хәлим белән очрашып, аны чын күңелдән ярата башлау, егетнең дә шундый ук хис белән җавап бирүе Рахильгә әлеге аскетлык карашларын җиңеп чыгарга ярдәм итә. Ул кешенең шундый дәһшәтле заманда да мәхәббәттән башка яши алмавын аңлый.

Повесть геройларыннан берсе, яралы кызылармияче Салават госпитальдә ятканда иптәшләренә болай ди:

— Революция ул үзенең яңа кешесен, әдәбен, әхлагын тудыра. Ул иске тәрбиядә үскән кешеләрне дә, үзенең казанында кайнатып, үзгәртеп чыгара. Безнең киләчәк буыннар хатын-кызларны, хатын булган өчен генә түгел, ә кеше булган, иптәш булган, бөек төзелештә бергәләп эшләгән өчен сөярләр. Билгеле, матурлык, гүзәллек мәсьәләсе арттагы планга китәчәк түгел. Аның роле булачак. Ләкин җенси мәсьәләдәге бөтен әшәкелек, түбәнлек югалачак. Аның урынын саф, матур һәм көчле мәхәббәт алачак...

Бу сүзләрдә әсәрнең төп идеясе гәүдәләнә. Автор Хәлим белән Рахильнең бербереннән яратуын шундый мәхәббәтнең ярлгысы итеп күрсәтә.

Революция тудырган яңа кеше, яңа әдәп һәм әхлак мәсьәләләре хакында сүз А. Шамовның «Бер мәхәббәт турында» повестенда (1933) дәвам ителә. Әсәрнең исеменнән үк күренгәнчә, биредә дә үзәккә мәхәббәт куела һәм образлар беренче чиратта шушы мәсьәләгә мөнәсәбәттә ачыла. Повесть битләрендә шактый ук драматик төс алган психологик коллизия туа. Бер шәһәрдән чигенгәндә әсәрнең үзәк герое Нуруллин хезмәт иткән эскадронга Рабига исемле кыз килеп кушыла. Командир кызны Нуруллин карамагына тапшыра. Егет күңелендә бик тиз мәхәббәт уты кабына. Әмма бераздан командир, кыз шпион түгелме икән дип, шикләнә башлый һәм моны ачыклау өчен аны полк штабына җибәрергә дигән карарга килә. Бу эш Нуруллинга тапшырыла. Әлеге хәбәр егеткә башына винтовка түтәсе белән суккандай тәэсир итә. Җитмәсә тагын командир Нуруллинга юлга чыгар алдыннан болай ди:

— ...Әгәр, безнең шикләнгәнне сизеп, качарга теләсә, үзең беләсең, сине әйрәтеп торасы юк.

Ачыграк әйткәндә, ул очракта егет, кызны юк итәргә тиеш. Болар барысы геройны гаять авыр хәлгә куя.

Кыз белән аерылышканнан соң Нуруллин аны онытырга, аңа булган мәхәббәтен ничек тә булса сүндерергә тырыша. Әмма бу тырышудан бер нәрсә дә чыкмый. Рабига белән госпитальдә кабат очрашкач, аның күңелендә сөю хисе яңа көч белән кабына. Автор саф мәхәббәтнең кешегә тормыштагы теләсә нинди кыенлыкларны җиңеп чыгарга булыша, яшәү омтылышын арттыра торган рухи һәм илһам чыганагы булуын ачуга игътибар бирә.

А. Шамовның «Рәүфә», «Днепр буенда» һәм «Бер мәхәббәт турында» повестьлары 20 нче еллар ахыры һәм 30 нчы еллар башы прозасында чынбарлыкны гәүдәләндерү юлында кызыклы адымнар булып тора. Яңа җәмгыять төзүдә актив катнашучы герой шәхесе белән якыннан кызыксыну, аның интим тормышын һәм уй-хисләрен калку итеп, халыкчан тел белән тасвирлау яшь язучы иҗатында реализмның ныгуы турында сөйли. Шул ук вакытта бу әсәрләр әлеге чор прозасында яңа кеше формалашу процессын реалистик планда сурәтләүгә омтылышның көчәя баруын күрсәтүче фактлар иде.

Бу повестьларны язу белән бергә, А. Шамов хикәя өлкәсендә дә эшен дәвам итә. Соңга таба әлеге жанр аның иҗатында төп урынны ала. А. Шамов безнең прозада хикәяче булып таныла.

Үз хикәяләрендә язучы совет чынбарлыгының төрле-төрле мәсьәләләрен яктыртып килә. Аларда бер сыйфат аеруча күзгә ташлана. Эш шунда ки, А. Шамов бер вакытта да әллә нинди шаккатыргыч вакыйгалар яки геройлар турында сөйләми. Киресенчә, ул үз игътибарын тормыштагы артык күзгә ташланмый торган гадәти хәлләргә һәм шәхесләргә юнәлтә. Әмма шулар нигезендә зур мәсьәләләр һәм фикерләр чагылдыра. 20 нче еллар ахырында язылган «Шпана» һәм «Налог» хикәяләрендә, мәсәлән, шул чорда кешеләрнең дөньяга карашлары үзгәрүе, аларда социалистик аңның җиңеп чыгуы үтемле детальләр ярдәмендә гәүдәләндерелә.

Соңга таба, 30—40 нчы елларда дөнья күргән хикәяләрендә А. Шамов күбрәк әхлак мәсьәләләре белән кызыксына. Авторның стилендә дә үзгәрешләр барлыкка килә. Хәзер аның хикәяләве эзлеклерәк төс ала, ул уйланыбрак яза, образны тулырак гәүдәләндерергә омтыла.

Мисал өчен, «Ана» (1933) һәм «Госпитальдә» (1938) хикәяләрендә А. Шамов аналар һәм балалар мәсьәләләрен яктырта. «Ана»да баланың ана күңелен соңга калып аңлавы, шуның өчен үкенүе сурәтләнә. «Госпитальдә» хикәясендә исә үз баласын ярату белән бергә, ананың ил язмышы өчен дә борчылуы олы җанлы кеше булуын ачуга басым ясала. Госпитальдә авыр яралы кызылармеец Саттаров ята. Сугыш кырында ул курку белмәс батыр булган. Ә менә хәзер, госпитальдә, Саттаров үзен гаҗәп чыдам һәм зур ихтыярлы егет итеп күрсәтә. Әмма ул бер нәрсәдән — үзенең аяксыз калуы турында әнисе белүдән курка. Ана күңелен җәрәхәтлисе килми аның. Менә ана госпитальгә улын күрергә килә. Әмма егет юкка гына курыккан икән. Аның белән булган хәлне ана инде ишеткән. Бу хакта белү бик авыр булган аңа, әмма улының ил азатлыгы өчен көрәштә зур батырлык күрсәтеп яралануын белү, шуны аңлау ана күңелендә горурлык хисе тудырган.

«Госпитальдә» хикәясе белән А. Шамов иҗатына Бөек Ватан сугышы темасы килеп керә. Аны яктыртуга авторның шактый үзенчәлекле килүе күренә. А. Шамов турыдан-туры сугыш күренешләрен яки геройларның сугыш кырындагы батырлыкларын сурәтләми. Ул шушы чор белән бәйләнгән аерым идеяләрне яктыртуга күбрәк дикъкать итә. Аның «Саубуллашу хикәясе», «Өзелгән кыллар», «Көзге чәчәкләр» һәм «Дустым кабере янында» хикәяләрендә төп лейтмотив булып явыз дошманнан үч алу идеясе үтә.

Сугыштан соң А. Шамов үз иҗатында тыныч тормыш мәсьәләләренә әйләнеп кайта. Аның бу чорда язылган иң уңышлы хикәяләреннән берсе — «Миңнур карт» (1946). Бирелә автор сугыштан соңгы авылга мөрәҗәгать итә һәм Миңнур картның

гаҗәп җанлы һәм үзенчәлекле образын тудыра. Бу образ бигрәк тә гади хезмәт кешесенең рухи дөньясын ачу ягыннан кызыклы. Миңнур карт колхоздагы бөтен хәлләр өчен борчылып яши икән. Колхоз идарәсе утырышына очраклы рәвештә, идарәдә вакытлыча каравылчы булып калганга күрә генә эләксә дә, ул «күңеленнән үзен бу утырышның тулы хокуклы катнашучысы» итеп саный һәм чыгышларны зур игътибар белән тыңлый. Кирәк вакытта туры сүз әйтергә дә курыкмый. Менә утырышта колхозчыларның караңгы тирәсе җирләре тикшерелә башлый. Шунда авылның бердәнбер миччесе Шәрифулланың ике хуҗалык тотуы йомылып кала. Яңарак кына эшли башлаган председатель Гәрәй бу хәлне белми. Идарә членнары белсәләр дә, дәшмәү ягын карыйлар. Ни өчен дисәң, мичченең һәркайсына кирәк булып куюы бар. Идарә членнары менә шушы фәлсәфәгә буйсыналар. Миңнур карт исә моның белән килешә алмый, аңа шәхси мәнфәгать түгел, дөреслек кадерлерәк. һәм ул председательгә чынын ачып сала.

Шушы вакыйгадан соң Шәрифуллада Миңнур карттан үч алу теләге туа. Моның өчен тиз арада җае да чыга. Миңнур картның өендә миче ишелеп төшә. Автор геройларның үзара мөнәсәбәтләрендәге киеренкелекне, ике арадагы конфликтта Миңнур картның җиңеп чыгуын ышандырырлык итеп ача. Бигрәк тә мич чыгарганда Шәрифулла белән Миңнур картның үз-үзен тотышлары бөтен табигый киеренкелеге белән тасвирлана. Тәптән уйлаганда Миңнур картның хаклы булуын аңласа да, Шәрифулла абзыйның «тырпаюы, мин-минлеге кочле» була һәм ул картның гафу үтенүен көтә. Мич чыгарырга ул нәкъ менә шул ният белән килә дә. Әмма теләгенә ирешә алмый, ачуыннан салынып бетә язган мичне җимереп төшерә. Икенче көнне исә иртән иртүк эш коралларын күтәреп тагын килеп җитә, Тик бу юлы инде шактый үзгәреп, Миңнур картның хаклыгын тулысынча танып килә. һәм яраткан эшен бөтен күңелен биреп башкара. Ике карт бер-берсен аңлашалар. Аларның күңелләрендә «тупас йөрәкләрне дә йомшартырлык гаҗәп бер җылылык» барлыкка килә.

Мондый гадел һәм киң күңелле өлкән кешеләр белән без А. Шамовның кайбер башка хикәяләрендә дә очрашабыз. Әйтик, «Ата күңеле»ндәге Хәйрулла абзый характеры белән Миңнур картка бик якын тора. Аларны барыннан да элек һәрвакыт гаделлеккә омтылу, кешеләрне һәр яктан да матур итеп күрергә теләү бер-берсенә якынайта. Хәйрулла абзыйча, «кеше һәр җирдә — өендә, гаиләсендә булсын, тышта, җәмәгать арасында булсын,— бары тик яхшы ягыннан гына күренергә тиеш». Бу «яхшылыкның» нигезендә исә, кешенең «тырыш хезмәте, һәр эштә гадел, тугрылыклы булуы ятарга тиеш».

Икенче төр хикәяләрендә А. Шамов геройларны мәхәббәткә һәм семья тормышына мөнәсәбәттә күрсәтә. Моның өчен ул тормышчан ситуацияләр һәм детальләр таба. «Хисаметдин абзый» исемле хикәядә (1957), мәсәлән, колхозның ревизия комиссиясе председателе Хисаметдин абзыйның гыйбрәтле рухи эволюциясе ачыла. Өйләнеп бераз торгач, «чамасыз ачы телле, явыз, шуның өстенә өй тирәсен карарга яратмый торган бик җыйнаксыз» кеше булып чыккан хатыныннан көч-хәл белән аерылып котылгач, ул хатын-кызларга бик шикләнеп карый башлый. Моннан соң Хисаметдин абзыйның фермада эшләүче Сәкинә исемле тырыш кызга гашыйк булуын һәм хатын-кызга карашы үзгәрүен автор самимилек белән, ышандырырлык итеп гәүдәләндерә. «Көннәрдән бер көнне» хикәясендә исә (1957) сугышта һәлак булган иренә турылыклы булып калган колхозчы хатын Фәрхинур тасвирлана. Геройняның бу сыйфаты җитди сынауларга дучар була. Сугыш елларында Әхтәме хәбәрсез югалгач, ул немецларга сатылган икән дигән хәбәр тарала. Әмма бу хәл яшь хатынның иренә ышанычын, мәхәббәтен сүрелдерә алмый. Киресенчә, ул һәрвакыт «үзен якларга, Әхтәмен якларга, аның намусын якларга, кирәк икән, аның өчен бөтен көче белән тартышырга, сугышырга» әзер тора. Бары сугыш бетеп байтак еллар үткәч кенә Әхтәмнең әсирлектә батырларча һәлак булганлыгы ачыклана. Бу хакта ишеткәч тыела алмыйча үкси-үкси елаган Фәрхинурның күз яшьләрендә «чамасыз кайгы да, ире өчен горурлану да, үзенең хаклыгын тагын бер кат тою да һәм бер нәрсә белән дә тутырырга мөмкин булмаган күңел бушлыгы да» бар иде.

А. Шамов хикәяләрендә татар хикәясенең күптәннән килә торган бер традициясе чагылыш таба. Сүз язучының гади хезмәт кешесенә үтә игътибарлы булуы, аны үзгә

бер симпатия белән тасвирлавы хакында бара. Автор шушы кешеләрнең олы күңелен һәм рухи матурлыгын калку итеп гәүдәләндерүгә басым ясый. Моның белән ул татар халкының совет власте елларындагы мөһим иҗтимагый-рухи үсешен нигезләп чагылдыра.

Татар халкының үткәне белән бүгенгесен чагыштырып карау, аның язмышындагы һәм тормышындагы тарихи үзгәрешләрне гәүдәләндерү А. Шамов очеркларының да иң мөһим сыйфатларыннан берсен һәм үзенчәлеген тәшкил итә. Болар хакында автор конкрет документаль материалга нигезләнеп фикер йөртә. Шуңа күрә аның очеркларына документаль тәгаллек хас. Менә «Ике заман — ике тормыш» исемле очерк (1957). Ул ике бүлекчәдән тора. Беренчесендә А. Шамов К. Лаврскийның 1884 елда Казанда чыккан «Татар ярлылары» диган китабының кыскача эчтәлеген сөйли. Китапта элекке Чистай өязе Егоркино волосте Кәкре Атау һәм Бикүле авыллары кешеләренең аяныч тормышы тасвирлана. Бу хезмәт белән танышкач, А. Шамовта шушы авылларның хәзерге тормышы, К. Лаврский телгә алган крестьяннарның оныклары белән танышу теләге туа. Нәтиҗәдә очеркта Кәкре Атау һәм Бикүле авылларының ике замандагы ике төрле язмышы калку булып баса.

А. Шамовның «Нефть шәһәрендә» (1954) һәм «Зөя буенда» (1955) очерклары заман чынбарлыгын җентекләп өйрәнү нәтиҗәсендә туганнар. Аларга тормышны киң колачлап һәм төрле яклап сурәтләү хас. Шунлыктан очеркларда авыл һәм шәһәр тормышының киң катлаулы панорамасы тудырыла, күп төрле мәсьәләләре күтәрелә. «Нефть шәһәрендә»дә, мәсәлән, Әлмәт шәһәренең ничек төзелүен күз алдына бастыру белән бергә, автор яңа шәһәр салганда барлыкка килә торган байтак мәсьәләләрне күтәрә, житди кимчелекләрне ача һәм җәмәгатьчелек игътибарын шуларга юнәлтә. Биредә автор тормышны битараф тәстә күзәтүче булып түгел, бәлки дөньяга хуҗаларча караучы, заман алдында үзен җаваплы сизүче гражданин рәвешендә алга баса.

Сугыштан соңгы авыл белән якыннан таныш булу А. Шамовка «Зөя буенда» очеркында Буа районы «Коммуна» колхозының илленче еллар уртасындагы тормышын төрле яклап һәм реаль барлыгы белән күз алдына бастырырга, авыл хуҗалыгы алдында торган кайбер әһәмиятле мәсьәләләрне күтәрергә мөмкинлек биргән. Очеркта авторның актив позициясе аның авыл тормышына хуҗаларча таләпчән карашында, бу чынбарлыкны бөтен дәреслеге белән күрсәтергә, үсеш кыенлыкларын ачарга омтылуында чагыла.

А. Шамов иҗатының тагын бер әһәмиятле тармагы тәрҗемәгә карый. Ул рус язучылары әсәрләрен татар телендә иң оста тәрҗемә итүчеләрнең берсе булып танылды. Аның тәрҗемәсендә татар укучысы А. Пушкинның «Капитан кызы» повесте, Л. Толстойның «Хаҗи Морат» повесте һәм «Яңадан туу» романы, Н. Гоголь хикәяләре, А. Толстойның «Ватан» исемле очерклар җыентыгы, Ф. Гладковның «Цемент» һәм «Энергия», Н. Островскийның «Корыч ничек чыныкты», А. Фадеевның «Тар-мар» романнары һ. б. белән танышты.

Язучы иҗатында, тегеләйме-болаймы, аның үз шәхесе, үз характеры чагыла диләр. Хак сүз бу. Афзал ага Шамов әсәрләрендә дә язучының аны һич картаймый торган сабыр холкын, эчке оптимизмын, кече күңеллелеген, кешелекле табигатен чамалавы кыен түгел. Аның язу стиленә, хикәяләвенә дә салмаклык, оптимистик пафос, җыйнаклык хас. Афзал аганың шушы рәвешле язылган повесть һәм хикәяләрендә туган халкыбызның милли рухы һәм характер сыйфатлары ачык гәүдәләнә.

ФЛҮН МУСИН.

# САНДУГАЧЛАР, КЫР КАЗЛАРЫ ҺӘМ КЕШЕ

„Бу хакта язу инде җитмәдеме икән?— дияр, бәлки, кайсыбер укучы.—Табигатьне саклау кирәклеге һәркемгә ачык бит. Хәзер бу сүзләрне конкрет эшләр белән ныгыту кирәк!»

Әйе, ул укучы хаклы булыр.

Әмма биредә сүз табигатьне саклау турында түгел, ә бүгенге кеше хакында, аның ничек яшәве хакында барачак.

Алайса, сандугачлар һәм кыр казларын нигә телгә алдык соң? Бу сорауга җавапны драматург Илдар Юзеев иҗатыннан эзлик. Чөнки аның бүгенге кешеләр турындагы драма әсәрләре әнә шундый исемнәр белән аталганнар: «Сандугачлар килгән безгә», «Кыр казлары артыннан».

1974 һәм 1976 елларда беренче мәртәбә Татар дәүләт драма һәм комедия театры сәхнәсендә уйналган бу әсәрләр соңрак бүтән халыклар тамашачысын да таптылар, алар турында илебез матбугатында байтак кына рецензияләр дөнья күрде. Әлеге драмалар хакында фикерләрен язып чыккан иптәшләр спектакльләр уңышының иң төп сәбәбе итеп аларда күтәрелгән мәсьәләләрнең бүгенге көн өчен гаять актуальлеген атадылар, авторның безне бик борчыган сорауларга мөрәҗәгать итүен күрсәттеләр.

Ләкин спектакль ул — автор, режиссер һәм артистлар тудырган әсәр, аларның өчесенең уртак иҗат җимеше. Ә менә спектакльгә нигез булып яткан драма әсәренең үзен генә алып карасак, без драматург Илдар Юзеевны якыннанрак һәм тулырак аңлый алмабыз микән? Моның өчен әйбәт кенә җай да чыгып тора: драматургның соңгы елларда язган әсәрләре Татарстан китап нәшриятында аерым җыентык[1] булып басылып чыкты.

И. Юзеевның соңгы елларда иҗат ителгән драмаларыннан иң уңышлысы «Сандугачлар килгән безгә» булды. Бу әсәр уңае белән инде матбугатта әйтелгән фикерләр белән килешмичә булмый: әлбәттә, драма бик үткен мәсьәлә күтәрә, тамашачыны гыйбрәтле хәлләр эченә алып керә.

Агачларны, җәнлекләрне, кош-кортларны үзенең дуслары кебек якын күреп, күбрәк алар белән аралашып һәм аларны яклап яшәгән урманчы Хәмзин больницага эләгә. Әнә шунда ул бөтенләй бүтәнчә гомер итүче кешеләр белән очраша. Алар Хәмзин өчен — тимергә әйләнә башлаган кешеләр. Алар — җан җылысы, күңел тормышы, табигатькә һәм бер-береңә кадер дигән нәрсәләрне онытып баручылар. Болай яшәүчеләрне Илдар Юзеев берничә төрле итеп күрсәтә, әсәренә төрле өлкә, тармак вәкилләрен ала. Шул юл белән тормышта әлеге күренешнең шактый киң таралганлыгына ишарә ясый.

«Тимер кеше»ләрнең берсе булып әсәрдә автоколонна җитәкчесе Зыя гәүдәләнә. Ул табигатькә, бүгенге матурлыкка китерелгән зыянны, зур югалтуларны бик тыныч кына кичерә, олы эш вакытында аларны котылгысыз дип саный. Безнең күз алдында — бер үк вакытта бер-берсенә капма-каршы, ике төрле мәгънәле ике төрле эшне үти ала торган бәндә. Төзүче һәм бер үк вакытта җимерүче дә. Ул бер матурлыкны төзи, ә икенчесен җимерә.

Ә Эварисны — үзе әйтүе буенча перспективалы яшь галимне — кызгана Хәмзин. Тар максатлар өчен генә тырышкан, кешелекнең бик кадерле рухи хакыйкатьләрен белмичә, тоймыйча яшәп инде әкренләп машинага әйләнеп баручы кешене кызгана ул.

Болар янәшәсендә тагын студент Айтуган да бар. Ул — оптимист, һәрчак көр күңелле. Ләкин нинди киләчәккә йөз тоткан көр күңеллелек бу? Айтуган безнең каршыга куелган җанлы сорау булып аңлашыла.

Әсәрнең жанры «моңсу комедия» дип билгеләнсә дә, анда бик җитди каршылыклар, капма-каршы көчләр бәрелеше хәлиткеч урын тота. Алар геройларның килешмәүчән бәхәсе төсендә чагыла.

Әсәрнең төп герое Хәмзин турында уйланганда, И. Юзеевның икенче бер сәхнә әсәрендә («Бәхетемнән узып барышлый») әйтелгән сүзләре хәтергә килә. Ул анда: «Художник һәр образында үзен дә иҗат итә, аңа җанының бер өлешен бирә», дип яза. Безнеңчә, Хәмзинда драматург күңеленең, җанының иң зур өлеше чагыла. Алай гына да түгел — бу образ авторның кешелек идеалына иң якын торган герое кебек. Бүтән барлык әсәрләрендә алга сөрелгән, расланган кешелек сыйфатлары менә шушы урманчы карт кыяфәтендә бер уртак яшәеш, табигый берлек табалар.

Хәмзин образының әсәрдә ничек ачылуын күзәтик. Иң актив кулланылган ысул,

---

[1] Илдар Юзеев. «Кыр казлары артыннан». Пьесалар, Казан, 1980 ел.

мөгаен, чагыштырудыр. Әсәрнең башланып китү өлешен генә алыйк. Зыя, Эварис һәм Айтуган үлем турында сөйләшеп утыралар. Ә Хәмзин, алардан күпкә олы кеше, бу хакта уйламый да. Киресенчә, ул аларның хәлләрен белешеп, күңелләрен күтәрергә тырышып йөри. Янсә Хәмзин белән Җамалның яратышуын һәм яшьләр — Айтуган белән Роза «мәхәббәтен» карыйк. Бу ике парны укучы (тамашачы) һичшиксез чагыштыра. Беренче парның ихлас ярату, бер-берсен кадерләү, үзара тирән аңлашу, күңелләр туры килү дип аталган матурлыкка, бәхеткә ия икәнен күрә ул. Ә яшьләрдә бу исә бик кирәкле байлыкның барлыгына әле ышанып җитеп булмый.

Драматург тормыш хәлләрен көчәйтеп бирү ысулыннан да кыю файдалана. Мәсәлән, Зыя һәм Эварис белән булган бәхәстән соң, Хәмзинның төштә тимер кеше күрүен алыйк. Ул инде тегеләр яклаган фикерләрнең бер куркыныч нәтиҗәсе булып гәүдәләнә. Сугышта ут, мәхшәр эчендә калган бер атны коткару шулай ук, искә төшерү алымы буларак, Хәмзин характерын тулыландыра төшә.

Менә шундый күп төрле алымнар ярдәмендә безнең алга бер тере кеше килеп баса. Ул әйләнә-тирә тормышка бик сизгер, игътибарлы кеше. Ул чиксез ярату һәм көчле нәфрәт хисенә, тирән хәтергә һәм дулкынланырлык моңга ия. Ул эчтән, бөтен барлыгы белән әрни ала, шатлыгын һәм сагышын җырга сала белә. Кыскасы, ул — матур кеше, аның тышкы һәм эчке дөньясы аерылгысыз бер бөтен.

«Кыр казлары артыннан» драмасында автор күзаллаган уңай герой образы тагын да тулырак ачыла. Яңа тормыш күренешләре, яңа мөнәсәбәтләр аңа — ул геройга икенчерәк сыйфатлар да өсти бара.

Әсәрнең төп каршылыгы археолог Халик белән аның туганы Малик арасында. Биредә дә без Илдар Юзеев драматургиясенә хас булган шактый кискен каршы кую белән очрашабыз. Игътибар итик: ике туганның берсе үз эшенә фанатикларча бирелгән, зур максатлар белән янып яши, ә икенчесе, тап-таза булуына карамастан, каравылда гына тора, читтә, төшемле эшләрдә эшләп акча көри, берсе киң күңелле кеше, кешедән, халыктан үзенең бер нәрсәсен дә җәлләми, ә икенчесе тиенен хәтле санап тота, үтә саран... Күзгә бәрелеп торган, чик дәрәҗәдә диярлек кискенләштерелгән мондый каршылык авторга нигә кирәк соң?

Илдар Юзеев драматургиясенең иң төп идеясе, иң көчле пафосы — кешене тормыш ваклыкларыннан азат булган югары яшәешкә өндәү, шагыйрьләрчә дәртләнеп, мавыгып шунда чакыру. Ул бөтен йөрәге белән әнә шундый яшәүне мактый, матур күңел канатында биеккә күтәрелүнең җир кешесе өчен нинди бәхет, никадәр ләззәт икәнен илһамланып тасвирлый, аңлата.

Биредә дә уңай образны ача башлауга ул тискәре герой — Маликның тормышын күрсәтүдән тотына. Малик өчен мал җыю бердәнбер максатка әйләнеп калган. Шуңа күрә өкренләп кешелердән аерыла, аның юлы торган саен тарая, караңгылана. Драмада моны иң ачык итеп Маликның хатыны Ясминә әйтеп бирә: «Әйе, мин әйбер... Синеңчә, затлы әйбер... Малик, син оныттың, кайчандыр минем тыпырчынып торган кайнар җаным бар иде!.. Син мине суыткыч шикелле бер әйбергә әйләндердең».

Менә шушындый сүзләрдән соң инде безгә Ясминәнең җыры да ныграк аңлашыла:

> **Кыр казлары артыннан**
> **Биеклеккә тартылам,**
> **Хыялыма китәр идем**
> **Кыр казлары артыннан...**

Бу җыр сандугач һәм кыр казлары образларының да серен ачып җибәрә. Алар икесе дә — безне, кешеләрне биеккәрәк чакыручылар! Күңелләрне, йөрәкләрне шунда таба дәшүчеләр!

Китаптагы өченче сәхнә әсәре — «Бәхетемнән узып барышлый» дип исемләнгән поэтик драма. Алдагы ике пьесада нигез итеп алынган тормыш каршылыгы бусында икенчерәк яссылыкта тасвирлана. Беренче әсәрдә күрсәтелгән Хәмзин һәм «Кыр казлары артыннан»дагы археолог Халик образлары инде биредә югары күңел яшәешенә ирешкән кеше, рәссам Айтуар образына килеп ялгана. Алар өчесе дә бер үк холык, бер характерның төрле өлкәдәге, мохиттагы яшәеше кебек. Ә тирәнгәрәк карасак, бу — мөгаен, авторның үз күңел чынбарлыгыдыр, шуның төрлечә чагылуыдыр, төрле яклары белән ачылып-ачылып китүедер...

Уңай герой үсешнең, күңел тормышының биегрәк дәрәҗәсенә күтәрелгән саен, аңа очраган каршылыклар да үзгәрә бара. Башта карап үтелгән ике әсәрдә уңай типка каршы геройлар Зыя, Малик кебек кешеләр булса, «Бәхетемнән узып барышлый»да инде каршы көч тә бүтәнрәк. Ул биредә яшь кыз Асия булып гәүдәләнә.

Асия тулы, матур тормыш белән яшәргә тели. Ләкин аның әлеге матурлыкны аңлавы шактый чикле. Асия матур, рәхәт яшәүне — иркенләп, байлык белән гомер итү диебрәк күзаллый. Айтуар белән торганда әнә шул тышкы җитешлек күренмәү аны куркыта, ул гомер әрәм үтәр дип курка. Яшь иҗатчы Айтуарны тормышның зур сынавы менә шушындый гүзәллек сынында көтеп тора.

«Кайтмый калсам котәрсеңме?» — Илдар Юзеевның замандашыбыз тормышыннан алып язылган икенче бер сәхнә әсәре шулай атала. Жанр ягыннан ул «моңсу комедия» дип билгеләнгән. Әмма бу әсәрдә дә алда без карап үткән пьесалар белән уртак яклар шактый.

Әсәрнең үзәгендә торган мәсьәлә — кешенең ничек яшәве хакында уйлану — бүтән пьесаларда күтәрелгән фикерләрнең табигый дәвамы булып яңгырый. Авторның геройлары исә бу юлы мебель фабрикасы эшчеләре, алдагыларына караганда гадирәк эш кешеләре. Бәйрәм — шуларның берсе — әсәргә төп герой итеп алынган.

Нәрсә борчый соң Бәйрәмне? Аның күңелендә безнең өчен кадерле нинди уй-фикерләр бар?

Юк, киресенчә, башта берни дә борчымый, уйландырмый Бәйрәмне. Ул бернәрсәгә исе китмичә, ничек туры килә шулай үткәрә бирә көннәрен. Әмма көтмәгәндә тормыш аңа һич уйламаган аяусыз хакыйкатьне ачып сала: Бәйрәм үз танышларыннан беркем өчен дә кадерле, кирәкле түгел икән бит! Хәтта — гаиләсе өчен дә! Менә шушы хәл бик нык уйландыра Бәйрәмне.

Гомер, аның ничек, ни рәвешле үтүе хакында борчыла башлавы — Бәйрәмнең яңадан тууы сыман. Хәер, мондый зур үзгәрешне ул үзе дә сизә: «Ул әле туып кына килә... Ул туар... валлаһи, туар — ди Бәйрәм үзе хакында — аның җан сөйгәне, дус ишләре генә түгел, дошманнары да булыр, һай күп булыр! Аны көннәрдән бер көнне соңгы юлга озатырлар... Озатып кайткач, йөрәкләрендә бушлык сизеп, тирән сагынуга түзә алмыйча, үксеп-үксеп еларлар. Инде кире капкасына ышангач, бөтен өметләр өзелгәч тә көтәрләр әле. Сугышта һәлак булган солдатны көткән кебек.. Сугыштан кайтып, үзе үстергән арышлар арасында үлгән агрономны көткән кебек...»

Күрәсезме, тормышка карата нинди зур өметләр уяна кешедә! Кеше гомере әнә ничек матур, мәгънәле була ала икән!

Күңел күзе ачылганнан соң Бәйрәмгә килгән бу уйлар безнең барыбыз өчен дә кадерле. Бәйрәм образы, һичшиксез, драматургның зур уңышы.

...Шагыйрь-драматург Илдар Юзеевның дүрт әсәрен кыскача күздән кичердек. Гаптади кешеләр тормышында барган олы драмалар белән очраштык, аларның тирән кичерешләренә, борчылу-уйлануларына тап булдык. Ә иң әһәмиятлесе — без бу әсәрләрдә һәрчак югарыга, биеккә талпынып яшәгән шагыйрь йөрәге белән очраштык. Үзе әйтмешли геройларына бүлеп бирелгән аның олы җанын тойдык.

Инде бу әсәрне укыганда туган кайбер теләкләргә тукталыйк. Аларның күбесе очраклылык мәсьәләсе белән бәйләнгән. Мәсәлән, «Кыр казлары артыннан»да борынгы заманнардан калган бик мөһим табылдык — көмеш битлекнең икесе дә пьеса герое Халикка очрый. «Бәхетемнән узып барышлый»да рәссам Айтуар сугыш батыры Әнвәр Садыйковның рәсемен карарга йөри, ә ул Асиянең әнисе Нәгыймә апаның яшьли сөйгән яры булып чыга. «Сандугачлар килгән безгә»дә Хәмзин больницага кергәч урмандагы ике пошиның берсен аталар, ә икенчесе шәһәргә килә. Шулай ук сугыш ветераны Гаффанның да безнең көннәрдә нәрсәгәдер бик борчылганда: «Тукта, чигенмә, атам!» диюе дә (бер үк әсәрдә бу хәл ике мәртәбә кабатлана) чынбарлык таләпләреннән чыгып караганда шактый ышандырмый кебек.

Ләкин, икенче яктан, югарыда без күздән кичергән әсәрләрнең романтик рухта язылганлыкларын искә төшерсәк — бу очраклылыклар берникадәр аклана да сыман.

«Бәхетемнән узып барышлый» поэтик драмасында Айтуарның апасы Камилә белән җизнәсе Нурминың әллә кайдан ук күзгә ташлана торган бүгенге мещаннар булуын да әнә шул романтик рух белән генә акларга тырышырга мөмкин.

Теләкләрнең икенче бер төрлесе рәвешендә тагын шунысын да әйтеп үтик: әсәрләрнең кайбер персонажлары телендә еш кына «Сез студент?!» тибындагы сораулар күренеп китә. Белгәнебезчә, бу табигый яңгырамый, Илдар Юзеев геройлары сөйләменә ятышып бетми.

Мәкаләбезне сандугачлардан, кыр казларыннан башлаган идек. Аларны онытып әкренләп кешеләргә күчтек түгелме?

Юк, безнең уйлавыбызча, ул сандугачлар һәм кыр казлары Хәмзин, Халик, Айтуар кебек кешеләрнең һәрчак күңел түрендә яши. Алар кеше җанын табигать белән тоташтыручы, шул юл аша аңа гел яңа матурлык өстәп торучы символик мәгънәгә ия.

Шуңа күрә, бу кошларның исемен атау белән, аларны бик яратып, үз күреп яшәгән авыл кешесе күз алдына килә. Йомшак табигатьле, матур җанлы, нечкә күңелле авыл кешесе. Ул тормышка да, табигатькә дә бик сизгер, игътибарлы. Аның кеше буларак бөтен олылыгы да әнә шуннан башлана... Табигыйлектән, киң һәм тирән күңелгә ия булудан, кешелек матурлыгыннан...

Илдар Юзеевның сәхнә әсәрләрен укыгач безнең күңелдә әнә шундый образ яшәп кала.

**МАНСУР ВӘЛИЕВ.**

# СЕБЕР КИҢЛЕГЕННӘН

Һәр чагыштыру камил булмый, диләр. Шулай да миңа шагыйрьләр җимеш агачлары шикелле булып тоела. Берәүләре, үз җирлегендә яшьли утыртылганнары, әйбәт кенә тамырланып китә. Карап-кадерләп торсаң, берничә елдан чәчәк атып, җимеш тә бирә. Тиешле игътибар җитмәгәннәре чүп үләннәре белән тартыша-тартыша үсә. Тамыры көчле булганнары кайчан да булса барыбер чәчәккә бөреләнеп, җимеш бирә. Мондыйларның җимешләре ачырак, кыргыйрак була-булуын, мәгәр ачы яратучылар да бар бит әле дөньяда. Кайвакыт ачы да кирәк...

Булат Сөләйманов тәгаен гына бу ике төрнең берсенә дә керми шикелле. Ул безнең шигърият бакчасына ерак тайга урманнарыннан, Себер татарлары арасыннан килде, әлегәчә үзенә шигърият аша гына якын булган Татарстан туфрагына аяк басты.

Аңа игътибар җитмәде дип әйтеп булмый. Студент елларында ук абруйлы шагыйрьләрнең аны үз күрүләре, язганнары белән даими кызыксынып торулары барыбызга да мәгълүм. Тиз аралашучан, ачык күңелле Себер егете татар совет поэзиясенең кайгыртучан бакчачылары Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Нури Арсланов кебек остазлар күңеленә юлны тиз тапты. Шулай да шигърияттә тиз тамырланды дип әйтеп булмый Булатны. Озак, әмма Себер кешеләренә хас үҗәтлек белән, ныклык белән тамырланды ул. Һәм, ниһаять, теле, сөйләшүе, мәзәкчел холкы-фигыле белән башкаларны һәрвакыт диярлек елмаерга мәҗбүр иткән «Себер алмагачы» безнең җирлектә өлгергән беренче җимешләрен бирде. Аның Татарстан китап нәшриятында «Таңнар фонтаны» исемле шигырьләр җыентыгы басылып чыкты [1].

Әлегәчә без татымаган үзгә җимешләр болар.

**Бөтен Себер буйлап,**
**Орлык кебек,**
**Татар авыллары сибелгән.**
**Гасырларның**
**Изге туфрагына**
**Тамырлары**
**Тирән күмелгән.**

«Шулар арасында минем Сопра да бар»,— дип, җыентыктагы беренче шигыреннән үк үзенең чыгышы турында уйлана шагыйрь, халык рухының, гадәт-традицияләренең ныклыгын, аның тамырлары тирәндә булуын әйтә. Шигырьдә лирик геройның шул халык улы булуы белән горурлануы хисләре сизелеп тора. Ерак Себердәге туган авылын сагыну хисе зурая барып, башка халыкларны, уртак Ватанны, Җирне ярату яңгырашын ала.

Шигырьдән-шигырьгә без лирик геройның эч серләрен тирәнрәк аңлыйбыз, образ тулылана бара, яхшы күңелле кешегә хас сагына-сагышлана белүе, кимчелек-йомшаклыклары, риясызлыгы белән үзен яраттыра бара ул. Тиздән без аңа карата теләктәшлек хисе тоя башлыйбыз, лирик геройның уй-хисләре, теләк-омтылышлары безнеке дә булып әверелә. Без дә «саф нарат исләре тулы бүлмәдән уйларыбызга ияреп чыгабыз», безнең дә «күкрәк читлегебезне Иртыш дулкыннары кага» кебек. «Тоболга сугылмый үтелсә, үзебезгә-үзебез ят булырбыз сыман».

**Әйтмәгез Себерем хакында —**
**«Үткәндә каргалган җир булган».**
**Каргалса каргалсын, аңлагыз,**
**Ул минем туган җир, и туган!**

Әйе, кайчандыр Хаклыкны яклап күтәрелгәннәрне патша шунда сөргән. Шунда декабристларның кабере сибелеп калган. Даһи Ленин һәм аның шәкертләре сөргендә интеккән урыннар бу. Әйе, кеше әти-әнисен үзе сайламаган кебек туган җирен дә сайлап алалмый. Ул аны нинди булса, шул көенчә ярата һәм үзе күрергә теләгәнчә матурлый гына ала. Булат Сөләйманов безгә Себернең бүгенге матурлыгын, кешеләрнең күңел байлыгы аркылы, буыннан-буынга изге итеп сакланган гореф-гадәтләре аша күрсәтеп бирә.

Әнә, заманында кыңгырау кагып, шаман булып йөргән Юван бабай. Ул уйга талып, Обьтагы ташуны күзәтә. Бозлар белән бергә кышны куып, баржалар килә, Себерне аякка бастыру өчен илнең төрле почмакларыннан ярдәм килә. «Самотлорга бар да кирәк...» Мәңге туң катламнар астында байлык-хәзинә яшерелгән. Анда — нефть. Әнә «тырнагын кыяга батырган кара кош шикелле беренче буровой». Ничә йөз елларның күз яше тамган, каргалган мәңге туң шул җирләрне яңартырга чакыра шагыйрь, «нигез ташы итеп, шунда өметне, бәхетне, шатлыкны бораулап салырга» чакыра. Бу — коры теләк, буш хыял гына түгел, чөнки «салкыннан җир ярылганда да, үкереп тимерләр сынганда да салкынны эченә йотып, эретеп чыгарырлык чын ирләр» эшли биредә.

Күргәнебезчә, Б. Сөләйманов образларны, бизәкләрне Себер пейзажларыннан эзли, шулар аша урынчалыклы колоритка ирешә.

**Бозлар белән капланса да,**
**Обь сулары барыбер ага.**
**Факелларда таң шикелле**
**Тынлык яна, тынлык яна —**
**Күктә яра.**

**(«Түбән Варта» шигыре).**

[1] Булат Сөләйманов. Таңнар фонтаны. Казан. Татарстан китап нәшрияты, 1980 ел.

Саран гына буяулар белән тасвирланган шушы индустриаль пейзажда без салкын Себернең кайнар йөрәк тибешен сизәбез.

Аның лирик героеның мәхәббәт хисләре дә Себер табигатенең шашкын дулаулары, яшенле яңгырлары, кар-бураннары арасында сынала.

Хәлбуки, «хыянәт учагында канатлары көйгән хисләр, саф мәхәббәт көткәндә яшьлекләрен җилгә урлаткан каеннар, сүгенеп йөргән җилләр» бездә авторга карата канәгатьсезлек тойгысыннан башка нәрсә уята алмый. Башкалар бик күп язды инде боларны. Самотлорның «Себернең йөзек кашы» булуын, «Эйфель башнясыдай, саздан буровойлар үсеп чыгуын», буровойдан кайтып килүче егетнең «аккош йоны кебек йомшак карга ятып, карашын күккә атып», марсианнар турында уйлануын да поэтик яңалык дип булмый, әлбәттә.

> **Поезд чаба килер көнгә —**
> **Давыллардан, җилдән көчле.**
> **Рельслар чаба, рельслар**
> **Җирнең**
> **Билен буган каеш төсле,—**

бу юлларны укыганда Хәсән Туфанның:

> **Кыңгыр яткан Урал**
> **Челем тарта,**
> **Челем сабы — озын таш торба;**
> **Билгә кат-кат рельсе билбау урап,**
> **Күпер белән муенын каптырган,**

кебек мәгълүм строфасы искә төшә. Әйе, шигъри табышың булмаганда, тема зурлыгы да, авторның изге нияте дә тезмәләрне чын сәнгать әсәре итә алмый.

Булат Сөләйманов эзләнә, форма төрлелегенә омтыла. Аның бу сыйфаты аеруча соңгы елларда, Мәскәүдәге М. Горький исемендәге әдәбият институтында укыганда көчәйде. Бу елларда яшь шагыйрьнең иҗат офыгы киңәя, карашы үткенәя, шигъри дөньясы байый төште, сүзе җитдиләнде.

Җитдиләнде дигәннән, артык җитдиләнеп тә китмәдеме икән әле? Казанга килгән беренче елларында аның шигырьләрендә тыенкы гына юмор хисе дә бар иде. Салехардка баргач, ак төннәр вакыты булганлыктан кичке намазын укый алмый тилмергән бабай турындагы шигыре шул вакытта язылды. А. П. Чехов юморны «тормышның давыллы океанында коткару түгәрәге» дип атаган. Безнең халыкка, безнең шигъриятькә гомумән дә җылы юмор хас. Булатка да шаян холкын, уен-көлке яратуын шигырьләреннән һәм укучыларыннан яшермәскә, кызганмаска иде.

Китапка кереш сүзендә өлкән шагыйрь Сибгат ага Хәким билгеләп үткәнчә, «шагыйрьнең биографиясе зур булса, җирлеге нык булса, ул техник кимчелекләреннән арынachак». Ә Булат шигырьләренең биографиясе чыннан да зур. Яшь шагыйрь киң илебезнең төрле якларында төрле шәһәрләрендә төрле эшләрдә — йөк ташучы, маляр, бетончы, балта остасы, нефтьче-оператор булып эшләде, поэзиягә бай тормыш тәҗрибәсе туплап, тормышның үзеннән килде. Җирлеге дә нык аның. Әдәбиятыбызга Хәмит Ярмине, Хәернисә Сафинаны, Фатих Урманчеевларны биргән Себер киңлекләре хәзер илебезнең матди куәтен арттыру гына түгел, гомумсовет әдәбияты һәм сәнгатенә яңа рухи хәзинәләр өстәү ягыннан да гаять әһәмиятле җирлек. Булат Сөләймановның югары белем алгач Себергә, яңадан үз җирлегенә кайтуы аның киләчәктәге иҗатына уңай йогынты ясар дип өметләнергә тулы нигез бирә.

**ШАМИЛ МАННАПОВ.**

## ЯШЬ ТӘНКЫЙТЬЧЕ СҮЗ АЛА

# ЧИШМӘЛӘР КАЙДАН БАШЛАНА?

Елгалар да бер генә төрле булмый. Тау-таш арасыннан шаулап-ярсып, тирә-якны күкрәтеп агучылары бар. Икенчеләре исә тигез үзәннәрдән талгын гына, тыныч кына үтеп, үзенең суын диңгезгә илтә. Язучы Ләбибә Ихсанованың «Наил һәм Фаил» повестен[1] укыгач, безнең күңел түрендә нәкъ шул елгалар сыман төрле язмышлы геройлар яши башлый. Әлеге геройларга икенче яшәеш биргән сәбәп-чыганакларны аңларга тырышып карыйк әле.

Повестьны укый башлауга ук, укучы аның гадәти генә сюжетка корылган булуына игътибар итәр. Ике классташ — Наил белән Фаил — икесе ике полюста: Наил, яхшы йөк аты кебек, ничек таләп итәлсә, шулай яши белә. Фаилгә исә, тау елгасы шикелле бәйсез, шаулап тормыш итү якынрак. Шуңа күрә Фаилнең һәр хәрәкәте, фикере ул яшәгән тирәлектә генә түгел, укучыда да бәхәсләр кузгата. Ләкин ул үз сукмагына, диңгезенә омтылуы белән кечле.

Автор ике героена да бертигез дәрәҗәдә игътибар итеп, аларның характерлары, хәрәкәтләре төрле булуын исбат итә башлар кебек. Күнегелгән юл әнә шундый. Әмма ул очракта шаблонга гына корылган сюжет булып, повесть геройлары да аерым мисал, факт дәрәҗәсендә генә калыр иде. Язучы өзер хакыйкатьне исбатлау юлына басмаган.

Китапның төп «хуҗалары» белән якынынрак танышыйк. Отличник Наил шахмат уйнарга ярата, шәһәр ярышларында беренчелекне алган, «бишле»гә генә укучы Сәвия белән дуслаша. Фаил исә капма-каршы булган бик күп сыйфатларга ия. Укырга хирыслыгы булмаса да, класстагы егерме кызны Наил кебек юаш малайлар белән бергә бәйләп сапырлык гайрәте бар. Әтисе аңа күптән кул селтәргә тора: «Буй дисәң, буе җитәрлек үзендә, беләк дисәң, беләк бар. Ә баш юк. Акыл юк. Буй үстергәнче, акыл үстерсен икән ул бала»,— ди. Кечкенә герой үзе хакында нинди фикердә соң?

— Мин урамны гына яратам. Анда пыяла банкадагы кебек гел бер төрле тормыш түгел, гел үзгәреп тора, кызык. Урамдагы эшләр дә, кешеләр дә дус миңа. Мәктәптәге, өйдәге кебек акыл өйрәтеп торучы да юк анда. Киресенчә, кешеләрнең үзләренең йомышы төшә. Берәрсенә аптекадан дару алып кайтырга кирәк булса, тәрәзә ачып кына кычкыра — очып барып кайтам...

Аның дус-ишләре, әти-әниләре әнә шуны өнәп бетермиләр. Урамда начар малайлар гына йөри, имеш. Әнисе дә, бәтен яктан да үрнәк малайга һәйкәл куярга уйласалар, ул нәкъ Наил сурәтендә булырга тиеш дип уйлый. Нишләп әле Фаил ул фикер белән килешергә тиеш? Унеч яшьлек үсмер төрле юллар белән үзенең мөстәкыйльлеген расларга омтыла. Бер генә мисал. Класс тактасына «Наил-Сәвия» дип язган малайны Фаил акылга утырта. Юк, ул моны Наилне кызганып түгел, зәп-зәңгәр күзле, соры толымлы Сәвияне яратудан эшли.

Малайлар бер-берсеннән шактый аерылып торсалар да, аларны беркатлылык һәм эчкерсезлек кебек табигый сыйфатлар берләштерә. Чөнки бу — аларның әкият һәм хыял дөньясыннан реаль тормышка йөз борган чагы. Тормышның катлаулы күренешләрен аңларга омтылган чаклары. Шул үзенчәлекләрдән чыгып карагандa, төп конфликт ике яшүсмер — Наил белән Фаил арасында булырга тиеш кебек. Чыннан да, ике төрле караш — ике төрле көч арасында яшәгән бу каршылык баштан ук күзгә ташлана. Конфликт билгеләнә, ләкин ул алга таба башка бер сызык буенча үстерелә башлый. Чөнки геройлар каршы-

---

[1] Ихсанова Ләбибә. Наил һәм Фаил. Повесть. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1960.

лыклы ситуацияләрдә үзләренең характерлары таләп иткәнчә хәрәкәт итмиләр.

Кирелеге белән дан казанган Фаил икегә бүленгән кебек була. Конфликтның үзәге аның үзенә генә кайтып кала. Моңа Фаил тормышында вакыйга булырлык бер хәл сәбәпче була. Тәртипсезлеге өчен класстан куып чыгарылган малай, Мактау тактасыннан Сәвиянең фотосын кубарып ала. Ул фоторәсем караклар талаган квартирага барып эләгә. Фаил тагын гаепле: шушы йортта яшәүче хатынның туганы дип белеп караккa ишек ачып бирә. Бу очракта аны кешеләргә яхшылык эшләү теләге харап итә. Менә шушы күңелсез вакыйгада Фаилнең чын йөзе ачыла да инде. Дөньяны балаларча аңласа да, күңелендә олыларга тиңләшү хыялын йөрткән малай нинди карар кабул итәр? Сәвиянең фотосын алганлыгын, каракларга ярдәм итүен таныса, хәл бик тиз ачыкланыр иде. Ләкин шук малайның җиңел генә ул юлдан атлавы укучыны ышандырып бетерерме? Автор, шул моментны исендә тотып, Фаилнең күңелендә барган көрәшне тасвирлый. Мөстәкыйльлеккә, тормышта үзен расларга омтылган үсмер үз гаебен үзе төзәтергә тиеш. Язучы әлеге көрәшне менә шул хакыйкатькә нигезләп сурәтли, кешенең иң авыр, киеренке чакларда сыналуына басым ясый. Үз карашларыңның дөресләген раслау өчен көрәшкә чакыру, чын мәгънәсендә кеше булып формалашуда ярдәм итү — әсәрнең төп бурычы — шул рәвешчә уңышлы хәл ителгән.

Бу җәһәттән повестьның тагын бер үзенчәлегенә игътибар итәргә кирәк. Язучы асылда балалар дөньясын сурәтләсә дә, ул ниндидер үзенә бер аерым «утрау» түгел. Олылар язмышына замана тавышына авазда ул дөнья. Балалыкны сурәтләү аша автор, тулаем алганда, гомумкешелек мәсьәләләрен күтәрә. Яшәү мәгънәсе изгелек, матурлык, күңел сафлыгы, каһарманлык, кебек төшенчәләрдән аерылгысыз, дип раслый язучы.

Әсәр безнең игътибарны бала күңеленең саф башлангычларына, тормышка, ата-аналарга юнәлтә. «Әти күк заводта эшлисем килә минем,— ди Фаил.— Көчем күп булыр минем, беләкләр таза. Әти цехына да эләксәмме? Аталы-уллы Шакировлар дип дан тотар идек.» Кеше матурлыкка, киләчәккә омтыла икән, димәк, аның рухына яхшылыкны тоя, күрә белү орлыклары да салынган. Ләбибә Ихсанованың яңа повесте бала күңелендәге әнә шул игелекле шытымнарны саклау, үстерү хакында уйландыра.

Әсәрнең кимчелекләре аз булганда, тәнкыйтьчеләр, гадәттә, аларны мәкаләнең ахырындарак күрсәтергә яраталар. «Наил һәм Фаил» повестенда да аерым җитешсезлекләр алгы планга чыгып тормый. Шулай да алар хакында әйтеп китү урынлы булыр.

Гади күзгә дә ташланып торган бер мисалга игътибар итик. Партта балалар Фаилне уртага бастыралар да, кулга-кул тотышып җырлап әйләнәләр.

**Безнең Фаил бигрәк тату шашлык белән,**
**Ашый аны тәмләп-тәмләп шатлык белән...**

Бу җырны төрле милләт балаларының татар телендә җырдый алуы ышандырып җиткерми. Шулай ук «Сәвия класс җитәкчесе булса, Сәвия гел мактап кына торыр иде, «әшәке» дип төртеп җибәрмәс иде» рәвешендәге авыр ,аңлашыла торган җөмләләр дә укучы өчен мәгълүм кыенлык тудыра. Әлбәттә, бу кимчелекләргә генә карап, әсәр үзенең тәрбияви әһәмиятен югалтмый. Ул безне күңел чишмәләребез башланган төбәккә алып кайта.

**ХӘКИМҖАН .ЯНОВ.**

# АГЫМ УРТАСЫНДАГЫ ЯЗМЫШЛАР

Кыска гына вакыт эчендә ике тапкыр хәлиткеч сораулар каршында, юллар чатында калырга туры килә Зөһрәгә. Беренчесе — Казанда. Мәктәпне бик яхшы билгеләргә генә тәмамлап, институтка имтиханнар тапшырырга килгәч уңышсызлыкка , очрый. Абитуриентларны үзенең җылы почмагына сыендырган бабайга гына бу бик гадәти хәл. Ел да шулай бер-ике баланы озатып кала ул. Бабай дөньяның ачысын-төчесен күп татыган, «гыйлемең булмаса да, дөньяда яшәү үзе — бинниһая рәхәт нәрсә!» дип саный. Зөһрә әле бу хакыйкатькә тора-бара гына төшенәчәк. Аның авылына кайту юлында Чаллыга тукталасы, очраклы рәвештә генә яхшы кешеләр белән очрашасы бар. Илнең төрле ягыннан зур төзелештә катнашырга килгән яшьләр аңа ярдәм кулы сузарлар, үзе өчен бөтенләй яңа тормыш, яңа язмыш башлануына сәбәпче булырлар, дип әлегә күз алдына да китерә алмый ул...

Икенче сыналу инде КамАЗда үз кешегә әйләнеп килгәндә, башкара торган хезмәтенең асылына төшенеп җиткән көннәрдә була. Файдаланылмаган мөмкинлекләрне абайлап ала Зөһрә һәм рационализаторлык тәкъдиме белән чыга. Изге ният белән — эшкә җиңеллек, илгә файда булсын дип, әлбәттә. Ләкин яңалык җиңел генә юл яра алмый, вакытлыча булса да өстәмә кыенлыклар тудыра. Нәтиҗәдә, кызның хезмәттәшләре белән мөнәсәбәтләре киеренкләшә. «Кешеләр язмышы белән шаярма син, кит безнең заводтан!» — ди аңа Мәрвия. Зөһрәгә апасы кебек илтифатлы булган, иң кыен чакларында ярдәм иткән кеше белән дә аңлаша алмау аеруча авыр. «Тоташ бәйрәмнән генә торса, бу дөнья әллә кайчан туйдырган булыр иде инде. Монда туеп өлгерергә ара юк, шатлыгы янына тупырдап кайгысы килеп баса. Гел аралашып торалар», — дип юата аны Табибә апасы...

Повестьның[1] башка геройларын да тормыш әнә шулай «сындырып» сынамакчы. Менә, мәсәлән, иң истә калырлык образларның берсе — Мәрвия. Заводның нигезеннән алып корышкан кыз. Акыллы, уңган, чибәр. һәм аның үзенчә бәхетле һәм бәхетсез көннәре бар. Яңа төзелешнең беренче мәшәкатьләреннән куркып, ир-атларның да шактые «төртәнә кирегә борган» чакта Мәрвия авырлыкларга бирешми һәм җиңеп чыга. Нечкә күңелле бу кызның зур ихтыяр көченә, кешелекле сыйфатларга ия булуы психологик яктан төгәл һәм тормышчан күренеш-ситуацияләрдә ачыла. Мәрвиянең дә, Зөһрәнең дә, Табибәнең дә, яхшы кешеләр арасында, тормышта үз юлларын дөрес таба алуларына ышанасың. Гомумән, КамАЗ төзелешендә дә «эпизодик персонажлар» булган Витя белән Клавамы исәпкә алмаганда, әсәрдә тискәре геройлар юк. Язучы җиңел юлдан — акка, карага гына аерып чыгу, гадәттән тыш вакыйгалар кору юлыннан китмәгән.

Җыентыктагы хикәяләрдә дә гади генә хәлләр, гади генә кешеләр сурәтләнә, ләкин аларның уңышы да шунда: укучыны характерлар һәм кичерешләр табигыйлеге дулкынландыра, җитди мәсьәләләр турында уйга сала. «Шикәр Гайшә» исемле кыска гына хикәя, мәсәлән, әнә шундый тәэсир көченә ия булуы белән арада аерылып тора. Әсәр безне сугыш елларына, авыр вакытларга алып китә. Шикәрне дә җан башына берәмтекләп бүлеп бирә торган чак. Кибетче булып эшләүче Гайшәнең кинәт кызы чирли башлый. Врачлар им урынына шикәр ашатырга кушалар. Шундый заманда шикәр табулары җиңелме соң! Табигатендә һичнинди яман ye булмаган ана, баласы хакына кешеләрне рәнҗетәсен дә онытып, сатып алучылар өлешеннән яртышар-берәр шакмак булса да шикәр алып кала башлый. Күршесе Гөлшатка шикәр үлчәгәндә аның нәфесе бөтенләй котыра. Бик ишле гаилә булгач, илледәр граммнан да шактый шикәр чыга боларга, тугыз-ун шакмакны гына сизмәскә дә мөмкиннәр, янәсе. Кыскасы, Гөлшатның төпчек кызы Миләүшә өлешенә тиясе тугыз шакмак шикәрне кибетче кызы суыра... Шушы рәнҗеш дистәләрчә еллар үткәч тә онытылмый, Гайшәгә җан тынычлыгы бирми. Ул үзенең үткәненнән куркып яшәргә, намус хөкеменнән калтырап гомер кичерергә мәҗбүр.

Гайшә образы — тулаем китапта ачык төсмерләнгән рух-принципны сакламау, ягъни геройны һәм аның гамәлен ак һәм карага гына бүлү түгелме соң? Ахыргача ачылып җитмәгән булса да хәләл хезмәте

[1] Сүз Кояш Тимбикованың «Агым уртасында» исемле повесте турында бара. Аның яңа җыентыгына («Шатлык белән кайгы янәшә». Казан, 1979) әлеге повестьтан тыш, берничә хикәя дә тупланган.

белән зур гаиләне туендыручыларның берсе булган Гөлшат нәфес коткысына бирелгән кибетче хатынга каршы куелган кебек. Икенче яктан, авыру кызын кызганып хаталанган бичара Гайшә еллар үткәч тә ярлыканмаган хәлдә кала... Ләкин төп хикмәт мондый тышкы каршылыкта түгел. Хикәянең тел төбендә кешеләр өчен борчылу, аларның киләчәген кайгырту ята. Шуңа күрә аның эчке мәгънәсе яшьләр өчен аеруча гыйбрәтле яңгырый. Әле алларында язылмаган кәгазь кебек ап-ак тормыш юлы булган яшьләр өчен.

Үткән гомер — калган хәтер генә түгел, ул — бүгенге көнеңнең, язмышыңның аерылгысыз бер кисәге, дип раслый автор. Ул көннәрнең берендә үз вөҗданы белән күзгә-күз калган кешеләр күңелендәге кичерешләрне тәэсирле итеп сурәтли. «Таяныч» хикәясендәге тегүче кыз Фикрия, «Авыл малае» хикәясендәге яшь укытучы Фәйрүзә, «Ут» хикәясендәге агроном Нажия... Болар — югарыда телгә алынган повесть геройлары кебек үк, тормыш сынавы алдында калган һәм җиңеп чыккан геройлар. Төрле характерлар, төрле язмышлар, әмма хәлиткеч адымдагы тәвәккәллекләре берләштерә-туганлаштыра сыман аларны. Менә шушы эчке уртаклык җыентыктагы барлык әсәрләрне идея-фикер ягыннан бер үзәккә туплый, аның композицион бөтенлеген күрсәтеп тора. Язучы кешелеклелек проблемаларын әсәрдән әсәргә дәвам итеп, яңадан-яңа яссылыкларга күтәреп тасвирлый. Шунлыктан «Шатлык белән кайгы янәшә» китабы тулаем бер зур әсәр итеп укыла. Аның героиняләры да бер күркәм сыйфат — хәлиткеч моментта дөрес карарга килә алу, үз асылыңа хыянәт итмәү сыйфаты белән хәтердә кала. Мәрвия («Агым уртасында»), Гөлҗиһан («Сөлге булсын бүләгем»), Нажия («Ут») һәм башкалар чын бәхетне әнә шунда күрәләр. Әлеге юлдан читкә тайпылучылар кырыс һәм аяусыз хөкемгә тап була (инде телгә алынган «Шикәр Гайшә»не искә төшерик).

Әйе, бу китапның каһарманнары гадәти тормыш белән яшиләр, кайберләре беренче карашка очраклы тоелган хәлләрдә ачылып китәләр. Ләкин холык-фигыльләре, үз-үзләрен тотышлары һич тә очраклы түгел. Язучы аларны әлеге халәттә, «агым уртасында» бер генә мизгелгә туктатып торган төсле. Китап адәм баласын мәңгелек хәят уртасында яшәү мәгънәсе, кешелеклелек нигезләре һәм көрәшү бәхете турында уйландыра.

**ИЛДУС ШАҺИЕВ.**

# ХЫЯЛЛАРГА ХЫЯНӘТ ИТМӘГЕЗ!

Һәр язучыга тормышның аеруча якын, бөтен нечкәлекләре белән таныш өлкәсе була. Диләрә Зәбәерова өчен ул — укытучылар, мәктәп тормышы һәм тормышка аяк басып килүче яшьләр. Аның геройларына бер уртак сыйфат — яшьлек хыялларына тугры булып калу, үзләре сайлаган юл-максатка чын йөрәктән бирелү хас. Язучының «Яшьләр күңеле»[1] дигән китабында да без шундый кешеләр белән очрашабыз.

Җыентыктагы «Дустым авазы» һәм «Кыр чәчәге» повестьлары темалары, төп мәсьәләләре, сурәтләнгән вакыйгалары белән бер-берсенә бигрәк тә якын. «Дустым авазы»ның төп герое Нәзирә — яшь укытучы. Ул үзенең күптәнге хыялына ирешкән, педучилище тәмамлагач авыл мәктәбенә укытучы итеп билгеләнгән. Аны биредә көтелмәгән сөенечләр һәм көенечләр, тормышның яңа сынаулары каршы ала. «Кыр чәчәге» повестендагы Ләйсән исә, Нәзирәдән аермалы буларак, мәктәптә эшләп чирканчык алган, азмы-күпме тәҗрибә туплаган кеше.

Әсәрләрнең икесендә дә бүгенге мәктәп һәм укыту-тәрбия проблемалары күтәрелә, шушы катлаулы процесста укытучы шәхесе тоткан роль үзәккә куела.

«Кыр чәчәге» повестенда укытучыларның бергәләп, коллектив фикере белән хисаплашып эшләүләре һәм мораль яктан үрнәк, гүзәл булулары мөһим, дигән фикер үткәрелә. Мәктәпне чын күңелдән яраткан Ләйсән хезмәттәшләрен һәм директор Җәләловны әнә шул таләпләрдән тайпылмаска чакыра.

Кызларның характерларында да, язмышларында да уртак яклар байтак. Икесен дә язмыш вакытлыча укытучылыктан аера. Дөрес, Ләйсәннең яңа эше дә мәктәпләр белән бәйле, тик Нәзирә генә бу һөнәрен алмаштырырга мәҗбүр була. Әсәрнең башында ук укучы Нәзирәне яратып өлгерә, шатлык-кайгыларын уртаклаша, аңа теләктәшлек итә. Үз эшенә җаны-тәне белән бирелгән бу кызның ниндидер гайбәтләргә карап кына мәктәпне ташлап китүе аңлашылып та җитми. Тырыш, тынгысыз Нәзирәнең холкы-фигыле белән кылган эшләре арасында каршылык килеп чыга кебек. Аның шулай кинәт кенә мәктәбен ташлап, яратмаган кешесенә кияүгә чыгуы, ахыргача көрәшмәве укучының Нәзирәгә булган симпатиясен киметә.

Ләйсән дә — гадел, саф күңелле кыз. Аны мәктәптәге төрле кимчелекләр борчый, ул шуларга каршы көрәш ача. Тик Ләйсәннең бу көрәше дәрестә укытучы ясаган хаталарны төзәтүгә генә кайтып кала. Эшендә очраган беренче авырлыклардан ук ул җиңелә, Нәзирә кебек үк, гайбәтләргә каршы тора алмый.

Язмыш тарафыннан читкә тибәрелсәләр дә, кызлар барыбер яшьлек хыялларына тугрылыклы булып калалар: икесе дә яңадан мәктәпкә, балалар янына кайта. Шушы рухи халәт бигрәк тә Нәзирә образы аша тулы ачыла. Ул, шактый вакыт үтсә дә, үзгәрмәгән, үзенең идеалларына хыянәт итмәгән. Күңеленең түрендә үк яшеренеп, ваемсыз еллар тарафыннан томалана язган бу тугрылыкны яңадан баш калкыттыру өчен яшьлек дустының шифалы сүзе генә җитмәгән икән.

Д. Зәбәерованың геройлары кайвакыт, югарыда әйтелгәнчә, тормышның төрле авырлыклары каршында каушабрак калсалар да, нигездә, чорыбызның ару-талу белмәс, кайнар йөрәкле яшьләре. Алар — тынгысыз, алар көрәш эчендә, юлда. Бу юлда ялгышлар да була, билгеле. Язучы ул хакта ачынып, әрнеп яза. «Яшьләр күңеле» җыентыгына кергән «Сызган балдак», «Кыз вөҗданы» кебек хикәяләрне укыгач, без моңа тагын бер кат инанабыз.

Д. Зәбәерованы, нечкә күңелле, тынгы белмәс язучы буларак, тормышның төрле яклары кызыксындыра. Тик кайбер хикәяләрендә аның вакыйгаларны журналистларча, алдан билгеләнгән план-схема буенчарак бәян итүе сизелә. Мәсәлән, «Табын» хикәясендә автор әйтергә теләгән фикерен дәлилләү өчен ачыктан-ачык фактлар китерү юлына баса. Хикәя шундый ук рухтагы нәтиҗә-сөземтә белән тәмамлана.

Д. Зәбәерованың яңа китабы күпләрне уйланырга мәҗбүр итә, яшьләрне яратып сайлаган һөнәрләренә, хыялларына хыянәтсез яшәргә өнди.

**ЗИННУР ХӨСНЕТДИНОВ.**

[1] Казан. Татарстан китап нәшрияты, 1980 ел.

Фирдәвес Әһлиуллина

# АЛТЫНЧӘЧ

ДОКУМЕНТАЛЬ ӘСӘРДӘН ӨЗЕК

Кунак бүлмәсендә аны көтеп утырам. Тын. Тәрәзәдән тышта сирәк кенә машиналар узгалаганы гына ишетелеп тора.

Аннары тагын якты төстәге обойлар ябыштырылган стенада үткән гасырның суга торган француз сәгате текелди.

Сәгатьләр саный торган вакытны без, гадәттә, сизмәскә күнеккәнбез. Ә хәзер мин аны җаным-тәнем белән тоям шикелле. Алтмыш секунд — бер минут хасил итә. Ә бер минут ул шартлы вакыт берәмлеге буларак, үтә дә китә, ләкин беркайчан да кире әйләнеп кайтмый. Шул хакта уйланырга безнең вакытыбыз җитми...

Менә сәгать теле тагын бер минут чиген узды. Ләкин ул мәңгелек упкынында эзсез югалмый. Ул мине актриса һәм җырчы Галия Кайбицкаяның искиткеч кызыклы тормыш юлы турында уйландыра.

Һәр кешенең күңелендә үз «сәгате» бар. Аның кабатланмас язмышының минутларын һәм елларын санап бара ул. Сәгать телләре — хәтер кебек алар. Хәтер теләсә кайсы мизгелдә кешенең үткән тормышында берәр вакыйганы яңадан җанландыра ала.

Сәгать каты итеп дүртне сукты. Шул ук мәлне ишекләр киң итеп ачылып китте дә тиз адымнар белән бүлмәгә шат һәм якты йөзле Галия апа килеп керде.

— Озак көттереп алҗытмадыммы соң?— дип сорады ул.— Ашыгыч эшем бар иде.

Ул чишенеп тормады, һәм без шунда ук, алдан сүз куешканча, А. М. Горький музеена юл тоттык. Галия Кайбицкая инде унөч елдан артык эшләгән музейның ике катлы ак бинасына килеп җиттек. Музейда халык юк, тынлык хөкем сөрә иде. Күп кешеләрнең язмышын зур игътибар белән саклый бу изге тынлык. Тәбәнәк баскычлар буйлап икенче катка күтәрелгәч, Муса Җәлил почмагына уздык. Биек пыяла шкафта Алтынчәчнең кайчандыр җилфердәп торган җизле юка ак күлмәге, муенсасы, күкрәккә тага торган бизәнү әйберләре, беләзеге һәм күп төрле ташлар белән бизәлгән бил каешы, тарак. Алтынчәч ролен беренче тапкыр башкарганда Галия Кайбицкая сәхнәгә шушы күлмәкне киеп чыккан.

Шкаф белән янәшәдә «Алтынчәч» операсының премьерасы алдыннан җырчыга Муса Җәлил бүләк иткән грим салу өстәле һәм аның бөтен гомерен, бөтен рольләрендәге чагылышын күргән көзге.



Сиздермичә генә Галия ханымга күз салам. Аның карашы көзгегә текәлеп калган. Бу минутта, күрәсең, Муса Җәлил исеме белән бәйле бөтен үткәне — Мәскәү консерваториясендәге опера студиясендә укуы, шагыйрь белән танышып, бергәләп озак еллар нәтиҗәле эшләве көзгенең томанлы тирәнлегендә чагылып күз алдыннан үтәдер.

Галияне сабырсыз пассажирлар агымы элэктереп, метродан алып чыгып куйды. Өстендә җәйге җиңел пальто, башында күзләре төсендәге зәңгәр берет. Кулында улына дип алган (бу вакытта инде аның өченче улы — Ирек туган иде) ике зур апельсин һәм Станиславскийның хәзер ул ныклап өйрәнә башлаган «Минем сәнгатьтәге тормышым» дигән китабы салынган кечкенә сумка.

Галия тиз генә түгәрәк кул сәгатенә карап алды, йөгереп диярлек шау-шулы киң проспектны аркылы чыгып, борынгы йортлар арасына кереп китте. Өченче катка күтәрелгәч, сак кына итеп көрән төстәге ишек янындагы кыңгырау төймәсенә басып алды. Ишек ачылып китте дә бусагада ак алъяпкычлы юан бер хатын пәйда булды.

— Ә, Галочка!— дип шатланды хатын.— Узыгыз, уз. Дора Борисовна көтә сезне.

Галия алгы бүлмәдә пальтосын салып элде, көзге алдында чәчен сыпыргалады да П. И. Чайковскийның гипс бюсты куелган пианинолы бүлмәгә узды. Урам тузанын һәм машиналар шавын чак кына үткәреп торган яшел калын пәрдәләр эленгән тәрәзәләр... Стеналарда танылган композиторларның рәсемнәре. Өстәл лампасы яна.

Тәбәнәк тәз гәүдәле, буй-буйлы соры күлмәген каеш белән билдән буып куйган Дора Борисовна тирән кәнәфигә чумып утыра иде.

— Утырыгыз, Галия,— диде ул.— Әйдәгез, бераз ял итеп алыйк.

Ишекне тавышсыз гына ачып, Галияне каршы алган Дора Борисовнаның апасы Дарья Семеновна килеп керде. Ул поднос тоткан, ә аңа үтәкүренмәле лимон кисәкләре йөзгән ике чокыр чәй һәм өйдә пешерелгән печенье салынган ваза куелган.

— Бераз хәл алыгыз, кадерлем,— дип дәвам итте Дора Борисовна,— эшебез күп.

Алар һәр көнне сәгать ярым музыка белән шөгыльләнәләр. Укытучысы күп тырышлык куйса да, моның әле Галия өчен күзгә күренеп торган әллә ни файдасы тигәне юк. Галиянең тавышы еш кына сынып киткәли, нигездә милли музыкаль жанрлардан торган репертуарыннан башканы ул уңышлы җырлый алмый иде әле.

Дөрес, Дора Борисовнаның мондый нәфис хатынның, һичшиксез, нечкә тавышлы булуына ышанычы нык була. Чөнки табигатьтә бар нәрсә бер-берсенә туры килеп тора, гармонияле. Моңа ул күпьеллык укыту тәҗрибәсе һәм сизгерлеге нигезендә нык инана.

Бер-ике минуттан соң Дора Борисовна чокырын читкә этәреп куйды да аягына басты:

— Я, башлыйк, алайса,— диде ул һәм пианинода беренче аккордны алды.

Галия укытучысы янынннан нәкъ бишенче яртыда чыгып китте. Аны шомлы бер борчу билән алды һәм ул бераз гына Мәскәү урамнары буенча йөреп алырга булды. «Башка беркайчан да җырлый алмам микәнни?!»— дигән өметсез уй биләгән иде аны. Кузгә килгән яшьләрен кечкә тыеп, шулай әкрен генә Мәскәү елгасы ярлары буйлап йөри торгач, ниһаять, театр янына килеп чыкты. Кемдер аңа билет сузды, ул акча түләп, залның арткы рәтенә кереп утырды да шунда ук балет башланып китте. Галиянең бала чагында балет мәктәбенә йөрүе исенә төште. Һәр көн саен өйдән китеп, качып кына ишектәге ачкыч тишегеннән зур кызыксыну белән ак пачкалар һәм пуантлар кигән кызларның серле хәрәкәтләрен күзәтеп, па, батман, пируэт кебек сүзләрне тын да алмыйча тыңлаган кызны күреп, әнисе түзмәде, аны балет мәктәбенә илтеп бирде.

Менә сәхнәдә әйтерсең лә яшен яшьнәп җибәрә, күк күкри... Балерина «Марсельеза» биюен башкара. Көрәшкә чакырып, ал байрак күтәреп китә. Ул, ут ялкыны кебек, җирдән килеп чыга да өермәдәй җилфердәп күккә омтыла. Бу — революция уты, аның ярсулы йөрәге. Күз нярмәс зәңгәр яктылык таралып, тынлык урнашкач, сәхнәгә салмак кына аккош йөзеп чыга. Кыштырдап торган каурыйларыннан тирәякка, әйтерсең, нәфис балкыш тарала. Галия сихерләнгән кебек утыра, әйтерсең, кемдер җитәкләп, аны әкиятләр дөньясына алып кергән дә һәм менә ул үзендә, таугa күтәрелгәндә кинәт икенче сулышы ачылып киткән кеше сыман, гаҗәп үзгәрешләр тойган хәлендә тын алырга да базмыйча шунда йөри. Аның күңелен кинәт кенә бер дәһшәт биләп ала.

Балерина куллары... «Менә ул чын сәнгать,— дип уйлады Галия театрдан чыкканда.— Актер осталыгы нинди зур тылсым көченә ия!»

Ару-талуны белмичә эшләргә! Галия әнә шундый катгый карарга килеп, йөгерек һәм дәртле адымнар белән консерватория бинасына таба юнәлде.

Беркем юк. Ул репетиция бүлмәсенә кереп ут кабызды һәм пальтосын элгечкә элеп куйды да пианино янына килеп утырды. Кичке урамда туңган бармаклары язылып, беренче аккордларны алгач, ул җырлап җибәрде.

Ун минут чамасы узды микән,— әдәпле генә ишек шакып берәү килеп керде. Галия ноталардан аерылып, керүчегә караш ташлады: бүлмәдә кыскарак буйлы, түгәрәк тут йөзле, күзеннән искиткеч яктылык, җылылык сирпелеп торган бер ир кеше басып тора иде.

— Гафу итегез, Галия ханым, узып барышлый тавышыгызны ишетеп кердем...

Ул, якын килеп, ягымлылык һәм ихтирам белән кулын сузды.

— Муса Җәлил. Опера студиясенең әдәби бүлеген җитәклим,— дип, ул ике тимер каптырмалы калын күн портфелен ачты һәм тыгыз итеп язылган кәгазьләр чыгарды.

— Монда сезнең өчен дә кайбер нәрсәләр бар,— дип елмайды ул.— Карап карагыз әле.

Галия зур кызыксыну белән шул кәгазьләрне карарга кереште. Болар Моцартның «Фигароның туе» операсыннан Сюзанна, Дж. Россининың «Севиль чәч алучысы»ннан Розина, Гретриның «Леонор» операсыннан Леонор арияләренең татарчага тәрҗемәсе иде. Аңа бу әсәрләрнең барысы да таныш. Ә менә бусы... ниндидер яңа нәрсә. Ул нотага карап тын гына көйли дә башлады, бераздан тулы тавышка җырлап та карады.

Муса, балаларча куанып:

— Беләсезме, бу булачак операдан Алтынчәч ариясе,— диде.— Хәзер шуның либреттосын язып йөрим. Композитор Б. Асафьевтан музыканы сезнең тавышыгызга җайлаштырып язуын сорармын,— телисезме?

— Әлбәттә!

— Сезнең җырлавыгыз бик ошый миңа, ярый бүлдермим. Сау булыгыз.

Галия күпмедер вакыт аптырап утырды. Бераздан соң гына ул үзенең бая җырлаган тавышының агына барып җитүен сизеп алды: тавышы яңарды түгелме соң?! Түбән колоратур сопрано! Дора Борисовна үз дигәнен иткән лабаса: элеккесен үзгәртеп аңа бүтән тавыш бүләк итте бит. Бер үк вакытта җырлыйсы да, елыйсы да

килде Галиянең. Үзен тиз кулга алып, ул киләчәге хакында хыяллана башлады.

Аның элеккеге репертуары яраксыз иде инде. Бик җентеклап җыеп, яңа әсәрләр өйрәнә башларга вакыт. Аның алдында хәзер элек хыяллана да алмаслык гүзәл мөмкинлекләр ишеге ачылып киткәндәй булды. Җиңеңне сызган да тиз көндә эшкә кереш!

Аны алда опера көтә иде.

Ә опера сәнгатенең күп төрләре белән үзара мөнәсәбәттә. Аңа балет һәм скульптура элементлары хас: актерлар хәрәкәте мәгънәле, тегел булырга тиеш, сәхнә хәрәкәтенең һәр мизгеле тәмамланган скульптур композицияне хәтерләтсен.

«Опера кайгы һәм шатлык, борчу һәм сагыш чагылган кеше тавышының зур, чиксез мөмкинлекләрен ача. Мәңгелек һәм бер мизгел дә аның ихтыярында...»— дип уйлый Кайбицкая.

Күп тә үтмәде, Казаннан Опера һәм балет театры ачыла диган шатлыклы хәбәр килеп төште. Студиягә йөрүчеләр бу яңалыкны сөенеп каршы алдылар.

Татар халкы музыканы борын-борыннан яраткан һәм иҗат иткән. Үз заманында бөек Тукай да безнең халыктагы җырга һәвәслекне күреп горурланган. Билгеле, шундый халыкның үз опера театры булырга тиеш инде ул. Дөрес, әлегә бинасы да юк, милли репертуар да берничә исемнән генә тора. Опера студиясендә күнегүләр башлау өчен Мәскәүгә Н. Җиһановның Ә. Фәйзи либреттосына язган «Качкын» тарихи-героик операсы җибәрелә.

Рус композиторы Василий Иванович Виноградов һәм Солтан Габәши тарафыннан Газиз Әлмөхәммәтов либреттосына язылган беренче татар опералары «Эшче», «Сания» Казанда 1925—27 елларда ук куелган иде инде. Галия Кайбицкая аларда берьюлы икешәр роль башкарды: «Эшче»дә — хезмәтче һәм кулак хатыннарын. Ә «Сания»да — Сания һәм аның дус кызын. Ә татар крестьяннары арасында Пугачев хәрәкәтенә багышланган «Качкын» операсында аңа төп рольләрнең берсе — халык восстаниесе җитәкчесе Булатның сөйгән кызы Рәйхан партиясе тапшырыла. Мәскәүдә чакта Г. Кайбицкая бу рольне ныклап торып өйрәнә.

Һәм менә, ниһаять, ул Казанда. Беренче репетиция вакытында ук Әхмәт Фәйзи аңа:

— Менә, Галия, мин либреттосын яздым, Нәҗип Җиһанов музыкасын. Операның язмышы инде хәзер синең кулда,— диде.

Операның язмышы премьерада ук хәл ителде һәм аның әлегәчә сәхнәдән төшкәне юк.

Рәйхан партиясе өчен Галиягә Татарстанның халык артисткасы диган мактаулы исем бирелә.

«Качкын»нан соң Мансур Мозаффаровның «Галиябану», Н. Җиһановның «Ирек», П. И. Чайковскийның «Евгений Онегин», Ш. Гунонең «Фауст» опералары куела, һәм аларның барысында да җырчы җаваплы төп партияләрне башкара.

Тиздән Мәскәүдә узачак татар сәнгате һәм әдәбияты декадасына әзерлек башлана. Анда куяр өчен Н. Җиһановның М. Җәлил либреттосына язылган «Алтынчәч» операсы сайлана. Бу чорга инде шагыйрь либреттоны тәмамлап, театрның әдәби бүлеген җитәкләр өчен Казанга кайта. Муса Җәлил бер репетицияне дә калдырмый йөри, ярым караңгы залның әле бер ягында, әле икенче ягында аның тәбәнәк гәүдәсе күренеп китә. Инде башына берәр фикер килсә, ул сикереп тора да, оркестр урынын тамаша залыннан аерып торган барьерга терәлеп, киңәшләр бирә башлый, бәхәсләшергә керешә, шатлана, көлә...

Үзендә мәңгелек яшьлек, халык күңеленең матурлыгын туплаган алтын чәчле гүзәл кыз Алтынчәч роле Галиягә тапшырыла һәм бу әкияти шигъри образны иҗат итүдә аңа М. Җәлилнең күп файдасы тия.

Театрның яңа гына билгеләнгән директоры Ильяс Әүхәдиев әсәрне сәхнәләштерү өчен Мәскәүдән Зур театрның режиссеры Леонид Васильевич Баратовны чакырта. Алтынчәчнең сәхнәгә беренче чыгышын аның болайрак хәл итәсе килә:

— Галия сәхнә артыннан — ерактан ук җырлап килсен. Шул чагында аның тавышы күп катлы тирән яңгыраш алып, кайтавыз сыман таралыр, ә сәхнәгә чыккач, ул күп чабулар тынганчы иң югары нотада җырласын.

Муса Җәлилгә бу бик ошый. Ул урыныннан атылып торып сәхнәгә таба йөгереп килә:

— Яле, Галия, карап карыйк, ничек чыгар икән?

Галия, режиссер киңәшеннән бер дә читкә тайпылмыйча, иң югары нотаны алып (ә ул партитурада күрсәтелгәнгә караганда бер ярым тонга югарырак ала иде), сәхнә уртасына чыга, ә үзе сабыйларча шатлык белән балкыган Муса аны кул чабып тәбрикли башлый.

Аның тавышы өзелергә җитеп, нык тартылган кыл кебек, нечкә яңгырый, ә Муса туктый алмыйча кул чаба да кул чаба. Ике минутка якын шулай дәвам итә. Ниһаять, Галия чыдый алмый, тыны бетеп, җырны кискен генә өзә дә шагыйрьгә:

— Нимә дип кул чабасың да чабасың син, Муса? Чиксез суза алмыйм бит инде мин! — дип кычкырып җибәрә.

— Тавышыгыз күпмегә җитәр икән дип сынап карамакчы идем,— дип көлә Муса.

Аңа күңелле, ә менә Галиянең күңелен икеләнү хисе биләп алды: әгәр берәү дә кул чапмыйча, залда үле тынлык каршы алса нишләрсең? Ул шикләрен режиссерга да әйтте. Ләкин Муса шундук:

— Шикләнмә, Галия! «Алтынчәч» барган һәр кичтә театрга үзем килеп, арганчы кул чабармын. Тамашачыларның исә миңа кушылмыйча хәлләреннән килмәс,— ди.

Галия «Алтынчәч» образын бик теләп, шатланып, канатланып эшләде. Әйтерсең лә аңа бу образга кереп тә торасы юк, гүя Алтынчәч аның күңелендә күптән яшәгән дә ирекккә чыгуын гына көтеп торган.

Спектакльне дәүләт комиссиясенә тапшырыр көн килеп тә җитте. Дулкынландыргыч көн.

Залның беренче рәтләрендә кабул итү комиссиясенең таләпчән әгъзалары: композиторлар, язучылар, художниклар...

Операның бишенче картинасы бара иде инде.

...Алтынчәч дошманнар кулында әсирлектә газап чигә. Ул күктә йөзеп барган болытларга кулын суза, күзендә сагыш, моң. Җил болытларны югалган оныгы кайгысыннан хәсрәтләнүче ялгыз бабасы, дус кызлары калган туган авылына таба куадыр.

Алтынчәчнең карашы болытлардан каен ябалдашына төшә. Каен яфракларын җилфердәтә, әйтерсең лә, Алтынчәчнең ятим калган өенә ишарә итә. Һәм Алтынчәч, үзенең исән икәнен белгертеп, якташларын тынычландырыр өчен җаны-тәне белән шунда таба ашкына.

Ул шаян елга агышына да колак сала. Аның шушы елганың кечкенә бер дулкынчыгына да әйләнәсе килә. Сайрар кошлары, матур болыннары белән күңелдә җәйрәп яткан туган авылыңа кайтып керсәң икән!..

Күзеннән яшь бәреп чыккан шул мәлне аның карашы халыкның курку белмәс батыр яклаучысы Җик-Мәргән аерылышыр алдыннан бүләк иткән алтын каурыйга төшә. Кинәт йөзе ачылып китә һәм ул әкрен генә кул хәрәкәтләре белән һавада каңгылдап очучы аккошларны үз янына чакырып төшерә.

Аяк астында җәелгән киң канатлар — үзенең гаҗәеп югары тавыш канатларында ул күккә омтыла. Ә тавышының чиста яңгырашы каядыр еракларга таралып ерагайганнан ерагая бара...

Шул арада чиксез бәхетле кыяфәтле түземсез Муса сәхнә артына йөгереп менеп, Галияне каршы ала.

— Рәхмәт сиңа, дускай! Мин нәкъ шушындый Алтынчәч турында хыялланган идем дә инде!— ди ул дулкынланып.

Аннары йөзе җитдиләнә төшә. Тиз адымнар белән килеп, өстәл янына утыра, «Алтынчәч»нең бер нөсхәсенә эре хәрефләр белән кул куя да аңа суза.

— Тарихи көн бүген, Галия! Шуның истәлеге булсын.

Алтынчәч ролен уңышлы иҗат иткәне өчен Галия Кайбицкаяны комиссия СССРның халык артисткасы дигән мактаулы исемгә тәкъдим итә.

Ләкин сугыш башлана. Декада уздырылмый кала.

Театрның күп хезмәткәрләре, шул исәптән Муса Җәлил дә сугышның беренче көннәреннән үк үзләре теләп фронтка китәләр. Ил өчен авыр көннәр башлана. Халык тез чүкми, һәм театр да көрәшкә чакырып эшләвен, иҗат итүен дәвам итә.

«Алтынчәч» премьерасы Бөек Ватан сугышы башланып, берничә көн узгач була.

Театрга төркем-төркем халык агыла. Араларында фабрика кызлары, эшче егетләр, урта яшьтәге парлар.

Бер нәрсәгә карамастан — монда бүген бәйрәм рухы. Матур игъланнар. Биек ишекләр әледән-әле ачылып, алардан тамашачылар иркен фойега үтә. Зәңгәр кием-ле билет тикшерүчеләр ягымлылык белән программкалар тәкъдим итә.

Театр тамашачылар белән тула. Кешеләр азга гына булса да кайгыларын онытып, ашыкмыйча гына вестибюльдә йөриләр, танышлары белән сөйләшәләр, әкренләп театр дип аталган искиткеч гүзәл дөнья хисенә бирелеп китәләр.

Өченче кыңгырау шалтырагач, тирән тынлык урнаша. Әкренләп утлар сүнә, карашлар сәхнәгә төбәлә. Тик ара-тирә генә йөткерү, пышылдау ишетелгәли. Оркестрда соңгы кат әле теге, әле бу музыкаль инструмент тавышы яңгырый һәм бер генә мизгелгә барысы да тын кала. Шул чак дирижер таякчыгы җилкенеп куя да зал тантаналы увертюрага күмелә.

Бүген «Алтынчәч»нең премьерасы. Галия театрга килгәндә сәгать биш кенә иде әле. Сугыш башланса да, халык әле исенә килеп җитмәгән. Дошман ил эченә тирән үтеп кереп, тарих битләренә кара хәрефләр белән язылган коточкыч явызлыкларын кылырга өлгергән дә инде. Ләкин барлык сынаулар алда.

Халык хуҗалыгы сугыш ритмына кереп җитмәгән. Бары тик вокзаллар гына балаларын, ирләрен фронтка озатучы аналарның елашуы белән тулып тора.

Галия үзе дә дусларын, туганнарын, якыннарын озата. Ләкин еламый ул. Эшләргә кирәк.

Ул үзенең грим салу бүлмәсенә кереп бикләнде. Үз-үзе белән бергә-бер калып онытылырга, бары опера һәм аның геройлары Тугзак, Урмай, Җик-Мәргәннәр турында гына уйларга кирәк аңа.

Шулай бераз утыргач, Галия тынычланып кала, аннары берәм-берәм киемнәрен киеп карый. Тәненә ниндидер бер рәхәтлек биреп торган ак күлмәген киеп алгач, күңеленә бөтенләй бәйрәм хисе кереп кала. Муенсасын тагып җибәрә, билен буа, саклык белән генә паригын киеп, көзгегә караса, анда шаян елмайган Алтынчәч үзе басып тора икән. Бүлмә Галиянең матур челтерәп аккан тау чишмәсен хәтерләтеп торучы яңгыравыклы көлү тавышына күмелде.

Галия Алтынчәчнең дус кызлары белән сөйләшүен күз алдына китерде, бу — аны урманга озата чыккан бабасына кул изәве.

Менә тар гына сукмак. Ике яклап куе куаклык. Читтәрәк урман елгасы аша салынган агач күпер. Шул күпер аша йөгереп үтеп, ул кура җиләге куаклыгына килеп чыгар. Йөзе шаян елмаю белән балкыган булыр...

Галиянең күңеле матурлык һәм хис белән тулы бу минутта әкрен генә ишек шакыдылар, сәхнәгә чыгар вакыт җиткән икән.

Салмак йөрешле Алтынчәчнең җырлап сәхнәгә чыгуын тамашачыларның көчле алкышы каршы алды: спектакль башланып китте.

Халыкның үз азатлыгы өчен көрәше турындагы аллегорик бу әсәр илдә барган вакыйгалар белән хәзер бик авваздаш, шуңа күрә ул тамашачы күңеленә аңлаешлы. Әйтерсең лә, куркыныч янаган Туган илне гәүдәләндереп, ак күлмәкле Алтынчәч яшьлек, музыка, гүзәллек кебек изге нәрсәләр хакына аяусыз көрәшкә чакыра.

Гадәттә тамаша залы белән сәхнәне аерып торган шартлы бер чик әнә шулай сизелмәс хәлгә килә. Һәр совет кешесенең күңелендә хәзер бер генә уй — Туган илне илбасарлардан азат итү.

Без «Муса Җәлил Моабит төрмәсендә» һәм «Галия Кайбицкая Алтынчәч ролендә» картиналары янында бераз басып тордык та ишеккә таба юнәлдек.

Баскычтан миннән алдарак төшеп барган Галия Кайбицкая кинәт артка борылып карады. Искиткеч бер күренеш: гүя, шаян елмаеп, миңа Алтынчәч карап тора иде. Гүзәллек һәм яшьлекнең гәүдәләнеше булып чынбарлыкка әйләнгән Алтынчәч. Ул баскычның соңгы басмасында кинәт тагын тукталып кала, яңадан аркан борылып, миңа кул изи дә елмаеп үлемсезлеккә кереп китә.

# Рафаэль Белялов

# ТАМЫРЛАРЫ — ХАЛЫКТА

„Бәхетле йолдыз астында туган» — танылган педагог һәм композитор, актив җәмәгать һәм фән эшлеклесе Альберт Семенович Леман турында хезмәттәшләре әнә шулай диләр. Хәлбуки композиторның тормыш һәм иҗат юлына күз салсак, без анык тормышка аталаган беренче адымнарыннан ук үз йолдызын, талант көченә зур тырышлыгын өстәп, зур кыенлыклар белән үзе кабызганлыгын күрербез.

Элеккеге Саратов губернасы Вольск шәһәрендә музыкант гаиләсендә туып-үскән Альберт Леманның музыкага һәвәслеге бик яшьли беленә. Ул җиде яшеннән фортепьянода уйнарга өйрәнә, әмма гаилә матди кыенлыклар кичергәнлектән, яшь музыкантка бик иртә эшкә керергә туры килә. Ул тавышсыз кино сеанслары вакытында пианинода уйный, башкаларны фортепьянода уйнарга өйрәтә, ансамбльдә, концертларда катнаша. Фортепьянода уйнавы, пианист-импровизатор булып эшләве яшүсмернең иҗади сәләтен үстерүдә ярдәм итә. Ул үзе дә музыкаль әсәрләр яза башлый. Музыкага, серле авазлар дөньясына булган мәхәббәт аны Ленинград консерваториясенә алып килә. Гыйлем алу өчен бу шәһәрне сайлау очраклы булмый. Утызынчы елларда Ленинград — дөньядагы музыкаль мәркәзләрнең берсе, анык консерваториясендә иң күренекле педагоглар укыта. Биредәге профессорлар арасында А. Г. Рубенштейн, П. И. Чайковский, Н. А. Римский-Корсаков, М. П. Мусоргский, А. П. Бородин, А. К. Глазунов кебек бөек музыкантларның шәкертләре һәм дуслары шактый. Консерваториядәге гаҗәеп музыкаль атмосфера, педагог һәм студентларның иҗади тормышы, төрле ил музыкантлары катнашында уздырыла торган концертлар яшь иҗат көчләренә ифрат та яхшы йогынты ясый. Бу — Ленинград консерваториясендә белем алган зур талант— Дмитрий Шостаковичның иҗаты чәчәк аткан чор була. Нәкъ менә шундый бер вакытта, төгәлрәк әйткәндә 1935 елда Альберт Леман, имтиханнарны уңышлы тапшырып, Ленинград дәүләт консерваториясенә керә, композиторлар әзерләү факультетының профессор М. Ф. Гнесин классына эләгү бәхетенә ирешә.

Укуының беренче елларында ук булачак композитор иҗади активлык күрсәтә, төрле жанрларда көчен сынап карый. Өметле пианист буларак, аны 1936 елда профессор Н. И. Голубовский һәм В. В. Нильсен җитәкләгән махсус фортепьяно классларына да беркетәләр. Альберт Леман үзенең яраткан уен коралына зур игътибар бирә, рус һәм чит ил классикларының, замандаш композиторларының фортепьяно әсәрләрен тырышып өйрәнә. Бу вакытта Ленинградта гастрольдә булган атаклы пианистлардан А. Шнабель, А. Корто, Э. Петри концертлары, совет пианистларыннан М. В. Юдина, В. В. Нильсен, В. В. Софроницкий, Л. Н. Оборин чыгышлары аңа онытылмаслык тәэсир ясый. Ул үзе дә яраткан композиторларыннан Бах, Бетховен, Шопен, Прокофьевның фортепьяно өчен язган музыкаларын концертларда башкара. XX гасыр композиторларыннан И. Стравинский, С. Прокофьев, Б. Барток, М. Равель әсәрләре белән дә тирәннән кызыксына яшь музыкант.



Тырышлыкның җимешләре тиз күренә: 1938 елда яшь композиторның М. Лермонтов шигырьләренә язган романсы һәм А. Глоба шигырьләренә иҗат ителгән җырлар циклы басылып чыга. Бу вакытта шулай ук берничә камера әсәре һәм балалар өчен «Өч юан» (Ю. Олешин әсәре буенча) балеты дөнья күрә. Шундый иҗади уңышлары нәтиҗәсендә өченче курс студенты Альберт Леман СССР Композиторлар союзына член итеп алына. Ленинград дәүләт консерваториясенең ике факультетын да уңышлы тәмамлау (диплом эше итеп ул үзенең яңа симфониясен һәм фортепьяно концертын башкара) яшь музыкант өчен иҗат эшчәнлегенең беренче этабын йомгаклау була. Күренекле музыкант М. И. Чулаки «Советская музыка» журналында (10 нчы сан, 1940 ел): «Альберт Леман — эзләнүчән композитор һәм аның музыкасындагы кызыклы фикер яңалыклары, һичшиксез, киләчәктәге уңышларының нигезе булачак»,— дип язды.

Хәлбуки, яшь композиторны әле шөһрәткә илтүче чәчәкле юллар гына түгел, ә бәлки зур сынаулар да көткән икән. Илебезгә ябырылган афәт — Бөек Ватан сугышы башланганда А. Леман Ленинград шәһәр советы башкарма комитетының Сәнгать идарәсендә музыка бүлеге начальнигы булып эшли иде. 1942 елда башка музыкантлар белән бергә ул Казанга эвакуацияләнә. Шул көннән башлап, аның иҗади, музыкаль-иҗтимагый һәм педагогик эшчәнлеге Татарстанның музыка культурасын үстерү белән аерылгысыз бәйләнә.

Милли республика башкаласына килеп төшүгә, А. Леман, үзенә генә хас энергия һәм кызыксынучанлык белән, татар музыкаль фольклорын өйрәнә башлый. Кырыс сугыш елларында һәм аннан соң композитор татар халык авыз иҗатына нигезләнгән күп кенә әсәрләр иҗат итә. Аның 40-50 нче елларда иҗат ителгән «Татар моңнары» симфоник сюитасы, Бәйрәм увертюрасы, Скрипка белән оркестр өчен язылган концерты, Өченче фортепьяно концерты, симфоник оркестр өчен Татар рапсодиясе һ. б. әсәрләре музыкаль культурабызның алтын фондына керделәр, музыкасының тормышчанлыгы, халык җырларына тартым гаять аһәңле һәм югары профессиональ осталыкка ия булуы белән алар хаклы рәвештә халык ихтирамын яулап алдылар. Композиторның 1952 елда СССР Дәүләт премиясенә лаек булган Скрипка белән оркестр өчен язылган концерты аеруча зур уңыш казанды. Бу — Татарстан музыкаль культурасы тарихында инструменталь концерт жанрындагы тәүге әсәрләрнең берсе. А. Леманның скрипка һәм фортепьяно концертлары атаклы виртуозлардан Ю. Ситковецкий, А. Каплан тарафыннан Мәскәү, Ленинград, Казан концерт эстрадаларында башкарылдылар. Ул, менә дигән пианист буларак, фортепьяно әсәрләрен үзе дә бик еш башкара.

А. Леман 1945 елда Казан дәүләт консерваториясен оештыруга һәм ачуга да бик күп көч куйды. Мондый югары уку йорты ачылу исә республикабыз музыкаль мәдәниятының зур үсеш алуына мөмкинлек тудырды. Композитор, үзенең иҗат темпын һәм башкару эшчәнлеген киметмәгән хәлдә, консерваториянең композиция һәм фортепьяно классларында укыта башлый. Моннан тыш — теоретик-композиторлык факультетында музыкаль формаларны махсус анализлау буенча лекцияләр уку, музыка училищесында композиция һәм махсус фортепьяно классын алып бару. Бу өлкәдә А. Леманның педагоглык таланты бик тиз күренә. Яшь иҗат кешесенең үзенә генә хас якларын билгеләү һәм аңа иҗатта үз юлын табарга ярдәм итү — аның педагог буларак төп үзенчәлеге әнә шул. Студентларның теге яки бу әсәрен дәрестә бергәләп анализлау, һәркемгә үз фикерен әйтергә мөмкинлек бирү, соңыннан педагогның йомгак ясап куюы — башкаларның хатасын кабатлаудан саклый, укуда һәм иҗатта уңыш китерә, иҗади ярыш дәртен көчәйтә.

Ул үз студентларының музыка фольклорын, дөнья музыкаль культурасын өйрәнүенә зур әһәмият бирә. Төрле музыкаль әсәрләр тыңлау һәм фикер алышулар еш кына аның үз өендә дәвам итә. Алар бергә Бетховен һәм Малер, Онеггер һәм Хиндемит, Прокофьев һәм Шостакович язмаларын тыңлыйлар.

Казан дәүләт консерваториясенең А. С. Леман җитәкләгән композиторлык классында уку-укыту эшләренең бик яхшы куелышы смотрлар вакытында күп мәртәбәләр билгеләп үтелде. Казанда чирек гасыр эшләү дәверендә профессор Леман композиторларның берничә буынын тәрбияләп үстерде. Алар арасында күренекле композиторлар һәм пианистлар бар. Татарстан Композиторлар союзы членнарының шактые — А. Леман шәкертләре. Моннан тыш Башкортстан, Мари, Чувашстан, Удмуртия, Тува автономияле республикалары, Алтай һ. б. өлкә һәм шәһәрләрнең күп кенә күренекле композиторлары Альберт Семеновичны үзләренең остазлары итеп саный.

1960-70 еллар А. Леман өчен аеруча илһамлы иҗат еллары булды. Аның бу елларда иҗат иткән монументаль әсәрләренең яңачалыгы, композиторның туктаусыз эзләнүе вакытлы матбугатта кат-кат билгеләп үтелде. Үзенчәлекле художник, талантлы оста язган әлеге әсәрләр халкыбызның социаль һәм рухи хәрәкәтендәге прогрессив сыйфатларын үзендә туплаган. Шундыйлардан — «Ленин» һәм «Атлантлар» ораторияләре илебезнең бик күп шәһәрләрендә яңгырап, совет музыкасы тормышында күренекле вакыйгага әверелде, киң җәмәгатьчелек хуплавына лаек булды. Инструменталь концерт жанрына тугры калган хәлдә, композитор бу елларда Икенче скрипка концертын, ике виолончель концертын, оркестр өчен каприччио концертын иҗат итте.

А. С. Леманның күп тармаклы эшчәнлеген партия һәм хөкүмәтебез югары бәяләде: 1957 елда композитор РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, ә 1965 елда РСФСРның халык артисты дигән мактаулы исемнәргә лаек булды.

Профессор Леман композиторлар укытудагы күпьеллык педагогик тәҗрибәсен Ленинград һәм Мәскәү дәүләт консерваторияләрендәге коллегалары белән бик теләп уртаклаша. 60 нчы елларда ул Казан һәм Ленинград дәүләт консерваторияләрендә эшли. 1970 елдан — П. И. Чайковский исемендәге Мәскәү дәүләт консерваториясенең композиция кафедрасы мөдире. Күренекле педагог илебезнең төп музыка югары уку йортында иң җаваплы эшләргә яңа дәрт белән тотына: студент-композиторларның Бөтенсоюз конкурсларын һәм фестивальләрен оештыра, илебез консерваторияләренең композиторлык факультетлары өчен укыту программалары һәм планнарын төзи, музыкаль белем бирүдәге, иҗаттагы проблемалар турында халыкара киңәшмәләрдә һәм вакытлы матбугатта чыгыш ясый. Педагогик һәм җәмәгать эшләрен күпләп башкаруына карамастан, ул иҗат активлыгын киметми. Соңгы ун елда композитор күпсанлы сим-

фониялəр, хор һəм камера əсəрлəре язды. Себер халкының музыкаль фольклорын өйрəнү нəтиҗəсе буларак, киң полотнолы хор һəм симфоник əсəрлəр тууга сəбəпче булды. Болар: «Диңгез буе җырлары» (халык темаларына), «Минем Карелиям» (А. Прокофьев шигыренə) кантатасы, «Карелиана» симфоник композициясе, «Вятка җырлары» исемле хор циклы һ. б.

Ул нинди генə жанрга тотынмасын, яңа иҗади бурыч куя һəм шуны җиренə җиткереп тормышка ашыра. Аның əсəрлəре тирəн эчтəлеге, яңачалыгы белəн музыкаль тормышыбызда һəрвакыт вакыйга була. Сəнгатькə, халыкка бирелеп хезмəт итү, иҗади активлык һəм туктаусыз алга таба хəрəкəт итү — А. С. Леманның иҗат яшьлəренə үрнəк булырлык сыйфатлары.

Яшь музыкантлар тəрбиялəү кебек мактаулы миссияне үтəп 40 елга якын гомер узып киткəн. А. С. Леманның шəкертлəре (алар 200 дəн артык) актив иҗаттан тыш, илебез консерваториялəрендə, музыка училищеларында уңышлы гына эшлəп килəлəр. Алар арасында профессорлар да, доцентлар да, дəүлəт бүлəклəре лауреатлары да, халык артистлары да бар.

Композитор — коммунист Альберт Семенович Леман һəрвакыт эштə, һəрвакыт иҗади эзлəнү юлында. Һəм шиклəнми əйтергə мөмкин: күренекле композитор үзенең яңадан-яңа əсəрлəре белəн күпмиллəтле совет сəнгате данын тагын да югарырак үрлəргə күтəрешер, табигать биргəн талантын, туган илебез биргəн мөмкинлеклəрен килəчəктə дə тулы файдаланыр. Аның иҗат тамырлары — халыкта.

# ГӨЛСЕМ КАМСКАЯНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Татарстанның халык, РСФСРның атказанган артисткасы Гөлсем Камская үзенең сəхнə эшчəнлеген фронт буе театрларында башлады. 1922-1926 елларда Казанда, Кызыл Октябрь исемендəге Татар дəүлəт театрында эшлəде, 1927-1933 елларда Мəскəү татар эшче театрында һəм 1933-1934 елгы сезоннан башлап, пенсиягə чыкканчы Г. Камал исемендəге Татар дəүлəт академия театрында уйнады.

Г. Камская — иҗади сəлəтенең əле бер, əле икенче ягы белəн җемелдəп, эзлекле рəвештə ачыла барган һəм һəрвакыт үзенең табигыйлеге, гадилеге белəн тамашачыны сокландырган гаҗəеп талант. Югары сəнгати сиземлəүгə ия булган нечкə зəвыклы бу артистка образларның холкынфигылен, эчке дөньясын тирəнтен ачуга ирешə иде.

Гөлсем Камскаяның таланты К. Тинчурин, З. Солтанов, К. Шамил, Ф. Ильская, Х. Əбҗəлилов, Н. Таҗдарова, Г. Болгарская кебек күренекле татар артистлары һəм режиссерлары йогынтысы белəн ныгыды һəм үсте. Шул ук вакытта аның үз иҗаты да күп кенə чордашларына һəм бигрəк тə яшь артистларга гаять зур йогынты ясады. Артистка иҗатына буяуларның кискенлеге, персонажның аеруча типик сыйфатларын ассызыклап күрсəтə белү осталыгы хас иде. Камская сəхнəдə уйнаганда без һəрвакыт ул иҗат иткəн портретларның тормышчанлыгына соклана идек.

Ничектер бервакыт артистка, моңсу гына елмаеп, үзенə гел карчыклар ролен уйнарга туры килүе турында əйткəн иде. Əйе, Камская башкарган рольлəрнең күпчелеге, чыннан да, өлкəн яшьтəге хатынкызлар яки бик бетəшкəн карчыклар. Беренче карашка, бу рольлəрнең бер кызыклыгы да юк һəм алар уйлану өчен бернинди азык бирмилəр сыман тоелырга мөмкин. Алар нинди дə булса сəнгати кыйммəткə ялəрме соң, əллə бер эстетик категориягə дə кермилəрме?

Г. Камская кызыклы һəм тирəн образлар иҗат итте. Т. Гыйззəт драмасы буенча куелган «Борчулы көннəр» спектакленнəн Гөлниса, мəсəлəн — артистканың камил һəм уңышлы хезмəтлəреннəн берсе. Əлеге үзенчəлекле портретта Камская бөтен барлыгы белəн ачылды, ул хис-омтылышларын балаларына багышлаган карт ананың гомумилəштерелгəн характерын күрсəтте. Аның күзлəрендə балаларының кичерешлəре, шатлык-кайгылары көзгедəге кебек чагылыш тапты. Ул бөтен спектакль дəвамында бары тик балалары турында гына уйлап яшəде, аларның шатлыкларына куанды, кайгы-мəшəкатьлəренə борчылды. Гөлниса образы игелеклелекнең, кайгыхəсрəт һəм моң-зарның җанлы гəүдəлəнешенə əверелде. Əнə шул рəвешле, Камская сəхнəгə патриархаль татар авылының җанлы вəкилен — йомшак күңелле, мохтаҗлыкта һəм кайгыда тилмереп, кыерсытылып яшəгəн крестьян хатынын алып менде. Аның сокландыргыч табигый тыйнаклыгы, ягымлы, матур тавышы, игелеклелек һəм наз белəн сугарылган моңлы күзлəре, кешелəргə сабыйларча беркатлылык белəн яратып каравы, мөлаемлылыгы тамашачы хəтерендə онытылмаслык булып калды. Ə саный китсəң, мондый образлар ничаклы?!

1944 ел иде. Авыр сугыш барган вакыт. Академия театры залы халык белəн шыгрым тулы. Сəхнəдə фронттан ерак бер колхоз тормышы сурəтлəнə. Көчле рухлы, кайнар йөрəкле, инанган һəм шушы инануы өчен ахыргача көрəшергə əзер

торган батыр Маһинур әле дә күңелдән китми. Бу образны Гөлсем Камская М. Әмирнең «Миңлекамал» драмасы буенча эшләнгән спектакльдә гәүдәләндерде.



*Рәсемдә: Гөлсем Камская (уртада) артисткалар Әминә Бикбаева (уңда) һәм Маһирә Юнысова белән (1920 еллар фотосы).*

Х. Гобәйдуллин архивыннан.

Солдат хатыны Маһинур образын ул бөтен тырышлыгын куеп, героиняга дәртдәрман биргән рухи көчнең серләрен ачарга омтылып әзерләде. «Маһинур беркайчан да күңел күтәренкелеген югалтмаска тиеш,— дип уйлый иде актриса.— Образ киләчәк җиңүгә тирән ышаныч белән сугарылган булырга тиеш. Ышаныч булганда бернн дә куркыныч түгел, ышаныч кешегә көч, дәрт һәм илһам бирә.» Әлеге тема бөтен спектакль аша кызыл җеп булып узды.

Гөлсем Камская беркайчан да образларны куертеп күрсәтергә омтылмый иде һәм тамашачыга ярарга тырышмый иде. Ул тормыш хакыйкатеннән, персонаж характерының чынбарлыкка туры килүеннән, персонаж кылган гамәлләрнең үсеш логикасыннан чыгып иҗат итте. Шуңа күрә дә Камская тудырган образларның һәркайсы — тәмамланган, иң вак детальләренә кадәр уйланып, эшләнеп беткән образлар. Актриса кешенең характерын оста рәссам кебек бер-ике төгәл штрих белән дә ачып бирә ала иде.

Г. Камалның «Бәхетсез егет» драмасы буенча эшләнгән спектакльдәге Мәгъри карчыкны гына алыйк: кечкенә генә, бераз бөкрерәк гәүдә, хәрәкәтләре кискен, күзләрендә зәһәрлек һәм нәфрәт очкыны. Мәкерле гайбәтче һәм хәйләкәр им-томчы Мәгъри карчык томаналыкны теше-тырнагы белән яклый, искелеккә ябышып ята.

Актриса үзенең кайбер героиняларының монафыйклыгын аяусыз рәвештә фаш итте, кешеләргә бәхетле яшәргә комачаулаучыларга нәфрәт белән карады. Бу очракта ул ахыргача рәхимсез иде. Шунлыктан аны персонажларның характерын ярымйорты, эскиз рәвешендә генә күрсәтү канәгатьләндерми иде. Камская һәрвакыт образларны төгәлләнгән тестә күрсәтергә омтылды, зур рольләрдә дә һәм кечкенә генә эпизодта да бу стильгә тугры калды. Г. Камская иҗат иткән һәм драматик һәм комик характерлар, күмәклек исем алып, һәртөрле кимчелекләрне камчылый, фаш итә бардылар. Нәкый Исәнбәтнең «Зифа» комедиясе буенча эшләнгән спектакльдәге Кәләмзә үз вакытында нәкъ әнә шундый иде. Актриса рухи яктан череп таркалган бу хатынның чикләнгәнлеген, әхлаксызлыгын тулысынча ачып салды. Бирәдә тагын шуны билгеләп үтәргә кирәк, спектакльдә героиняның кимчелекләре реалистик нигездә ачыла. Шулай да әхлаксыз Кәләмзәне фаш иткән актриса аңа иң югары хөкем карары чыгармый, ул әле күңелендә героиняның төзәлечәгенә, җәмгыятьтә файдалы кеше булачагына өмет саклый.

Гомумән алганда, актриса үзенең тискәре героиняларына тәнкыйть белән караса да, аларны берьяклы гаепләү юлына басмый иде.

Г. Камская иҗат иткән образларны мәгълүм чор, мохит, җәмгыять тудырган. Мисал өчен, «Татар хатыны нилэр күрми»дән Сабираны яки «Хаҗи әфәнде өйләнә»дән яучы Нәсимәне алыйк. Бу образлар кешеләр арасында ямьсез мөнәсәбәтләр тудырган заманны бик ачык чагылдыралар.

Гөлсем Камская сәхнәдә 50 ел чамасы уйнады. Ярты гасыр эчендә ул милли үзенчәлеге, табигыйлеге белән аерылып торган, зур ышандыру көченә ия булган бик күп үзенчәлекле образлар тудырды. Шуңа күрә дә без аны мәгълүм чор һәм мәгълүм халыкның психологик портреты остасы буларак искә алабыз. Гөлсем Камская төрле елларда иҗат иткән образлар тезмәсе совет артисткасы узган зур һәм җитди иҗат юлы турында сөйли.

**ХАЛИТ КУМЫСНИКОВ.**

## ҮЗЛӘРЕ ТУРЫНДА ҮЗЛӘРЕ

# ТАГЫН БОЛГАР ИЛЕ, ТАГЫН ГАБРОВО...

*Габров /Габрово/ — Болгариянең моннан 600 ел элек нигезләнгән борынгы бер шәһәре. Биредә эшләп чыгарылган тукымалар һәм аяк киемнәре бөтен дөньяга билгеле. Аның шулай ук бөтендөнья белгән икенче даны да бар: Габров кешеләре елмаймыйча сөйләшмәс, теләсә нинди уңай белән чәнечкеле сүз әйтми калмас. Габровның ике кешесе очрашкан җирдә — көлке бәйрәме башлана. Шунысы кызык, алар үзләрен үзләре тәнкыйть итәргә яраталар. «Без сараннар» дигән «гаеп»не юри үз өсләренә алып, мәсәлән, алар дөньядагы барча сараннардан көлә. Габров, рәсми төстә булмаса да, юмор-сатира башкаласы дип игълан ителгән. Анда традицион юмор-сатира фестивальләре үткәрелә, дөньяда бердәнбер юмор-сатира музее бар. Биредә сәнгать һәм культура комитеты исеменнән дөньяның иң оста юмористлары һәм сатирикларына «Алтын эзоп» һәм «Хитр Петр» /болгар фольклоры персонажы/ дигән премияләр бирелә.*

### КИРӘКСЕЗ ДИП ТАБА

Берәүнең хатыны квартира бүлмәләрен бик еш буйый икән. Шуны күргән саен ачулана торган ире көннәрнең берендә аның кулыннан буяу тулы чиләген һәм пумаласын тартып ала да әйтә:

— Җитте сиңа, туктат бу эшне! Күрмисеңмени, бүлмәләр болай да күптән кысанланды инде...

### МУНЧАДА

— Ванна өчен күпме түләргә кирәк?
— Ике лев.
— Менә сезгә бер лев акча, ваннаны яртылаш кына тутырыгыз.

### БИЛГЕСЕН БЕЛҮ

— Миңа биш йомырка бир, апа, ләкин барысы да кара тавыкныкы булсын.
— Әгәр кайсы шундый икәнен беләлсәң, үзең сайла.
— Ярый, — ди үсмер һәм... иң эре йомыркаларны гына сайлап ала.

### ЯНГА КАЛДЫРА, ИМЕШ

Поездддан әле генә төшкән пассажир таксисттан сорый:
— Шәһәр үзәгенә хәтле илткән өчен күпме аласың?
— Ике лев. Әйдә, утыр!
— Рәхмәт! Мин күпме акчам янга кала икән дип кенә сорадым.

## ФАЙДАЛЫ КЛИЕНТ

Ресторанда бер официант икенчесеннән сорый:

— Әнә теге бәндәне ник урамга куып чыгармыйсың инде? Күреп торам бит: син аны дүрт тапкыр уятып карадың, ә ул йоклый да йоклый...

— Ник аны куарга ди?! Уяткан саен счет сорый да миңа акча бирә бит ул.

## ЙӨЗЬЯШӘР КЕШЕ

Кырда кәҗә һәм сарык көтүе көткән бер йөзьяшәр янына картаймау сере белән кызыксынучы журналист интервью алырга килә:

— Нинди сөт эчәсез сез, бабакай: кәҗә сөтеме, әллә сыерныкынмы?

— Кайсы арзанрак, шунысын эчәм, балакай.

## ХРИСТО ИТ ЯРАТМЫЙ

Бер тол хатын күршесеннән үтенә:

— Алла хакына, миңа шушы тавыкны суеп бирсәгезче?

— Алай булса син Христога кер инде, күрше, чөнки ул итле аш ашамый бит.

## КАЙСЫ КИЛЕРЛЕРӘК!

Берәүнең улы хирург булырга укымакчы.

Ә атасы аңа: «Син — юләр! — ди. — Иң яхшысы — теш докторы булу ул! Чөнки кешедә йөрәк бер генә, ә авызда тешләр исә утыз ике була».

## ӨЙДӘ ТӘРТИП

— Петко, миңа ун лев акча биреп тормассыңмы икән?

— Берсүзсез бирер идем, ләкин кесәмдә бер стотинок та юк бит.

— Ә өйдә?

— Рәхмәт, өйдә, аллага шөкер, бар да... исән-саулар.

## КИБЕТТӘ ТОТКАРЛАНУ

— Син аулак кичена ник соңгарып килдең, ахирәт, тегүчегә барган идеңме әллә?

— Тегүче тагын сиңа, парфюмерия кибетендә үтте ике сәгатем.

— Чираттамы?

— Юк, өстем-башыма хушбуй исе күбрәк сеңсен дип озакладым.

## ДҮРТЕ — ЭШ ХАКЫ

— Бу күзлек алты диоптрилы. Шуны икеле итеп төзәтеп бирегез әле миңа, ә калган дүрт диоптрие сезгә эш өчен түләү булсын.

## БАРЫБЕР ИДӘН СҮТӘСЕ...

Бер стотинок акчасы идән ярыгына төшкәч, берәү шунда ук тагын егерме стотинок сала икән.

— Нишләвең бу? — дип сорый куркынган хатыны.

— Барыбер идән сүтмичә булмый, бер стотинок өчен генә сүтмәбездер бит инде аны?!

## ЫШТАН ТУЗМАСЫН ӨЧЕН

Хатынын бала кыйнаган чакта күргәч, әйтә икән берәү:

— Баланы, акылсызым, ыштан салдыртмыйча кыйнамыйлар аны, ыштан бит ул болай да тиз туза.

## АВАНС БИРЕП КУЙГАН

Бер агай ресторанга кереп метрдотельне чакырта да аңа акча тоттыра.

— Сезгә өстәл әзерләргәме? — дип сорый теге.

— Юк, — ди агай. — Озакламый мин биргә бер ханым белән керәм. Сез шул чакны миңа «ресторанда буш урыннар юк» дип әйтерсез.

## ӨЙЛӘНЕШКӘЧ

— Синең никах балдагың кая?

— Бу атнада аны хатыным кия.

### ЯХШЫ ХӘТЕР

— Габрово кешеләренең хәтере искитмәле икән!
— Нәрсәдән чыгып әйтәсең?
— Мин биредә моннан егерме ел элек булган идем, ә алар шулчакта мине кайсы, кайда һәм нәрсә белән сыйлаганын әле дә булса онытмаганнар.

## ЛАЙХИА МӘЗӘКЛӘРЕ

*Финляндиядә Лайхиа дигән бәләкәй кала Болгариядәге Габрово шәһәре кебек үк атаклы. Лайхиа кешеләре дә үзләре турында үзләре уйлап чыгарган мәзәк һәм шаян хикәяләр сөйлиләр. Гадәт буенча, аны көненә тик бераерне сөйләргә, икенче көнне генә күләргә, ә өченче көнне исә иң якын дустыңа сөйләргә кирәк икән. Шуларның берничә үрнәге белән танышыйк.*

### ДУШ БҮЛМӘСЕ

Берәү яңа өй сала, ләкин аның бер бүлмәсе өстенә түбә япмый.
— Ни гаҗәп эшләвең бу синең?— дип сорый аңардан күршесе.
— Душ бүлмәсе була ул минем,— ди хирыс хуҗа.

### ИТ КИБЕТЕ АЧКАЧ

Шул кибет хуҗасы гәзиттә кыска гына белдерү бастыра: «Түшкәләр турарга ярдәмче яллыйм. Эшкә керергә теләүче вегетарианец булсын иде дигән теләгем бар».

### БОРЧЫЛМА, АЛЫРСЫҢ

— Кичер, хуҗа, ләкин бит мин, үзара әйткәндә, өч кеше өчен эшләп тә, быел әле бернинди эш хакы алганым юк,— ди бер көнлекче.
— Яхшы, яхшы. Кичерәм, әлбәттә,— ди хуҗа аңа.— Эш хакы турында, гомумән, киләчәктә дә борчылма син, тиешен алырсың... Ә менә теге ике кешенең фамилияләрен әйт әле, аларны мин эштән чыгарырга тиешмен!

### РЕДАКЦИЯГӘ ХАТ

Бер редакциягә Лайхиадан хат килә. Тулы тексты менә нинди була аның: «Әгәр безнең хакта мәзәкләр бастыруны туктатмасагыз, мин беркайчан да сезнең гәзитне күршемнән алып торып укымаячакмын».

## БЕРГЕН ХИКӘЯТЛӘРЕННӘН

*Бөек Британиядәге шотландлылар һәм Болгариядәге габровлылар кебек, Норвегиядәге Берген шәһәре кешеләре дә үзләре турында үзләре уйлап чыгарып мәзәк сөйләргә ярата.*

### ТИКШЕРЕП БЕЛДЕ

Осло шәһәреннән дәрәҗәле бер әфәнде Берген балалары сүз эзләп кесәгә кереп тормый дигәнне ишетә дә, шуны Бергенгә беренче килүендә үк тикшереп карамакчы була. Вокзал тирәсендә гәзит сатып йөргән бер малай янына килә дә сорый:
— Ә иртәгәге көн гәзитләре бармы синдә?
Малай күз ачып йомганчы җавап бирә:
— Әлбәттә, юк. Мин, аларны, абзыкай, инде кичә үк сатып бетердем.

### БЕРГЕН ЯҢГЫРЫ ТУРЫНДА

Читтән килгән кеше бер баладан сорый икән:
— Сездә бу яңгыр кайчан да булса туктыймы?
— Белмим,— ди малай,— чөнки миңа ун гына яшь әле.

### БАЛЫК БАЗАРЫНДА

— Менә хәзер генә судан тоткан сайда сатам!

— Хәзер генә дисеңме? Яле, башта мин аның белән сөйләшеп алыйм,— дип бер ханым, нидер мыгырдап, балыкка иелә.

— Нәрсә лыгырдыйсыз анда?

— Диңгездә нинди яңалыклар бар, дип сорадым.

— Алаймы. Я, нәрсә диде соң балык?

— Белмим, ди, чөнки инде диңгездә ике атна булганы юк икән.

# КИНДЗЮЛИС КИЛӘ ДӘ ӘЙТӘ

*Киндзюлис — моннан ике дистә чамасы еллар элек Литва сатирик журналы «Шлуоту» («Себерке») битләренә юморист Витаутас Николаускас керткән әдәби һәм халык иҗаты герое. Бүгенге Киндзюлис, күпчелек төрки телләренең Хуҗа Насретдин сыманрак итеп, коллектив иҗат җимеше буларак гомумиләштерелгән мәзәкче образы. Без дә аның белән тагын да якыннанрак танышыйк әле.*

### КОРБАН ТУРЫНДА

— Хәзер ниндидер югалтулар яки корбаннар турында күп сөйлиләр,— дип гаплашә икән ресторан янында берничә ир.— Кайсыгыз белә: нәрсә ул корбан?

Шул чакны Киндзюлис килә дә әйтә:

— Бер төркем адәми затны исертеп аяктан еккан хәмер бәясен берүзе түләүче абзый дип белик аны.

### АТ ТИПМӘСМЕ!

Яшьрәк булып күренер өчен чамасыз бизәнгән-ясанган бер кыз, бәләкәй станциядә поездан төшкәч, колхозчы абзый олавына сак кына менеп утыра да сорый икән:

— Атыгыз тибә торганнардан түгелме?

Шул чакны Киндзюлис килә дә әйтә:

— Типмәс. Ул артка карамый.

### ТИЗЛЕК

— Поездга әле генә кереп утырдым, ә кесәмдәге акча янчыгымны инде кемдер чәлгән?

Шул чак Киндзюлис килә дә әйтә:

— Ә ник котәргә ди аны. Бу бит, апай, тиз йөрешле поезд дип атала.

### УТЫРЫР АЛДЫННАН

Берәү үзенә бик яхшы таныш адвокаттан сорый:

— Ни өчен гаепләнүче кеше суд карарын аяк өсте басып тыңлады?

Шул чакны Киндзюлис килә дә әйтә:

— Чөнки шуннан соң шактый озак утырырга тиеш иде ул.

### ОЗАК АЗАПЛАНМАГАН

Шәһәрдә торучы бик яман холыклы һәм ызгышчы бер ханым авылдан килгән туганына зарлана икән:

— Минем ирем туйдан соң биш кенә көн яшәп дөнья куйды.

Шул чакны Киндзюлис килә дә әйтә:

— Бәхетле булган бичара, озак азапланмаган...

### КАЯН БЕЛГӘН!

Бер гражданин кибетчегә мөрәҗәгать итә:

— Мөдирегез кайда утыра сезнең?

Шул чакны Киндзюлис килә дә сорый:

— Ә сез аның инде утырганын каян белдегез?

## БЕРӘҮ ГЕНӘ БЕЛӘ

— Ире кайда икәнен нинди хатын теләсә кайчан белә ала?
Шул чакны Киндзюлис килә дә әйтә:
— Тол хатын.

## ЯҢА ФИЛЬМ ЧЫККАЧ

— Ничек, яңа фильм ошадымы?
— Рецензияләр бик яманлап яза.
Шул чакны Киндзюлис килә дә әйтә:
— Димәк, карарга кирәк.

## УРЫНЛЫ КИҢӘШ

— Теге Йонас дигән егетегез бер дә ошамый миңа. Һич күңелем тартмый шуңа. Безгә килеп йөрмәсен өчен нишлим икән?
Шул чакны Киндзюлис килә дә әйтә:
— Син аңа әҗәткә акча биреп тор.

## НИК КИМСЕТӘСЕЗ

Ике кеше ызгыша:
— Алама ишәкнең дә иң аламасы бит син!
— Ә син иң аңгыра сарык!
Шул чакны Киндзюлис килә дә әйтә:
— Бу хәтле яманлап ник кимсетәсез хайваннарны?

## ИШЕТТЕРМӘ

— Беркайчан да кешегә күсәк күтәрмә син, чөнки кайберәүләр тәнкыйть сүзен ишетмәс өчен хәтта чукрак булып кылана беләләр, ә берәүләрнең исә...
Шул чакны Киндзюлис килә дә әйтә:
— Бик кычкырып сөйлисең, сине ишетүләре мөмкин.

## ИС КИТӘРҮ

Берәүнең туган көненә барышлый кунаклар: «Хуҗаның исен нәрсә белән китәрик?» — дип киңәшәләр.
Шул чакны Киндзюлис килә дә әйтә:
— Бер шешә дә аракы алмыйча барыгыз.

## ИҢ ЯХШЫ ВАКЫТ

Бер кафеда ике кеше сөйләшеп утыра:
— Минем иң яраткан вакытым нәкъ менә шул үзе инде.
— Ә ник алай?
Шул чакны Киндзюлис килә дә әйтә:
— Чөнки бу вакыт — эшкә кире барырга инде соң, ә өйгә кайтырга әле иртә чак.

## ТАКСИСТКА СОРАУ

Статистика белән бик кызыксынып шөгыльләнүче берәү таксисттан сорый икән:
— Сезгә күп төрле профессия кешеләрен машинада йөртергә туры килә. Әйтегез әле, нинди пассажирлар күбрәк эләгә?
Шул чакны Киндзюлис килә дә әйтә:
— Безгә утырганнары күбрәк исерек булалар.

## КАЙЧЫ БЕЛӘН...

Хатынының пальтосын чистарткач, бер ир бик зур мактау ишетә:
— Инде дә әйбәт булган бит бу, тапларын ничек бетерә алдың шул хәтле яхшы итеп? — ди хатыны.
Шул чакны Киндзюлис килә дә әйтә:
— Кайчы белән эш итте бугай.

## ТЫҢЛАР ӨЧЕН ТҮГЕЛ...

— Музыка белән шөгыльләнергә улыгызны ник болай көчләп кушасыз. Аның тыңлау сәләте юк,— ди музыка мәктәбе укытучысы малайның әнисенә.
Шул чакны Киндзюлис килә дә әйтә:
— Ә ул бит музыканы тыңларга җыенмый да: без аның уйный белүен телибез.

## ЯЛДАН КАЙТКАЧ

Бер клубның художество җитәкчесе ялдан кайткан директорына рапорт бирергә ашыга:
— Күрәсезме, нинди күңелле — клубыбыз тулы эшче бит!
Шул чакны Киндзюлис килә дә әйтә:
— Әйе шул: алар клуб ремонтлыйлар.

## АВТОМАТ БУЛЫРГА ТЕЛӘҮ

Бер фабриканың ике эшчесе сөйләшә:
— Минем автомат буласым килә.
— Ник?
Шул чакны Киндзюлис килә дә әйтә:
— Чөнки аның күп вакыты эшсез уза, ә акчаны барыбер ала...

## КЕМНӘР НИЧЕК СЫНЫЙ БИТ...

Бау ныкмы икән дип сынарга теләп, ике өлкән агай аны икесе ике баштан тартып бик тиз өзәләр. Егылган урыннарыннан торгач, куанычлары эчләренә сыймый: янәсе, аларда да көч бар икән әле!
Шул чакта Киндзюлис килә дә әйтә:
— Черек бау өздегез ич сез.

## МӘСКӘҮДӘ ТАТАРСТАН АССР ӘДӘБИЯТЫ ҺӘМ СӘНГАТЕ КӨННӘРЕ

Узган елның 17—21 декабренда башкалабыз Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате көннәре булып узды. Әдәбият һәм сәнгать көннәрендә КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев (җитәкче), Татарстан АССР Министрлар Советы председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов, КПССның Татарстан өлкә комитеты культура бүлеге мөдире М. М. Мусин, КПССның Казан шәһәр комитеты секретаре А. Г. Кадыйрова, Татарстан АССРның Культура министры И. Н. Алиев, Татарстан АССР Язучылар союзы идарәсе председателе Г. А. Ахунов, СССР Композиторлар союзы секретаре, СССРның халык артисты Н. Г. Җиһанов, СССР Художество Академиясенең член-корреспонденты, СССРның халык художнигы Х. А. Якупов составындагы рәсми делегация катнашты.

Иң беренче көнне әдәбият һәм сәнгать көннәрендә катнашучылар бөек якташыбыз, бөтендөнья пролетариатының даһи юлбашчысы В. И. Ленин Мавзолеена республикабызның барлык хезмәт ияләре исеменнән венок куйдылар. Шундый ук венок Ватаныбызны немец-фашист илбасарларыннан саклап калган баһадирларыбызның халык күңелендәге мәңгелек истәлеге символы булган Билгесез солдат каберенә дә куелды.

Кич белән «Россия» Үзәк дәүләт концерт залында әдәбият һәм сәнгать көннәрен ачу тантанасы булды. Тантанада түбәндәге иптәшләр катнашты: КПСС Үзәк Комитеты Политбюросы членлыгына кандидат, СССР Культура министры П. Н. Демичев, КПСС Үзәк Комитеты Политбюросы членлыгына кандидат, РСФСР Министрлар Советы Председателе М. С. Соломенцев, КПСС Үзәк Комитеты секретаре М. В. Зимянин, КПСС Үзәк Комитетының бүлек мөдирләре Е. М. Тяжельников, В. Ф. Шауро, РСФСР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасарлары В. П. Орлов, А. М. Калашников, РСФСР Министрлар Советы Председателе урынбасарлары Е. Ф. Карпова, В. И. Кочемасов, Л. П. Лыкова, КПСС Үзәк Комитетының бүлек мөдире урынбасары З. П. Туманова, РСФСР Культура министры Ф. С. Мелентьев, РСФСР Культура министрының беренче урынбасары Е. В. Зайцев, партиянең Мәскәү шәһәр комитеты секретаре А. М. Роганов, РСФСР Язучылар союзы идарәсе председателе С. В. Михалков, РСФСР Художниклар союзы идарәсе председателе С. П. Ткачев, КПСС Үзәк Комитетының, РСФСР Министрлар Советының, СССР һәм РСФСР культура министрлыклары, партиянең Мәскәү шәһәр комитетының, халык депутатларының Мәскәү шәһәр Советы башкарма комитетының җаваплы работниклары. Залда шулай ук КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Р. М. Мусин, ТАССР Верховный Советы Президиумы Председателе С. Г. Батыев, Татарстан АССР Министрлар Советы Председателе Г. И. Усманов бар иде.

Татарстаннан килгән кунакларны башкалабыз хезмәт ияләре исеменнән СССРның халык артисты, Социалистик Хезмәт Герое Б. П. Чирков котлады. КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев җавап сүзе белән чыкты.

Аннары Татарстан сәнгать осталарының зур бәйрәм концерты күрсәтелде. Концертта башкарылган җырларда, биюләрдә илебез халыклары арасындагы дуслык, туганлык хисләре калку итеп күрсәтелде. Сәнгать осталары Совет власте елларында Татарстан республикасының нинди гүзәл уңышларга ирешүен, халыклар дуслыгының мәңгелек икәнлеген концерт барышында тагын бер кат раслыйдылар.

Мәскәүлеләр республикабыз вәкилләрен һәр җирдә туганнарча ачык йөз һәм киң күңел белән каршыладылар. Мәскәүнең төрле концерт залларында Татарстан АССРның Дәүләт симфоник оркестры, җыр һәм бию ансамбле, ТАССРның халык артисты Р. Ибраһимов катнашында зур концертлар булды. Татарстан кинематографистлары Документаль фильмнар үзәк студиясендә очраштылар. «Россия» кинотеатрының кече залында Казан кинодокументалистлары төшергән фильмнар фестивале ачылды. Анда «Революциягә беренче адым», «Сабан туена юл», «Җәлил: көрәш сәхифәләре», «Беренче «КамАЗ» туды», «Татарстан» исемле документаль фильмнар, төрле кинотеатрларда «Хисләрнең яңаруы», «Хәзинә» һәм «Моабит дәфтәре» исемле нәфис фильмнар күрсәтелде.

Язучыларның А. А. Фадеев исемендәге Үзәк йортында Татарстан АССРның төзелүенә 60 ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичәне кереш сүз белән Социалистик Хезмәт Герое, Ленин премиясе лауреаты Сергей Михалков ачты. Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе

Гариф Ахунов татар совет әдәбиятының үткәне һәм бүгенгесе турында сөйләде. Кичәдә татар әдипләре Сибгат Хәким, Зәки Нури, Илдар Юзеев, Шәүкәт Галиев, Әхсән Баянов, Әдип Маликов, Ринат Мөхәммәдиев, Ренат Харис, Равил Фәйзуллин, Рөстәм Кутуй, Роберт Миңнуллин, рус шагыйрьләре Николай Доризо, Михаил Львов, Вадим Кузнецов, Рувим Моран һәм Людмила Щипахина катнашты, аларның әсәрләре татар һәм рус телләрендә яңгырады. Очрашу сәнгать осталарының зур концерты белән тәмамланды.

Язучылар һәм сәнгать осталарының шундый ук очрашулары шулай ук Войков исемендәге чуен кою заводында, СССР Госстроеның икенче проект институтында, Н. А. Некрасов исемендәге китапханәдә, А. А. Яблочкина исемендәге үзәк Актерлар йортында, бөтенсоюз Композиторлар йортында да уздырылды. СССР Художниклар йортында исә Татарстан рәссамнарының әсәрләреннән торган зур күргәзмә эшләде. М. Ермолова исемендәге театр Мәскәү тамашачыларына Диас Вәлиевнең «Тормыш бүләк итәм» һәм «Казан университеты» исемле пьесалары буенча куелган спектакльләр күрсәтте.

ТАССР төзелүгә 60 ел тулу уңаеннан үткәрелгән бу дуслык бәйрәме партиябезнең ленинчыл милли политикасын тормышка ашыру нәтиҗәсендә Совет Татарстанының нинди биеклекләргә ирешкәнлеген ачык күрсәтте.

## РСФСР ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ V СЪЕЗДЫ

1980 елның 9—12 декабрендә Россия язучыларының V съезды уздырылды. Съездда Татарстан язучыларының да зур төркеме катнашты. Аңа делегат булып Гариф Ахунов, Сибгат Хәким, Зәки Нури, Гомәр Бәширов, Илдар Юзеев, Туфан Миңнуллин, Фәрваз Миңнуллин, Вакыйф Нуруллин, Нурихан Фәттах, Мөхәммәт Мәһдиев, Ринат Мөхәммәдиев, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Кояш Тимбикова, Азат Әхмәдуллин, Диас Вәлиев, Рөстәм Мингалимов, Эдуард Касыймов, Әдип Маликов, Хәкимҗан Халиков, Владимир Мальцев һәм кунак булып Атилла Расих, Рөстәм Кутуй, Равил Фәйзуллин, Марсель Зарипов, Тәлгат Галиуллин, Лирон Хәмидуллин, Марс Шабаев, Кыям Миңлебаев, Роберт Миңнуллин, Габдулла Шәрәфи, Радиф Гатауллин, Флүн Мусин, Нонна Орешина, Әхәт Гаффар, Мансур Вәлиев, Әхмәт Рәшитов иптәшләр катнашты.

Фикер алышуларда Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Г. Ахунов чыгыш ясады. Ул Татарстан Язучылар союзының яшьләр белән эшләү тәҗрибәсе турында сөйләде.

Съездда Гариф Ахунов РСФСР Язучылар союзы идарәсе члены һәм секретаре итеп, Сибгат Хәким, Илдар Юзеев һәм Туфан Миңнуллин идарә членнары итеп, Ринат Мөхәммәдиев һәм Эдуард Касыймов ревизия комиссиясе членнары итеп сайландылар.

Съезд шулай ук СССР язучыларының VII съездына РСФСРдан делегатлар да сайлады. Анда татар язучыларыннан Сибгат Хәким, Зәки Нури, Гариф Ахунов, Әхсән Баянов, Шәүкәт Галиев, Рафаэль Мостафин, Әмирхан Еники, Аяз Гыйләҗев, Геннадий Паушкин, Гәрәй Рәхим, Мәдинә Маликова, Разил Вәлиев катнашачак.

## ӘДИПНЕҢ ЮБИЛЕЙ КИЧӘСЕ

26 декабрь көнне Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында күренекле татар совет шагыйре, татар совет поэзиясенә нигез салучыларның берсе Хәсән Туфанның 80 яше тулу уңае белән иҗат кичәсе булды. Анда республикабызның партия, совет, комсомол оешмалары, иҗат интеллигенциясе катнашты.

Кичәне кереш сүз белән шагыйрь Сибгат Хәким ачты.

Хәсән Туфан совет әдәбиятын үстерүдәге хезмәтләре өчен һәм 80 яше тулу уңае белән хөкүмәтебез тарафыннан Хезмәт Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнгән иде. Әлеге кичәдә бу югары бүләкне, СССР Верховный Советы Президиумы исеменнән, КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев тапшырды.

Әдипнең тормыш һәм иҗат юлы турындагы доклад белән филология фәннәре докторы, профессор Хатип Госман чыкты.

Юбилярны РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретаре Николай Доризо, КПССның Казан шәһәр комитеты һәм халык депутатларының шәһәр советы башкарма комитеты, ТАССР Культура министрлыгы, республикабызның иҗат союзлары вәкилләре, Башкортстаннан килгән шагыйрьләр Сәйфи Кудаш, Нәҗәр Нәҗми иптәшләр котлады. Юбилей кичәсе республикабызның сәнгать осталары концерты белән тәмамланды.

## «ТАТАРСТАН ШАГЫЙРЬЛӘРЕНЕҢ ТАВЫШЛАРЫ»

«Мелодия» грампластинкалар фирмасы соңгы вакытта татар сәнгатенә һәм әдәбиятына багышланган күп кенә пластинкалар чыгарды. Шуларның берсе — «Татар шагыйрьләре үз шигырьләрен укыйлар» дип атала. Күренекле шагыйрьләребез Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Әхмәт Исхак, Зәки Нури, Нури Арсланов һәм Шәүкәт Галиев шигырьләренә багышланган бу пластинка әдәбият сөючеләр өчен, татар теле һәм әдәбияты укытучылары өчен әйтеп бетергесез хәзинә булачак.

Пластинкада шагыйрьләрнең фоторәсемнәре һәм иҗатлары турында кыска белешмәләр дә бирелгән.

## ШАГЫЙРЬ ИСЕМЕНДӘГЕ УРАМ

Илебездәге бик күп авыл-шәһәрләрдәге урамнар татар шагыйре, Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты Муса




Җәлил исемен йөртә. Башкалабыз Мәскәүдә дә андый урам бар. Әлеге фотоны фотохәбәрче Мидхәт Шакирҗанов Мәскәүдә узган Татарстан әдәбияты һәм сәнгате көннәрендә төшереп алып кайтты.

## ЖЫРГА — ДИПЛОМ

КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре, СССР Верховный Советы Президиумы Председателе Л. И. Брежневның «Кече җир» китабында безнең якташыбыз, Тәтеш егете Сәләхетдин Вәлиуллинның батырлыгы турында да ихтирам һәм соклану хисләре белән язылган. Бу батырлык иҗат кешеләрен яңа әсәрләр иҗат итәргә рухландырды. Шагыйрь Самат Шакир һәм композитор Сара Садыйкова да Кече җир каһарманына багышлап «Үлемсезлеккә адым» исемле җыр яздылар. Комсомоллар һәм яшьләрнең совет халкының революцион, сугышчан һәм хезмәт даны урыннары буйлап үткәрелә торган Бөтенсоюз походлары Үзәк штабы әлеге җырны диплом белән бүләкләде.

## ТӘРҖЕМӘЧЕЛӘР СЕКЦИЯСЕНДӘ

Тәрҗемәчеләр секциясенең чираттагы утырышында Галимҗан Ибраһимовның Татарстан китап нәшриятында «Библиотека татарского романа» сериясендә басылып чыккан «Яшь йөрәкләр» романының тәрҗемәсен тикшерү булды. Романны рус теленә Роза Фәткуллина тәрҗемә иткән.

Тәрҗемә ителгән роман турында Солтан Шәмси чыгыш ясады. Ул тәрҗемәнең уңай һәм кимчелекле яклары турында сөйләде.

Тәрҗемәне тикшерүдә Кыям Миңлебаев, Азалия Бадюгина, Марк Зарецкий, Роза Кожевникова катнашты.

* * *

«Яшьлек» әдәби берләшмәсенең чираттагы утырышы күренекле язучы Әмирхан Еники белән очрашуга багышланды. Әдип яшьләрне кызыксындырган күп кенә сорауларга җавап бирде, иҗат эшенең кайбер нечкәлекләре һәм «серләре» турында җентекләп сөйләде.

## ЮГАРЫ БӘЯ БИРДЕЛӘР

Чаллыдагы язучылар оешмасы үзенең чираттагы утырышын Алабуга дәүләт педагогия институтында үткәрде. Анда тәнкыйтьче һәм галим, институтның уку-укыту эшләре буенча проректоры Н. Лаисов иҗаты тикшерелде. Бу турыда институтның татар әдәбияты укытучысы, филология фәннәре кандидаты Р. Салихов доклад ясады. Институт ректоры, тәнкыйтьче Т. Галиуллин, студентларның «Чулман» әдәбият-иҗат түгәрәге җитәкчесе, филология фәннәре кандидаты Ә. Шәрипов, филология фәннәре кандидаты А. Кәримова, укытучы Х. Дулалаева, язучыларның Чаллы оешмасы вәкилләре Н. Лаисовның әдәби тәнкыйть өлкәсендәге хезмәтләренә югары бәя бирделәр, аны СССР Язучылар союзына член итеп алырга тәкъдим иттеләр.

## «САЛАВАТ КҮПЕРЕ»НЕҢ ҖИДЕ ТӨСЕ

«Хезмәт даны» газетасы каршындагы «Салават күпере» әдәби-иҗат берләшмәсенә әдәбиятның һәм сәнгатьнең табигатьтәге җиде төсне хәтерләткән җиде төрендә эшләүче яшь көчләр — колхозчылар, район хезмәткәрләре, укучылар, студентлар һәм башка әдәбият сөючеләр катнаша. Биредә шигырь һәм хикәяләре белән республика матбугатында күренеп килгән Рифә Сабирҗанова, Заһид Мәхмүдов, Шаһинур Мостафин (берләшмәнең җитәкчесе), Рәниф Шәрипов һ. б. әсәрләре тикшерелә.

Берләшмәнең рәссамнар секциясе дә актив эшли. Секция җитәкчесе Нурислам Галиев, яшь рәссамнардан Байрак Галимов, Галиәхмәт Гатин, Рамил Сәләхетдинов рәссамнарның һәм сынлы сәнгать осталарының III республика күргәзмәсендә катнашып, II дәрәҗә диплом белән бүләкләнде.

Татарстан Язучылар союзы идарәсе тарафыннан берләшмәнең шефы итеп билгеләнгән язучы Ләбибә Ихсанова яшь иҗатчылар белән еш очраша, аларның әсәрләрен тикшерүдә катнаша.

Кукмара районының культура тормышына зур йогынты ясаган иҗат берләшмәсе төзелүгә ун ел тулды. Шул уңай белән партиянең район комитеты берләшмәне һәм аның актив членнарын Мактау грамоталары белән бүләкләде.

## МУСА ҖӘЛИЛ КАРАКАЛПАКСТАНДА

Каракалпакстанда татар әдәбияты һәм сәнгате көннәре уздырылган чорда Кегейли районының «Куаныш жарма» (татарча «Куаныч елгасы») совхозына герой-шагыйрь Муса Җәлил исеме бирелгән иде. КПССның XXVI съезды хөрмәтенә алган социалистик йөкләмәләрен, авыр табигать шартларына карамастан, намус белән үтәп чыктылар.

Герой-шагыйрьнең тууына 75 ел тулу уңае белән совхозда зур кичә уздырылды. Совхоз эшчеләре, инженер-техник хезмәткәрләре белән очрашуга М. Җәлил иҗатын өйрәнүче галим, филология фәннәре кандидаты Исхак Зәбиров килде. Ул совхоз хезмәтчәннәренә шагыйрьнең тормышы һәм иҗаты турында сөйләде, тыңлаучыларны сирәк очрый торган фотодокументлар, кызыклы материаллар белән таныштырды.

## ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫ!

Билгеле ки, апрель — кешелеккә даһи юлбашчы В. И. Ленинны тулак иткән ай. Шунлыктан журналның бу айда чыгачак 4 нче саны «Кояшыбыз — Ленин» рубрикасы белән ачыла. Монда юлбашчыга багышланган шигырьләр һәм язучы Д. Вәлиевнең «1887 нче ел» исемле пьесасы урнаштырылган. Драматург үзенең бу әсәрендә Володя Ульяновның Казан университетында уку чорына мөрәҗәгать итә, аның революцион юлга аяк басуын тасвирлап бирә.

Проза әсәрләреннән бу санда укучыга яхшы ук таныш язучы Шамил Бикчуринның яңа романы тәкъдим ителә. Бу прозаик күп еллардан бирле нефтьчеләр хезмәтен өйрәнә, алар арасында яши. Яңа романның да төп персонажлары — нефтьчеләр, күтәргән мәсьәләсе — нефть промышленносте проблемалары.

Ф. Яруллинның «Фаҗига» исемле хикәясе әчкечелекнең тормышыбызга китерә торган күңелсезлекләрен фаш итә.

Журналның бу саны шигырьләргә дә бай. Нури Арслановның яңа шигырьләре «Дулкыннарга карап...» дигән исем астында бирелә. Ш. Маннапов, Л. Зөлкарнәев, Х. Әюпов, Р. Идиятуллин шигырьләрен дә укучы яратып кабул итәр. Болардан тыш русчадан тәрҗемә ителгән бер бәйләм шигъри әсәрләр бар. Алары — «Звезда» журналы битләреннән алынган шигырьләр.

Очерклар һәм публицистика бүлеге 4 нче санда күбрәк урынны истәлекләргә биргән. З. Рәсүлованың Г. Тукай тормышына һәм иҗат юлына кагылышлы мәкаләсе, Х. Бадамшинның «Биш хатирә» дип исемләнгән язмасы һәм И. Ковалевның «Академик Королевның дусты» дигән очеркы — шундыйлардан.

Әдәби тәнкыйтькә багышланган битләр Р. Кукушкинның «Шигъри бишек» исемле мәкаләсе белән башланып китә. Монда тагын «Бер китапка ике караш», «Безнең календарь» рубрикалары бар.

4 нче санның соңгы битләрен әдәбият һәм сәнгать яңалыклары тутырган.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210